# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Луиза ЯНСУАР. Шәмнәргә ут элләм... *Шигырьләр.* ....3
Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Тау башында бүре бар. *Роман.* ....8
Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА. Гомер кышы озак тоелса да... *Шигырьләр.* ....62
Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ. Намазлыксыз намаз. *Хикәя.* ....66
Ленар ШӘЕХ. Ә югыйсә яшәү бөек иде... *Шигырьләр.* ....86
Габдулла ВАФИН. Тукай. *Хикәя.* ....90

*Яңа исемнәр:* Гөлназ ГАЗИЗОВА. Ә офыкта ал җилкәннәр йөзә... *Шигырьләр.* ....94

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Әлфирә ГАЛИЕВА. Сары атым алтын нукталы. *Хикәя.* ....97

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Тау гөлләре ташта да үсә. *(Кереш сүз).* ....112
Асламбәк ТУГУЗОВ. Төш. *Шигырьләр. (Р.Мөхәммәтшин тәрҗемәләре).* ....113
Шәриф ЦУРУЕВ. *Шигырьләр. (Р.Зәйдулла, Ф.Гыйләҗев тәрҗемәләре).* ....115
Аламахад ЕЛЬСАЕВ. Профессор. *Хикәя. (А.Әхмәтгалиева тәрҗемәсе).* ....118
Арби УСМАНОВ. Әбүбәкер. *«Гомер дәвамында» романыннан өзек. (Р.Җамал тәрҗемәсе )* ... 123

*Юбилейлар:* Марсель БАКИРОВ. Кара таплы бәхет. *Биографиям, тормыш һәм хезмәт юлым турында бәян.* ....127

*Хәтер:* Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Шамил Усманов: матур тормыш төзүгә багышланган гомер. ....150

*2023 ел – Дастаннар елы:* «Гыйсә улы Амәт» дастаны. *(Л.Мөхәммәтҗанованың кереш сүзе белән).* ....160

*Китап күзәтү:* Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА. «Аяз Гыйләҗев» исемле фәнни-популяр җыентыкка бәяләмә ....164

*Фотоархив:* Ринат Мөхәммәдиевка – 75 яшь ....168

*Укучы сүзе:* Г.Исмәгыйлева, С.Шәмси, Л.Минһаҗева, Л.Хөснетдиновадан кайтавазлар. ....170

*Хатлар яздым утырып:* Миргазиян һәм Вахит Юнысларның Марсель Галиевка язган хатлары....177

*Газиз тавышлар:* Радио дәверен ачкан әдип *(Шамил Усмановның тууына – 125 ел.)* ....183
Туган якның китмәс кошы *(Марсель Гыймазетдиновның тууына – 80 ел)*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....184

*2023 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге* ....185

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН
УТЛАРЫ
*№ 12 (1214) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.11.2023, график буенча 30.11.2023, басылып чыгу вакыты 06.12.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-3266. Тираж 5580.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Луиза
Янсуар

# ШӘМНӘРГӘ УТ ЭЛӘМ...

## Сут

*Акмаңгай белән Елгырга, аларга кул күтәргән бәндәләргә багышлана* [1]

**1**

Үләннәр керфеген йома да күзләрен күтәреп карамый.
Бу җирдә еларга ярамый. Бу җирдә көләргә ярамый.
Сак кына, сыпырып бәкәлен, уза җил, җил уза үзәннән.
Пошкырып куя ул, югыйсә кыйналган җөйләре төзәлгән.
Ирене кагыла чыкларга: и, чытлык бу төнге тамчылар!
Сискәнеп уяна төшеннән... Төшендә уйнаклый камчылар.

**2**

Үләннәр күзләрен ача да керфеген төшерә яңадан.
Йөрәге ярыла күрмәсен күтәрә алмаслык ярадан –
Дөньяның... Үләннәр сак шундый. Сак шундый үзәннәр. Сизәләр:
Тереләй бәгырен өзәләр. Тереләй каберен изәләр.
Тик җирдә еларга ярамый. Тик җирдә көләргә ярамый.
Учларын сыпырып җил уза... Әйтерсең камчылап яралый.

**3**

Сак кына... сак кына... чык тама... Һәм йолдыз сызыла... убыла...
Һәм төшә нәп-нәни угланның күккә дип сузылган кулына...
Ул сабый, белми дә ни барын, куанып йөгерә: «Әтие-е-е-ем!!!»
Һәм җуеп бәэлди көтүдә бер ачык авызы бәтиен.
Көн ката бәэлди. Төн ката. Сак кына... сак кына... кан тама...
Кайдадыр йөзеннән пычакның... Һәм суык йөгерә аркага.

---

[1]Акмаңгай – колын чагыннан кыйналып үскән һәм йөрәгендә курку эзе калган балачагым юлдашы булган бахбайның исеме. Елгыр – кулдан ашарга иялəшеп, елгырлыгы җитми, тозакка төшкән гаҗәеп матур чем-кара мәхлүк сарык бәтие.

---

Луиза ЯНСУАР (1981) – *шагыйрә; Россия-Италиянең Халыкара «Белла» һәм Республиканың М.Җәлил исемендәге, язучыларның С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләре лауреаты. «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

**4**

Үләннәр күзләрен каплый да таңгача күтәрми йөзләрен.
Үләннәр алмыйлар кычкыра... Йома тик җинаять эзләрен.
Сак кына, сыпырып бәкәлен, уза җил... җил уза үзәннән...
Җип-җиңел шулкадәр җәсәде: Җир белән исәбе өзелгән.

**5**

Үләннәр күзләрен ача да, томыра карашын биеккә:
Һәм белә кемнәрнең керәсен, чиратын узып йә хәрәмләп,
Берәү дә кералмас ишеккә.
Һәм белә кайтасын кемнәрнең. Һәм белә нинди хак түләрен.
Исәпләп чыгара алмаса, килбәтен югалтыр көннәрен.
Үләннәр Күк җырын ишетә. Үләннәр ишетә Җир тынын.
Төшүен никадәр тирәнгә тамырдан – бу Яшәү Сутының.

## Гөнаһсыз

Җиһанның бу соңгы көннәре
Һәм соңгы төннәре? Охшаган.
Ышанмыйм тик. Синең күзләргә.
Бер синең сүзләргә ышанам.

Болытлар артында – гел кояш.
Ул безне иркәли. Юата.
Кемнәрдер кемнедер очрата.
Кемнәрдер кемнедер югалта.

Ут эчә... Һәм кичә тәкъдирен –
Язылган борыннан. Охшаган.
Ышанмыйм тик... Безнең өметкә...
Бер безнең бәхеткә ышанам.

Һәм тәүге авазын кычкырган
Улларга... Кызларга... – Карусыз.
Дөньяга – чикләрен ачкан һәм
«Яшәгез, – дигән, – бер таныксыз...»

Оҗмахка кадәр без булганмы?
Һәм бармы? Бармы без оҗмахсыз?!
Күземә карыйлар сабыйлар:
Гөнаһсыз... Шулкадәр гөнаһсыз...

Җиһанның бу соңгы көннәре
Һәм соңгы төннәре? Ышанам.
Ышанам... Тик безнең өметтән
УЛ нидер көткәнгә охшаган.

## Самайн – 2023

Караңгы ягына дөньяның
Чыгам да шәмнәргә ут эләм.
Һәм сыйпыйм туң каткан туфракны
Җып-җылы ялангач кул белән.

Һәм көйлим бәллүме, сыктаумы...
Мүк тишеп үскәндәй иреннәр,
Сулкылдап, сулыга җавапка...
Кемнәр ул – Үлеләр? Тереләр?!

Җиһанны күмгән дөм куеда
Шәм ягып, мин кая барамын?
Һәм сыйпыйм карлардан яшьләнгән
Җып-җылы кытыршы яңагың.

Карлар күк җип-җиңел ярату...
(Мин өннән төшләнеп уяндым).
Җаннарда ут сүнгән... Ут сүнгән –
Караңгы ягында дөньяның.

## Әнә!!!..

*И-га*

Күзләреңә кемнәр карый? Кем пышылдый колагыңа?
«Уйна, – диеп, – курыкмыйча, болар бары – йола гына...
Борынгы бер гадәт бары, курчаклары нинди тәти...
Агалары – ага түгел, аталары түгел әти –
Улларына, кызларына... Аналары – түгел ана...»

Шәһәремдә манаралар, йөз яшереп, җиргә ава.
«Син уйлама алар хакын, уйна, әйдә, куркып торма...»
Сүзләреңне кемнәр ваклый? Кем ысылдый колагыңа?
Киемнәрең алышына. Һәм иманың – кичә, бүген.
Елмаясың: «Ансы түгел, менә монсы хәзер – үзем!»
Күрмәс иде... Күрә күзем ни типкәнен йөрәгеңдә.
Әйләнүен ул йөрәкнең Җирнең тере өрәгенә.

Йолалары шундый гади бу ватанның – ал да уйна.
Килешә ул матәмгә дә, килешә ул хәтта туйга.
Буйдан-буйга, буйдан-буйга сөрелгән дә, чабылган да.
Пакуслары – манма кызыл яра сыман кагылганда.

Аягына торып баса, чыклар белән йөзен сөртеп.
Раббым, ди ул, Раббым, әллә кичердеңме?! Җан йөгертеп,
Җилләр тула күлмәгенә. Кендегендә сулык-сулык
Нидер тибә, тибә нидер... Әллә давыл? Әллә солых?
Аягына торып баса, яңактагы канны сөртеп...
Һәм тәгәри туфрагына яшь тамчысы – ике бөртек.

Күзләренә кемдер карый. Кемдер карый күзләренә.
Һәм елмая сүзләренә, кендек җебен өзгәненә:
Җире белән, Күге белән, үзе белән – бер, бердәнбер.
Эзләгәнгә кешеләрдән әллә кабер, әллә кадер.

Кем пышылдый колагына? Өрфия бер тавыш янә:
«Яшәү ә-ә-ә-әнә шунда гына... Әнә!!!..»

***

*Разил абыйга*

Ни сөйләр безгә гөлләре җирнең,
«Бар иде» диеп уфтанган чакта? –
Башларын борып тибрәрләр бары
Кояш караган, караган якка.

Һәм китәр сере тагын берәүнең
Бер үзе белән – яшерен... моңлы...
Кемдер юатыр арыган җанын –
Оныту иңәр, сыйпагач кулы:

Еллар кереннән чистарып калыр...
Ялантәпиләп, и ул йөгерер!
Тугайлар буйлап... Тугайлар буйлап...
Шундый кечкенә булып күренер...

Әйтерсең аннан калмаган алып
Уйлар, хыяллар... Җирдә кылганнар...
Яңгыр, бураннар... «Өмет югында,
Сабыр бар, шуны җуймыйк, оланнар...»

«Бар идең» диеп елмаям, Күкне
Кичкән чагымда, болытлар аша.
...Син дә елмаеп карыйсың кебек,
Карыйсың, куеп кулыңны кашка...
– Моңайма башка!

## Багышлану

Берни калмаганда йөрәгеңдә, дөрләгәндә ике ягы җирнең,
Урманнарны сула... урманнарны... Һәм онытма: Яратудан килдең.
Һәм онытма: килдең яратырга. Онытса да дөнья – нәрсә ул, ни?
Яшәсә дә акылыннан язып, ник язганын хәтта үзе белми.
Сулышыңнан кайнар ялкын бөрки. Тамырларым буйлап ага афәт.
Тамырларым буйлап ага бәхет. Елап, яше кипшергән... мәрхәмәт.
Кемгә сөйлим моны? Кемгә сөйлим?! Яшерәм дә йөзем күкрәгеңә,
Кулларыңның ышыгында синең ышаналмыйм җирнең күкрәвенә.
Үзәгемне ярып, сулар ага. Үзәгемне ярып, давыл кага.
Нидер шартлый һаман... нидер яна... Һәм Ярату... Тамчы-тамчы тама.
Урманнарны сулыйм... урманнарны... Алар шундый тып-тын булгангамы?
Алар шундый булгангамы тере? Сыя бөтен хәтеремнең сере.
Сыя сере дәверемнең бөтен. Ут та төтен. Юкса... Ут та төтен.
Пышылдыйсың: «Елар өчен түгел, мин елмаер өчен сине көттем –
Берни калмаганда йөрәгемдә, ышанам дип кайтып йөгәнергә».

***

*Анда аның эчәр суы, ашар икмәге бар.*
Нурия Измайлова

Эчкән суың, йөргән юлың. Бар да калыр, калыр.
Кешеләрдән кала бар да. Калмаганда – авыр.
Кем күтәргән сагышыңны. Күз яшеңнең тәмен.
Елмаюың эчкән кемдер. Һәм сорашкан хәлең.
Җиһан кадәр җиһан өчен тузан гына – гомер.
Безне беркем белмәс, белсә, тик УЛ гына белер.
Эчкән суың. Йөргән юлың. Ниятеңне. Уең.
Бар да кайта, кайта АҢА. Кайтмаганда – кыен.

***

*Родила меня марийка.*
*И сказала: «Сын, живи!»*
Йыван Кырла

Шәһәрләр шәһәргә ялгана.
Күк Җиргә тоташа, Җир – Күккә.
Мин манам кулларым бер тозга,
Мин манам кулларым бер сөткә.

Сагыну саркылган күзләрем
Яңгырны сеңдерә, карларны,
Кичләрне, ә аннан – таңнарны...
Һәм җанны өшеткеч зарларны.

...Ярларны – кургаш су биегән...
...Кошларны – канатын киергән...
...Бәхетне – учында биегән...
...Сулышны – яшәргә бирелгән...

Мин монда бер килдем, яратып.
Мин моннан, яратып, бер киттем.
Әйтерсең икенче гасырда...
Шулкадәр иде бит Җир... иркен...

Чәчләрне чәчләргә чияләп
Җил исә... (Җил генә... җил бары...)
Һәм кайда булсак та... җибәрми:
Кендеккә тоташа Җир шары.

***

Син авазлар тулы. Һәм наз тулы.
Киек Каз һәм киткән кошлар юлы.
Гитараның әрнегән бер кылы.
Һәм илеңнең җәберләнгән улы.
Кадер белән. Аннан хәтер белән.
Икесе дә – шулкадәр бер күләм.
Елар идем... әмма никтер көләм...
Җирне тишеп шыта кыяк үлән.
Көзгә таба... Әйе, Көзгә таба...
Урманнарда дөрләп йөрәк яна.
Үзәгемне шартлау булып яра
Тымызык бер сүзең... Кара! Кара!
Өзелмәсен... Җепкә тезелмәсен...
Хыялыңа тугры сүзеңдәсең.
Һәм шулкадәр әле үзеңдәсең.
Өзелмәсен генә... өзелмәсен...
Мин авазлар тулы. Һәм наз тулы.
Киек Каз һәм кайтыр кошлар юлы.
Яратуның тымызык бер кылы.
Һәм галәмнең азагы юк елы.
Бәгырь белән. Түлим бәгырь белән.
Яфраклары Көзнең – алтын келәм...
«Елар идем, – дисең, – ник соң көләм?..»
Без икебез генә белгән сердән.
Тыңла! Тыңла!
Йоласы шул... йола...
Якаларга өерелеп тула...
...һәм болай да... болай... яшәп була.

## Мәҗлес

Очрашасы иде дуслар белән.
Өстәлләрдә – тәгам... тустаганнар...
Без очрашмый торган бу арада
Әллә кемнәр телгә остарганнар.

Остарганнар әллә нигә... Күктән
Кояшны ук яшергәннәр алып.
Күзләрендә – хәвеф тә бар... шатлык...
Сүзләрендә һаман шул бер – «хаклык».

Без карыйбыз төтен аша – һаман.
Безгә безнең гасыр... язмыш – таман.
Янәшәдә... иңнәрдән үк кочып...
Тора нидер... – Бабалардан калган.

Без борылып карыйбыз да... кабат
Сөрлегәбез әллә нидән генә.
Һәм чыгабыз гүя яңа көнгә.
Һәм керәбез ай тотылган төнгә.

Очрашасы иде бу гомердә.
Гомер, әнә, кулын изи... көлә...
Өстәлләрдә – тәгам... тустаганнар...
Тостлар укып дуслар остарганнар.

Остарганнар, кул бирешеп, кагып
Иңнәренә бер-беренең: «Туган!..»
«Исемдә» дип пышылдый да берсе,
Чалулыйбыз янә чалыш юлдан.

Һәм сирпелә тәрәзләргә – нуры:
Кояшы да, ае да – бер чама.
...Нинди биек иде манаралар...
...Нинди бөек бер ярату кала...

Кемдер. Бии. Сөякләрдә. Анда.

Равилә
Шәйдуллина-Мурат

# ТАУ БАШЫНДА БҮРЕ БАР

РОМАН

**Бишенче бүлек**

***

Асия күпкатлы йорт кадәрле «Коста» лайнерының җиденче катындагы иң кыйммәтле каюталарның берсендә океанга карап, үз уйларына чумып басып тора. Океан дулкыннары, берсен-берсе куып тотарга теләгәндәй, агарып-чаларып, лайнерга ташлана. Шаккаткыч хәл – каютада бернинди чайкалу-чайпалу юк. Әйтерсең лә галәмәт зур су көймәсе кояшлы көндә тыныч океан өстеннән иксез-чиксез су дәрьясын борыны белән ярып, тыныч кына йөзә. Асиянең башыннан «Алансу инешендә ак казлар барган кебек» дигән уй сызылып үтте. Акчарлаклар көтүе уйнаклап, лайнерны озата бара. Бәгырькәйләрем, офыкларны иңләп, очы-кырые күренмәгән океан өстеннән очканда, канатларыгыз ничекләр талмый сезнең? Сез дә үзегезгә азык эзләп, берәр тук сәяхәтче җим атмасмы дип, безне озата барасызмы? Әллә сезнең дә йөрәгегез биеклекләр, киңлекләр, дәрьялар эзләп җилкенәме? Шуңа күрә ашкынган җаннарыгызга җирдә урын таба алмыйча, чал дулкыннар өстендә көчле канатларыгызны чарлыйсызмы?

– *Дулкыннар, дулкыннар, ник болай шаулыйсыз?*

Асиянең күңелендә җыр юллары кабатланды:

– *Ярларга сугылып, сез нәрсә даулыйсыз?*

Кем, кайсы җырчы җырлый иде соң әле бу җырны? Мөнирә Булатова җыры бит бу! Казанда беренче елын яшәгәндә, Алансуын, әти-әнисен, әне-сеңелләрен сагынып, төннәр буе йоклый алмый ятканда, һаман саен күңелендә кабатлана иде бу җыр. Һәм Вәкилне сагынганда. Казанга чыгып киткән көнне сөт машинасы янында Вәкил күренмәде. Соңыннан беленде: ул әнисен ялгыз калдырасы итмәгән. Киләсе елда гына Казанга укырга барырга хәл кылган икән.

---

*Дәвамы. Башы 11 нче санда.*

Әнисе әйтеп караса да:

– Улым, мин ничек тә яшәрмен, Нурия Янсуаргa укырга барса да, кит син Казанга. Атна ахырында кайтып йөрерсез, – дисә дә, Вәкил авыл клубына эшкә урнашып калырга булган, ә Асия менә җыенып, хыяллары канатына тотынып чыгып китте. Аңа калса, Казан аны сагынып көтеп торадыр, әгәр кыз бу ак калага килмәсә, Казанның бер кырые китек булыр кебек. Әй, балачакның эчкерсез хыяллары! Сез дә бик тиз арада чынбарлыкның рәхимсез кыяларына бәрелеп, чәлпәрәмә килдегез! Соңыннан Асия ничә еллар буена, океан өстендә бөтерелгән акчарлак кебек, хыялларына таба ялгыз талпынды. Үз илендә, татар илендә рус телен яхшы белмәвеннән интекте, Казанга беренче килеп кергән көнне үк юан маржадан ишеткән «чаплашка» дигән сүзне ул әле мең кат ишетәчәк, һәм, ниһаять, әлеге сүзнең мәгънәсен аңлый башлаячак. Ләкин трамвайда барганда булсын, укыган җирендә булсын, Казан ханлыгы, татар иле, Сөембикәләр турында авыл китапханәсендәге сирәк китапларны укыган кыз хурланып елаячак. Үз илендә татарча сөйләшә алмаган кызый төннәр буе русча китапларны, дөнья әдәбиятын башын бәрә-бәрә өйрәнәчәк.

– Мин үземнең, сез әйткәнчә «чаплашка» түгел, данлы, шанлы олуг татар иленең уңган, булган кызы икәнлегемне дәлилләячәкмен. Ач булсам да, әни теккән ситсы күлмәк өстеннән Гыймран Рәхиме сырган сырма гына киеп йөрсәм дә, Казан каласының кызыл пәлтәле, кызыл эшләпәле койгырыш бикәләре әле миңа баш иеп, үзләре киләчәк!

Асиянең күзләре яшьләнде – еллар аша үзенең яшьлеген, балачагын кызганды. Икешәр көн буе ашарына каткан ипие генә дә булмыйча, су гына эчеп торган вакытларын исенә төшерде.

Лайнер, океан дулкыннары ажгырып өстенә килүгә карамастан, бер җайга акрын гына бара да бара. Сирәк кенә каршыга кораблар, яхталар очрый.

Асия дә үсмер чагында тормышның дәһшәтле, куркыныч дулкыннары белән «Коста» лайнеры сыман көрәште. Егылды да торды, елады да көлде. Әнә өстәл өстендә ни генә юк! Чиләктәге бозга шампан шәрабы шешәсен батырып куйганнар. Кара, кызыл уылдык, төрледән-төрле тәмле тәгамнәр, нәни-нәни кабымлыклар... Каюта ишеген шакыдылар. Ханым сискәнеп китеп, уйларыннан бүленде. Ишек төбендә, ләнгәз тотып, официант басып тора. Тагын ашарга китергән! Ап-ак китель, башына түгәрәк кәпәч кигән, төннең үзеннән дә карарак егет күзләрен, ап-ак тешләрен ялтыратып елмайды. Каюта эче яктырып киткәндәй булды.

– Сез нинди ризык ашарга телисез? – дип сорады ул. Бу кара тәнленең телен аңламый Асия, шуңа күрә телефонына русча язды:

– Миңа төшке ашка токмачлы тавык шулпасы китерегез.

Телефон тәрҗемә иткәч, егет, аңламыйча, аңа кап-кара зур күзләрен төбәде дә тагын елмайды. Асия белә, бу, әлбәттә, ихлас елмаю түгел, шулай тиеш. Асия андый елмаюларны күп күргән! Официант шулай итеп акча эшли, аның иң беренче хезмәте ул – матур итеп елмая белү.

– Ноу, – диде бу, телефонына нидер язып, тәрҗемәсен күрсәтте.

– Бездә андый ризык юк, башка берәр нәрсә сайлагыз. Хәзер мин сезгә меню китерәм,– дип, гыйфрит кебек ишектән чыгып юк та булды.

Юктыр шул, җаным, каян килсен сезгә йомырканың сарысына гына басып, җеп кебек нечкә итеп кискән татар токмачы?! Яңа чалынган яшь чебеш итеннән пешергән шулпа ашап карасагыз, Татар иле, ул илдә яшәгән халык турында нәрсә дә булса белер идегез. Әле ул халыкның моңлы җырларын да ишетсәгез, сез кайдан дип сораганга, Татарстаннан, дигән җавап алгач, Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, дип санап китмәс идегез. Мин сезгә, әгәр телегезне белсәм, татар халкының нинди бөек халык икәнлеге, Казан ханлыгы хакында сөйләр идем, сез исегез китеп, шаклар катып тыңлап торыр идегез. Юк инде, юк! Асия, авылдан килгәч, рус телен яхшы белмәвеннән интексә, хәзер инглизчә белмәвеннән изалана.

Асия быел җәй Сингапурга баргач, менюга рәсеме төшерелгән тутырган тавык ботына төртеп күрсәтте. Тавык ботын үзенең рестораннарында да еш әзерлиләр анысы. Ә монда ит ризыкларын ашарга тайчана, әллә хәләл алар, әллә юк.

Иллә дә мәгәр тавык ботын зәвыклы итеп, чәчәкләп, чуклап китерделәр. Башта ул аны телефонына төшереп алды. Монда бөтен илләрдән аш-су осталары конкурска җыелган, кайткач, үзенекеләргә күрсәтергә кирәк булыр. Әзерләвен дә шәп әзерләгәннәр, афәрин! Зәвыклы, затлы ризык.

Җанга ятышлы тәгам белән тамак ялгап куйгач, ул Мәскәүдән килгән шеф-повар Антонина белән Сингапур урамнары буйлап шәһәр карап йөрде. Шундый матур шәһәр! Бер шәһәр – бер ил, кызык. Мондагы тәртипләр – искиткеч.

– Минем, – диде Антонина, – шул бака итен кабып караганым да юк әле, күңелем тартмый. Ә сез шундый тәмләп ашадыгыз.

Асиянең күз аллары караңгыланып китте. Нинди бака, кем бака боты ашаган? Җүләрме соң әллә бу хатын? Ул бит тавык ботына заказ биргән иде! Ләкин сер биреп тормады:

– Мин, – диде, – бака итен бик яратам.

Шунда Асиянең күңелен болгатып, Ялантау күленең гөберле бакасы күз алдына килеп басты. Менә-менә хәзер «ква-ква» килеп... Ул барган җиреннән капылт туктап калды:

– Безнең рестораннарда бака итен бик яратып ашыйлар...

– Бакаларны сездә махсус үстермиләрмени?

– Юк, Казанда андый индустрия юк әле, Кабан күленнән генә тотабыз.

Асия чатта су сатып торучыларны күргәч, шунда таба атлады.

– Антонина, минем кибеткә кереп чыгасым бар иде, син кайта тор, – диде ул.

Боз кебек ярты литр салкын су эчеп куйгач, бераз җиңелрәк булып китте. Күлдәге бакалар да су ярата бит. Әй җаныем, тел белмәгәч, шулай инде, нәрсә бирсәләр, шуны ашыйсың.

Ап-ак тешләрен җемелдәтеп, официант егет тагын килеп керде. Менюга күз салып алгач, Асия, бик белдекле кыяфәт чыгарып:

– Чикен, пли-из, – дип сузып, кояшның үзе кебек сап-сары, рус әкиятләрендәге «колобок»ка охшаган кабартмага төртеп күрсәтте. Ишарәләп, өстәл өстенә официант иртән тезеп куйган ризыкларны, шампан шәрабын алып чыгып китәргә кушты.

– Бу юлы апагызны алдый алмассыз, татар, диләр мине!

Ашарга керттеләр – тавык ите, кыздырылган төрле-төрле яшелчәләр, җиләк-җимеш, тагын әллә ниләр. Бик тәмләп ашады Асия. Бу юлы, һичшиксез, тавык ите иде. Сөякләрен затлы зәңгәр тәлинкә кырыена куеп, ханым әле суынып та өлгермәгән, майда пешкән «колобок»ка тешләрен батырды. Ничекләр итеп кенә пешергәннәр диген син аны! Иртәгә рецептларын сорап алырга кирәк. Әгәр бу ризыкны Казанда пешерсәңме, әй җаным, кала халкы өнсез калачак! Йомшак итеп басылган камыры авызда эреп китәргә генә тора! Кабартма өстендә кып-кызыл, вак-вак төрткеләр дә бар. Русларның «колобогы» бер читтә торсын! Асия авызындагы ризыкны йотты да, бөтен каютага хуш ис аңкытып торган каһвәне уртлап куйды, кабартманың калганын кабыйм дип авызына китерсә, коты чыгып кычкырып җибәрде. «Колобок»тагы кызыл төрткеләр берсен-берсе уздырып кыймылдаша иде...

Әстәгъфирулла тәүбә! Раббым Аллам, кичерә күр! Соңыннан белде: «колобок»ка диңгез бете салып пешерәләр икән. Ул кып-кызыл хәшәрәт бетләр, кайнар майда үлеп бетә алмыйча, Асия кебек тел белмәгән сәяхәтчеләргә ризык була. Гаҗәбенә ни диярсең, валлаһи?! Асиянең, Кытайга баргач, көнбагыш урынына кыздырган таракан уртлап йөргән кытайларны күргәне бар иде. Кайнар майда кызып, аякларын тырпайтып катып калган тараканнар, Асиянең күз алдыннан китмичә, озак аптыратты. Хәзер менә үзе диңгез бете ашап утыра!

Йа Аллакаем, белеп кылган, белмичә кылган гөнаһларымны кичерә күр!

Бу лайнерга халык бөтен дөньядан җыелган. Монда әллә ничә ресторан, әллә ничә кибет, әллә ничә концерт залы бар – шаккатмалы! Үзе бер кечкенә шәһәр сыман.

Телефонына хәбәр килеп төште: Америка сулыкларына кергәннәр икән, иртәгә тукталыш Кубада, диелгән.

Куба – любовь моя, остров зари багровой...

Асиянең төшләренә кереп йөдәткән Куба утравы! Кыз чәрәшә-чәрәшә Урыстау асты чишмәсеннән су ташыганда иңнәрен кисеп кергән көянтә-чиләк авырлыгына түзә алмыйча, тавыш-тынсыз гына елаган чакларын, абый-сеңелләре белән кукуруз арасыннан алабута, билчән, эт эчәгесе, зәңгәр чәчәк җыеп, кышка мал-туарга азык әзерләгән вакытларын, һәм интегә-интегә, тормышта үз урынын табарга омтылган бер дәвердә, океан ярларында аксыл-сары комлыкларда кызынып, су коенып, рәхәт чигүче Куба халкына кызыгып яшәгән чакларын исенә төшереп, моңсу гына елмаеп куйды. Менә бит ул дөньяның иң затлы океан лайнерында, аның да иң кыйммәтле каютасында, Америка сулыкларын узып, үзенең балачак хыялына таба йөзә! Куба ярының алтынсыман комлыкларында кызынып, океанның зәңгәрсу-аксыл тозлы суларында коенырга бара.

Лайнердагылар иртәгә көне буе Гавана шәһәре, утрау белән танышачак. Комлыкларда кызынып, тәннәрен, җаннарын иркәли торган җылы Атлантик океанда коеначаклар.

Асия, ашап-эчеп алгач, өстенә ефәк алсу күлмәген, аягына ап-ак, йөзлегенә чын асыл ташлар ябыштырылган биек үкчәле туфлиләрен киде. Балачакта Алансуга кайтып йөргән Сөмбеләнеке шикелле иде аның

туфлиләре. Кунак кызының киемнәре, туфлиләре үсмер кыз баланың күңеленә мәңгелеккә кереп калган, күрәсең. Киенгән, ясанган Асия астагы палубага төшеп китте. Ялгыз калып, океан өстен күзәтәсе килә иде. Әнә, чыр-чу килеп, балалар, яшьләр галәмәт зур бассейнда су коена. Бассейнга торбалардан шуып кына төшәләр дә зәп-зәңгәр суга чумалар. Балык кебек йөзәләр. Рәхәтләнеп, төрле телләрдә чыркылдашалар. Әй, балачакның мәңге кабатланмас самими, әкиятләргә ышана торган бәхетле мизгелләре!

Лайнерда бай балалары рәхәтләнеп ял итә. Алар Асиянең бу балалардан күпкә кечерәк чагында яшәргә, тормыш арбасыннан төшеп калмаска тырышып, уфалла арбасы сөйрәгәнен белми. Болар, гомумән дә, өстенә дию, албасты атлангандай, андый арба барлыгын күз алларына да китерә алмыйдыр. Юктыр, юктыр! Бу балалар өйләрендә дә, әниләре эштән кайтышка ашарга пешереп, идән, сәке юып, бала карашып та тормыйдыр. Әнә бит, беләкләрендә мускул-мазар күренми. Кайсысы әвен кебек юан, кояшта кызынган тәннәрендә май катламы сырланып тора. Хәрәкәтсез тук яшәү нәтиҗәсе бу. Аларны әниләре, татлы йокыларыннан уятып, ашатып-эчертеп, мәктәпләренә озатып җибәрәдер. Аннан кайткач, әллә ниткән спорт залларына озаталардыр, юан әвеннәрен кеше рәтенә китерәселәре килеп тилмерәләрдер.

Асияләрнең җәйләре Алансу ярларында бака кашыклары җыеп, сусыл күзләрен кояшка карап ачкан сары төнбоекларны кочып, Мишә суында уйнак балыклар кебек йөзеп үтте. Кышлары исә Ялантауның өркәч сыртыннан үрәчәле чанага, яисә кер юа торган ләгәннәргә утырып шуып үтә иде. Ә инде җәен әниләреннән яшереп алып чыккан җәймәләр белән инештә ташбаш балыгы, маймыч сөзүләр! Ул балыкларны кайнар мич төбенә куеп куырып та алсаң, һи-и, җаным, аның тәмлелеге, андагы фосфор! Хәер, балык сөягендә фосфорның күп булуын авыл баласы каян белсен? Ачлы-туклы тамакка барыбер. Алай дисәң, куырган балыкны бер тапкыр кетердәтеп ашаган адәм беркайчан да кайнар майда аякларын тырпайтып катып калган таракан кимереп йөрми инде. Балачаклары никадәр авыр заманга туры килмәсен, Асияләр менә бу мимылдап торган нәзберек бай балаларына караганда күпкә бәхетлерәк булган икән. Бу – туган якның шифалы җилләрендә чыныгып, Урыстау өстеннән күтәрелеп, Кыйгасар елгасы артындагы Кәвәл үре астына төшеп баеган кояш нурында кызынып, кырыс та, назлы да табигать кочагында үсү нәтиҗәсе!

Асия сәяхәтчеләр арасында ыгы-зыгы купканын ишетеп, уйларыннан бүленеп, кәнәфиеннән кузгалды да палуба читенә килеп басты. Барысы да дулкынланып, төрле телләрдә кычкыра, сөенешеп, океанга төртеп күрсәтә. Ә анда лайнер белән янәшә дельфиннар гаиләсе йөзә. Әйе, әйе, нәкъ гаилә – әтисе, әнисе һәм өч нәни баласы. Алар уйнаклап сикерешә дә яңадан суга чума. Кояшның якты нурлары астында елкылдап торган кара сыртлары ялтырап-ялтырап китә. Дельфиннар озак озата барды лайнерны.

Асиянең уйлары ерακта – туган авылында. Ялантау, Чакрактау, Кыйгасар буйларында һәм җаннарыннан да газиз, дөньядагы бернинди шәһәргә дә алыштыргысыз, һәрбер почмагы таныш булган Казан каласында.

Океан, океан – иксез-чиксез су дәрьясы. Бәлки әле Ялантау асты чишмәсенең сандугачлар моңында коенып, челтер-челтер агып

яткан көмеш суы да шушы дәрьяга килеп кушыладыр. Асиянең әби-бабаларының, әти-әниләренең, үзенең дә яшьлектә сөйгән яры белән вәгъдәләшкән кичләренең хатирәләрен ул Тереклек елгасына алып төшеп, Мишәгә, Чулманга, гүзәл Иделгә, Каспий диңгезенә, аннан – дәрьяга, океанга илтеп җиткергәндер. Алансуы күз алдына килгәч, ханым моңсу гына елмаеп куйды. Шулайдыр, алай булмыйча мөмкин түгел. Хәтерлисеңме, чишмә, иңнәренә көянтә элгән җыйнак гәүдәле кызны? Хәтерлисеңдер, суның хәтере бар, диләр. Әле, бәлки, утызынчы елларда менә-менә бала табарга торган кызын Себергә сөргәндә: «Җибәрмим, тимәгез минем балама!» – дип, йөрәк парәсен яклап калырга тырышкан ананы да онытмагансыңдыр? Рус гаскәрие һуштан язганчы кыйнаганнан соң, дәү әнисенең тасма-тасма итеп теленгән канлы күлмәген дә синең суыңда юганнар бит. Океан суының кояш баеганда алсу шәфәкъ төсенә керүе дә, бәлки, дәү әнисенең канлы күлмәгеннән калган алсулыктыр. Елгалар – чишмәләрдән, диңгезләр елгалардан башлана бит. Менә Асия, сабый килеш Алансуның уфаллага җигелгән, иңнәренә көянтә-чиләк эленгән яланаяклы кызы, бүген бөтен дөнья байлары җыелган корабта күзләрен киң дәрья өстенә төбәп басып тора. Кайсы кыйтгаларга бара ул? Балачагы хыялынамы? Лайнерны озата барган дельфиннар белән океаннарда йөзәрмен дип уйлаган идеме соң Асия? Ханымның күңелендә шигырь юллары яңарды:

*Иңнәремне кискән чакта чиләкләр авырлыгы,*
*Кешеләргә сиздермәскә җитте лә сабырлыгым!*

Әйе, сабырлыгы җитте Асиянең, ач булса да кешегә сиздермәде, шаярды, көлде.

*Үткәннәргә үпкәләмә, борылып, артка кара.*
*Ә анда безнең балачак уфалла тартып бара.*
*Ул нинди арба дисеңме? Шуны да белмисеңме?*
*Әгәр бик беләсең килсә, тәртәгә керәсең килсә,*
*Бар, үзең тартып кара, бер тәмен татып кара.*
*Ул уфалла арбасының кышын була чанасы –*
*Авылда гомер иткәннең дөнья көтү чарасы.*

Лайнерда ял итүчеләр, дөнья белән танышу өчен сәяхәткә чыгучылар уфалла арбасының ни икәнен белми. Кәттә киенгән, тук чырайлы бу адәмнәргә таныш түгел ул арба.

*Уфалланы ни дисеңме?*
*Өстенә дию атланган, балачакның җанын алган*
*Советлар арбасы ул, нужаның бабасы ул.*

Белмәсәгез, белегез, апагызның спорт залы, фитнес клубы шул булды! Концерт, театрлары – сандугачларның чутылдап сайравы, бытбылдыкның, тәкәрлекнең балаларын чакырган авазлары, тукран тукылдавы, кәккүкнең гомер агышларын санавы. Һәм йөрәкнең кысылып-кысылып, туктамасана, кәккүк җаным, дип тибүе, минем гомерем озынрак булса иде, күбрәк итеп санасана, дип ялварулары. Ә кәккүк әллә ишетә: «Кәк-күк, кәк-күк, кыз бала, синең гомерең бик күп, бик күп күк», – дигән кебек туктамыйча күкелди дә күкелди.

Җилләр, җилләр! Кышкы салкын төннәрдә бүрәнәләр шарт-шорт атып торганда, әниләре мич төбенә салган яңа пешкән ипи исен китереп торган җилләре!

Асияләр үскән заманда балаларга кичләрен клубка кереп, концерт, театр, фильмнар карау, мәктәп директоры әйтмешли, «категорически» тыела иде. Ярамый! Җәй көннәрендә агач клубның ачык тәрәзәсеннән агылган моңга мөкиббән китеп, мәшһүр артистның үзен күрер өчен генә клуб тәрәзәсенә өелгән балаларны, яшүсмерләрне укытучылар сөйрәп-сөйрәп төшереп, исемлекләрен мәктәп директоры кулына тапшыра. Ә иртән линейкада тәртип бозучыларны бастырып куеп «тәрбиялиләр».

– Син, Асия, кыз бала башың белән ничек оялмыйча, ирдәүкәләнеп, клуб тәрәзәсенә асылынып тордың?

– Абый, минем Илһам Шакировны күрәсем килгән иде. Ул бит Алансуга көн саен килеп тормый, кайчан күрәм ди әле мин аны?

– Башың яшь әле, күрерсең. Сезгә артистларны күрер өчен клубка керергә ярамый.

– Ә күрсәк, нәрсә була соң, абый? Әнә Вәкил матур җырлый да бит, Илһам абый бөтенләй башка инде ул!

Вәкилне клубтан ук сөйрәп чыгарганнар, ул эскәмияләр астына сузылып ятып, Илһам Шакировны тыңлаган. Аның әти-әнисен чакырып сүккәннәр. Ә этисе кайткач, матчага кыстырып куйган чыбыгын алып, малайны ярган. Балачагы бит малайның. Үсә төшкәч, Вәкил авыл Сабан туенда сиксән килограммлы көрәшчеләрне баш аркылы чөя башлагач, этисе балаларына булсын, әниләренә булсын, кул күтәрергә базмады.

Бүгенге көндә Илһам Шакиров белән кара-каршы утырып, дөнья хәлләрен сөйләшә Асия, җырчының чын дустына әйләнде. Ә ул чакта моңсарның үзен күрү балалар өчен нинди зур бәхет иде. Илһам Шакировны күрү, әле үзләре дә ни икәнен аңламаган, ләкин җаннарын айкаган моң дәрьясының сихри канатларына утырып тибрәлә-тибрәлә, офыкка таба очу ләззәтен балачакның самими хыяллары гына аңлый аладыр, мөгаен. Ә Вәкил җыр-моң тыңлар өчен генә йөрәк-бәгырьләреннән саркылып агылган моңның иясен күрү өчен генә авылдашларының аяк асларына кереп яткан. Әтисе улын канга батырып кыйнаганнан соң, малай бик озак кулына тальянын алмады. Укытучылар нихәтле генә үгетләмәсен, озак вакытлар сәхнәгә менмәде. Күңеленә җыелган әрнү-хәсрәтләрен нәни йодрыкларына, юк, сулкылдап әрнеп торган йөрәгенә йомарлап, үз эченә бикләнде.

Асия тарих дәресендә юлбашчыбыз Ленин бабай турында унике битле дәфтәрне тутырып язган поэмасы өчен «икеле» алган иде.

Мәктәп директоры:

– Син үзеңне даһи дип беләсеңме? Кем сиңа тарих дәресендә шигырь язарга кушты? Аның өчен әдәбият дәресе бар. Шунда үзеңнең булган-булмаган сәләтеңне күрсәтерсең. Шуны бел, синнән кеше чыкмаячак. Журналист буласың килә, имеш. Язучы буласың килә? – дип, кызга дәфтәрен тоттырды. Директорның йөзе җир төсенә кергән иде.

– Ярар, башка язмам, – диде Асия, укытучының ачулы зәңгәр күзләренә карап. Үзенең күзләре тулы яшь иде. Әрнүле, ачынулы яшьләр. Ул кулына башка каләм алмады.

Журналист була, имеш, язучы була, юк инде!

Әнә, нинди белемле директор:

«Синнән кеше чыкмаячак», – дип, кызның хыял канатларын канатып сындырды. Шулай харап булган язмышлар азмыни! Балаларны яратмыйча, ялгышып укытучы һөнәрен сайлаучыларның, балаларның җанын изеп, әле иңсәләрендә төртә генә башлаган хыял канатларын, яисә очарга талпынып торган кавырсын канатларын яралаган, әллә ялгыш, әллә юри әйтелгән сүзләре! Күпме җаннар җәрәхәтләнгән, күпме язмышлар имгәтелгән! Ленин турында язылган поэма астына пөхтә итеп куелган «икеле» билгесе Асиянең күңеленнән һичкайчан китмәде. Әле «икеле» астына нокта да куелган иде. Бу инде сиңа журналистика турында хыялланасы да юк, урысча әйткәндә, «Точка!» дигән сүз иде.

Бусы мәктәп директорының әллә белеп, әллә ялгыш: «Тукта, үзсүзле этисенә үч итеп, бу баланың хыялларын җимерим әле», – дип кылган гөнаһы булдымы, Асия өенә кайтып, елый-елый, үзенең бала чагында язганнарын җыеп, мичкә якты.

Әнисе ул көнне ипи салырга җыенган, кичтән камырга баш куйган иде. Иртән мичен үрләтеп җибәрде. Кыз, йокысыннан уянып, дөрли-дөрли янган мичкә карап торды. Чаткылар чәчрәтеп янган коры утын кызның чынга ашмас хыяллары кебек көйрәп ята иде.

Мичтә утын яна. Асиянең колагында һаман бер җөмлә кабатлана: «Булыр-булмас сәләтең белән! Синнән беркайчан да кеше чыкмаячак!»

Әйе шул, дөрес әйтә мәктәп директоры. Кем дип белә соң Асия үзен?! Кыз бала, ипләп кенә урыныннан торып, гәҗит-журналларда басылып чыккан мәкаләләрен, шигырьләрен, дәфтәр битләренә язылган шигырь-хикәяләрен, әкиятләрен утка китереп салды. Күзеннән бертуктамый яшьләре акты да акты. Җилпуч күтәреп, әнисе килеп кергәндә, ул дәфтәрләренең күбесен яндырып бетергән иде инде. Үзен-үзе белә башлаганнан бирле сызыклы дәфтәр битләренә төшергән җан җылысын, йөрәгеннән актарылып чыккан хисләрен утка якты кыз бала!

Ниндидер ярамаган эш барлыгын сизенгән ана:

– Ни эшлисең, кызым, ник ягасың аларны? – дип, янып бетә алмаган кәгазь битләрен, кабалана-кабалана, кисәү агачы белән мичтән сөйрәп чыгарды. Казаннан су алып көйрәгән кәгазьләргә сипте. Аннары кызы янына килеп утырды. Әнисенең кытыршы кулы шундый җылы иде!

– Кызым, – диде ул, – шулай эшлиләрме инде, ә? Ничаклы хезмәтеңне юкка чыгаргансың. Күрмичә калдым, әрәмнәр генә иткәнсең ләбаса! Тормыш юллары сикәлтәле, авыр. Үзеңне юкка чыгарырга тырышкан адәмнәргә сер бирмичә яшәргә кирәк. Андыйларга үч итеп, дәһшәтле җилләргә йөзеңне куеп, алга барырга кирәк. Мәктәп директоры дөрес әйтми ул. Каләмең бар синең, балам, матур язасың, – дип, мичкә керергә өлгермичә калган дәфтәр битләрен, пөхтәләп, гәҗиткә төреп куйды. – Башка күрмим мондый эшеңне! Харап икән, сәләтең юк, дип әйткәннәр икән! Ә менә син үзеңнең чын бәяңне эшең белән расла. Шунда чын кеше булырсың! Мин ышанам сиңа, кызым. Әнә бабаң да әйтә: «Асия алга таба чын кеше булыр. Язган шигырьләрен, сездән яшереп, миңа сөйли, язсын», – ди. Бабаң белә ул. Син үзең дә аның нинди укымышлы

икәнен беләсең, – дип, гәҗиткә төргән дәфтәрләрне алып чыгып китте. Каядыр яшерде.

Асия, бала чагының уттан калган ул әсәрләрен инде кияүгә чыгып, үз балалары тугач кына исенә төшереп, әнисеннән сорап алды. Яртылаш янган дәфтәр битләрен ачып карады да моңсу гына итеп елмаеп куйды.

Балалар кулы белән язылган самими шигырьләр:

*Болыт та мине яратты –*
*Монда гына кал, малай.*
*Син кар яудырып торырсың*
*Бик оста булгач алай.*
*Юк, дидем мин ак болытка,*
*Кыстама, зинһар, юкка.*
*Кайтмый калсам, әнием*
*Сагыштан үләр юкса!*
*Шуннан тиз генә әйләнеп*
*Энҗе кар бөртегенә,*
*Иплән кенә төшеп кундым*
*Әнием керфегенә.*

Ханым ертылган, көйгән дәфтәр битен сыйпап куйды.

Хәтерли Асия, ул елны озак кар яумый торды. Әле Яңа ел алдыннан да тугайлар яшел иде. Бу шигырь кар яудырырга болытка менеп киткән малай турында иде бугай. Әй, балачак, моңлы-зарлы, авыр, мәңге әйләнеп кайтмаячак серле балачак! Менә шуларны уйлады Асия «Коста» лайнерында дәһшәтле дулкыннарга каршы йөзеп барганда.

Әйе, әйе, әнисе шул кыз хыялларын мичкә яккан иртәдә әйткән иде:

– Кызым, әле син белмисең генә, тауга биегрәк менгән саен анда сине тешләрен ыржайтып бүреләр көтеп торырга мөмкин. Тормыш шундый катлаулы мәктәп ул. Бирешмәскә, яшәргә тырышырга кирәк! – дигән, кытыршы кулы белән кызының башыннан сыйпаган иде. Инде әнисе дә туксан яшен тутырып килә. Үз акылында, Аллага шөкер! Әтисе генә алтмыш яшендә үк китеп барды.

Әнисе дөрес әйткән икән. Тау түбәсенә югарырак менгән саен, Асияне, чыннан да, тешләрен ыржайтып, бүреләр өере сагалап торды. Тик ул инде иңнәрен көянтә баскан ундүрт яшьлек кыз бала түгел иде. Үҗәт иде. Дәһшәтле дулкыннарга каршы колач салып йөзәргә сәләтле татар кызында гайрәтле бабаларының каны ага иде.

Асиянең әле дә хәтерендә: укырга кая керергә дип, кагылып-сугылып йөри торгач, ул Татарстан урамындагы аш-су осталары әзерли торган уку йортына юлыкты. Аннан соң, ике көн ашханәдә практика – димәк, тамагың тук дигән сүз. Ике көн – теория. Әй, сөенде кыз! Аллага шөкер! Урта белемне кичке мәктәптә алыр. Иптәшләре ун сыйныфны тәмамлаганда, Асиянең аш-су остасы дигән һөнәре дә булачак! Восстание урамында Галимҗан Ибраһимов исемендәге кичке татар мәктәбе бар. Шунда йөрер.

Әмма кызны ул мәктәпкә укырга алмадылар. Анда керер өчен һөнәр мәктәбеннән «кичен укырга ярый» дигән рөхсәт кәгазе кирәк икән. Кыз,

рус телен вата-җимерә, ялынып сорап карады. Тик кая ул, тыңлап та тормадылар. «Юк, сиңа кичке мәктәптә укырга рөхсәт юк. Киләсе елга барырсың», – диделәр.

– Ә минем быел укыйсым килә, бирегез инде белешмә, – дип ялынып та карады Асия. – Сыйныфташларым укып бетергәндә, минем дә урта мәктәпне тәмамлыйсым килә, алардан калышасым килми. Әнә, мәктәп директоры педсовет вакытында әнине елатып кайтарган: «Мактаулы журналист буласы кызың мин Казанга барганда, минем арттан өстәл җыештырып йөрер», – дигән. Кыскасы, Асия ул рөхсәт кәгазен ала алмады. Ләкин мәктәпкә йөрүдән туктамады. Аннан беркем берни сорамый, дәфтәрләрен тикшерүче юк. Гомумән, әйтерсең дөнья йөзләрендә Асия исемле кыз юк.

«Минем бит укыйсым килә, ник миңа укырга рөхсәт итмисез?» – дип әрни-әрни, тәгәрәп елыйсы килә Асиянең. Тик юк, аның көн саен һөнәр мәктәбеннән соң, бер көн дә калмыйча, кичләрен мәктәпкә килеп утыруында беркемнең дә эше юк.

«Җитте, туктарга кирәк. Нигә әле син үз-үзеңне кимсеттереп, күзле бүкән кебек сыйныфка кереп утырасың? Кайда синең горурлыгың, Асия? Тукта! Ял итәрсең, кичен йокың туйганчы йокларсың».

Яңа ел алды иде. Ап-ак кар бөртекләре, бөтерелә-бөтерелә, Асиянең куян мамыгыннан әнисе бәйләгән ак шәленә, озын кара керфекләренә куна. Шундый матур кышкы кич. Асия бүген соңгы тапкыр мәктәпкә бара. Үзенең Җир йөзендә мескен, мәхлук кеше булып яшәвенә чик куярга кирәк. Инде әнә, укырга хокукы булган сыйныфташлары – контроль эшләрен Асия язып биреп барган укучылар укуларын тәмамлады. Бүген Асиянең дә соңгы тапкыр укырга килүе. Әллә ничек кенә шунда, соңгы тапкыр дигән сүз кызның йөрәген әрнетә. Әнисенең сүзен тыңламады шул. Авылда калган булса соң, бу кадәр авыр тормышта яшәмәс иде. Вәкилне дә сирәк кенә күрә – Асия кайтканда йә районга киткән була, йә вакыты булмый – концерт, спектакль-мазар оештырып йөри. Ә Асия өзелеп-өзелеп көтә ул очрашуларны, шундый да сагына иде. Һөнәр мәктәбендә уку да шулкадәр авыр булыр дип, һич тә уйламаган иде. Рус телен белми диярлек. Төркемнәрендә авыл кызы берүзе. Актаныш кызы бар иде дә, укый алмыйча кайтып китте. Дәресләрдә үткәннәрнең барысын да үзләштереп бара Асия, тик рәтләп сөйләп кенә бирә алмый. Шуның аркасында әллә нинди көлке хәлләргә калган чаклары булды.

Менә «Оборудование» дәресе. Бу фәнне озын буйлы, алтынсыман кысалы күзлек кигән, чандыр гәүдәле укытучы алып бара. Ул такта янына Асияне чакырды. Кич буе дөрес итеп сөйләргә өйрәнгән иде кыз. Кабан күле буендагы эскәмиягә чыгып утырып, үткән-сүткәннәр юкмы дип карана-карана, кычкырып укыган иде.

Асия такта янына чыкты да, күрсәткеч таяк белән машинаның детальләренә төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләде. Башта җайлы гына барды үзе. Ә «сопло» дип аталган деталь турында сөйләгәндә, «вставить в отверстие сопло» дип әйтәсе урынга, ялгыш «суют туда со...» дип ычкындырды... Бер авазны дөрес әйтмәде. Сабакташлары ат кешнәгән тавышлар чыгарып, бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, кыздан көлде. Асиянең күз аллары караңгыланып китте. Әгәр шунда җир ярылса, җир тишекләренә кереп китәргә әзер иде. Юк

бул идең шунда, бу хурлыкларга түзгәнче юкларга чык идең! Кыз ишеккә ташланды. Тик укытучы Владимир Дмитриевичның:

– Ася, ставлю пять, молодец, материал усвоила на отлично,– дигән сүзләрен ишетеп, ишек тоткасына ябышкан кулларын ычкындырып, акрын гына атлап, үз урынына килеп утырды. Сыйныфташлары әле һаман тыела алмыйча көлә иде. Шунда укытучы, шап итеп, кулы белән өстәлгә китереп сукты. Өстәл кырыена өеп куелган дәфтәрләр ишелеп, идәнгә коелды.

– Сез, – диде Владимир Дмитриевич,– моннан соң ничек яшәмәкче буласыз? Берегезнең дә ояты юк. Асяның ничек тырышканын күрмисезмени? Иң тирән белем анда, иң күп белгәне – Ася. Сез түгел! Мин фашистларда әсирлектә булган кеше. Анда кешеләрне ничек мыскыл иткәннәрен күп күрдем, кешелекләреннән чыгаралар иде. Бүген сез гомеремнең шул кара көннәрен искә төшердегез.

Ахтина, такта янына чыгыгыз. Әйдәгез, ул деталь турында хәзер безгә татарча сөйләп күрсәтегез. Рәхим итегез.

Сыйныфта чебен очкан тавыш та ишетелерлек тынлык урнашты.

– Ахтина, телегезне йоттыгызмыни? Мин күптән күзәтәм инде сезне. Сез гел Асядан көләсез. Миңа калса, нәкъ менә аннан әйбәт белгеч чыгачак, ә сездән түгел. Утырыгыз, икеле.

Шул көннән башлап, Ахтина Асиянең кан дошманына әверелде. Зур гына бер түрәнең затлы киемнәр киеп йөргән кызы Асиянең ситсы күлмәгеннән, зәңгәр сырмасыннан, тапталып, тузып беткән аяк киемнәреннән көлде. Йа Раббым, булса да була икән адәм баласында явызлык!

Әле шулар өстенә физкультура укытучысы аның командаларын аңламаган кыз баланың үзәгенә үтте. Асиянең физкультура дәресләренә кияргә формасы юк иде. Зәңгәр сатиннан теккән шаровары белән ул матур киенгән укучылардан ала карга кебек аерылып тора. Аның озын авыр толымнарын күреп, баш түбәсе агарып, пеләшләнә башлаган сирәк чәчле укытучы һәрдаим:

– Ат койрыгыңны җый! – дип җанын талады.

Һәм Асия әнисе әче сулар белән юа-юа тәрбияләп үстергән дулкын-дулкын чәчләрен кистереп кайтты. Бер чәчтарашханәдә өлкән генә хатын:

– Син җүләрме әллә, шундый чәчләрне кисәләрмени? – дип куып чыгарды. Ә икенчесе, сөенә-сөенә, толымнарын кисеп алды да шкаф тартмасына салып куйды.

Авылга кайткач, әнисе әрнеп елады:

– Кызым, толымнарың толым гына түгел, чәчең чәч кенә түгел иде, хараплар гына иткәнсең! – диде.

– Әни, минем чәчемне ат койрыгы, дип көләләр, шуңа кистердем.

– Толымнарың кая соң, кызым?

– Алып калдылар, әни. Сорап алырга оялдым.

– Мин бит, балам, сезнең һәрбер чәч бөртегегезне җыеп яндыра идем. Халык арасында, «Чәч бөртеген кошлар алып китсә, баш авыртучан була», дигән гыйбарә йөри. Ә син толымнарыңны әллә кайларда, әллә кемнәргә биреп калдыргансың. Әй, бала, бала! Ничекләр яшәп

бетерерсең бу йомшаклыгың белән калада? – Әнисе кул аркасы белән күзләрен сөртеп алды. – Ярар, буласы булган инде, хәзер бернәрсәне дә үзгәртеп булмый.

Кичке мәктәпкә соңгы баруында Асиянең күңеле тәмам төшкән иде. Сыйныф җитәкчесе Мәгъмүрә апа дәресе. Ирекле темага инша язалар. Язды Асия. Күзеннән яшьләре агып төшеп, дәфтәр битенә тамды. Күңеленә җыелган сүзләрен тезде генә: «Минем бит укыйсым килә! Ник миңа рәхәтләнеп укырга бирмисез? Беләсезме сез, шәһәргә килгән яклаучысыз, тел белмәгән ялгыз кыз балага ничек авыр икәнен? Мин бүген мәктәптән китәм, бәлки, әле һөнәр мәктәбеннән дә китәрмен. Арыдым мин. Канатлары каерылган ялгыз аккош кебек әллә кайларга, ерак-еракларга, гаделсезлекләр, явызлыклар юк җиргә очып китәсем килә минем. Әйе, минем өстемә кияргә юньле киемем юк, торырга урыным юк, ашарга ризыгым юк, ләкин яшәргә тырышып, ашкынып торган җаным, йөрәгем исән. Кеше тәрәзәләренә карап кызыгып йөрим: сез – бәхетлеләр! Сез үз ачкычыгыз белән ачып, үз өегезгә кереп йоклыйсыз. Ач булсагыз, бәрәңге белән кара ипи ашап булса да тамак туйдырасыз, үз урын-җирегезгә ятып йоклый аласыз. Их, минем дә үз почмагым, баш куярлык кына бүлмәм булсын иде! Фатир хуҗасы, кичке унынчы ярты булу белән, кереп утны сүндермәс иде.  Дәрес хәзерлисе бар бит. Кем дә булса шуны аңласын иде! Адәм баласының тормышы гел рәнҗетелүдән, кагылып-сугылудан гына торырга тиеш түгелдер ләбаса! Алда якты көннәр, сөю-сөелүләр дә булырга тиештер. Тиздән миңа уналты яшь тула. Гомеремнең иң матур, гаҗәеп ашкынулы, күңел күбәләгенең канат кагынып очынып торган мәле. Җанның җырлап, сөю көтеп тилмергән вакыты. Йа Аллакаем, минем гомерем яшәү өчен көрәшеп, тилмерепләр уза. Кире әйләнеп кайтмас бит ул унбиш, уналты яшьлек чаклар! Алар инде мәңгелеккә гомер тәгәрмәчләре тәгәрәп узган тузанлы юлда аунап калыр. Ә яшисе килә! Матур итеп, үзем теләгәнчә яшисем килә минем! Укыйсым, туган илемә файдалы кеше булып яшисем килә. Ник мине беркем аңламый!?

Әй, канатлы кош булсаң иде дә, бер талпынып алып, канатларыңны кагынып очсаң иде. Әллә кайларга, әби сөйләгән әкиятләрдәге Каф таулары түбәсенә менеп кунсаң иде! Юк икән шул. Канатларың каерылгач, очып булмый икән!»

Шулай тәмамлаган иде Асия иншасын. Язып бетерде дә, кабат укып та тормыйча, дәфтәрен укытучының өстәленә куеп чыгып китте.

Урамда әле һаман ябалак-ябалак кар ява. Җәяү генә кайтырга булды. Шундый да матур кич. Әллә бөтенләйгә авылга кайтып китәсе инде? Тиздән каникуллар башлана. Әтисе ни дияр икән? Киткәндә әйтте бит:

– Кызым, шуны бел: киттең икән, кайту юк. Мин дәрәҗәмне төшереп, синең өчен башымны иеп, Янсуар мәктәбенә барып йөрмәячәкмен. Үзең пешергән картаңны елый-елый тарт, – диде. – Дөнья җебегәннәрне яратмый ул.

Әтисе әйткән сүзеннән кире кайтмаячак. Әнисе кызын кызганып елаячак.

Ак кар бөртекләренә урала-урала,  шундый авыр уйлар белән кайткан иде Асия.

* * *

Кышкы каникулны, үзәкләре өзелеп, сагынып көтеп алды ул. Авылда аны Вәкиле көтә. Яңа елга концерт әзерләп йөриләр икән. Вәкил шулай дип язган. «Казаннан кайтачак яшьләрне дә концертта катнашырга чакырабыз, кайт, бик күңелле булачак», дигән. Кайтмыймы соң?! Инде көннәрне түгел, сәгать-минутларын санап көтә Асия. Каникулда әти-әнисе, абый-сеңелләре янында булачак. Шундый да рәхәт буласы инде! Казанда күргән гаделсезлекләр, рәнҗетелүләр онытылып торыр. Әнисе белән тәмле ризыклар пешерерләр. Пешерү-төшерүләргә Асиянең кулы ятып тора, диләр. Практикага килгән ашханәдә дә әле яңа гына укый башлаган кыз баланың осталыгына хәйран калдылар. Бар эшне ялт иттереп эшләп куя, кушасы да юк, үзе белеп эшли. Шулай булмыйча, Асия бит өйләрендә әнисе мәктәптән кайтышка ашарга пешереп торырга өйрәнде. Ә аннан соң пионер лагеренда аш-су остасы Гөлсем апасы мәктәбен үтте ләбаса!

Яңа ел кичәсенә Асия әнисе теккән яңа күлмәген киеп килде. Зәңгәрсу тукымага ак чәчәкләр төшкән күлмәк бик тә матур, Асиянең зифа буена шундый килешә. Кистерелгән чәчләре дулкын-дулкын булып иңнәренә агып төшеп тора. Кыз ашкынып кичне көтте. Аны сөйгәне көтә! Асиянең сулар сулышына әйләнгән мәхәббәте Вәкил көтә!

«Кайт, көтәм, мин сине бик сагындым, Асия!» дип, хатында да язган иде. Шакмаклы дәфтәр битенең чит-читләренә кызыл карандаш белән йөрәк рәсеме дә ясап куйган.

Матур итеп чыршы бизәгәннәр. Агач клубта ылыс исе, аклык, сафлык исе аңкый. Вәкил тальян гармунда акрын гына «Яшь наратлар» көен уйный. Концерт әле башланмаган. Төрле-төрле матур киемнәр кигән яшьләр, төркем-төркем булып җыелышып шаулаша, көлешә, тамаша көтә.

Асия сыйныфташлары белән кочаклашып күреште. Әнә дусты, Вәкилнең сеңлесе Нурия, арттан килеп күзләрен каплады.

– Таныдым мин сине, Нурия дускаем, – диде Асия. Сагынышканнар иде, кочаклашып күрештеләр. – Әй, сагынам соң, Нурия. Бүген үк Казаннан кайтып китәр идем дә, синең белән Янсуарга барып укыр идем. Тик әтидән куркам.

– Әйдә, кайт, Асия. Әйбәт укыйсың бит син, куып җитәрсең әле.

– Мин бит Казанда кичке мәктәпкә йөрдем. Шуңа күрә укуда артта калдым дип аптырамыйм. Тик оят дигән нәрсә бар бит әле. Укый алмыйча кайткан, җебек, диярләр.

– Дускаем, кайт әле син. Беләсеңме, теге Хәдичәттәйләргә кайта торган Сөмбелә сөлек кебек ябышты абыйга. Атна саен кайта, киенеп-ясанып, клубтан кайтып керми. Авылда: «Вәкил белән Сөмбелә арасында нидер бар»,– дигән сүзләр йөри. Әни дә әйтә: «Кызым, Асиягә әйт әле, авылга ешрак кайтып йөрсен. Бигрәк яратам үзен. Араларына кем дә булса керә күрмәсен», – ди. Абый өчен кайгыра.

– Ярар, Нурия, җаны теләгән елан ите ашаган, ди, Вәкил үзе беләдер, – дип куйды Асия, чигәсе буйлап шаулап кан йөгергәнен тоеп. Шуны гына көтеп торгандай, клуб ишеге ачылып китте дә, ап-ак салкын буга уралып, өстенә кыска ак тун, аякларына ак күн итекләр кигән Сөмбелә килеп керде. Әйтерсең, Кар кызы! Матур иде Сөмбелә. Челтерәп көлеп, тальян

тартып утырган Вәкил янына килеп утырды да ялт итеп Асиягә карап алды. Асия өйдә чакта үзенә хәйран гына матур күренгән күлмәгеннән оялды. Аягында да әлеге дә баягы акбур белән буялган брезент чүәкләр иде. Күңеле төште кызның.

Вәкил – Кыш бабай, Сөмбелә Кар кызы булып, кичәне алып бардылар, җырладылар, биеделәр. Концерт барышында Сөмбелә әллә нинди киемнәр киеп, төрле биюләр биеде. Күбәләк булып очты, кар бөртеге булып бөтерелде.

– Шәп икән бу кызый, моны бер кочар өчен әллә ниләр бирерсең! – дип, тел шартлатты клубта утырган ир-ат.

Вәкил әле гармунда уйнады, әле җырлады. Әнә, хәзер Асия яраткан «Бишмәтеңдә синең биш төймә»не җырлый.

Асия, күзләренә яшь төелеп, урыныннан кузгалды, сәхнә артында салып калдырган сырмасын табып киде. Клубтан чыгып, акрын гына өенә таба атлады. Юкса ничекләр ашкынып кайткан иде авылга! Вәкил аның кимсенгән җанына бердәнбер дәва иде.

Нинди генә дөнья соң бу?! Ник, ни өчен Вәкил, аңа хыянәт итеп, Асияне матур, затлы, зәвыклы киенгән, чытлык Сөмбеләгә алыштырган?

Соңгы өмете киселде кызның. Ишелеп яуган ак кар да аның күңелен күтәрмәде. Җанда әйтеп, аңлатып бетерә алмаслык бушлык, газап иде. Әйтерсең кызның җанын суырып алганнар да шул бушлыкка дыңгычлый-дыңгычлый нидер тутырып куйганнар. Асия хыяллары чәлпәрәмә килеп ватылган, йөрәгендә соңгы өмет бөреләнеп килгән саф мәхәббәтенең чәчәк ата алмаган гөл кебек сулуын тойды. Әнисенең:

«Ник иртә кайттың, кызым? Иптәшләрең белән Яңа ел каршыламыйсызмыни?» дигән соравына кыска гына җавап бирде: «Арыдым мин, әни, мин шундый арыдым», – дип, сәке читенә җәелгән урынына ауды.

Әнисе аңлады. Вәкил белән Сөмбелә арасындагы мөнәсәбәтләр турында күршесе Хәдичәттәй сөйләгән иде. Шуңа күрә ул кызына бер сүз дә әйтеп тормады, эчтән генә тынды.

* * *

Океанның очсыз-кырыйсыз калын дулкыннарын каерып барган кораб палубасында, йомшак кәнәфидә уйларына чумып озак утырды Асия.

Каникуллар бик тиз үтеп китте. Иптәш кызлары кереп, озак итеп үгетләп тә карады, тик кыз клубка башка чыгасы итмәде. Авыл ничектер караңгыланып, ятимләнеп калган иде.

«Тизрәк, тизрәк китәргә кирәк! Шәһәргә китәргә һәм укырга. Әнисе әйтмешли, дөнья булгач, төрле хәлләр була – очрашулар, кавышулар, аерылышулар».

«Кызым, авыр чаклар үтеп китмәс кебек тоела гына алар, – дигән иде ул. – Барысы да яхшы булыр. Укып бетерерсең, әле синең Сөмбеләнекенә караганда да затлырак киемнәрең булыр. Әни әйткән иде, диярсең. Синең бит күңелең якты. Әнә шул җан яктылыгың йөзеңә күчкән. Әле синнән дә бәхетле кеше булмас. Иптәш кызларың белән клубка чык. Башыңны югары күтәреп, «минем исем китми» дип йөр!»

«Әй, әни, минем Казан каласында ничек яшәгәнемне белмисең бит син. Мин бит анда ике көн ашап, ике көн ач торам. Ләкин мин сездән беркайчан да бер тиен акча да алмаячакмын. Сезгә болай да авыр, ләкин түзәсез, дәшмисез, зарланмыйсыз. Мин укуымны ташламаячакмын. Ә Вәкил үзенчә яшәсен». Бу сүзләрне Асия әнисенә әйтә алмады. Үз-үзенә генә әйтте.

Димәк, аның язмышы шул. Бәлки, мәхәббәт өчен Сөмбелә кебек көрәшергә кирәктер? Юк, юк, Аллам сакласын! Асияме шулай әрсезләнеп, егетләргә тагыла?! Сагынудан, сагыштан үлсә үлә, ләкин беркайчан да сер бирмәячәк! Үзенең беренче мәхәббәтен йөрәгенең иң ерак почмагына яшереп, онытырга тырышып яшәр Асия! Ә бәлки онытыр да. Гомеренең озын юлларында бәлки Вәкилне оныттырырлык берәү табылыр.

Каникуллардан соң укырга килгән беренче көнне үк Асия көллияткә мәктәп директоры белән татар теле укытучысы килеп керде.

Мәгъмүрә апасы Асиянең иншасын сыйныф саен укып йөргән дә – мәктәп директорын көллияткә барып, Асиягә: «Бу кызга кичке мәктәптә укырга ярый!» – дигән белешмә алырга күндергән.

Февраль ахырларында Асия бүлмәсенең ишеген шакып, Нурия килеп керде. Күңеле төшенке иде кызның. Кочаклашып күрештеләр, авыл хәлләрен, тегесен, монысын сөйләшеп утырдылар. Нуриянең нидер әйтәсе килеп тә, ничектер уңайсызланып, Асиянең күзенә туры карамыйча утыруыннан кыз сизде: нидер булган. Сүз башлый алмыйча гына утыруы.

– Әниеңнең хәлләре ничек соң, Нурия? Әтиеңнең үлеменнән соң бик хәсрәтләнә иде,– дип, үзе сүз сөрешен үзгәртеп җибәрде Асия.

– Ни эшләмәк кирәк, Асия, үлгән артыннан үлеп булмый. Йөрәк яна дисәләр дә, чи ит янмый, яшәп ята инде. Мин дә атна саен кайтып йөрим, абыйлар да... Бергә-бергә яшәп ятабыз шунда.

Асия, күкрәк турысында нидер өзелгәнне тоеп, Нуриянең күзләренә карады:

– Нурия, ник әле син Вәкил турында күплек санда сөйләшәсең?

– Бәй, син ишетмәдеңмени, абый өйләнде бит. Сөмбелә абыйдан балага узган. Яңа ел кичәсендә эчкәннәр дә, икесе генә клубта калганнар. Аннан соң да Сөмбелә атна саен авылга кайтып йөрде.

Әй, әни кайгырды инде: «Ник кайтмый бу Асия? – дип өзгәләнде. – Кайларда гына йөри бу кыз? Шундый яратам үзен. Киленкәем генә булса иде дип, иртә-кич теләкләр телим. Күңелем сизгән иде аны, Хәдичәттәйгә кайтып йөрүче шул чытлык башын әйләндерер дип курыккан идем».

Шулай булып чыкты да. Беркөнне Сөмбеләләр әти-әнисе белән кайтып төште. Абый өйдә юк иде. Күрсәң бездәге тамашаны. Әнигә ябыштылар: «Вәкил Сөмбеләне көчләгән, шуннан кызыбыз йөккә узган, йә бүген үк өйләнә, йә төрмәгә утыртабыз», – дип, әнинең котын алдылар. Әни, мескен, хәлсезләнеп, сәке читенә килеп утырды.

«Туктагыз әле, зинһар өчен! Бу бит илдә, көндә булмаган хәл. Йа Раббым, Аллам! Авылда кеше күзенә күренерлегемне калдырмаганнар лабаса! Әйттем бит: «Улым, калага чыгып кит! – дидем. – Ничек тә яшәрмен әле, – дидем. – Юк бит, юк. Инде бу хурлыкларны да күрәсем бар икән!» – дип үкси-үкси елады әни. Бөтен дөньясына рәнҗеп елады.

Әй, Асия җаныкаем, җәлләдем соң әнине. Бер рәхәт күрмәгән кеше бит ул. Гомер буена әтидән рәнҗетелеп, кыйналып яшәгән әни җаным бит ул минем! – дип, Нурия үзе дә калтыранып елап җибәрде. – Аннан соң абый кайтып керде. Сөмбеләнең әти-әнисе, икәүләшеп абыйга ябышты. «Төрмә сиңа, анда синең ише көчләүчеләрне нишләтергә икәнен беләләр! Йә өйләнәсең, йә бүген үк милициягә язабыз. Шунда синең башың бетә. Бел шуны», – диләр. Абый, бер сүз дә әйтмичә, әни кырыенда утыра, күтәрелеп тә карамый. Шуннан әни, көчкә телгә килеп: «Ярар, нишлисең инде. Кара сакалың үзеңә ияреп йөри икән инде ул. Үземнең бәхетем булмады, инде улыма да шундый язмыш язган икән!» – дип кузгалып китеп, самавырга тотынды. Сөйләшмичә генә чәй эчтек. Шул ук кичне, мулла чакыртып, никах укытып алдык. Кодалар, Сөмбеләне калдырып, Казаннарына кайтып китте. Менә шундый хәлләр бездә, Асия. Сөмбелә барыбер үзенекен эшләде. Син дә инде шунда Яңа ел кичәсеннән кайтып китмәгән булсаң соң. Абый икенче көнне сорый: «Нурия, Асия кай арада юкка чыкты соң ул? Минем эш урыным бит ул клуб. Ул кичәне оештырырга тиеш идем. Мин аңа яздым бит: концертта Казаннан кайткан яшьләр дә катнашачак, дип. Кар кызы ролен башкарырга Сөмбелә бик теләп алынды. Бигрәк матур бии бит, кушкуллап риза булдык. Их, сеңелкәш, Сөмбелә кайтмаган булса шунда», – ди.

Күңеле бик төшенке иде абыйның.

«Ник алай дип әйтәсең, абый? Асия кайтыр әле. Аның укуы авыр. Ике җирдә укый. Тик бер дә кайгырма, ярата бит ул сине. Яраткач, бөтен нәрсәне гафу итеп була», – дим.

«Юк инде, Нурия, бу гафу итәрлек кенә хәлләр түгел», – диде. Бик каты борчылды. Мин аның бу халәтен ул вакытта аңлап бетерә алмаганмын. Кодалар кайткач кына аңладым. Сөмбеләнең ике айлык көмәне булган икән. Бер көнне, хатыны кибеткә киткәч, абый әнигә әйтә: «Әни, яратмыйм бит мин аны, ничекләр итеп торып бетерәсе булыр, бер минут та тормас идем», – ди.

«Юк инде, улым, беркая барыр хәлең юк, кеше баласын рәнҗетеп, үз балаңны ятим итеп яшәргә ярамый, рөхсәтем юк, – диде әни. – Ак биләүләргә биләгәндә, бәхете булсын баламның, дип әйтмәгәнмен, күрәсең. Яратмаган кеше белән яшәүне менә миннән сора син. Ул бит мәңге атмас таң кебек. Әтиең белән яшәгәндә, тагын кич җитә, аның белән тагын бер түшәккә ятасым бар дип, котым чыгып тора иде. Сине дә минем язмыш көтеп торган икән. Ни эшләмәк кирәк, үзең гаепле. Әле Асияне дә рәнҗеттең. Дөнья бәһасе бала иде бит. Ярар, җаны теләгән – елан ите ашаган, диләр. Аллага тапшырдык. Тик хатыныңа әйт, иртәнге сәгать унга хәтле чаршау артында аунап ятмасын. Ачык ишектән кем килеп кермәс. Бигрәкләр дә ялкау. Бер генә дә эшкә өйрәтеп үстермәгәннәр үзен. Дөнья булгач, гел биеп йөреп кенә яшәп булмый шул ул. Менә балагыз туар. Бәлки, улым, Казанга чыгып китәрсез. Киленнең әти-әнисенең фатирлары өч бүлмәле, ди бит. Көн саен зарлана, газыгыз да, ваннагыз да юк, ди. Монда ничек тормак кирәк, ди. Абзарыгыз сасы», – ди.

«Торасы килмәсә, әти-әнисе янына китсен. Минем аларга йортка керүемне телисеңмени, әни?»

«Юк инде, улым. Аптыраган үрдәк арты белән күлгә чумган, шуннан гына әйтүем».

Абый көн саен соңга калып кайта, өйгә кайтасы килми инде аның. Шуңа күрә эш тапкан булып йөри. Ә әни абыйга әйтә: «Улым, алай ярамый, хатыныңны рәнҗетмә, аның ана буласы бар. Балага зыян-зәүрәт килә күрмәсен. Соңыннан үкенерсең, соң булыр», – ди.

Сөмбеләсе акырып елый. Әни аны тынычландырып карый каравын. Кая ул! Абыйга унҗиде генә яшь бит әле. Сөмбелә аннан биш яшькә олырак. Бездәге хәлләрне күрсәң син, малай җаным, исләрең китәр! Әле теге ялда гына абый әйтә: «Нурия, әгәр Сөмбеләне аерсам, Асия мине гафу итәр микән? Их, сеңелкәш, терсәк якын, тешләп булмый, – ди. – Кичермәс ул мине. Шундый ярата идем үзен, өзелепләр ярата идем. Көн саен төшләремә керә, – ди. – Урыстау башындагы карт имән төбендә көтеп торам, имеш. Чатыр-чотыр килеп, очкыннар ата-ата, учак яна. Учак янында яшьләр җырлаша. Шундый матур, тымызык кич. Асия куаклар арасындагы тар сукмактан очына-очына миңа таба килә. Тик килеп җитә алмый. Бик якын ара югыйсә. Мин, кочагымны җәеп, аның каршысына йөгермәкче булам, ләкин аякларыма гер таккан кебек бер урында таптанып торам. Ә аннан соң тау ишелгәндәй була да, аска тәгәрим, – ди. – Көн дә шул бер төш керә. Сеңелкәш, – ди, – минем бу ялгыш адымымны кабатлый күрмә, зинһарлап әйтәм! Әгәр бу эшне эшләсәң, әни бу кайгыны күтәрә алмас, – дип, мине өйрәткән була.

– Асия! Мин синең янга абый кушканга килдем. «Барыбер тормыйм мин Сөмбелә белән. Мин беренче түгел идем», – ди. Ул: «Сөмбеләне аерып җибәрсәм, Асия мине гафу итәрме икән?» – дип сорарга кушты. Синең җавабыңны көтеп калды, ни әйтерсең?

Асия, күзләрен бер ноктага төбәп, озак утырды. Күз алдыннан лагерьда эшләгән үсмер кызның авыр, ләкин ләззәтле, матур көннәре тезелешеп үтте. Вәкилнең зәңгәр моң сирпелеп торган күзләре, төз гәүдәсе... Авылга сөткә төшкән чагында, ургылып аккан елга ярында: «Ашыкма, Асия, теге ярга үзем күтәреп чыгарам», – дип, чалбар балакларын сызганып, чиләкләрен күтәреп алуы якты хатирә булып яңарды. Колагында Вәкилнең сүзләре янә ишетелгәндәй булды: «Асия, авырдыр сиңа, бир чиләкләреңне, үзем алып менеп куйыйм, – дип, кызның тулы чиләкләрен алып, Урыстауга таба йөгерә-атлый менеп китүе...

Шунда кыз Сөмбеләнең кысынкырак күзләрен күргәндәй, Асиягә мыскыллап караган зәһәр күз карашын тойгандай булды. Һәм ул караш тау башында үзен көтеп торган ана бүре карашы белән кушылып, җаныннан иңрәүгә охшаган бер өн чыкты:

– Әй, Нурия, минем өчен Вәкил сулар сулышыма әйләнгән иде бит, гомерләрем буе янәшә барырбыз кебек иде. Аннан башка яшәүне күз алдына да китерә алмый идем. Нишләмәк кирәк? Тау башында баласын эзләп йөргән ана бүре миңа тимәгән иде, кызгангандыр инде. Бүредә дә кызгану хисе бар микән әллә? Япь-яшь кыз бала яшәсен, дигәндер. Ә Сөмбелә белән Вәкил бөтен хыялларымны җимерде. Дөрес түгел бу! Мин хәзер Вәкилнең туачак баласын бәхетсез, ятим итимме? Юк, мин андый адымга мәңге бармаячакмын! Әйт Вәкилгә, кайчан да булса, бәлки, онытырмын

да. Ә хәзер беренче мәхәббәтнең татлы мизгелләре йөрәгемдә яра булып, ничек кенә әрнеп тормасын, мин аларның араларына кермәячәкмен! Бәхетле булсыннар, Вәкил мине онытсын. Бәлки, мин дә үз бәхетемне табармын әле. Ләкин кеше тормышын бозып, баланы ятим итеп түгел. Кеше рәнҗетеп тапкан бәхетнең ахыры яхшы бетмәс. Әниеңә әйт, алай кайгырмасын. Вакыт барысын да дәвалый, диләр бит. Вакыт кирәк, – дип, күз яшьләрен сөртте Асия. Һәм ул дусты белән кочаклашып аерылышты.

* * *

Ул елны Асия җәй буена авылына кайта алмады. Аларны «Зәңгәр күл» пионерлагерендагы ашханәгә ашчы ярдәмчеләре итеп практикага җибәрделәр. Аена утыз алтышар сум хезмәт хакы түләделәр. Кызлар үзләре яшендәге үсмерләргә ашарга хәзерләп торды.

Иртән сәгать биштә торып, зур мичне ягып җибәрергә кирәк. Чи утын янып китә алмыйча интектерә. Аннан соң кичке сәгать уннарга чаклы суган, бәрәңге, кишер әрчеп, ашарга пешереп, савыт-саба юып, арып-талып, көч-хәл белән тактадан әмәлләнгән торакларына кайтып авалар. Көн саен шулай, Алансудагы кебек. Тик монда, җаннарны җылытып, каядыр биеккә, чисталыкка, очсыз-кырыйсыз илаһи бер серле дөньяга чакырып торучы беренче мәхәббәте Вәкил, аның тальяны юк. Асиягә авыр, һай, авыр. Янында авыр чиләкләрен күтәреп алырдай, егылырдай чакларында иңен куярдай, ургылып аккан елганы кичкән вакытта янәшә басардай ир-егет юк. Шуңа авыр кызга. Тораклары артында гына үсмерләрнең чырык-чырык көлүләре, русча җырлаулары Асияне кызыксындырмый. Тиз генә юына да йокларга ята. Иртән иртүк торып, тагын эшкә керешергә кирәк. Кирәк терәкне ега, ди. Ул эшләргә тиеш. Быел сеңлесе дә Казанга киләчәк. Аңа һич югы пәлтә алырга кирәк. Асия кебек тилмереп, кешедән оялып йөрмәсен. Ә үзе эшли башлагач, киенер әле. Бабасы әйтмешли, Аллаһ ярдәменнән ташламас, бер җае чыгар.

Иртәгә якшәмбе көн, ял итүче балалар янына әти-әниләре киләчәк. Мастерлары Фәния Гариповна алдан ук кисәтеп куйды: иртәгә ризыкларыгызны бик тырышып әзерләгез, чөнки әти-әниләр килә. Алар ризыкның сыйфатын тикшерәчәк, диде.

Иртән Асия көчкә-көчкә генә урыныннан кузгалды. Бик арыган иде. Нигәдер елыйсы килде. Уналты яше яңа тулган кыз бала ни өчен шулай тилмереп яшәргә, үзе кебек үсмерләргә хезмәт итәргә тиеш? Арыды, бик арыды ул. Торырга урын, кияргә кием юк. Җанында – әрнүгә әйләнеп калган Вәкил.

Көч-хәл белән мичне үрләтеп җибәрә алды. Шунда Фәния апасы:

– Асия, әле дә ярый син бар, – дип әйтеп куйды. – Бу Казан кызлары белән ничекләр генә әлеге эшләрне башкарып чыгар идем? Юк, болардан бернинди ашчы чыкмаячак, чын әгәр. Без бит синең белән – авыл балалары. Тормышның ни икәнен беләбез. Син бигрәкләр дә әзер ашчы булып килеп кердең, син практика узган. Ашханә мөдире әйтә: «Бу кыз синең ун практикантыңны алыштыра ала», – ди. Алла теләсә, барысы да булыр, киемең дә, фатирың да. Кайчан да булса, мине искә алырсың әле. Фәния апа әйткән иде диярсең, – дип, кызның күңелен күтәреп җибәргән

иде мастерлары. Төшке ашны ашатып, табак-савытлары җыештыргач, Асия, мастеры янына килеп:

– Фәния Гариповна, мөмкин булса, мин ятып торыйм әле, нигәдер башым авырта, хәлем юк, – дип, китәргә рөхсәт сорады.

Кызның битләре комачтай янып тора, үзе көч-хәл белән генә сөйләшә иде.

– Тукта, тукта, Асия, жарың бар бугай. Тиз генә медпунктка барып килик әле, – дип, мастер апасы кызны такталардан корылган, яшел төскә буялган, «Кызыл хач» билгесе куелган бинага таба алып китте.

– Температурасы утыз тугыздан артык, ангина, – дип озаттылар Асияне.

– Тамагын һәрдаим содалы җылы су белән чайкап торсын. Соңыннан кереп, хәлен белеп чыгармын, – диде табиб.

– Асия, бөтен йөзең корымга буялып беткән, төннек тишегеннән чыккан җен кебек булгансың. Кайткач, көзгедән карап ал, – дип, елмаеп кул болгады Фәния апасы.

Асия торагына кайтып җиткән иде инде. Хәзер керә дә юынып, ятагына ава. Шулчак:

– Асия, синме? – дигән тавышка борылып караса, янәшәсендә Газиз басып тора иде. Кыз, аптырап:

– Газиз, сез кайдан килеп чыктыгыз бу якларга? – дип елмайгандай итте.

– Минем кечкенә сеңлем биредә ял итә. Әти-әнием килә алмады. Баланың күңеле кителмәсен дип, мине җибәрделәр. Ярый әле, килгәнмен, менә сине очраттым, югалткан идем. Ә син нишлисең монда?

Асия, корымга буялып беткән ак халаттан, үкчәләре тапталган башмаклардан булуына уңайсызланып, тизрәк кереп китәргә ашыкты.

– Тукта инде, Асия, мин бит сине күптәннән эзлим. Мехчылар урамын мең урадым. Аннан соң Митрофанга эт эчәгесе җыеп йөрмиме икән, дип, елга вокзалы тирәсендә әйләнгәләдем. Адресың истә калмаган. Мә әле, битеңне сөртеп җибәр, мичкә кергән кеше кебек корымга батып беткәнсең ләбаса, – дип, Газиз кесәсеннән ап-ак кулъяулык чыгарып, Асиягә сузды.

– Әй, мин бит аш пешерүчеләр әзерли торган уку йортында укыйм. Без монда практика узабыз. Мичләре янмый интектерә, утыннары чи булгач, кабынып китә алмый. – Егет ап-ак чалбардан иде. Кыз, күзләрен тутырып, Газизгә карап алды. Өстендә акка буй-буй зәңгәр сызыклар төшкән кыска җиңле күлмәк. Асия үзенең кыяфәтеннән оялды. – Мә кулъяулыгыңны, буялмасын. Сабынлап юмыйча, бит-кулларымны корымнан чистартып булмас. Ярый, Газиз, мин керим әле, әллә нигә хәлем юк, – дип, кыз китәргә җыенды.

– Адресыңны әйт әле, Асия. Гел сине күрәсем килеп тора.

– Нигә инде ул сиңа, Газиз? Әле мин тагын унбиш көнләп лагерьда булам. Ярый, хуш, – дип, кыз торакка кереп китте. Лагерьда ял итүче үсмерләр барысы да каядыр чыгып киткән. Көч-хәл белән өстерәлеп барып, Асия ятагына ауды. Ул рәхимсез дөньяга ник туганына үкенеп, рәнҗи-рәнҗи, үзенең мескенлегенә үртәлеп, һәм шушы хәленнән берничек тә чыга алмаячагын аңлап, тәмам төшенкелеккә бирелеп, еларга җыенган иде дә... Адәм баласы бу дөньяга яратыр, яратылыр өчен килергә тиештер

ләбаса! Әти-әнисен, туганнарын яратырга, алсуланып туган яңа көнне, моңсуланып кояш баюын, күккә ашкан Зөһрә кызны күреп сокланырга һәм Вәкилне...

Юк инде, юк! Булмаса булмый икән. Әнә, ялгыш кына юлында очраган Газиз дә Асияне корымга батып беткән хәлендә күрде. Әле тигез ак тешләрен ялтыратып, кесәсеннән кершән кебек ап-ак кулъяулыгын чыгарып: «Мә, Асия, битләреңне сөрт әле, тәмам корым чистартучы булгансың», – дип тора. Көлүе инде. Теге юлы абыйларының кәҗәсе Митрофан турында сөйләп, адәм хуры булган иде. Инде менә бүген морҗа тишегеннән чыккан җен-пәри булып каршысына килеп чыкты. Йа Аллам, бу егет азрак алданрак яки соңрак кайтып киткән булса соң, Асияне мондый котсыз, мәзәк кыяфәттә күрмәс иде.

«Нигә шундый булдыксыз, җебек соң син? Кыз балага матуррак, чистарак киенеп йөрергә кирәктер ләбаса», – дип, аңа Газиз эндәшәдер кебек тоелды.

«Менә минем кебек иртә таңнан торып, мичкә чи утын ягып, йөздән артык балага ашарга хәзерләп кара син, шунда минем хәлемне аңларсың. Ак күлмәк-ыштаның шундук корымга батар. Ә ул корымны күпме генә сабынлап юсаң да, аннан арынып булмый».

Асиянең күз аллары караңгыланып китте. Җанында бетмәс-төкәнмәс гаҗизлек, әрнү иде. Тукта, ул яраланган, тәне түгел, җаны яраланган ялгыз болан баласы хәлендә түгелме соң? Кая барырга, ни эшләргә белмәгән, ачлы-туклы, җаны җәрәхәтле болан баласы! Әнисен, барыр юлын югалтып, урманда әле бер якка, әле икенче якка чабулап, кайсы тарафларга китсәм, мине, тешләрен ыржайтып, баласын Мишараб атып алган ана бүре сагалап тормасмы, дип гаҗизләнеп бәргәләнүче нәни, нәфис болан баласы хәлендә түгелме соң ул?

Саташулы йокыга чумып барган Асиянең колагына һаман Газиз сүзләре ишетелә икән:

– Мин сине эзләп, автовокзал тирәсен мең кат урадым. Елга вокзалы янындагы аланлыкта да эзләп карадым, шунда Митрофанга эт эчәгесе җыеп йөрмисеңме икән, дип уйладым, тик очрамадың. Адресыңны оныттым бит. Башта кирәге булмас кебек иде. Тик ихласлыгың белән күңелемә кереп урнашкансың, Асия! Үзем дә көтмәгәндә, уйламаганда, сине сагынып, күрәсем килә башлады.

Кыз төшләнә иде бугай. Үзе һаман Газиз белән сөйләште:

– Мин нәрсәгә инде сиңа, Газиз, ярар, хуш, – дип кереп китте. Аның тизрәк бу ыспай егет яныннан китәсе килде. Җир ярылса, җир тишекләренә кереп югалыр иде, имеш. Үзе дә инде нәрсәгә дип бу егеткә Митрофан турында, аның эт эчәгесе ашавы хакында сөйләп торган булды. Гадилегең – ике тиен, бер акча! Ниемә кирәк иде? Әнә бүген дә шул абыйларының кара кәҗәсе турында искә алып торган була. Әйдә, ярар, сөйләсен шунда. Асиянең аны башка күрәсе юк. Берәр Казан түрәсенең иркә баласыдыр әле. Аның тамагы тук, өсте бөтен, өс-башы юылган, ә төннәрен ятып йокларга чиста урын-җире бар.

Асия менә кичләрен, якты утлар янып торган тәрәзәләргә карап: «Нинди бәхетлеләр болар, эштән кайткач, бәрәңге өстенә майда кыздырган

суган, кишер салып ашасалар да, өстәлләрендә күпереп пешкән күмәч яки кара ипи генә булса да, аларның җылы, якты үз почмаклары бар. Адәм баласына тагын ни кирәк? – дип уйлый. – Их, подвалда гына булса да, кунып чыгарлык почмакка тиенсә иде! Юк бит, юк. Асия инде менә икенче ел бәргәләнеп яши. Фатир хуҗасы сәгать кичке унынчы яртыда ук, мырлый-мырлый, утны сүндереп куя. Ә Асиянең дәрес хәзерлисе бар, укыйсы килә аның. Шуңа күрә иртәнге сәгать биштә торып, җәяү генә уку йортына китә. Караңгыда аның сырмадан булуын да, аягындагы постау каталарын күрүче дә, аннан көлүче дә юк. Иртәнге саф һаваны сулап, уйларын үз иркенә җибәреп, рәхәтләнеп җәяү атлый. Ә каравылчы Гыйльметдин бабай, кеткелдәп көлеп, аны каршы ала. Сакал-мыекларын пөхтәләп кискән базык гәүдәле бу карт Асия күзенә Хозыр Ильяс булып күренә, чөнки ул кызның хәлен аңлый.

– Килдеңме, кызым? Әйдә, чәем кайнап чыкты. Хәзер карлыган кайнатмасы салып бирәм, – дип, калай кружкага хуш исле кайнар чәй агыза. – Мөслимә әбиеңә бүген йомырканы күбрәк пешерергә куштым.

Каравылчының кечкенә генә бүлмәсенә хуш исле мәтрүшкәле чәй исе тарала. Өстәлгә йомшак күмәч кисеп куя. Өндәме соң бу күмәч, төштәме?

– Әйдә аша әле, аша. Синең үсә торган чагың, – дип, йомыркаларны да Асия алдына этеп-этеп куя.

– Кирәкмәс иде, бабай, тамагым тук минем, – ди Асия, авызына мул булып төкерек җыелганын тоеп.

– Утыр, аша, кызым. Син бит биш чакрымлап җәяү киләсең, җәяү йөргәч, тамак ача ул.

Икәү утырып, рәхәтләнеп чәй эчәләр. Аннан соң Асия дәресләрен хәзерли, китап укый. Көн дә шулай. Кыз китапханәдәге барлык китапларны укып бетерде бугай инде. Язга таба русчасы да яхшыра төште.

Асия төшендә каравылчы бабай белән, имеш, чәй эчә. Фәния апасы, чыннан да, кызга чәй әзерләп куйган. Чәйгә карлыган яфрагы салган. Эчеп куйды. Аннары: «Ярый, – дип, уйларыннан арынды кыз. Төшләнгән бугай. – Булыр әле. Бабасы әйтмешли, Аллаһ тырышларны ярата. Тырышып укыса, аннан соң яхшы итеп эшләсә, аның да Сөмбеләнеке кебек матур киемнәре булыр. Институтка да керер, барысы да булыр...» – Уйланып ята-ята, ул тирән йокыга талды. Төшендә Газиз, киң итеп елмаеп, тигез ап-ак тешләрен балкытып, каядыр офыклар артына китеп югалды, тәмам юкка чыкты.

Йокылы-уяулы, саташулы бу төн аның хәтерендә үткәннән бүгенгегә, бүгеннән иртәгәгә бер сәяхәт кылгандай үтте.

Икенче атнаның якшәмбесендә Фәния апасы Асиягә ял бирде.

– Сеңлем, бик арыдың инде. Якшәмбе көнне синнән башка авыр булыр булуын, тик ял ит әле. Авырудан соң өзлегүең бар. Душка кереп, юынып ал да… – диде ул. Мастер бу чандыр кызны ничектер кызганып ярата иде.

Асия, куанып атлый-йөгерә, ашханәдән чыгып китте. Көн эссе иде – июль чилләсе. Юынып алгач, җиңел ак күлмәген, аягына чүәкләрен киеп, Зәңгәр күл буена төшеп китте. Күлнең суы зәп-зәңгәр, яр буендагы куакларда төрле кошлар чыркылдаша. Җанына ниндидер тынычлык иңде.

Кысып бәйләгән чәчүргечен чишеп, калын чәчләрен иңнәренә таратты. Нигәдер, җаны очынып, күңеле талпынып, каядыр ашкынып тора иде. Әле теге атнада гына дөньясына рәнҗеп, күз яшьләренә коенып йоклап киткән иде Асия. Чытлык Сөмбелә аны Вәкилдән, өзелепләр сөйгән, җаныннан да кадерлерәк булган сөйгәненнән аерып алды. Алай дисән, монда бер Сөмбелә генә гаеплемени соң? Әгәр Вәкил Асияне яраткан булса, ул шундый адымга барырга тиеш идеме? Кызның беренче мәхәббәтен аяк астына салып таптар идеме?! Асиягә бит Вәкилдән башка яшәү мөмкин түгел шикелле иде. Юк, яшәү генә түгел, сулыш та ала алмас кебек иде. Ул бит үсмер кыз бала, сагынып, сәгатен генә түгел, минутларын санап, Яңа ел кичен ашкынып көтте. Өр-яңа күлмәк тектереп, ул күлмәкне әллә ничә кат киеп карап, Вәкиле каршына килеп басасы минутларны саный-саный көтте! Бөтен җаны-тәне белән ашкынып, Яңа ел бураннарына уралып, мәхәббәтенә таба атлады. Һәм саф сөю, сәгадәт көткән кыз бала мәхәббәт бураннарына кереп адашты! Һәм хыянәт! Сабыр канатлары сынып, клубтан чыгып китте. Ул кичне Асиядән дә бәхетсезрәк кеше юк иде кебек. Аңа нибары уналты яшь тулырга тиеш иде. Нибары уналты яшь! Гомеренең иң матур, иң садә чагы!

Асиянең, Казанга килеп, ярты ел эчендә күргәннәре соң…

Әтисе юкка гына:

– Бар соң, китеп кара, сине бик көтеп торалар ди анда. Лаеш шулпасын гарык булганчы чөмерерсең! – димәгән икән. Асия ул вакытта бу сүзләрнең чын мәгънәсен аңламаган иде. Аңа калса, Казан каласы – ак кала, үзенең якты утлары белән балкып: «Асия, кил син Казанга, бәхетеңне шәһәрдә табарсың», – дип чакырып тора иде. Сөт ташый торган машинада Вәкил күренмәгәч тә, күңеле сизенде кызның. Вәкил авылда калып, бер ел эшләячәк, дигәнне ишеткәч тә, күңелендәге бер кыл зеңләп өзелгән икән ул чакта. Сизенүе хак булган. Вәкилен мәңгегә югалтуын сизенеп зеңләгән ул кыл.

Әле соңыннан да күпме күз яшьләре түкте Асия! Ул инде Вәкилне яраткан кебек беркемне дә шашып ярата алмаячак. Аңа барча ир-егетләр дә Вәкил кебек вәгъдәсез булып күренде. Уналты яшьлек кыз шундый бәхетсез иде. Мескен итеп сизде Асия үзен.

Ә менә Зәңгәр күл буенда, ничектер, күңеле күтәрелеп китте. Ничектер, монда аның күңелендәге бар нәрсә дә ачык зәңгәр төскә керде. Зәп-зәңгәр күк йөзе әйтерсең лә күл зәңгәрлеге белән тоташкан. Күл ярларындагы яшел каен ботакларына кунып сайраган кошлар да ачык зәңгәр су төсендә. Бер генә дә кара тап юк кебек. Әнә каеннарда кара таплар бар анысы. Тик алар каен кәүсәләренең аклыгын тагын да агартып күрсәтер өчен махсус буялган кебек. Әнә, каеннарның азрак кубып торган тузларында җил кубыз уйный. Асия кубыз тавышын да ишетә кебек. Әллә инде кубыз тавышында да зәңгәрлек, сафлык бар! Бу – Асиянең йөрәгенә Вәкил салган хыянәт ярасының җөйләнеп, сызлау, сулкылдауларының басыла башлавы, сихәтләнүе иде, ахры.

Зәңгәр күл шундый сай булып күренә, ә, баксаң, төпсез икән. Вәкил күзләре кебек, дип уйлап куйды Асия. Юк, Вәкилнең зәңгәр моң сирпелеп торган күз карашын онытмаган әле ул. Йөрәк яралары җөйләнә башлаган, ә беренче мәхәббәт, кызны күкләргә, зәңгәр күкләргә ашырасы мәхәббәт тиз генә онытыламыни?..

* * *

Бу хәтер дигәнең йөгәнсез тай кебек сикергәли. Океан киңлегенә карап хозурланасы урынга, Асияне хәтере ни дип әле үткән көннәренә, еракта калган авылына алып кайтты да Вәкилләр тормышы белән яшәтеп алды? Нигә кирәк ул булган-беткән хәлләрне искә төшереп, кадерле мизгелләрне сарыф итү? Асия, синең үзең өчен кадерле булган хатирәләрең азмыни? Берәм-берәм барла шуларны. Күңел күгеңне яңарт. Казанда чагыңда хәтер бөктәрләрен сүтеп, җилләтеп алырга бер вакытың да юк бит синең. Бәлки, арада шушы дәрья суларына агызырдайлары, күңелне үртәп, хәтта әрнетеп торганнары да бардыр.

Унбиш яшеңнән туган өең бусагасыннан шәһәргә таба чыгып киткән бала бит син. Әллә барысы да юкка гына булдымы?

Яңа тормыш башлар алдыннан күңелдәге рәнжеш-үпкәләрне юып төшерү мәслихәт булгандыр инде ул. Күңелдәге «генераль уборка»ны гомернең кайсы комрыгыннан башлыйсы икән? Нигә соң әле хәтер, үч иткәндәй, Асияне – бу тормышта ачысын-төчесен, бәхетен-уңышын, табышын-югалтуларын мулдан татыган олпат ханымны еракта ымсындырып, сагындырып торган яз башына кайтара?

Яз. Тып-тып итеп тамчы тама. Өй кыекларында рәт-рәт тезелгән боз сөңгеләренең очында эленеп торган бәллүр тамчылар, яз җиткәнгә куанып, боз сөңге очларында күз яшедәй эленеп торалар да кояш нурларында челтәрләнә башлаган ап-ак кар өстенә тамалар, анда нәни генә чокырчыклар хасил итеп, тыпырдашалар. Тып-тып, тып-тып… Асиянең йөрәгенә Вәкилнең хыянәте салган яраларны дәвалап тама ул тамчылар.

Менә тиздән кыз беренче курсны тәмамлар. Сырмасын салгач, нәрсә киеп йөрермен дигән хәсрәте дә юк. Чөнки бабасының энесе кызына язгы-көзге пәлтә сатып алды. Ул яңа пәлтәнең матурлыгы-ы-ы-ы! Асиянең күз алдына өрфиядәй алсу-ак ефәк күлмәкле Сөмбелә килеп басты. Һәм аның аягындагы биек үкчәле, өстенә зәңгәрсу перламутр брошкалар ябыштырылган туфлиләре…

Ул күлмәкләр һәм туфлиләр Асиянең төшләренә озак кереп йөдәтте. Инде менә апасына әтисе алып кайткан яңа пәлтә.

Асия кечке мәктәптән соң җәяүләп кенә янә абыйларына китте, чөнки икенче көн инде авызына бер валчык ризык капканы юк. Ә аларда һәрвакыт ашарга бар. Абыйсының хатыны Сәлимә апа ашарга шундый тәмле әзерли. Ул юк кына азык-төлектән дә телеңне йотарлык аш пешереп куя. Әллә ач тамакка шулай тоеламы икән? Белмәссең.

Шуның өстенә өйдәгеләр:

– Менә, Асия, иртәгә апаңның пәлтәсен таманлап кыскарткач, искесен сиңа бирәбез, – диде. Ике төймәле зәңгәрсу-кара пәлтә Асиянеке булачак.

Апасы буйга Асиядән күпкә кайтышрак. Булса соң! Асиянең аяклары шундый төз! Аны бит шундый мода дип кабул итәчәкләр. Аллаһ боерса, кыз Гыймран Рәхиме сырган сырмасыннан котылачак. Алдагы тормышы шундый әйбәт булачак! Алла боерса, Асия дә үз гомерендә беренче тапкыр пәлтә киячәк.

Ул өстенә сырмасын киеп, акрын гына елга вокзалына таба атлады. Аның да күңелендә язгы тамчылар биешә иде. Алла теләсә, иртәгә аның

пәлтәсе булачак! Түгәрәк якалы, өстендә күзләр кебек ике төймәле язгы-көзге пәлтә. Ә иртәгә бу сырма дигән хикмәтне авылга озатачак. Тагын аз гына көтәргә кирәк. Чүт кенә.

Уналты яшьлек хыялый кыз җитез адымнар белән «хрущёвка»ның өченче катына шундый тиз менеп җитте. Хыялдагы түгәрәк якалы, ике төймәле пәлтә. Ул хәзер уку йортына да кеше күрмәсен дип, яктырганчы, җәяү түгел, йокысы туйгач, трамвайга утырып барачак. Шундый әйбәт булачак. Дөнья гел караңгы төсләрдән генә торырга тиеш түгелдер бит инде. Болай да кыз гомере буе: «Алда матур көннәр булыр – коммунизмга җиткәч, бөтен кеше бертөсле көн күрер, алда совет халкын бары тик бәхет-шатлыклар гына көтә», – дип өметләнеп яшәде. Менә шундый татлы хыяллар белән кайтты Асия, яңа гына уналты яше тулган авыл кызы.

– Асия! Иртәгә укудан туры безгә кайт. Иртән апаңның язгы-көзге пәлтәсен киеп китәрсең, – диде Әхмәт абыйсы. – Ә бу сырмаңны авылда калдырып килерсең, әниеңә абзар-кура тирәсендә йөргәндә кирәге чыгар.

– Ә мин кыш көне нәрсә киярмен соң, Әхмәт абый? – дип сорыйсы итте Асия. – Әти-әнинең миңа кышкы пәлтә алырга акчасы булмаячак. Киләсе елга сеңлемнең дә калага киләсе бар. Абый да укый.

– Әйе, кызым, сез ишле шул. Әти-әниегез сугыштан соң ел саен бер бәби алып кайтты. Ярар, авырлык артыннан бер җиңеллек килә ул. Туганнарың ишле булгач, яшәве рәхәт бит ул. Тормышның төрле чагы була. Шатлыгыңны уртаклашырга, кайгыңны бүлешергә туганнарың булу зур бәхет инде ул.

– Әхмәт абый! Җәйгә мин пионер лагерена ашчы ярдәмчесе булып барам. Анда безгә стипендияне икеләтә түләячәкләр. Ике ай эшләсәм, җитмеш ике сум булачак. Шул акчага сеңлемә пәлтә алам. Минем шикелле хәерчелегенә хурланып яшәмәсен. Мин шундый арыдым, Әхмәт абый. Үзеңне кешедән ким санап, кимсенеп яшәү шундый авыр. Авылда вакытта без барыбыз да бертөсле идек. Шундый рәхәт иде авылда. Әти әйтте: «Кызым! Китәргә ашыкма. Унынчыны Янсуарда укып бетер», – диде. Ә мин тыңламадым. Казанга китәм, имеш. Әти-әниемә булышам. Булышырсың, бар! Монда ачлы-туклы яшәп, классташлардан калышмыйм дип, укудан соң кичке мәктәпкә чабып, рус телен белмичә, адәм хурларына калып яшәп яткан көн, Әхмәт абый. Соңыннан ни булыр, белмим. Яңадан авылга кайтып китәр идем. Кешедән оят. Әти-әни ни әйтер? Ю-у-у-ук. Кайтасым юк, Әхмәт абый. Укырга, эшләргә кирәк. Тырышырга, тырмашырга кирәк.

– Шулай, кызым. Әгәр кеше буласың килсә, бер башлаган эшеңне ташлама инде син. Русчасына да өйрәнерсең, Алла теләсә.

– Без бит трамвайда барганда кызлар белән татарча сөйләшә алмыйбыз, абый. Татарча сөйләшә башласаң, шунда ук: «Вы, чаплашки, заткнитесь», – дип авызны томалыйлар. Безнең тел нигә русларга ошамый? Мин бит татар шагыйрьләрен, язучыларын шундый яратам! Тукайның күпме шигырьләрен яттан беләм. Сөйләшергә дә ярамагач, ник безгә татар телен укыттылар? Татар теле – бөек тел, дип өйрәттеләр. Мин шәһәргә килгәч, күп нәрсәне аңлый алмыйм, Әхмәт абый. Никтер минем тормышым икегә бүленде. Авыл тормышы – әти-әнием янында, аларның безне

өзелеп яратуларын тоеп яшәү. Әйе, безгә әле кавырсыннары да катмаган балаларга уфалла тартып, мал-туарга курмы җыеп, хуҗалар йокыдан уянганчы, эскерт төбеннән салам йолкып алып кайтулар, тормыш арбасын сөйрәп яшәүләр бүгенге көнемә караганда рәхәтрәк кебек тоела миңа. Ул вакытта җан тыныч иде. Бәрәңге белән ипигә тамак тук иде. Ә Казанда фатир хуҗасы, сәгать унынчы ярты булуга, утны сүндереп куя. Ничек дәрес әзерләргә, анда беркемнең дә эше юк. Балачакта ымсындырып торган кала тормышы шундый да катлаулы икән ул, Әхмәт абый.

– Шулай, Асия кызым, еллар үтәр, синең урамга да бер бәйрәм килер әле. Авырлыклар үтмәс кебек кенә тоела. Яшь чактагы нужалар уйнап-көлеп узалар, кызым. Менә Әхмәт абый әйткән иде, диярсең. Укырсың, зур уңышларга ирешерсең. Сабыр ит. Сабыр төбе – сары алтын, диләр, – дип, сүзен тәмамлаган иде абыйсы ул кичне.

Җиңгәсе тәмле итеп аш пешереп куйган. Тамагын туйдырып алгач, күңеле күтәрелеп китте Асиянең. Әнә ишектә кыңгырау тавышы яңгырады. Апасы яңа пәлтәсенең итәген кыскартып кайткан. Аягына үкчәле итекләр, өстенә яңа пәлтә кигән апасы шундый матур. Озын чәчләрен ике толым итеп үреп, толымнарын баш түбәсенә килештереп җыеп куйган. Сөбханалла гына, диясе инде. Сөбханалла гына. Керфекләре озын, кашлары сызылып киткән.

Әхмәт абыйсы кызының иске пәлтәсен Асиянең иңнәренә салды:

– Мә, кызым, җылы тәнеңдә тузсын. Рәхәтләнеп киеп йөр. Иптәшләрең алдында сырма киеп, уңайсызланып йөрмә! Сиңа бераз кыскарак инде кыскасын, ярар, итәгеңне озынракны киярсең.

Асия инде күкнең җиденче катында иде:

– Рәхмәт, Әхмәт абый! Рәхмәт, апам! Мин сезнең бу яхшылыгыгызны мәңге онытмам. Килер бер вакыт, меңе белән түләрмен. Валлаhи, дип әйтәм, мең тапкыр артык итеп кайтарырмын!

Ул төнне Асиянең күзенә йокы төшмәде. Кичтән сырмасын төреп, бау белән бәйләп, иске яулыкка төреп, караңгы бүлмәгә кертеп куйды.

– Әхмәт абый! Бүген шунда торып торсын. Шимбә көнне авылга алып кайтып китәрмен, ярыймы?

– Ярар, кызым! – диде Әхмәт абыйсы, елмаеп.

Менә шулай котылды Асия авылдан киеп килгән сырмадан. Иртән аннан-моннан гына капкалап алды да, ике төймәле, түгәрәк якалы зәңгәрсу-кара пәлтәне киеп укырга китте. Аңынчы аяклы көзге каршына басып, пәлтәнең матурлыгына сокланды. Тасма белән җыеп куйган чәчләрен иңнәренә таратты. Чәчләре калын аның. Аннары апасының иннеген алып, иреннәренә сөртеп куйды. Үз кыяфәтеннән үзе канәгать булып укырга китте Асия. Ул шундый бәхетле иде. Иртәнге яз кояшы бүген башка көннәргә караганда мең тапкыр шәфкатьлерәк, яктырак иде. Йөрәге нидер көтеп, ашкынып торган уналты яшьлек авыл кызының бәхетенә язгы кояш та сөенә иде кебек. Хуш, кешедән калган кием булсын. Андамыни хикмәт, Асия бүген өстенә беренче тапкыр язгы-көзге пәлтә киде. Әйтерсең, бәхет үзе кызның иңнәренә килеп кунды. Их, киек казлар кебек бер талпынып ал идең дә, кулларыңны канат итеп, күккә күтәрел идең. Зәңгәр күкләрне иңләп, әй, очар иде Асия. Яшьлекнең үзен канат

итеп кагына-кагына очар иде. Язын туган илләрен, тугай-күлләрен сагынып кайткан кыр казлары, аккошлар кебек очар иде. Хәтта трамвайда баручылар да кызның пәлтәсенә карап соклана иде кебек. Бүген ул горур иде, шат иде. Яшь иде, матур иде. Ул үзенең бәхетенә бер адым атлады. Ул бүген Казан каласында аңардан башка бер кеше дә киеп йөрмәгән сырмасыннан котылды.

Ләкин Асиягә түгәрәк якалы, ике төймәле зәңгәрсу-кара язгы-көзге пәлтәне киеп йөрү бәхете ике генә көнгә тәтеде. Җомга көнне ул янәдән Әхмәт абыйларына килеп кунасы итте. Автовокзалга да якын. Аннан соң, теге гөнаһ шомлыгы сырманы да авылга алып кайтырга кирәк. Кеше өендә урын алып тормасын.

Бармаган булсачы! Иртән торып, авылга алып кайтасы әйберләрен җыйнап, ишек катына килсә…

Җиңгәсе Асиягә күпме шатлык-куаныч, бәхет китергән ике төймәле, түгәрәк якалы пәлтә урынына яулыкка төйнәп җыеп куелган теге сырманы элеп куйган иде. Чөйдәге ул сырма, кыздан көлгән кебек, кукраеп эленеп тора. Әйтерсең: «Юк инде, Асия, миннән тиз генә котыла алмассың, хәерчелек, гаделсезлек әле сине гомерләреӊ буена эзәрлекләп барачак», – дип мыскыллап көлә иде. Асиянең күз яшьләре яңакларын пешереп акты да акты. Ник кызны өметләндереп, ул пәлтәне биреп тордылар, ичмасам? Ник җиңгәсе пәлтәне үз туганнарына бирәсе килгәч, алдан ук ире белән сөйләшмәгән? Асия дә кеше бит. Аның да бернинди кер тимәгән җаны бар. Ник шундый рәхимсез бу кешеләр? Иңнәрендәге сырма шундый авырайган. Ул тагын да шыксызрак иде, чөнки ул – уналты яшьлек кызның өмет канатларын сындырган, күкләргә ашкан бәхет кошын үтергән өс киеме иде. Әле бер атна элек кенә Асия әнисенә хат язып салды: «Әни җаным! Син бер дә кайгырма. Миңа Әхмәт абый кичә кызының язгы-көзге пәлтәсен бирде. Әни, син белсәң иде, ул шундый матур! Искиткеч! Түгәрәк якалы, ике төймәле зәңгәрсу-кара төстә. Ә төймәләре күзләр кебек, чыннан да, нәкъ күзләр инде. Менә иртәгә кайткач, үзең күрерсең. Мине танымассың да әле, әни! Шаккатырсың! Группадагы Оркыя да: «Асия! Сиңа шундый килешә бу пәлтә», – диде. Ә теге сырманы сиңа алып кайтам. Мал-туар караганда киярсең. Син, әни, кызым яз көне нәрсә кияр инде, дип бер дә кайгырма! Минем хәзер язгы-көзге пәлтәм бар!»

Ә бүген Асия өчен кояш сүнде. Җаны каралды кызның. Әйтерсең Җир йөзен караңгылык басты. Аның йөрәгеннән үксүгә охшаган бер өн актарылып чыкты.

Казанга килгәннән бирле нәрсә генә күрде соң ул? Төркемдәге кызыл эшләпә, кызыл пәлтә кигән кызларның Асиядән, аның кием-салымыннан, рус телен белмәвеннән мыскыллап көлүләренме? Яисә фатир хуҗасының унынчы ярты булуга: «Электрга күп түлисе бар», – дип, утны сүндереп куюынмы? Ике көн ашап, ике көн ач торунымы? «Чаплашка» дип мыскыллауларынмы? Болар барысы да кыз күңелендә кара кан булып укмашты да җанын әрнетеп, йөрәген яндырып тора. Менә инде тагын бу пәлтә вакыйгасы!

Килер бер көн, Асиянең җиде-сигез затлы туны шкафта эленеп торыр. Ләкин теге ике төймәле, түгәрәк якалы, ике генә көн киеп калган язгы-

көзге пәлтә күңеленә мәңгелеккә кереп калыр. Сөмбеләнең ефәк күлмәге, биек үкчәле ак туфлиләре кебек. Асиянең беренче мәхәббәтен урлаган Сөмбеләнең үзе кебек. Пионер лагеренда гармунчы булып эшләгән Вәкилнең үзе кебек! Иңнәренә эленгән көянтә белән иртәнге савым сөте тулы мөлдерәмә чиләкләрне күтәреп, җитмеш җиде баскычны менгәнен тау башында көтеп торган, баласын җуйган ана бүре кебек!

Ике атнадан соң авылга кайтканда, автобуста ул пәлтәне янә очратты Асия. Җиңгәсе туганының кызы өстендә иде ул. Ә түгәрәк яка астындагы ике төймә, бүренеке кебек, күзләрен кыса төшеп, Асиягә мыскыллап карап тора иде. Аңа шулай тоелды. Асиянең күзләренә тагын яшь тулды. Тик базык гәүдәле кызга килешми иде бу пәлтә. Кеше өстеннән салдырып алган кием кебек, гәүдәсенә ятышсыз тора иде.

Әле ул баласын эзләп чыккан ана бүренең карашы кызны озак эзәрлекләячәк! Асия мең тапкыр үксеп елаячак, ләкин елаганын кешегә сиздермәячәк! Яшь аралаш елмаеп көләчәк, шаярачак. Ә кешеләр аны шундый бәхетле дип уйлаячак.

Әнисе язгы-көзге пәлтәдән кайтыр дип көткән кызының сырмадан икәнен күреп:

– Алай... – дип куйды. Асиядән берни сорамады. Кыз да бер сүз дә әйтмәде. Аңа әнисенең күзенә туры карау шундый авыр иде. Әллә ничек кенә шунда ялганлаган кебек килеп чыкты. Ул бит әнисен сөендермәкче иде. Кызының өстенә яңа кием алып бирә алмавына ничек кайгырганын белә бит ул аның. Әнисенең йөрәге парә-парә өзгәләнә. Ләкин балаларына булыша алмый. Әнә, сәбәп табып, ишегалдына ук чыгып китте. Асия тәрәзәдән үрелеп караса, әнисе ике кулы белән йөзен каплаган да, бөгелеп төшеп елый иде. Асиянең үзенең дә күзенә яшь килде. Ләкин… Еламаска! Нык булырга! Әнисенең йөрәген яралап, елап утырыргамы монда?! Әнисе, елмаеп, өйгә килеп керде дә:

– Әйдә, кызым, син кайтуга ит бәлеше салган идем. Хәзер әтиең дә кайтыр, эне-сеңелләрең дә озак тормас. Барыбыз да җыелгач, бәлеш ашарбыз. Озак торса, бәлеш төчеләнә башлый ул, – диде. – Абыең белән син булмагач, күңелнең бер кырые китек кебек. Исән генә булыгыз, балакайларым.

Асия әнисен кочып алды:

– Әй, әни, син бер дә кайгырма! Менә тиздән җәй җитәр, ә җәй көне пәлтә нәрсәгә соң ул? Ә эшли башласаммы, әни! Мин үземә дә, сиңа да шундый матур пәлтә сатып алачакмын. Кешедән калганны түгел, яңаны. Аның төймәләре шундый матур булачак.

– Әй, кызым! Бигрәк хыялый инде син. Алырсың, ди, тиз генә. Исән-сау гына йөрегез. Сездәге тырышлык белән авырлыклар бик тиз онытылыр. Булыр, булыр, кызым, исән генә була күр. Исән-сау булсаң, барысы да килер. Максатыңа ирешерсең. Инде быел көзгә сеңлең дә шәһәргә чыгып китәргә тора.

– Әни, мин җәй көне пионер лагерена практикага барам. Анда икеләтә стипендия түләячәкләр. Ике ай эшләсәм, сеңлемә пәлтә алырга җитәчәк. Чын, әни, сеңлем нәрсә киеп йөрер, дип бер дә кайгырма, мин аңа үзем пәлтә алып бирермен.

...Бу пәлтә вакыйгасы тәмам күңелне кузгатты. Мин фәкать матур хатирәләремне генә алып чыккан идем сәяхәткә. Әй, кодрәтле дулкыннар! Газиз белән очрашу хакында сөйлимме сезгә? Сез ул хакта Җир шарын төреп уйнаган вак дулкыннарга да сөйләрсез. Вак дулкыннар сезнең яшьлектер бит инде ул? Яшьлекне һәр тере җан кичерә. Яшьлек ул татлы да, газаплы да. Яшьлек беркайда да озакка тукталып тормый. Уза да китә. Йөгерек дулкыннар, сез бит инде ул яшьлекнең өлгесе. Уйнак, җитез, йөгерек, ашкынучан дулкыннар. Олпатлангач, сез дә куәтләнеп, гайрәтләнеп, кайвакыт дуамалланып аласыз. Кешеләр кебек.

* * *

– Менә син кайда икән! Мин бит инде барлык күл буйларын әйләнеп чыктым, Асия. Мастерыгыздан сораган идем: «Ул бүген ял итә», – диде. Казанга кайтып киткәнсең дип курыккан идем, ярый әле, монда икәнсең.

Асия матур уйларыннан арынып, борылып карaса – Газиз! Кулында – тук башакларын җиргә табан игән бодай-арыш арасында тургай моңнарында тибрәлеп үскән зәңгәр чәчәкләр бәйләме. Күкчәчәкләр!

– Асия, бу чәчәкләрне сине эзләп йөргән арада җыйдым. Кара, нинди матурлар! Ә син үзең дә шул чәчәкләрдән такыя таҗ үреп кигәнсең икән! Син бүген шундый матур, Асия!

– Исәнме, Газиз! – диде кыз, йөзенә шаулап кан йөгергәнен тоеп. – Исән генә йөрисеңме?

– Ярыйсы болай. Менә бүген ял көне дип, янә сеңлем янына килдем. Исәнләшергә дә онытып торам тагын. Сине күргәч, зиһенем таралып китте.

Асия, зәңгәр чәчәкләр гөлләмәсен Газиз кулыннан алып:

– Нинди матурлар! Рәхмәт сиңа. Беренче мәртәбә миңа чәчәк бирәләр. Без балачакта бу чәчәкләрне… – диде дә туктап калды.

Зәңгәр күкчәчәкләрне малга ризык итеп, чәчәк таҗларын көлтә кебек җыеп, иңбашларына салып кайткан чакларын исенә төшереп елмаеп куйды Асия. Ярый әле вакытында тукталып калды. Митрофанга эт эчәгесе җыеп кайткан чакларын сөйләп, адәм хурына калган иде бит инде.

– Без балачакта кырдан күкчәчәкләр җыеп кайтып, банкага утыртып куя идек. Алар шиңмичә шундый озак тора, – дип дәвам итте Асия. – Болын, кыр чәчәкләрен күбрәк яратам шул. Алар шундый гадиләр, табигатьнең үзе кебек!

– Син дә минем күңелемә гадилегең белән кереп калдың, Асия. Никтер гел сине күрәсем килеп тора. Кайчан якшәмбе җитәр икән дип көтеп, арып беттем. Әни әйтә:

– Ләйлә янына бүген үзем барам, кызымны бик сагындым, – ди.

– Юк, әни, үзем әйләнеп кайтыйм әле. Никтер сахрага чыгасым килә, табигать үзенә чакыра сыман, – дигәч:

– Ярый алайса, улым, мин өй эшләрен эшләрмен, – дип, өйдә калды.

Асия дәшмәде. Аның сүз әйтерлек хәле юк иде.

Ул чәчәкләрне күкрәгенә кысып, Газизне тыңлады. Әллә йөрәгенә Вәкил салган яраның акрынлап-акрынлап җөйләнә башлавы идеме бу? Егет аның күңеленә отыры ныграк керә бара түгелме?! Тукта-тукта, әллә Вәкил белән

Газиз икесе бер кешегә әйләнә барамы?! Бүгенге саф зәңгәрлек, күлнең зәңгәрлеге, күкләр зәңгәрлеге белән тоташып, аның балачагыннан бирле күргән авыр, ләкин бәхетле тормышын бизәргә җыена түгелме? Ул бит бүген иртәдән үк, кемнедер көткән кебек, чәчләрен дулкын-дулкын итеп иңнәренә таратты. Коңгырт чәчләре акка кара борчаклар сибелгән кыска итәкле, ачык якалы күлмәк кигән кызның иңнәренә агып төште. Кыз озын кара керфекләрен тушь белән буяп, иреннәренә беленер-беленмәс кенә итеп иннек сөртеп җибәргәч, көзгә каршына басып, үз кыяфәтен күздән кичерде һәм бик канәгать калды.

Менә шушы кыяфәтендә күрсен иде аны Газиз! Алайса ул аны йә төнлектән чыккан җен кебек, йә тузанга, тиргә баткан, брезент чүәкләре тапталып беткән хәлендә күрә. Бодай басуы яныннан узышлый кыз башына күкчәчәкләрдән такыя таҗ да үреп кигән иде. Инде менә Газиз каршында битләренә таң алсулыгы кунган кебек оялып басып тора!

– Кара әле, Асия, ник бер сүз дә дәшмисең син?

– Сез сөйлисез бит. Сезне тыңлыйм.

– Асия, кайсы яклардан соң син? Казан тирәсендәге берәр авылдандыр инде, әйеме? Аш пешерүче булырга укып йөрисеңме? Үзең шуны сайладыңмы, өйдәгеләр куштымы?

– Сайлап түгел инде. Тугызынчы сыйныфка, пропискаң юк, дип укырга алмадылар. Кире авылга кайтасым килмәде, дөресен әйткәндә, оялдым. Узып барышлый игълан күрдем дә, тамагым тук булыр, дип кердем инде шунда укырга. Без өйдә биш бала, әти авырый, әни дөньяны берүзе тарта – мәктәптә эшли. Йөрәге авыру. Әти-әниемә бик авыр. Әле мин кичке мәктәптә дә укыйм. Яшьтәшләремнән калышасым килми. Институтка керәсем килә минем, Газиз. Алла теләсә, кичке мәктәпне тәмамлагач, барыбер югары белем алачакмын! Әйтте диярсең менә! Мөгаен, әнием кебек, мин дә укытучы булырмын.

Газиз елмаеп куйды:

– Мин сиңа ышанам, Асия! Яшь чактагы нужалар җырлый-җырлый уза алар.

– Карале, Газиз, сез бит шәһәрнеке, ә татарча шундый матур сөйләшәсез.

– Мин үзем рус мәктәбендә укыдым. Өйдә әти-әниләрем русча сөйләштерми. Гел татарча аралашабыз. Актаныш ягыннан минем әниләр. Җәй буе каникулда авылда тордым. Бабаем шундый матур итеп тальянда уйный иде, инде вафатына биш ел булды. Мин әби-бабамны бик сагынам. Алар юк инде, хәзер бик еш кайтып йөри алмыйм. Әнинең энесенең хатыны – җиңги әллә нинди генә, төп нигезгә туганнар кайтып йөргәнне бик яратып бетерми. Йөзе карала. Ихласлыгы юк. Авыл җирендә эш тә күп бит, бәлки арый торгандыр. Балалары да ишле. Бабайларга ихата башыннан чөгендер кишәрлеге бүлеп бирәләр иде. Ул түтәлләрнең озынлыгы-ы-ы. Без чөгендер чүбе утый, көз житкәндә, кара чутырга әйләнеп бетә идек. Ә клубта шундый матур кичәләр була иде. Клуб бакчасында җырлы-биюләр… Кызлар белән урам әйләнүләр. Таң атканда гына өйгә кайта идек.

– Ул кызлар хәзер кайда соң, Газиз? Авылда калдымы? – дип сорады Асия.

– Әй, балачак мавыгуы инде алар. Унбиш-уналты яшьлек егет-малай…

Газиз икенче атнада да килде.

– Көчкә якшәмбене көтеп җиткердем. Син кайчан Казанга кайтасың, Асия? Бергә-бергә киногa, театрга барыр идек.

– Безнең төркем бу атна азагында кайтып китә. Мин тагын бер айга калам әле, чөнки безгә әйбәт кенә түлиләр – ике стипендия. Быел көзгә сеңлем киләсе бар. Авылда әниләр яңа йорт җиткерә. Сеңлемә кием-салым алырга акча кирәк.

– Ял итмичә каласың икән, Асия.

– Тырышырга кирәк, Газиз. Безнең бабай әйтә: «Тырыш кешегә Аллаһ үзе булыша», – ди.

– Асия, әйдә күл буйларын әйләнеп килик әле. Көне бигрәк матур.

– Газиз, миңа бүген бөтен дөнья саф, зәңгәрсу булып күренә: күк йөзе, зәп-зәңгәр күл, син миңа бүләк иткән чәчәкләр гөлләмәсе, хәтта синең күлмәгең дә зәңгәрсу.

Синең күзләрең дә зәңгәр күк төсендә, димәкче иде Асия, туктап калды. Оялды. Чынлап, Газизнең дөньяга гаҗәпләнеп, сокланып карый торган, куе керфекләр белән уратып алынган күзләре дә зәңгәр күк йөзе, күкчәчәкләр кебек зәп-зәңгәр иде.

Зәңгәр күлләр буенда озак җитәкләшеп йөрде алар. Монда әллә ничә күл бар икән. Асия бу күлләрнең күбрәк булуын теләде. Аның егеттән аерыласы килми иде. Аңа шундый рәхәт, шундый рәхәт иде инде менә. Әйтерсең җанына, дулкын-дулкын булып, Вәкил салган яраларны җөйләндереп, ниндидер бер шифа иңде. Башта Газиздән оялыбрак торса да, соңыннан күңелендәге хисләрен дәрьялар итеп агызды Асия. Үзен җәллләтәсе килгәннән түгел, күңелендәге хисләрен кемгәдер сөйләп, бушанасы килгән иде. Ел буе күңеленә юшкын булып утырган, җанын талкыган авыр хисләрдән котыласы килә иде аның. Үзен тыңларлык кеше булуына сөенде. Алда ни булачагы, бу егет белән мөнәсәбәтләре ни белән бетәчәге аны кызыксындырмады. Ул Вәкил хыянәтеннән соң бүген беренче мәртәбә бәхетле иде!

**Алтынчы бүлек**

Тын океан! Җир шарының ярларын төрле тарафлардан юасың син. Син бит иң зур океан. Киң холыклы океан. Иң тирән океан да син. Синдә утраулар да, су катламы яшергән мәкерле, һәлакәткә китерә торган тау сыртлары да бихисап. Синең Океания дигән «дәүләтеңдәге» утрауларга урнашкан курортларга кәеф-сафа корырга калын кесәле кешеләр йөри. Гаярь сәяхәтчеләр дәһшәтле дулкыннарың кочагында хәбәрсез югала. Син, гомумән, кешеләр яшәгән хәят кебек көтелмәгән хәлләр дөньясы. Син күк йөзе, галәм кебек үк серле, мавыктыргыч. Синдә һәлакәт тә, бәрәкәт тә бар.

Асия ханым мәгърур океан белән сөйләшеп тора иде. Шунда ул мәктәп лагеренда эшләгәндә, ундүрт яшьлек үсмер чагында ишеткән бер җырны әкрен генә көйләп җибәрде. Лагерь ябыласы кичне пионер учагы янында «Артек»та булып кайткан пионервожатый җырлаган иде. Вәкил исә гармунда көен уйнап торды. Ул җыр Салих Сәйдәшевнеке

булып чыкты. Искиткеч гүзәл җыр. Мәңге онытылмый, хәтердә кала торган җыр.

*Әдрән диңгез, гүзәл диңгез,*
*Ай, гүзәл диңгез.*
*Күп яуларны күргән диңгез,*
*Күргән ул диңгез.*
*Яу батыры Искәндәргә*
*Җан дәвасы биргән диңгез…*

Асия кинәт җырында абынып калды. «Дәва», «шифа» дигән сүзләр аны сискәндерә иде. Бу сүзләр һәрвакыт «газап» дигән кәлимәне исенә төшерә. «…шифа бирсен изге диңгез, изге ул диңгез!»

Бу юлы да хәтер лабиринтлары Асия ханымны «шифа» белән «газап» тоташкан көннәренә алып кереп китте.

Асиягә унҗиде яшь иде. Инде укулар тәмамланып, кулында ашчы дигән һөнәре булуын дәлилләгән таныклыгы һәм өлгергәнлек аттестаты бар. Теләгәненә иреште кыз. Иптәшләре мәктәпне тәмамлаган елны аның да кулында өлгергәнлек аттестаты булды. Кичке мәктәпне бишле билгеләренә генә укып тәмамлый алды.

Аны Алафузовлар җитен комбинаты ашханәсенә билгеләделәр. Аена ике тапкыр хезмәт хакы ала – җитмеш сум! Асиянең башы күккә тиде. Тулай торакта яши. Икешәр смена эшли. Ашханә мөдире Салих абый – җор күңелле, өлкән яшьтәге татар агае. Татар әдәбиятын яхшы белә. Вакыты булганда, Асия белән укыган китаплары турында гәпләшергә ярата.

– Әйдә, Асия сеңлем, синең белән стенгазета чыгарабыз, – диде бервакыт агай.

– Ярар, Салих абый, мин мәктәптә укыганда дружина газетасын чыгара идем.

Ай саен ашханә диварына яңа газета әзерләп элә башлады Асия.

Әминә апасы пәрәмәч пешереп тора. Камыры шундый уңа. Ләкин пәрәмәчләре озак кабарып тора да, бер-берсенә ябышып, кайнар майга салгач, бер-берсенә ялганып, бауда эленеп торган сыман була.

– Салих абый, әйдә «Әминә пәрәмәче» дигән шигырь язып эләбез.

– Ә син шигырь яза беләсеңме соң?

– Язам инде, әгәр язганнарымны шигырь дип булса.

Икенче көнне килсә, газета эленеп торган дивар янына эшчеләр җыелышып, сыгыла-сыгыла көлешә иде.

Газетага дарга асылган пәрәмәч сурәте төшерелгән:

*Сәгатенә мең әйләнә*
*Машина тәгәрмәче.*
*Хурлыгыннан асылынган*
*Әминә пәрәмәче.*

Әминә апасының пәрәмәчләре соңыннан гел матур, Салих абыйлары әйтмешли, законный, кайнар майда елмаеп пешә торган булды.

– Күрдеңме, Асия, мин бит Әминәгә мең әйттем. «Әминә, ник шулай ябышканчы кабартасың ул пәрәмәчләреңне, вакытында кызган майга

салып, уртасында ак сызык калырлык итеп кыздырмыйсың?» – дия идем. Шәп булды бу. Хәзер барысы да алдын-артын уйлап эшли.

– Тик миңа үпкәләмәсәләр ярар иде, Салих абый.

– Ярар, үпкәләмәсләр. Матур гына эшләсеннәр. Хилафлык кылмасыннар.

Ярты ел шундый матур эшләде ул Салих абыйсы белән. Лагерьда Гөлсем апасы янында аш пешерүче хезмәтенең барлык нечкәлекләренә өйрәнгән иде Асия. Үзе бер мәктәп булган икән ул. Монда да кыз яшелчәләрне телеп, чәчәкләр ясарга өйрәнде. Аны төрле ярышларга, башка шәһәрләргә йөртә башладылар.

Ярты ел узгач, кызны ашханә директоры чакыртты. Озын буйлы, чалара башлаган чәчле чибәр рус кешесе иде ул.

– Кер-кер, Асия! Миңа Салих Саматович Сезнең турыда гел әйбәт сүзләр генә ирештерде. Без сине төп ашханәгә бригадир итеп күчерергә булдык.

– Юк, юк. Мин бик аз эшлим бит әле.

– Бәхәсләшмик. Вам нужен карьерный рост.

Асия туку цехының ашханәсендә Люба исемле кыз белән бригадир булып эшли башлады. Их, күчмәгән генә булсачы. Салих абыйсы белән генә эшләп калган булсачы. Бригадир булып ике генә ай эшләп кала алды ул.

Газ плитәсе шундый зур, бер бүлмә кадәр булыр. Аның бер ягында иллешәр литр сыешлы казаннарда аш пешерәләр. Көн саен унбишәр казан. Плитәнең икенче ягында Люба исемле чуваш кызы, бригадир. Ул Асия белән татарча сөйләшә. Тик аңа пөхтәлек җитми. Асия аптырый инде. Дөге пешерә башласа, ярманы юып тормый. «Кайнаганда юыла ул», – ди.

– Люба, ник алай эшлисең, өеңдә юып пешерәсеңдер бит?

– Өйдә бит ул. Аны минем ирем, балаларым ашый.

– Ә житен комбинатында хайваннар ашамыйдыр бит? Әгәр юып пешерсәң, дөгең ап-ак, тәмле, ләззәтле була, ә синең ярмаң соры төстә.

– Бәйләнмә әле, Асия, үз эшеңне бел. Күкәй тавыкны өйрәтми.

– Алай ярамый, Люба, Аллаһтан курык.

– Синең үз Аллаң, минем үземнеке.

– Юк, Люба, Алла бер ул, динебез генә башка.

– Ася-Асия, әйдә болай сөйләшәбез. Син минем эшемә кысылмыйсың, мин синең ашларыңа тыгылмыйм.

– Ә минемчә, безгә синең белән бер-беребезгә булышып эшләргә кирәк, Люба. Мин үзем белгәннәрне сиңа өйрәтәм, ә син тәҗрибәлерәк, шуңа күрә син дә минем ялгышларымны төзәт.

– Кара әле, ник бәйләнәсең син миңа? Кайдан гына килеп чыктың син, белекле кыз, Ася-Асия?

– Люба, син ник миңа ике исем белән дәшәсең, мин бит сиңа Люба-Ләбибә димим.

– Миңа Ася күбрәк ошый.

– Тургеневның «Ася»сымы?

– Ниткән Тургеневның Асясы? – Люба андый әсәрне белми иде.

– Миңа әти-әнием Асия дип исем кушкан. Минем исемемне бозма инде

син, Любовь Михайловна. Миңа исем кушкан мәҗлестә мулла минем колагыма: «Синең исемең Асия булыр, Аллаһ менә тагын бер мөселман өммәте артты дип сөенер», – дигән.

– Кит булмаганны, син тугач та ишетә, сөйләшә башладың шту ли?

– Мин ишетмәсәм, Аллаһ ишетә.

– Әллә нинди син, Ася-Асия. Ниндидер сәер. Каян гына килеп чыктың соң син? – Люба сүзен татарча башлый да русчага күчеп тәмамлап куя: – На мою голову.

Ә беркөнне Асия ашамлыклар ала торган бүлмәгә керсә, Люба белән Ирина исемле кыз он алып чыгып килә иде. Он өстендәге үлгән тараканнарны күреп исе китте Асиянең. Кичә генә таракан агулаганнар иде. Ул хәшәрәтләр бөтен ашханәне баса. Агулап тормасаң, билләһи, үзеңне дә тотып ашарлар.  Асия токмач алып, бүлмәдән чыкса, Ирина он иләп тора, ә иләгендә – аякларын тырпайтып катып калган тараканнар.

– Ни эшлисең, Ирина, нәрсә кылануың?

– Люба кушты.

Асия Люба янына килде:

– Люба, сез нишлисез? Кешеләргә шуны ашатмакчы буласызмы әллә? Ничек Аллаһтан да курыкмыйсыз соң сез? Алай ярамый бит.

– Миңа Рәхимә кушты, ул монда – мөдир.

– Әгәр ул сиңа кеше үтерергә кушса, анысын да эшләр идеңме?

– Анысы башка мәсьәлә.

– Бу да – җинаять. Ташлагыз бу онны!

– Ася-Асия! Болай кылансаң, сине эштән куачаклар.

– Ни өчен?

– Кирәкмәгән җиргә тыгылган өчен!

– Кешегә агулы тараканнар ашатабызмыни хәзер?

Люба дәшмәде. Асиянең күз алдыннан агуланган җирән тараканнар китмәде. Көнозын күңелен болгатып тордылар. Шул көннән башлап, Асия Люба пешергән ризыкларны ашамас булды. Җирәнде.

Ничек инде шундый эшкә бармак кирәк? Ике ел уку дәверендә Асия бу һөнәрне яратып өлгергән иде бит. Үзе теләгәнчә, тиешле азык- төлекне салып, тәмле-тәмле ризыклар пешерермен, дип хыялланган иде.

Ә монда, ит урынына дуңгыз мае, ите кая китә икән соң, дип аптырый кыз. Шундый авыр эштә эшләгән тукучыларга ап-ак тирес кортлары кебек дуңгыз мае йөзеп йөргән аш бүлеп биргәндә, Асиянең йөрәгеннән каннар тама иде. Бабасы: «Кызым, дуңгыз ите ашый күрмәгез. Дуңгыз итен ашарыңа бернәрсә дә булмаганда, ач үлем янаганда гына ашарга ярый. Аллаһ тыелганнардан тыелырга куша. Аң булыгыз», – дия торган иде.

Ә монда мөселманнарга дуңгыз ашатып ят инде! Юк бит, юк! Кая гына китә икән соң ул сыер, сарык итләре? Авылларында ферма көтүе кайтканда, көтүнең очы-кыры күренми бит. Аннан соң бозаулары, сарыклары. Тавык фермасында күпме тавык, күркә! Ә Алафузов фабрикасында очсыз-кырыйсыз мыркылдыклар. Ярый, ите ит инде. Ә күпме дуңгыз башы килә. Аларын өстәлгә тезеп-тезеп куялар да, ул гөнаһ шомлыгы башлар, керфексез күзләрен текәп, Асиядән көлгән кебек астыртын карап тора: «Әһә, кызый, үзең теләгәнчә эшләмәкче идеңме? Юк шул инде. Тормыш

шундый нәрсә ул. Әле синең безнең туганнарга – дуңгызларга җизни дип әйтер көннәрең күп булыр. Син дөреслек эзләп, күп йөрерсең. Ә язмыш сине кыйнар да кыйнар».

Әле шуның өстенә, ашханә директоры өстәл өстенә тезеп куелган дуңгыз башларының танавын кисеп ала да юмаган килеш кетер-кетер итеп кимереп йөри. Шундый ярата ул дуңгыз танавын. Әле кайчагында колакларын да ашый.

– Асия, миңа дуңгыз колакларын пешереп бир әле, кетердәп торырлык булсын, – ди.

Пешерә Асия. Дуңгыз башын да пешерә, колакларын да… Ни эшләмәк кирәк? Аны бит хөкүмәт бушка укытты. Ил алдындагы бурычыңны үтәмичә, кая барасың? Кая җибәрәләр – шунда эшлисең. Һәм ни әйтсәләр, шуңа буйсынасың. Ә гөнаһын кая куярга? Корымлы казан янында йөреп, буялмыйча калып буламы икән ул? Юк!

Ак хыял канатлары да карала икән. Кара корымлы сөрем сеңде кызның җанына. Ә бит ул ак калфаклы, нәзакәтле татар кызы-туташы иде. Аның бит татар хатын-кызының ак яулыклы әбисе, әнисе кебек яшисе килә иде. Бу ни бу! Хәмдиянең ак калфагының каралган чагымы? Безнең яшьлек ак калфакның каралган чагына туры килдеме? Ә бит Асия ап-ак каен кызларының алкаларына, каеннар аклыгына сокланып, үзен каен кызларына тиңләп үскән иде. Асия үзе дә ак калфаклы зифа каен кызы иде.

Ә бүген дуңгыз башы пешереп, нәфис куллары белән дуңгыз ите турый. Тирес астыннан чыккан ап-ак тирес кортлары кебек телем-телем дуңгыз майларын турап, кешегә ашата.

*Ак калфакның табылган чагы…*
*Туганнарның сагынган чагы…*

Сагынасыздыр, туганнар, сагынасыздыр, акча эшләп, әти-әнисенә булышу нияте белән унбиш яшендә, кавырсыны да ныгымаган килеш чыгып киткән кызыгызны. Әти-әнисенең фатихасын алмыйча, калага чыгып киткән балагызны. Бу турыда Асия мең кат үкенеп, әллә ничә кат кабатлады:

– Их! Өр-яңадан яши башлыйсы иде. Балачактан, әнкәсенең ап-ак сөтеннән, ак биләүдән. Алансуның чәчәкле болыннарында яланаяк чабып йөргән, колыннарның тояк эзенә җыелган яңгыр суларын эчеп, Ялантауның көмеш сыман әремнәр, мәтрүшкәләр исе китереп искән назлы җилләреннән исереп, Мишәнең яңа сауган сөт шикелле җылы, назлы суларында коенып үскән балачактан – яңабаштан башлыйсы иде бу гомерне.

Әле яши дә башламаган иде югыйсә.

Кайларга гына китеп югалдыгыз соң сез, гүзәл Гөлҗамаллар, эрләгән җепләрегезгә ай нурларын, хыялларын кушып, Асиянең җанына, күңеленә кереп урнашкан ак калфаклы сылулар? Хәмдияләр? Асия үзен алар урынына куеп, ак калфаклар кадап, хыялында аз йөрдемени!

*Ак калфагым төшердем кулдан…*

Әйе, тормыш шундый аяусыз икән. Хыялый кызның күңелендә ак калфаклы кызлар, ә каршында – өстәлдә тезелешеп киткән кысык күзле, ак керфекле дуңгыз башлары!

Юк, Асия, гомер бер генә килә. Син инде беркайчан да яңабаштан яши башламаячаксың. Соң инде, Асия!

Син ап-ак беләкләреңә беләзекләр киеп, Гөлҗамаллар кебек, ай нурларына манып, җеп эрләмисең. Син җәйнең түзә алмаслык эссе көннәрендә, тәмуг уты кебек кайнар газ плитәсе каршында янып-пешеп, Алафузов фабрикасы эшчеләренә аш пешерәсең. Бабай әйтмешли, Аллаһ яраткан бәндәсен ризык әзерләргә куярмын, дигән. Асия күңеленнән бабасы белән сөйләшә башлый:

– Бабам! Нигә мине дуңгыз башы турарга куйдылар икән? Димәк, мине бик үк яратып бетермәгәннәр. Шулаймы?

– Әй, кызым, дөнья йорты бу. Димәк, сиңа шушы юлны үтәргә кирәк булган. Син бит бу эшне үзең теләп эшләмисең. Синең башка чараң юк, Асия! Дөньясы шундый. Әллә нинди, без аңлый алмаган дөнья бу.

– Мин бу эштән китә дә алмыйм, бабай, минем хөкүмәткә бурычымны түлисем бар. Өч ел буе Алафузов фабрикасы ашханәсендә эшләргә тиешмен. Әгәр китә алсам, идән юып торырга да риза.

Бабасы дәшми.

Дуңгыз башлары кысык күзләрен кызга төбәгән. Мыскыллап, ап-ак керфекләре астыннан карап торалар.

Беркөнне иртәнге сәгать биштә эшенә килсә, чиләктә кичәге көннән калган борщ дөбер-дөбер кайнап утыра иде.

– Ник болай кайнатасыз аны? – дип, кулына тастымал тотып, кыз чиләкне газ плитәсе өстеннән алып куярга уйлады.

Ә идән тайгак иде. Инде ничә көннән бирле краннан су агып тора. Төзәтмәделәр! Шунда кызның аягы таеп китте дә, бер чиләк кайнап торган майлы борщны өстенә аударды. Җитмеш процент тән тиресе киеменә ябышып, туналып төште. Үзәк өзгеч авырту. Һични белән чагыштыргысыз газап. Кызның күз алдында бөтен нәрсә кинәт эреп, юкка чыкты. Ул өстән үзе янында кайнашкан хезмәттәшләренә карап тора. Әнә, берсе килеп, аның өстенә бер чиләк көнбагыш мае койды. Ә ул ялангач. Янында ук йөк ташучы Гомәр басып тора. «Ябыгыз инде, өстемә ябыгыз, оят бит» димәкче була кыз. Тик тавышы чыкмый. Әнә, кемдер япма алып килде. Кызны күтәреп, япма өстенә салдылар да дүрт кеше каядыр алып китте. Кулы япма астыннан чыгып, асылынып бара. Сыдырылып төшкән кул тиресе үтә күренмәле чүпрәк кебек җилдә җилферди. Барысы да елашалар.

Ә Асиянең бер җире дә авыртмый. Шундый рәхәт кызга. Ник елыйлар? Кыз аны белми. Тик нигәдер аның бөтен тән, бит тиресе суелган, кып-кызыл. Әнә аны ниндидер бүлмәгә алып керделәр. Ник күтәреп йөртәләр соң? Үз аягы белән йөри алмыймы? Аптырый. Ак халатлы кешеләр кереп, аның тирәсендә кайнаша. Әнә, директор пышылдап кына ак халатлы хатын белән сөйләшә. Асия ишетә:

– Хастаханәгә илтергә ярамый, Лариса, мине утыртып куячаклар. Ничек тә монда гына хәл итәргә кирәк, – ди.

– Хастаханәгә хәбәр итмәскә хакым юк, – дип каршы килә Лариса. – Тәне җитмеш процент тирәсе пешкән, исән калмаячак. Сез мине җинаять кылырга этәрәсезме? Моның кадәр пешкән тән белән аның исән калуы икеле.

– Күпме кирәк, шуның кадәр түләр идем.

– Мин ул акча белән ничек яшәрмен?! Кыз үлгәч!

Директор дәшми, Асиягә текәлеп карап тора.

– Бетте баш! Ишетәсеңме, Лариса, төрмәгә тыгачаклар мине!

Асия берни аңламый. Дуңгыз танавы кимерергә яратучы директорны ниемә дип төрмәгә утыртырлар икән? Дуңгыз ашаган өчен Аллаһ каршында гына җавап тотасы бит. Алай дисәң, ул бит мөселман түгел, бәлки, мөселманнарга дуңгыз башы ашатканы өчендер?

Асиягә шундый рәхәт. Берни турында уйламыйча, аптырап, өстән аска таба ник ул үзенең ятакта ятканын үзе күрә икән, дип гаҗәпләнә. Аның җанының талпынып каядыр очасы, үзе дә белмәгән киңлекләргә күтәреләсе килә. Әллә ниткән нурлы җир бу. Шундый сафлык, иркенлек! Әй, канатлы кош бул идең дә, күкләргә күтәрел идең. Очар иде Асия, әллә кайларга, зәңгәр күкне канатлары белән телә-телә, гаделсезлекләр, ак керфекле, кысык күзле, ямьсез танаулы дуңгыз башлары юк якка, тик ул оча алмый. Өстән аска карап, аның нигәдер тиресе суелган гәүдәсе янында кешеләр кайнашканын аптырап күзәтеп тора.

Үзәк өзгеч авыртудан аңына килде кыз. Аның кырыенда кечкенә генә, ап-ак пөхтә сакал-мыеклы, ак халатлы карт басып тора. Асия шешенке күзләрен көчкә ачып ыңгырашты:

– Су, су, – дип, иреннәрен тибрәтте.

– Күгәрченем, хәзер, хәзер, – дип, карт әллә нинди көпшәдән Асиянең авызына су салды.

– Авырта, бөтен җирем авырта. Ярдәм итегез миңа.

– Хәзер, хәзер! Авыртуны баса торган укол салам. Син, кызым, түзәргә тырыш. Язмышың инде бу синең.

– Үләсем килә минем, үләргә комачауламагыз. Зинһар өчен!

– Син нәрсә, кызым, унҗиде яшеңдәме? Син гомереңә ныклап ябыш инде, бала. Аякка басарга диген, үлем турында сөйләмә.

Асия азрак калкынып, гәүдәсенә караса, гәүдә урынында кып-кызыл ит иде. Ә теге доктор кулындагы кайчысыман бер әйбер белән аның суелып төшкән тиресен туный. Ул үтә күренмәле тире нигәдер кулыннан туналып төшеп, бармакларына гына эленеп тора.

– Көзге бирегез, зинһар.

– Юк, кирәкми әле сиңа көзге.

– Ай, авырта бит, бик авырта. Ярдәм итегез. Зинһар өчен.

– Озакламый җиңеләя башлар. Түз инде, кызым. Хәзер барысы да үзеңнән тора, бары тик үзеңнән генә. Син кайттың инде болай булгач теге дөньядан. Могҗиза белән исән калдың бит. Яшьлегең булышкандыр. Аллаһка рәхмәт әйт!

– Йөзем дә шушындыймы минем?

Табиб җавап бирмәде.

Үзәкләре өзелерлек, мәңге бетмәс кебек авырту, сызлау…

– Ярый әле аркаң пешми калган. Алайса ни булган булыр иде? Ярый әле күзләреңә тимәгән.

– Нигә миңа көзге бирмисез!

Табиб җавап бирмәде.

* * *

Асиянең бөтен гәүдәсен, йөзен-битен әйтерсең иртән үзе газ плитәсенә ут кабыза торган факел белән яндыралар, көйдерәләр иде. Әллә ничә миллион энә тәненә кадала бара, кадала бара.

– Су, су, – дип ыңгыраштьı ул. Кемдер аның ирененә су тамызды. Ул су тамчылары уттай янган иреннәренә тиюгә, кайнар табага тамган су кебек чыжылдап юкка чыга. Парга әйләнәләр кебек. – Әллә бу тәмугмы икән? Анда да гөнаһлы кешеләрне шулай җәзалыйлар, ди бит. Ә Асия гөнаһлы – мөселман кешесенә дуңгыз башы ашатты. Күп итеп ашатты.

Аның күзләре ачылмый, күз кабаклары шешенгән. Кулларын да күтәрә алмый. Әллә бәйләп куйганнармы? Колагына якында басып торган кемнәрнеңдер сөйләшкәне ишетелә:

– Уф, Аллага шөкер, аңына килде. Үлсә – миңа төрмә. Аңлыйсызмы, бетерәләр башымны. – Директор тавышы. – Берәр нәрсә эшләгез инде!

– Мин нишли алам? Мин аның газапларын беразга гына булса да җиңеләйтә алам. Авыртуны баса торган дару бирәм. Тән моның кадәр пешкәндә, исән калу икеле. Җитмеш процентка якын җире пешкән бит. Йөзе дә пешкән. Кыз бала бит. Мондый йөз белән яшәгәнче… Кызганыч инде, ләкин нишлисең.

– Сез ни сөйлисез? Миңа ни булыр, ул үлсә?

– Сез нигә гел үзегез турында гына уйлыйсыз? Сезне бу яшь кыз баланың язмышы бер дә борчымыймы? Намусыгыз бармы сезнең? Аның гомере кыл өстендә. Сезнең хезмәткәрләр, ул торбаларыгыз күптән ага иде инде, дип сөйли. Сез бит бу турыда белеп торгансыз. Ичмасам, дәшмәгез. Бу кыз үлсә, ул сезнең намусыгызда булачак. Кызны тиз арада хастаханәгә илтергә кирәк!

– Күпме кирәк – шуның кадәр түлим!

– Бәйләнмәгез миңа ул хәрәм акчаларыгыз белән! Барыгыз, миңа комачауламагыз хет.

– Су, су бирегез, – дип өзгәләнде Асия. – Авырта, бөтен тәнем авырта бит. Үлсәм иде, ичмасам. Йа Аллам, үләсем килә.

– Түз инде, кызым, укол салдым, хәзер үтәр. Курыкма, без сине дәвәларбыз. Исән калырсың. Курыкма, – дип, кат-кат кабатлады доктор. – Йөзең дә матур булыр. Элеккедән дә чибәррәк булырсың әле.

Докторның тавышы калтырап китте, елый иде бугай. Калтыранган тавыш белән тагын кабатлады:

– Кызым, мин сине үзем аякка бастырам.

– Ой, бик авырта бит. Йа Аллам! Авырта. Әни, әни, шундый авырта, булыш миңа, әни.

Доктор кулын Асиянең пешмичә калган маңгаена куйды. Куллары салкын.

– Ярый әле күзләреңә тимәгән. Синең күзләрең бу гүзәл дөньяны күрә алачак! Кызым, күрә дә, ишетә дә аласың – бәхет бит инде ул. Ишетәсеңме, кызым? – диде доктор кабат-кабат.

Асия акрынлап, каядыр очканын тойды. Тәнендәге авырту каядыр юкка чыкты. Әллә докторның салкынча кулының сихәте тидеме? Шундый рәхәт иде аңа. Әнә, ул йомшак, каз мамыгы кебек зәңгәр күккә күтәрелә,

ә талгын җил аны әллә кайларга, әрнү-авыртулар юк җиргә очыртып алып китә. Җиңел Асиягә, балачакта бер хәсрәте булмаган наян кызчыкның болында чуар канат күбәләкләр куып йөргән чагындагы сыман. Егылып, берәр җирен авырттырып кайткач, әнисенең, җылы кулын куеп, авырткан урынын сыйпап, бар авыртуларын юкка чыгарып, оныттырганы кебек.

Асия – каз каурые, кайларга китеп барышың? Китмә, китмә, дип ялвара күкләргә менә алмаган Газиз. Аның кулында зәңгәр күкчәчәкләр бәйләме, ә җирдә калган Асиянең башында зәңгәр чәчәкләрдән үргән такыя.

Зәңгәр күл, зәңгәр күк, зәңгәр күзләр – күкләр зәңгәрлеген, төпсез зәңгәр күлнең серле зәңгәрлеген үзенә алган, Асиягә гел елмаеп караучы, куе кара керфекләр белән уратылган зәп-зәңгәр күзләр!

– Китмә, Асия, минем янда кал, яратам бит мин сине. Ихласлыгыңны, гадилегеңне, серлелегеңне яратам. Мин җирдә синсез ни эшләрмен? Нигәдер бу дөньяда ихласлык бетеп бара! Син үзгәрмә, яме, үзең булып кал, үзгәрә күрмә!

Ә Асия Газизгә җавап бирә алмый. Җирдә вакытта да уңайсызланып, оялып, егетнең ыспайлыгыннан югалып кала иде. Үзенең гади ситсадан тегелгән күлмәгеннән, брезент чүәгеннән һәм… тагын нидән әле? Әй, кыз үзе дә белми. Газиз буе җитмәслек, юк, буе гына түгел, хыялы да җитмәслек югарылыкта булып тоела иде. Ә үзе шундый якын һәм якты. Кояш кебек инде менә, нәкъ кояшның үзе кебек еракта, ләкин яктырта!

Асия белә: Газизнең әти-әнисе зыялы кешеләр, гади авыл кызын кабул итмәячәкләр. Беркайчан да! Асия моны бөтен җаны, тәнендәге һәрбер күзәнәге, хатын-кыз тоемлавы белән тоя. Егет белән араны өзәргә кирәклеген дә белә. Нигә вакыт үткәрергә? «Тибенгәндә, тиңең белән тибеш», дип әйтә иде әтисе. Ләкин ул Газиз белән араны өзә алмый. Юк, өзә алмый, чөнки Вәкил хыянәтеннән соң йөрәк яраларын азмы-күпме җөйләндерә алучы Газиз булды. Алар бер-беренә охшаганнар да бугай. Зур күзләр, дулкын-дулкын коңгырт чәчләр, озын, төз гәүдә!

Вәкил аңа тиң иде. Бер даирә кешеләре. Ә Газиз?!

Менә шулай уйлый иде җирдәге Асия. Элек. Яшь, матур, зифа буйлы кыз чагында!

Ә бүген аңа беркем, берни кирәкми. Әнә караватта кып-кызыл, бөтен тәне әллә нинди куыклар белән капланган бичара кыз ята. Аңа бүген беркем, берни кирәкми. Тик бу сызлау-авыртулар басылып торсын иде. Азга гына басылып торсын иде әрнүләре. Асия азрак хәл алганчыга чаклы гына. Көн саен теге табиб керә дә:

– Исәнме, кызым, хәлләрең ничек? – дип сорый һәм елмая.

Инде шеше кими төшеп, күзләре ачыла башлаган Асия:

– Авырта, бик авырта, – дию белән чикләнә.

Асия белә: кояшның үзе кебек якты, ап-ак сакал-мыеклы җыйнак гәүдәле бу карт аңа хәзер укол кадаячак, һәм азрактан скальпель белән гәүдәсендәге куыкларны ярып, аларны тагын бер кат тунап алачак.

– Түз, кызым, синең бит элекке кебек матур буласың килә. Әллә элеккедән дә чибәррәкме? Мин сине башкаларны дәвалаган кебек дәваласам, тәнең ямьсез, җөйле булып төзәлер. Син бит сабыр кыз, шулай бит, күгәрченем? Мин синең шундый икәнеңне күрдем инде, түземле син, Ася.

Асияне сөйләштерә-сөйләштерә куыкларны яра доктор. Бөтен тәненнән һәм битеннән каезлап, Асиянең тән тиресен әллә нинди савытка җыйный. Ул әле монысына түзә ала. Ә аннан соң бер ак савытка күп итеп зелёнка агыза, тагын ниндидер дару өсти, таягына бинт урап, койма буяган кебек, Асиянең бөтен гәүдәсен буяп чыга. Үзе һаман:

– Түз. Кызым, түз, – дип кабатлый.

– Авырта, бик авырта бит, – дип бәргәләнә кыз.

– Беләм, бик авырта, тик сиңа ничек ярдәм итәргә генә белмим. Кичер мине, кызым, кичер, – дип юата доктор.

Асия аңын югалтып, янә каз каурыена әйләнеп, каядыр оча.

Оча, оча – биеклекне, болытларны коча-коча оча. Аның бер җире дә авыртмый.

Ә теге табиб никтер елый, калтырана-калтырана елый карт доктор. Ятакта Асиянең гөберле бака кебек ямь-яшел гәүдәсе ята. Никтер кулларын бәйләп куйганнар. Ник бәйләгәннәр инде! Асия бит чыгып кача алмый. Киемнәре юк, ялангач ята бит ул!

Каз каурыен җилләр һаман биеккәрәк, биеккәрәк күтәрә. Болытлар янына, балачакта күзләрен күккә төбәп:

– Их, шушы болыт тауларыннан үрәчәле чанага, яисә әнисе кер юа торган тагаракка утырып шусаң иде, – дип хыялланган чагына оча Асия.

Чү, йомшак болыт ястыгына чумган теге нәни кызчык Асиягә кул изи түгелме?

– Мин болытларга менеп җиттем. Хыялларым чынга ашты, – дип, ул җирдә калган Асияне болытлар куенына чакыра. Хыялый кыз – Асиянең балачагы.

**Җиденче бүлек**

Җитен комбинаты поликлиникасының бер почмагындагы изоляторда Асия бик озак берүзе ятты.

Аңын җуйган чакларында әллә кайларда, җилләр иркендә очып йөрде. Аннары аңына килә торган иде. Аһ, ул газаплы, бетмәс-төкәнмәс сызланулы, үзәкләргә төшәрлек әрнүле көннәр вә төннәр!

Ачык йөзле, җыйнак гәүдәле табиб көн саен ак эмаль савытка скальпельләр, кайчыларын, әллә ниткән майларын салып керә дә:

– Исәнме, кызым! Ничек анда безнең хәлләр, йоклап булдымы? – дип сорый. – Беләсеңме, син крокодилга охшагансың. Яшел крокодилга. Шундый матур, ямь-яшел крокодил. Озакламый җиңеләер сиңа. Яңа тире үсәр. Син бит бик түзем һәм бик акыллы кыз. – Һәм ул, Асияне юатырга тырышып, төн эчендә янәдән бөтен тәнен каплап өлгергән кутырларны туный башлый. Тагын ак эмаль савытка зелёнка агызып, аңа әллә нинди майлар өсти, шуның белән Асиянең гәүдәсен майлый, буйый башлый.

– Әни, әни, авырта, ой, авырта…

– Түз, кызым, түз! Мин сине үземнең методым белән дәвалыйм. Әйе, мин синең тәнеңә берәр мазь гына сөртә дә алам. Син дә алай ук сызланмас идең. Ә алай синең тәнеңдә ямьсез җөйләр калачак. Артык ит үсәчәк. Синең бит кияүгә чыгасың, балалар үстерәсең килер. Тагын азрак түзсәң, элекке кебек матур булырсың. Синең бит йөргән егетең бар. Бар! Анда

көн саен синең янга дип, бер шаһзадә килә. Тәрәзә төбеңдә сәгатьләр буе басып тора. Аны синең янга кертмиләр генә.

– Юк, юк, кирә күрмәсен, миңа берәү дә кирәкми. Минем үләсем килә. Җен кебек ямьсез буласым килми минем. Яшисем килми!

– Кем әле сине ямьсез булачаксың, диде? Мин бит сиңа элеккедән дә чибәррәк булачаксың, дип вәгъдә бирдем. Син, кызым, миңа ышан. Мин тәне пешкән кешеләрне күп дәваладым инде. Ә хәзер түз…

– Авырта, – диде кыз, бөтен тәне белән куырылып, калтыранып. – Йа Аллам! Ничек авырта! Әни, әни! Шундый авырта…

Һәм ул тагын чоңгылга оча! Каядыр, авыртулар юк җиргә китә. Ә Газиз аның тәрәзәсе каршында моңаеп, башын аска иеп, басып кала.

Газиз, Газиз! Беләсеңме икән син минем хәлләремне? Белмисең. Сиңа мин күргәннәрне күрергә язмасын! Беркемгә дә, дошманыма да бу хәлләрне күрсәтмәсен Аллам. Тәмуг шушы буладыр. Бу тәмугтыр. Шундый авыр миңа, минем бөтен тәнем сызлый, юк, тәнем генә түгел, бөтен җаным сызлый минем, Газиз. Минем башымда бары бер генә уй! Ничек үләргә? Бабай әйтә иде: «Кызым, тәмуг җиде катлы була, – дип. – Адәм баласы теге дөньяга баргач, вак-төяк гөнаһлары өчен җавап тотып, оҗмахка керер алдыннан азрак чистарынып чыга икән. Ә тәмугның төбендә, мордарлар, бозым салучылар, сихерчеләр калыр, ди. Алар аннан мәңге чыга алмаслар. Сиңа Аллаһ гомер биргән икән, гомерне Ул үзе генә өзә ала. Ана карынында вакытта ук маңгаена язылып куела ул кешенең гомер озынлыгы. Гомер бакый тәмуг утларында янасың килмәсә, беркайчан да ул турыда уйлый да күрмә. Кеше беркайчан да ул эшкә барырга тиеш түгел. Син үлдем дә беттем дип уйлыйсыңмы?! Юк, кызым! Синең җаның беркайчан да үлми. Дөньялыкта кылган гамәлләрең өчен җавап тотасың бар. Шуңа күрә тыелганнардан тыелып, саваплы гамәлләр кылып яшәргә тырышырга кирәк. Әле аның үзең белми кылган гөнаһлары да бихисап була. Дөнья йорты бу, кызым. Сиңа бу сынауны Аллаһ җибәргән. Ни өчен икәнен аңлата алмыйм. Ни өчен син шундый газаплар аша узарга тиеш? Юк, мин сиңа аңлата алмыйм, балам».

– Әй, бабай! Син бит белмисең, мин бит мөселманнарга дуңгыз башы ашаттым, күп итеп ашаттым. Алар шундый ямьсез, әллә нинди тупыйк танаулы, ап-ак керфекле, үзләре шундый зур. Менә шуңа күрә җирдәге тәмуг утларында янам мин, бабай. Мин авыртуга, сызлауларга түзә алмам. Ә соңыннан ни була? Кеше күзенә күренә алмаслык куркыныч, ямьсез булып калачакмын. Мин бит докторларның сөйләшкәнен ишетеп тордым. Ә алар мине ишетми, дип уйлады. Аның үлүе үзе өчен хәерлерәк. Ул бит бик ямьсез, кеше куркытырлык булып калачак, диделәр. Мине дәвалый торган доктор: «Син элеккедән дә матуррак булачаксың», – дип юмалый. Барыбер үләчәкмен мин, бабай. Тик ничек итеп үләсемне генә белмим. Миңа инде анда да – тәмуг, җирдә дә – тәмуг.

Күктәге Асия җирдәге бабасы белән шулай сөйләште.

– Сабыр бул, кызым, зинһар, сабыр була күр! Ялганламый ул яһүд духтыры. Җир йөзендә төрле-төрле милләтләр яши. Әнә күрәсеңме, яһүдләр, руслар арасында да нинди яхшы кешеләр бар. Ул картның сиңа

булышасы килә. Сине матур вакытыңа кайтарасы килә. Ә син, үләсем килә минем, дисең. Алай уйлау үзе үк гөнаһ. Яшәргә тырышырга кирәк.

Һәм Асия караватта яткан яшел гөберле бака, яшел крокодил кыяфәтенә һәм сызлау, әрнүләренә янә әйләнеп кайтты.

Яшел крокодил янында җыйнак гәүдәле яһүд карты, озын буйлы, ыспай киемле директор аптырап басып тора иде.

* * *

Шулай бу дөньяга китә-кайта ничә көн, ничә төн үткәргәнен белми Асия.

Беркөнне палатага кояшның үзе кебек яктырып яһүд докторы килеп керде дә:

– Кызым, Асенька! Ничек безнең хәлләр? Ничек йокладың? – дип, учын кызның маңгаена куйды. Бу юлы докторның кулы алай салкын булып тоелмады.

– Беләсеңме, Ася, кризис үтте. Бүген температураң булмады. Ай буена диярлек кырык тирәсендә торды бит! Яшь организм үлемне җиңде. Хәзер инде авыртуларың да кимүгә таба барачак. Яңа тән тиресе дә үсеп килә. Молодец кыз булдың син. Беләсеңме, хәзер син кемгә охшагансың? Ташбакага. Әйбәт ташбакага.

Бу юлы докторның кулында Асиянең котын алып торган ак эмаль савыт һәм скальпель, кайчылар юк иде.

– Мин сине башка буямаячакмын. Ася, син тәмугны җиде кат урадың инде. Бик күп тапкырлар аңыңны югалттың, кайттың, тагын киттең… Ә мин кайтамы, юкмы, дип көттем. Хәзер инде бу ташбака кабырчыгының купканын көтәргә калды.

– Миңа көзге бирегез әле, зинһар өчен, – дип инәлде Асия.

– Юк, юк – иртә әле. Бик иртә. Ә синең шаһзадәң көн саен килә, синең янга керәсе килә, сорый, дулый, таләп итә. Керсенме?

– Юк, юк. Алла сакласын, кермәсен. Аның өчен мин юк инде. Әйтегез аңа, мине онытсын! Мондый ямьсез кыз нәрсәгә кирәк булсын ди аңа!

– Барысы да яхшы булачак, Ася! Син ямьсез булмаячаксың. Мин сиңа ант итеп әйтәм. Ышан син миңа.

Доктор нindидер май белән Асиянең йөзен, гәүдәсен майлап чыгып китте.

Ташбака кабыгы май белән каплангач, чатнап, канап торган тәне йомшап киткәндәй тоелды.

Доктор кадаган уколның сихәте тиеп, ни гомерләр үзәкләренә үткән сызлау, авыртулар кимегәндәй булды.

Әллә онытканнар, әллә шулай тиеш дип тапканнар, бу юлы кызның кулларын бәйләмәгәннәр иде. Коты чыгып, куркып калган Асия кулларын битенә тидерергә дә кыймый ятты.

Ә инде үзен җиңеп, кулын битенә тидергәч, коты алынып, кычкырып җибәрде. Бөтен йөзе каты кутыр белән капланган. Ташбака кабыгы дигәннәре шундый каты һәм кытыршы!

– Әни, әни җаным! Ни эшлим, ниләр кылыйм? Ничекләр итеп үлим? Минем бу кыяфәтемне күреп, син ничекләр түзәрсең? Болай да йөрәгең сау түгел.

Әрни-әрни елады Асия. Инде үләргә кирәк. Кайдан гына берәр агу табарга? Йоклап кына кит идең дә уянма идең. Раббым, бер Аллам! Ал мине үз яныңа. Минем үләсем килә.

Ишек артында кемнәрнеңдер сөйләшкәне ишетелде. Директор тавышы килде:

– Миңа аның белән сөйләшергә кирәк. Ачыгыз ишекне.

– Доктор сезне кертмәскә кушты.

– Аның ни хакы бар? Мин таләп итәм, ачыгыз. Юкса ватып-җимереп керәм.

Асия, өстенә япкан ак җәймәне күзләренә кадәр тартып куйды. Ишек ачылган тавыш ишетелде.

Директор үзе генә түгел, бухгалтер белән икәүләп керделәр. Татар булса да, исемен Еленага үзгәрткән хатын белән директор арасында нидер бар, дип сөйлиләр иде.

– Хәлләрең ничек, Асенька? – дип, бик җылы итеп исәнләштеләр.

Асия дәшмәде. Дәшәрлек хәле дә юк иде.

Икәүләшеп, аз-маз сүз сөйләшеп утырдылар да Асиягә әллә нинди кәгазьләргә кул куйдырдылар. Кыз кул куйды. Ул бит барыбер үләчәк. Әнә, бер амбар кенәгәсе кебек китап тышына «Техника безопасности» дип язылган. Ә икенче кәгазь битенә: «Мин үзем гаепле, аягыма артсыз башмак кигән идем. Бу очракта мин үзем гаепле», дип имза салды инде яшәүдән тәмам өметен өзгән унҗиде яшьлек кыз.

Юк, Асиянең аякларында таймый торган чүәкләр иде. Ул белә – бу кәгазьләрдә язылган язулар дөрес түгел. Болар җаваплылыктан котылу өчен тырыша. «Техника безопасности» китабына да ул кул куярга тиеш түгел, чөнки белгечләр өч ай саен укытып, аңлатып торырга тиеш. Соңыннан гына кул куярга тиеш Асия.

Ә бүген аңа барыбер. Аның гомере шушында өзеләчәк. Ә болар яшәсеннәр!

Әнә ничек итеп тилмереп:

– Ася, кулыңны куй инде, зинһар, –дип, күзгә карап торалар бит.

Асия керфекләрен күтәреп, карашын директорның яшькелт-сары күзләренә төбәде һәм җаны-тәне белән калтыранып куйды. Алар ундүрт яшьлек кыз каршына чыккан ана бүре күзләре төсле үк иде. Ике күз карашы бергә кушылып, ыспай директор юкка чыкты да, бары тик соры бүре генә Асия каршында ырылдап басып калды. Үзенә кирәк кәгазьләргә кул куйдырып алгач, ул:

– Менә молодец, Ася, син бик тә молодец. Йә, дәвалан, тизрәк савыгырга язсын. Сине азаплап тормыйбыз, киттек, Елена, – дип чыгып китте.

Асиягә авыр иде. Әнә, чиләкләренә мөлдерәмә сөт тутырып, баскычларны саный-саный, ундүрт яшьлек кыз тау түбәсенә менеп килә. Инде аз гына, бик аз гына калды. Бер баскыч, ун баскыч. Һәм ул үзенә төбәлгән ниндидер күз карашын тоеп, башын күтәреп караса – бүре! Бүре кызга каршы бер адым атлауга, Асия цементлап катырылган баскычтан аска таба тәгәрәде.

Ә бүген, үзләрен коткару өчен ялган кәгазьләргә кул куйдырырга кергән

теге икәү, чи дуңгызның юылмаган танавын кисеп алып, кетердәтеп ашаучылар Асиянең алдагы тормышын чәлпәрәмә китерде.

Унҗиде яшен яңа тутырган кыз, изолятор бүлмәсендә үзенә тизрәк әҗәл килүен сорап, Ходайга ялварып, үксеп елап калды.

Асия инде ике айдан артык изолятор бүлмәсендә берьялгызы ята. Үзәкләргә үтеп сызлауны түзеп булмаслык кычыту алыштырды.

– Яңа тире үсә, бик яхшы. Тиздән бу кабыктан котылырсың. Без синең белән үлемне җиңдек, Ася. Син шундый молодец, кызым. Сабыр! – диде доктор.

– Мин шайтан кебек котсыз булачакмын. Ямьсез.

– Сиңа кем алай дип әйтте?! Син элекке кебек чибәр булачаксың, хәтта элеккедән дә чибәррәк.

– Мин бит сезнең директорга әйткәнегезне ишетеп тордым. Мине тынычландырыр өчен генә ялган вәгъдәләр бирергә кирәкми.

Доктор дәшмәде. Асия дә тынып калды.

– Кызым, әйдә, тагын бераз сабыр итик әле. Бу кабырчык купмый торып, бернәрсә дә әйтә алмыйбыз. Миңа барысы да яхшы булыр кебек тоела. Минем дәвалау ысулым бик нәтиҗәле. Көтик, яме, – дип, авыр сулап куйды доктор. – Әйт әле, зинһар өчен, директорың башка синең янга килмәдеме? Никтер күптән күренгәне юк.

– Әйе, Ян Михайлович, алар баш хисапчы Елена белән кергән иде. Мин куркынычсызлык техникасы буенча кенәгәгә дә, «куркынычсызлык кагыйдәләрен үзем үтәмәдем» дигән кәгазьгә дә кул куйдым.

– Ася, күгәрченем, нәрсә майтардың инде? Шундый кәгазьгә кул куялар, димени?

– Ян Михайлович, алар үтенеп сорады, ялынды. Ә миңа барыбер. Аларның яшисе бар бит әле. Ә мин яшәмәячәкмен.

– Хайван икән алар. Сиңа бит кыйммәтле дәвалану курслары үтәргә кирәк булачак. Тән тиресен күчереп утыртырга кирәк булуы ихтимал. Әйттем бит, бер кәгазьгә дә кул куйма, дип.

– Алар үтенеп сорады. Мин аларны кызгандым.

– Аллаһ кичерсен инде, Ася, оятлары да, иманнары да юк икән.

– Ян Михайлович, минем бу кабырчыкны кубарып, салып атасым килә. Озак калдымы әле? Авыртмый инде хәзер, бөтен тәнем кычыта.

– Түземлек кирәк, кызым, түземлек! Барысы да яхшы булачак! Аллаһ рәхмәте белән терелерсең! Асенька, мин ышанам сиңа, син дә миңа ышан. Без синең белән үлемне җиңдек. Ә ул чалгысын тотып, ай буе синең баш очында торды. Әмма син көчле булып чыктың, геннарың көчле синең. Син бит авыл кызы, саф һава, хезмәт белән чыныккансың.

**Сигезенче бүлек**

Ян Михайлович ул көнне нигәдер эшкә килмәде. Асия янына яшь кенә бер кыз кереп, аның тәнен, кутыр белән капланган йөзен, битен йомшарта торган ниндидер май белән майлады. Күреп ятты кыз, марляга ияреп, йөзен каплаган панцирь кубып-кубып төшә.

Шәфкать туташының исеме Зәлия икән. Арча кызы.

– Асия, синең бу кутырларың тиздән кубып төшәчәк.

– Ә мин нинди кыяфәттә булачакмын соң, Зәлия, җен төслеме?

– Синең җен күргәнең бармы соң?

– Юк та, барыбер җен ямьсез буладыр инде ул.

– Юк, Асия, синең битеңдә андый җөйләр күрмим мин, үзең әйтмешли, кабырчык купкан урыннар кызыл, ләкин җөйләр күрмим.

– Зәлия, зинһар өчен, миңа кечкенә генә көзге кыйпылчыгы бир әле. Үтенепләр сорыйм синнән.

– Юк, Асия, Ян Михайлович сиңа көзге бирмәскә кушты. Үзенең йөзен күргәч куркыр, ди.

– Шулай ук куркынычмыни?

– Әйтәм бит, кутыр купкан урыннарда җөй юк, дип. Кызыл, ләкин җөй юк.

Зәлия Асиянең яшьле күзләренә карап торды да, кесәсеннән түгәрәк көзге чыгарып, аңа сузды.

– Ышанмасаң, мә, үзең кара!

– Рәхмәт, Зәлия, тик мин көзгегә карарга куркам әле. Син чыгып киткәч, азрак тынычлангач карармын. Ә көзгене сиңа соңыннан кире бирермен.

– Кирәкми, Асия, сиңа булсын. Ләкин мин биргәнне Ян Михайловичка әйтә күрмә. Яшереп куй. Ышан миңа, синең йөзеңдә җөйләр калмаячак. Әлегә битең кызыл булыр, ә соңыннан узачак ул. Бүгенгә сау бул, Асия, иртәгә Ян Михайлович үзе килә. Бүген Израильдән малае кайткан, шуңа килә алмады. Аның улы Яков доктор булып Тель-Авивта эшли. Ул да анда пешкән кешеләрне дәвалый икән. Иртәгә улы синең янга киләчәк. Ул бик зур профессор, диме шунда. Ян Михайлович сөйләп торды. Үз колакларым белән ишеттем. Мин бит аның белән эшлим. Шундый яхшы кеше ул безнең профессорыбыз. Сезнең директорыгыз хастаханәгә килеп, ялына-ялына сорады:

– Ян Михайлович! Миңа консультация генә кирәк. Сез үзегезнең ысулыгыз белән тәне пешкән кешеләрне генә дәвалыйсыз, дип ишеттем. Япь-яшь кыз бала, нибары унҗиде яшь. Сезгә китерә алмыйм, транспорт белән алып килә торган түгел, – ди.

Синең яннан кайткач, Ян Михайлович безнең хастаханәдәге докторларга сөйләп торды:

– Кыз бик яшь, без алынмасак, үләчәк ул, – диде. – Җитмеш процентка якын тәне пешкән. Ярый әле аркасына, өске өлешенә тимәгән, ятып тора ала. Бите пешкән. Күрсәгез авыртудан ничек газапланганын… Унҗиде яшьтә шундый йөз белән…

Ян Михайлович көн саен Израильдәге улы белән сине алга таба ничек дәвалау турында сөйләште. Асия, һич ялганламыйм, көн саен. Ә кичә миңа әйтә Ян Михайлович:

– Зәлия! Бүген Асенька янына керә алмыйм, – ди. – Үзең генә кер, менә бу дару белән җәрәхәтләрен, хәер, җәрәхәт дию генә аз, бөтен тәнен майлап чык. Тынычландыр. Тәне пешүдән эз калмаячак, монысына иманым камил. Үзенә дә шулай дип әйт. Без улым белән аны дөрес дәвалаганбыз. Билләһи, Асия, шулай диде. Һич ялганламыйм.

– Рәхмәт сиңа, Зәлия, минем шундый ышанасым килә. Профессор

да шулай дия дә бит, ул мине тынычландырыр өчен генә әйтәдер, дип уйлыйм.

– Ярый, хуш, Асия! Минем хастаханәгә кайтасым бар. Палатадагы авыруларым көтә.

– Хуш, Зәлия! Тагын кил, яме. Синең белән сөйләшкәч, ничектер өмет уянды.

Зәлия чыгып киткәч, Асия түгәрәк көзгене кулына алып, бик озак йөзенә китерергә куркып, уйланып ятты. Артындагы катыргыга ике аккош рәсеме төшерелгән, кояш кебек бу түгәрәк көзгегә карауга, кызга язгы кояш сүнәр сыман тоела иде. Үзенең ташбакага охшаган йөзен күрсә, йөрәге ярылыр кебек. Көзгене йөзенә китерергә куркып, озак уйланып ятты ул. Көзге артындагы катыргыда – ике аккош!

*Һаваларда оча ике аккош –*
*Каурыйлары җиргә коела!*

Авылда Вәкил җырлый иде бу җырны. Каурыйлары җиргә коела! Асиянең җимерелгән хыял канатлары кебек! Коелдылар, ап-ак хыял канатлары тәмам коелып бетеп, инде өч ай буе Асия әле яшел гөберле бака, крокодил, әле, доктор әйтмешли, бөтен тәнен кабырчык каплаган ташбака кебек кымшана да алмыйча изоляторда ята. Алда нәрсә көтә аны, белми! Кеше күзләренә күренә алмаслык коточкыч кыяфәткә кереп калса, ни эшләр? Авылга хәбәр итмәделәр, атна саен Асиядән хат алып торган әти-әни тәмам аптыраешта калып, абыйсыннан, сеңлесеннән хат аша сорап карыйлар. Алары да: «Язар әле, вакыты юктыр», – дип чикләнәләр. Ә сеңлесе бер көнне каләм белән дәфтәр бите алып килде.

– Асия! Әти-әни бик борчыла. Ике генә сүз булса да яза алмассыңмы? – диде. Куллары бинт белән бәйләнгән Асия дәфтәр битен тотырып, авыртуга түзә алмыйча, елый-елый язды. Соңыннан этисе абыйсына хат язып салган: «Әллә ул хатны трамвайда язганмы? Асия язуы түгел бу, эчтәлеге дә әллә нинди, килделе-киттеле сүзләр. Аннан килгән хатлар әдәби әсәр кебек була иде, ә бу хат! Нидер булган! Дөресен әйтегез. Югыйсә иртәгә үк Казанга чыгып китәбез», дигән.

Абыйсы белән сеңлесе үзләре авылга кайтып, әти-әнисе белән сөйләшеп килделәрме, азрак тынычландылар кебек.

Асия көзгедән йөзенә караганчы, башта кырый-кырыйлардан кубып-кубып төшә башлаган ташбака кабыгыннан арынган урыннарны пешми калган чәнти бармагы белән сыйпап-сыйпап карады. Азрак ачыта, ләкин шома! Шуннан, кабалана-кабалана, көзгене йөзенә китергәч, ул башта куркуыннан кычкырып җибәрде. Әллә ниткән, чатнап-канап беткән кара- көрән куркыныч йөз. Тик күзләре... менә-менә яше түгелергә торган моңлы, сагышлы күзләре. Йөзе… Ташбака кабыгы кубып төшә барган урыннарда бит тиресе яңарып килә. Шома, яшь тире. Зәлия әйтмешли, җөйләр күренми!

Асиянең күңеленә өмет кошы килеп кунды. Һәм яшисе килү дәрте уянды. Әнә изоляторның бердәнбер тәрәзәсеннән яз кояшы да кызга елмая.

– Асия, син бер дә кайгырма! Әле сине алда матур көннәр көтә! Ә син, җүләр, үләсем килә, дисең. Кит, булмаганны, шундый матур дөньяны

ташлап китәләрме! Күрәсеңме, инде кабат язлар килде. Түбә кыекларына рәт-рәт булып тезелгән боз сөңгеләреннән тып-тып итеп, ап-ак кар өстенә тамчылар тама. Беләсеңме, ул тамчылар – кышның күз яшьләре! Син бит үзең яраткан ак кышны, салкын, буранлы кышны күрми калдың. «Өстемә кияргә пәлтәм юк, ничекләр итеп кышкы пәлтә сатып алырга?» – дип кайгыра идең. Ә сиңа кышкы киемнең кирәге дә булмады. Ярый әле, лагерьда эшләп, язгы-көзге пәлтә сатып ала алдың. Үзеңә дә, сеңлеңә дә. Менә шулай сине җәлләп тә, сөенеп тә елый ул кыш.

Асиянең өч айлык яшь гомере минсез генә үтте! Һәм вәгъдәсез Вәкилне алыштырган Газизсез үтте. Әгәр Асия белән бу хәл килеп чыкмаган булса, алар бит Газизнең әти-әниләре янына барырга тиеш иде. Әле Асия тулай торакта бер бүлмәдә яшәүче, үзеннән биш яшькә өлкәнрәк Нинадан өстенә киеп барырга күлмәген һәм аяк киемен сорап торган иде. Шундый рәхәт буласы иде дә бит. Юк шул инде. Бабасы әйтмешли, кара сакалың үзеңнән калмый икән ул. Кара күләгәң кебек. Гел үзеңә ияреп йөри икән. Асия Газизгә әйтеп тә карады:

– Юк, Газиз, башта өс-башымны карыйм әле. Соңыннан, соңыннан барырбыз, танышырбыз, – диде.

– Юк, Асия, минем әти-әнием өчен синең өс киемең түгел, үзең кирәк, – диде Газиз. – Миңа да син үзең, ихласлыгың, дөньяга карашың, матурлыгың, сөйкемлелегең һәм… – дип, бераз тукталып торды да: – Яратам мин сине, Асия! – дип әйтеп салды. – Минем гел сине күрәсем килеп тора. Озын сүзнең кыскасы шул: мин бит синнән алты яшькә өлкәнрәк. Өйләнергә вакыт. Әти-әни дә: «Өйлән! – дип, һәрдаим әйтеп тора. Әнә эшләгән җиреңдә күпме кызлар! Бүген үк сиңа кияүгә чыгарга әзерләр. Ә син сайлыйсың. Сайлаган сазга очраган тазга! – диләр.

– Ярар, әти-әни, мин сезне бу атнада бер кыз белән таныштырам. Тик аның белеме дә, өстенә кияргә рәтле киеме дә юк, – дидем. – Ул гап-гади авыл кызы – повар.

– Син кемгә өйләнмәкче буласың соң? – дип, сүз башлады әти. – Ул кызның белеменәме, киеменәме? Ә без үзебез кайдан чыктык соң, авылдан түгелмени? Үзең дә авылдагы әби-бабайларны сагынып, һаман искә алып сөйлисең. Повар, имеш! Тәмле ризыклар пешереп ашатыр үзеңә!

– Юк, ул быел КДПИның татар теле бүлегенә керергә җыена, – дим. – Ул әсәрләр яза.

– Кызык, повар һәм татар теле бүлеге, – дип бүлдерде әни. – Минем инде ул кызны бүген үк күрәсем килә. Әйдә, бу ялда ук күрешик. Әгәр үзеңә ошый икән, нигә сузып торырга?

– Асия, минем әти-әнием сине бер күрүдә ошатачак. Иманым камил, шулай булачак. Аннан соң, сиңа бит алар түгел, мин өйләнәчәкмен. Безгә бит синең белән тормыш итәсе. Бу ялда безнең картлар белән күрешәчәкбез. Эшеңдә әйтеп куй, син бит кешегә каршы килә алмыйсың, әгәр сорасалар, өченче сменага да калып эшлисең ич син. Азрак үзеңне сакларга кирәк. Картайгач кына саулыкның кадерен беләсең, дип әйтә безнең әти. Шкафта эленеп торган кием тизрәк тузамы, әллә көн саен кигән киемме? Мин синең исән-сау булуыңны телим. Без өйләнешеп, күп балалар үстереп, тәмам картаеп, икебез бер көнне үләргә тиеш. Ишетәсеңме, картаеп, икебез бер көнне…

– Әй, җүләр дә инде син, Газиз! Мине әни, сәеррәк син, кызым, дип әйтә торган иде, ә син миннән дә сәеррәк. Сәер – җүләр дигән сүз инде ул, тиле үк түгел, җүләр. Ә без ике җүләр өйләнешсәк, бездән нинди балалар туар икән соң?

Икәүләшеп, үз-үзләреннән рәхәтләнеп көлгән иде алар ул көнне. Кич буе кинәнеп Кабан күле буенда йөргәннәр иде.

Асия бәхетле иде. Ундүрт яшьлек кыз чагында, карт имән агачы төбендә очрашырга дип, беренче тапкыр, курка-курка гына, Вәкил янына чыккан чагындагы кебек бәхетле иде Асия.

Ә бит ул вакытта агачларның инде яфракларын коеп, яз килүен көткән яңа бөреләргә урын калдырып, ничектер моңсуланып, моңаеп, кышны көткән мәле иде. Тиздән, бик тиздән үзенең бураннары, ачы җилләре белән җиһанга кыш килер, җир ап-ак тунын ябынып, йокларга ятар. Аннары табигатькә яз килер, челтер-челтер кар сулары аваз салыр, күңелләрдә кыш буе йокымсырап, йоклап яткан хисләр уяныр, язгы җилләр ап-ак карны челтәр-челтәр тишеп, эретеп суга әйләндерер. Асия быел табигатьтәге бу әверелешләрне күрми калды.

Яз! Җанда шундый да җылы, матур хисләр уята ул. Бигрәк тә сиңа унҗиде яшь тулганда, синең җаныңда беренче мәхәббәтең чәчәккә бөреләнгәндә! Йөрәгең рәхәт сулкылдап, кемнедер көтә, синнән нәрсәдер таләп итә. Кемне көтәсең син шулай сулкылдап, ашкынып, унҗиде яшьлек кыз бала! Мөлдерәмә көмеш чишмә сулы чиләкләреңне ябык иңнәреңне кисеп кергән көянтәңне үз җилкәсенә алган Вәкилнеме? Ул юк бит инде. Синең сулар сулышыңа әйләнгән, аннан башка бер генә минут та яши алмас кебек тоелган вәгъдәсез Вәкилне саф күңелле Газиз алыштырды. Урыстау астындагы томаннарда эреп югалды Вәкил! Онытты аны Асия, белми дә! Шулай да Вәкил белән Газиз арасында ниндидер охшашлык та бар кебек тоела аңа. Алар икесе бер кеше төсле. Кайчагында, Газиз белән очрашканда, аның Газизгә «Вәкил» дип дәшкән чаклары да була.

– Кем ул Вәкил? – дип сорый Газиз. – Син миңа бик еш «Вәкил» дип дәшәсең.

– Авылда бер мәктәптә укыдык, дустым иде, – дип, уңайсызланып кына әйтеп куя Асия.

Газиз башка сорашып тормый.

Асиянең күңеле исә иңендәге авыр йөкне үз иңнәренә күчереп, гомере буена янәшә барырлык ир-егетне өзелеп көтә иде. Менә шул киләчәккә, яхшы киләчәккә илтүче хыяллар бер мизгел эчендә юкка чыкты, аларның урынын бетмәс-төкәнмәс, иртәсен-кичен, көндезен-төнен бер дә туктамый торган сыктау-сызлау һәм өметсезлек биләде. Ян Михайлович укол кадап чыгып киткәч, авыртулары бераз басыла төшкәч, авыр, саташулы йокыга талгач, Асиянең каршысына һаман шул ана бүре чыга: ул яшькелт-соры күзләрен кыса төшеп, Асиягә текәлә.

– Мин тимәдем синең балаңа, – ди Асия. – Ник син һаман мине эзәрлеклисең? Синең алдыңда бер генә дә гаебем юк!

Ләкин ана бүре кызның сүзләрен аңламый. Ул ырылдап, азау тешләрен ыржайтып, кызга ташлана һәм Асиянең тәненнән итләрен умырып-умырып йолкырга керешә.

– Авырта, – дип елый Асия, аңына килеп. Даруның тәэсире беткән икән. Көн дә шул хәл кабатлана...

Кызның йөрәгендәге Газиз-Вәкилне әрнү-сызлаулар алыштырды. Үлем көтү газабы.

Хәзер исә түбә кыекларына эленгән боз сөңгеләрдән җемелдәшеп тамган тамчылар һич тә асылташлар түгел, алар – кышның күз яшьләре. Шулай да ничә айлардан соң тамчылар бүген беренче тапкыр Асиянең җанындагы каралыкны таратырга теләп тыпырдаша кебек...

Яз! Ул бит тереклекнең уянуы. Кышкы салкыннарны йокымсырап кичергән агачларның, чәчкә-гөлләрнең, уҗымнарның тамырларында яшәү суты уянып, ул дәртнең тамырлар, кәүсәләр, сабаклар буйлап таралуы.

– Без исән! Аллага шөкер! Зәмһәрир салкыннарда чыныгып, үлмичә, корымыйча язларны каршы алдык. Һәм без дөньяда яшәп, үзебез артыннан яшь үсентеләр калдырып, дымлы, уңдырышлы, йомшак, бәрәкәтле җиргә орлыкларыбызны чәчеп, нәсел калдырырбыз.

Гомер шулай дәвам итә.

Кыш артыннан яз килми калмый – кайгы-хәсрәтләр артыннан куанычышатлыгы килә, Асия. Сиңа да матурлыгың кире кайтыр. Кайтыр, Алла боерса, һәм мәхәббәтең, ярату-сөюләрең дә әйләнеп кайтыр. Тагын аз гына, бер чеметем генә көтәсең калды. Доктор әйтте ич:

– Шаһзадәң һаман сине көтә, тиздән, бик тиздән күрешерсез, – диде.

– Юк! Беркайчан да! Ул мине мондый котсыз хәлдә күрергә тиеш түгел.

– Бу бит вакытлыча гына, кызым, – диде Ян Михайлович.

Бүген беренче тапкыр бераз күңеле күтәрелеп, күңелсез уйларыннан арынырга теләп ята иде Асия. Инде көзгесе дә бар, тик әле аны йөзенә якын китерәсе килми, чөнки ул элеккеге чибәр, матур, бит урталары янып, күзләре ут чәчеп торган кызны күрергә тели.

Кинәт ишек шакыдылар. Аннан иңенә чытыр ак халат элгән, мәһабәт гәүдәле, күзлекле бер ир-ат килеп керде.

– Исәнме, чибәркәй! Мин – Яков Янович. Профессор Ян Михайловичның улы булам, – диде ул. – Без сине әти белән үзебез уйлап тапкан ысул ярдәмендә дәваладык. Көн саен нәрсәдер үзгәртеп тордык. Кая, карыйм әле җәрәхәт урыннарыңны.

Асия өстенә япкан җәймәне куллары белән чытырдатып кысты да күзләре генә күренерлек итеп тартып куйды.

– Юк, кирәкми! – диде ул, оялып.

Бу ир-атка, бик күп булса, утыз биш яшьләрдер. Үзе үтә дә чибәр иде.

– Асенька! Мин бит доктор, оялып торма. Эштә мин синең кебекләрне көн саен күрәм.

Шулчак ишектән, балкып, карт профессор үзе килеп керде:

– Асенька, син инде минем улым белән дә танышып өлгергәнсең икән. Без сине Яков белән бергәләп дәваладык. Димәк, ике ил бергә эшләдек. Россия һәм Израиль. Мин бүген бәхетле. Без сине дөрес дәвалаганбыз. Минем улым – профессор Яков үз күзләре белән күреп ышансын инде моңа, рөхсәт ит. Оялма!

– Асенька, сиңа зур рәхмәт! Тәмуг газапларына да түздең бит! Хәзер барысы да артта калды инде. Синең тәнеңдә бер җөй эзе дә калмаячак.

Бу кабырчык кубып төшәчәк. Әлегә кызыллык калыр-калуын. Ләкин син бик чибәр булачаксың. Ышан миңа, гүзәлкәй, – диде Яков һәм елмаеп әтисенә эндәште: – Әти, ул әле безне туена да чакырыр. Аның егете бардыр бит?

– Менә өченче ай инде көн саен аның янына бер шаһзадә килә, көн саен Асия янына кертүләрен сорый. Ася, озакламый мин сиңа көзге бирергә дә рөхсәт итәчәкмен. Вәгъдә! Барысы да яхшы икәнен үз күзләрең белән күрерсең.

Саубуллаштылар. Профессор белән улы чыгып китте. Асиянең өч ай буе әрнеп торган җанына өмет чаткылары салып, яз кояшы балкып торган бүлмәдә ышаныч, җылылык калдырып чыгып китте аталы-уллы яһүд докторлары.

Асиянең йөзенә елмаю кунды. Ул яшәячәк. Элеккеге кебек матур булып, шаян булып яшәячәк. Тиздән, бик тиздән Газиз белән дә күрешер. Тик кайчан соң ул «тиздән»? Тизрәк-тизрәк котыласы иде бу кабыктан!

Авылга кайтасы иде. Әти-әнисе, энесе, сеңлесе янына. Алар инде нидер сизенеп, ут йотып ятадыр. Асия матрас астына яшереп куйган көзгесен алып, бу юлы инде бик үк курыкмыйча йөзенә китерде. Бүген инде шактый гына кабык кубып, кызыл-шома бит тиресе киңәя төшкән.

Асиянең бу юлы йокысы да тынычрак булды. Баласын эзләп, каршысына чыккан ана бүре кызның үзәкләрен өздереп сызлаган тәненнән итләрен умырып-умырып ботарламады. Ул баласын ияртеп, җәйрәп яткан ап-ак кар өсләтеп, Ялантау болынына таба чабып китте. Асиягә карап, хәтта елмайгандай итте ана бүре. Кыз уйлап куйды: әллә бүреләр дә елмая беләинде?! Бүре артыннан уйнаклый-уйнаклый юырткан баласы исә шундый йомшак кебек тоелды.

«Әниеңне таптыңмы, бәләкәч, шуңа сөенәсеңме?» Ул да булмады, бүре баласы, Вәкилнең бүрегенә әйләнде дә, түмгәләп, җилләр иркенә ияреп, Ялантау түбәсеннән аңа таба тәгәрәп төште. Әле генә елмаеп, уйнаклый-уйнаклый, ап-ак кар өстеннән чапкан ана бүре исә елый иде. Яшькелт-соры күзләреннән бертуктамый яшь ага.

«Кара, нәкъ кешеләр кебек елый бит ана бүре. Баласын югалткан ана кебек елый».

...Йөзенә төшкән кояш нурлары уятты Асияне йокыдан. Әле баласын тапкан ана бүре кебек, күзләрен ачып, йөзенә төшкән кояш нурларына карап елмайды да бугай!

Өч айга беренче тапкыр керфекләренә елмаю кунды кызның. Ул бит элеккечә, яшьлекнең үзе кебек матур булачак! Бәхетле булачак! Әтиле-уллы яһүд профессорлары кебек бәхетле булачак Асия! Нинди яхшы кешеләр. Асия үзе дә: «Мин дә шулар кебек үк кешеләргә ярдәм итеп яшәячәкмен!» – дип күңеленнән ант итте кыз.

«Үләм, бетәм, тик ничекләр итеп кенә үләргә?» – дип, төннәр буе йокламыйча, яшьсез генә елап яткан кыз бала! Әнием, бәгырькәем! Мин сезгә бүген элеккечә озын итеп хат язачакмын. Элеккечә чәчәкләп-чуклап, сүзләремне уйлап, һәр хәрефне энҗеләр кебек тезәчәкмен.

Сез бит мине уйлап, балалар нидер әйтеп бетермәде дип борчылып,

ләкин минем исән-сау булуыма күңелегездән ышанасыгыз килеп, үзегезне юатып яшәгәнсездер.

Әни, җаным! Биш балаңның бишесе өчен дә хәсрәтләнеп яшисең бит син. Ана, баласына килгән бар хәсрәтне йодрык кадәрле генә йөрәгенә җыеп, җанын айкап, сулкылдап, сызлап, әрнеп тора. Ләкин үзе әти-әни булмаган кеше бу халәтне аңламый гына.

Юк, әни, кызыңның күңеле далада түгел. Минем сезне борчыйсым гына килми. Әгәр минем өч ай буе ни хәлдә ятканымны, ниләр кичергәнемне белсәң, ни хәлләр итәр идең икән син, әни? Авыру йөрәгең бу хәсрәтне күтәрә алмас иде. Хараплар булыр идең.

Әнисен җәлләп, кызның күңеле тулды. Аның мендәре астында җанын җылытып, тышкы ягына пар аккошлар ябыштырылган түгәрәк көзге ята! Арча кызы Зәлия! Рәхмәт сиңа. Син бит миңа көзге генә түгел, өмет бүләк иттең. Инде беттем, ничекләр генә итеп Аллаһ тарафыннан тыелган мордар китү кебек гөнаһка барырга әзерләнгән, үзеңнән дә яшьрәк кызга өмет бүләк иттең бит син, Арча кызы Зәлия! Әтиле-уллы яһүд профессорлары! Сезне миңа, авыл кызы Асиягә, бу яшь, сылу, болан баласыдай уйнак кыз баланы коткарырга дип, Аллаһ Үзе җибәргәндер. «Россия белән Израиль – сине ике ил бергә дәвалады, – диде бит, күз камашырдай чибәр, кап-кара күзле, мәһабәт гәүдәле Яков Янович. – Син – яңа ысул белән дәвалап караган беренче авыруыбыз», –диде.

«Без синең белән үлемне җиңдек! – диде Ян Михайлович. – Ике ай буе синең баш очында әҗәл басып торды. Без сиңа булышкан булсак, син безгә булыштың, Асенька! Яңа ысулыбыз нәтиҗәле булды. Кызым, беләсеңме, тагын күпме кешеләрне коткарачак әле бу ысул? Түзгәнең өчен рәхмәт! Син аңыңны югалтып ятканда, мин елый идем... Шулай да терелгәч, ул эшеңнән кит. Синең директорың бөтен нәрсәне дә акчага сатып алып була, дип уйлый. Нишләсә дә ярый, дип ышана. Асенька, беләсеңме, безнең халык нәрсә ди: «Түбәнлекнең төбе юк, биеклекнең күге юк», ди. Онытма бу мәкальне!»

Дөрес сөйли бит профессор, түбәнлекнең төбе тәмугтыр инде ул! Тау башыннан гына да ничә тапкыр төшкәне булды кызның. Очасың, тыгыз җилләрне кочып очасың да очасың, тукталырмын димә! Ләкин бу рәхәт очу – йөзеңне кышның салкын җилләренә куеп очу, чөнки син соңыннан, чанаңны сөйрәп, түбәсе болытларга тиеп торган Ялантауга тагын менәсеңне, биеклеккә күтәреләсеңне белеп, түбәнгә шуып төшәсең. Ә бит Асия, каршысына ана бүре килеп чыгып, йөзен, гәүдәсен, аяк-кулларын канатып, җитмеш баскыч буйлап тәгәрәгәч, чиләк-көянтәләрен күтәреп, тау башына кабат менә алды!

«Беләсеңме, Асенька! Ялган документларга кул куйдырткан директорың синең китәсеңне белгән бит. Ул үзенең мескен гомерен коткарган. Әгәр сине элекке ысул белән дәваласалар, синең тәнеңдә бик ямьсез җөй эзләре калса, үзең әйтмешли, котсыз, ямьсез булыр идең! Ә аңа барыбер иде! Син исән калдың ни дә аңа, үлдең ни, кәгазьләрендә имзаң тора бит. Менә шундый кешеләр түбән тәгәри дә инде, алар беркайчан да үргә таба күтәрелә алмаячак. Ул миңа шундый зур акчалар тәкъдим итте! Алмадым. Шифаханәгә илтүләрен генә сорадым. Мин бу турыда

хокук саклау органнарына җиткерергә тиеш идем. Ул елап, ялынып-ялварып сорады: «Хәбәр итмәгез!» – диде. Нинди түбәнлек! Ир кеше үзен коткарып йөри, ә унҗиде яшьлек кыз бала, аның үз эшенә бармак аша каравы аркасында, харап була язды! Шунда мин улыма шылтыраттым. Ул: «Әти, кызны шифаханәгә салачаклар да стандарт ысул белән дәвалаячаклар. Нәтиҗәсенең нинди буласын үзең беләсең. Исән калса да… Әйдә, үз ысулыбыз белән дәвалап карыйк. Изоляторда безгә комачаулаучы булмаячак», – диде. Менә шуның өчен дә бу җинаять турында берәүгә дә хәбәр итмәдем. Ә хәзер тыныч бул! Барысы да артта калды. Мин сиңа торырга рөхсәт итәм. Көзге дә китерергә кушам».

Асия үзалдына елмаеп куйды. Юк инде, Ян Михайлович, без бит татар кызлары, синең юаш Асенькаң, көненә мең кат көзгедән үзенең көннән-көн күбрәк кабыктан арына барган шома йөзенә карап сөенә. Ничек дигәннәр әле, «татар тугач, яһүд елаган», дигәннәрме?

Әйтсәләр әйтерләр, ләкин мин сезне шундый яратам, Ян Михайлович. Кадерле бабам кебек якын булып, йөрәгемә кереп урнаштыгыз. Сездәй докторлар булганда, үлем килмәстер миңа. Сезләрдән бөркелгән яктылыктан качар кебек ул.

Асия пар аккошлы көзгене, соңгы көннәрдә тәмам үзенең дустына, серен сөйләр сердәшенә әйләнгән көзгене кулына алып, йөзенә якын китерде.

Көзгедән аңа инде йөзендәге кабыгы шактый коелган, чистарган урыннары шомарган, әмма кызыл йөзле кыз карап тора иде.

«Күрдеңме, Асия, инде елмай, – дия кебек иде көзге. – Авыр чаклар үтмәс кебек кенә тоела ул. Каралык артыннан аклык, кайгы-хәсрәт артыннан шатлык килә. Ә аннан соң яшьлек артыннан картлык килә. Анысы да бик кирәк. Чөнки картлыгыңда сине оныкларың, синең гомереңне дәвам итәрлек оныкларың көтеп тора. Алар синең бәхетең, бәхетле киләчәгең. «Гомерең бәхетле, бәхетең гомерле булсын!» диләр бит. Синең дә алдагы көннәрең бәхетле булыр, Газизең дә көтә, Ян Михайлович аны синең шаһзадәң, ди. Көн дә килеп, хәлеңне белешеп китә, ди».

Тиздән, бик тиздән ул Газизне күрер. Бу өч ай эчендә күргәннәрен түкми-чәчми сөйгәненә сөйләр. Алай дисәң, ул барысын да белә булыр инде.

Асия ишек ачылган тавышка башын күтәреп караса, сеңлесе хәл белергә килгән икән. Өч ай дәвамында бер көн калмыйча Асия янында булды ул. Сеңлесе аннан бер генә яшькә кече. Бухгалтерлыкка укый. Асиянең барлык сызлануларын үзенә алырдай булып, апасын саклады.

– Апа, кара әле, йөзең ничек чистарган. Тик кызыл гына. Болай булгач, тиздән сине өйгә чыгарырлар. Иң күбе тагын бер ай калгандыр.

Сеңлесе ятьмә сумкасыннан өйдән алып килгән тәм-томнарын алып, өстәлгә куйды.

– Әйе, сеңлем, Ян Михайлович та, барысы да яхшы, диде. Үзем дә бүген ничектер тынычлап йокладым. Аллага шөкер!

– Апа, әйдә, әти-әниләргә озын итеп хат язып җибәр әле. Без инде абый белән алдый-алдый арып беттек.

– Үзем дә шуны уйлап, бүген язармын, дигән идем. Эштән кызлар

килде, озын-озак торып чыгып киттеләр. Кичкә язармын, сеңлем! Озын итеп язармын!

Бу көннәрне күрермен дип көткән идемени соң Асия?! Кайчан да булса, бу әрнү-сызлаулар бетәр дип аның уена да килмәде ләбаса.

– Сеңлем, мин көн саен бер төш күрә идем. Мишараб абый атып алган бүре баласын эзләп, минем каршыга чыккан ана бүре миңа ташлана да тәнемнән, йөземнән, аяк-кулларымнан итемне умырып-умырып йолкый. Шундый авырта иде! Чыдап булмаслык итеп авырта. Ә бүген ана бүре, баласын ияртеп, уйнаклый-уйнаклый яз кояшыннан челтәрләнә башлаган кар өстеннән Ялантауга таба чабып китте!

* * *

Әйе, әйе! Баласын эзләп йөрүче ана бүре Вәкилнең җилләр түмгәләк кебек тәгәрәтеп алып киткән бүреге артыннан чапты. Баласы дип белеп алданып, сөенеп чапты! Ә ул баласы түгел, кадерлесенең тәненнән тунап алган тиредән тегелгән бүрек икәнен белгәч, Асиягә әйләнеп карады һәм елады!

«Асия! Мин бит сиңа тимәдем, япь-яшь кыз баланың гомерен өзмим әле, аның бит беркем алдында бернинди гаебе юк! Кешеләр үз гамәлләре өчен үзләре җавап тотарга тиеш. Сунарчы Мишараб, явыз Мишараб гамәле өчен ник бу сөттән ак, судан пакь баланың гомерен өзим мин, дип тимәдем сиңа! Ә кешеләр минем баламны атып үтереп тунады».

Төшендә күргән бүренең яшьле, яшькелт-соры күз карашыннан шуларны аңлады Асия. Таудан, Ялантау түбәсеннән тәгәрәп төшкән бүрекне газизе дип уйлап, ничек сөенгәндер ана бүре. Ә аннан соң алданганын аңлап, Асиягә карап елагандыр!

Кыз да беренче мәхәббәте, үзе белән гомерләре буена рәттән барырга тиешле, аның ябык иңнәреннән көянтә-чиләкләрен алып, түбәсе болытларга тиеп торган Урыстауга менеп киткән Вәкилне гомерлек ярым дип алданды.

«Авырдыр сиңа, Асия, чиләкләреңне тау башына үзем алып меним». Бу сүзләрне кыз бик күп тапкырлар исенә төшереп елмаер. Йөрәге җылыныр. Асиягә авыр вакытта, иңнәреннән авыр йөкне күтәреп алучы егет – Вәкил бар иде ләбаса. Баламны таптым, дип алданган ана бүре кебек мең тапкырлар үксеп елар кыз бала. Хыянәтне күтәрә алмас. Алданып, җилләр иркендә тау түбәсеннән тәгәрәп төшкән бүрек артыннан елый-елый чапкан бүре кебек! Юк, Асия еламас! Ул шаярыр, көләр. Ул бары тик кеше күрмәгәндә генә елар.

Күргән төше иртән-иртүк йокысыннан уятты Асияне. Озак итеп уйланып ятты ул. Әнкә бүрене жәлләде. Бүренең дә төшенә баласы кергәндер. Бүреләр төш күрәме икән? Күрәләрдер, аларның да җаны бар бит. Югалткан якыннарын, балаларын сагыналардыр!

Асия инде өч ай буе күрмәгән әти-әнисен, сеңелләрен сагына. Шундый сагына инде менә! Бүген үк йөгерә-йөгерә кайтып китәр иде. Әти-әнисенең фатихасын алмыйча чыгып киткәненә үкенеп, күпме елады кыз! Бабасы әйтте: «Әти-әни фатихасы гына бәхеткә-шатлыкка алып бара! Ата-ана фатихасы гына адәм баласын җәннәткә илтә. Әти-әнигә «Уф» дип тә әйтергә ярамый, кызым. Аллага тапшырдык», – диде.

Асия инде аягына басты. Акрын гына атлап, изолятор дип аталган бүлмәдә йөри ала. Сеңлесе килеп, чәчләрен юып китә. Көн саен диярлек абыйсы, туганнары килеп йөри. Аның мендәре астында кояш кебек түгәрәк, артына пар аккошлар ябыштырылган дусты, ахирәте – көзгесе ята.

– Көзге дускаем, әйтче миңа, мин элекке кебек матур була аламмы? – Пушкин әкиятендәге үги ана кебек көзгедән сорый кыз.

– Курыкма, Асия, син элеккедән дә матуррак булачаксың. Ян Михайлович дөресен әйтә, – дип җавап бирә түгәрәк көзге.

– Чыннан дамы?

– Ян Михайлович алдамый, син курыкма! Син бер дә кайгырма, Асия! Син бит тәмугның төбендә булып кайттың.

Бу сүзләрне көзге Асиянең бөтен тәне ташбака кабыгы белән капланган, үтереп кычыткан чакта әйткән иде. Юк, көзге түгел, кыз үзе бу сүзләрне көзгедән әйттерде. Асия бүген дә көзге дускаен, Арча кызы Зәлия бүләк иткән көзгене мендәре астыннан алып, йөзенә китерде һәм сөенеченнән елмаеп куйды. Көзгедән аңа кызыл, ләкин элекке кебек үк матур йөзле кыз карап тора иде.

– Йа Раббым, минем үзәкләрем өзелеп сораганнарымны ишеттеңме? Рәхмәт сиңа! Тәңрем, кичер мине. «Үземне үзем үтерәм!» дигән сүзләремне дә кичерә күр! Сабырлыгым, авырту-сыктауларга түземлегем җитмәде. Сабыр канатларым сынган иде шул. Тәмам өметсезлеккә бирелгән идем. Кичер, Тәңрем, – дип, янә кабатлап куйды Асия.

Ишек шакыдылар. Исәнләшеп, Яков Янович белән әтисе килеп керде.

– О-хо-хо! – диде Яков Янович. – Әти, безнең гүзәл шаһинәгә кара әле син. Битендә бер кутыр да калмаган. – Ул кулларын юды, Асиянең йөзенә якын ук килеп, микроскоптан караган кебек, йөзен, муенын, колак артларын карап, тикшереп чыкты.

– Әти! Бу синең һәм минем җиңү, аңлыйсыңмы? Юк, юк, бу Асяның җиңүе! Асенька! Син түземлегең, сабырлыгың белән үзеңә нинди бүләк әзерләгәнеңне аңлыйсыңмы? Рәхмәт сиңа, кадерлем! Ә без фәнни хезмәтләр язарбыз да бу ысул белән тагын бик күп кешеләрнең гомерен саклап калырбыз! Ася кебек өметен өзгәннәргә дә булышырбыз. Әгәр дә без аларга ярдәм итә алсак, Ася, монда синең дә өлешең бар. Рәхмәт сиңа!

Асиянең күзеннән бертуктаусыз яшь акты. Шатлык-куаныч яшьләре! Аның өстендә инде сеңлесе китергән йомшак йокы күлмәге! Кеше алдында ялангач ятмый. Ул инде утырып тора ала! Ул инде акрын гына йөри ала! Ул инде үзе кашык тотып ашый ала! Ул инде үз йомышын үзе үти ала! Нинди бәхет икән ул үз йомышыңны үзең үтәү! Нинди бәхет икән кеше күзенә карап, кешедән ярдәм көтеп ятмау! Адәм баласы аны үз башына төшмичә аңлый алмый. Асия дә белмәде. Хәзер белә. Рәхмәт сезләргә, Яков Янович һәм аның кояш кебек якты әтисе Ян Михайлович!

– Бүген сиңа көзге китерерләр, – диде карт профессор.

– Ә минем көзгем бар инде, – дип, кесәсеннән түгәрәк көзге дустын чыгарды Асия.

– Кайчаннан бар ул синдә һәм аны кем бирде?

– Бер ай элек. Сеңлем, – дип алдады Асия.

Карт профессор чал кашларын ничектер өскә күтәреп, якты күзләрен кысып, Асиягә карап торды да бөтен изоляторны яңгыратып көлеп җибәрде.

– Кара әле, Яков, мин Асяның татар кызы икәнен оныткanмын бит! Хәйләкәр дә инде үзе, карт дустына берни сиздермәде. Ә мин, без дуслар, дип уйлаган идем.

– Әти! Асеньканы бәхетле киләчәк көтә! Ул үзенең тырышлыгы, үҗәтлеге белән теләгәненә ирешәчәк. Ышан миңа, Ася! Хак әйтәм.

– Беләм инде, Яков. Бүген шаһзадәсенә дә керергә рөхсәт итәчәкмен.

– Әлегә кирәкми! Ул көн саен миңа хатлар яза, чәчәкләр китерә. Минем аңа элеккечә сәламәт булып күренәсем килә.

Саубуллашып, чыгып китәргә җыенды яһүд профессорлары.

– Рәхмәт сезгә! – дип озатып калды аларны кыз. – Мин сезне мәңге онытмам. Гомерем буйларына исемдә тотармын.

Шулай да, чыгып барганда, карт профессор Асиягә борылып карады да:

– Асенька, мин бүтән килмәм инде. Минем ярдәмем башка кирәкми монда, – дип елмайды.

– Мин сезне кайдан таба алам? Кайсы хастаханәдән?

– Юк, Асенька, мин улым белән Израильгә китәм, бөтенләйгә. Тель-Авивта тәннәре пешкән авыруларны дәвалаячакбыз. Без сине онытмабыз. Тагын… Бу директор белән башка эшләмә. Бик юньсез кеше ул. Кәгазьләргә кул куйдырганнан соң, бер тапкыр да синең яныңа килмәгән. Шәфкать туташларыннан белештем. Бер тапкыр да хәлеңне белмәгән…

– Үзем дә калмыйм. Һөнәремне дә алыштырам, Ян Михайлович.

– Хуш, Асенька!

– Хушыгыз, Ян Михайлович! Гомеремне саклап калуыгыз өчен мең рәхмәт Сезгә!

Профессорлар чыгып киткәч, күңеле тулып, и, елады Асия. Бушанганчы елады. Нинди якты кешеләр дә яши Җир йөзендә. Яһүдме ул, рус, чуваш, мукшымы – нинди аерма бар?!

Яһүд карты көн саен кыз янына килеп, улына көн дә шалтыратып, киңәшләшеп, Асиягә гомер бүләк итте. Юллары уң булсын, гел бәхеттә, рәхәттә генә яшәсеннәр!

Ишек шакыдылар. Асия тагын җәймәсен тиз генә йөзенә таба тартып куйды.

Ишектән…

*(Дәвамы киләсе санда.)*

---

Унберенче санны басмага тапшырганда, ут бетү сәбәпле, техник өзеклек килеп чыкты. Шуның аркасында романда кайбер хаталар калган. Укучыларыбыздан гафу үтенәбез.



Шәмсия
Җиһангирова

# ГОМЕР КЫШЫ ОЗАК ТОЕЛСА ДА...

## Карыйм да мин көзгеләргә...

Бөтен нәрсәм җитеш минем – күлмәк, туннар, алкалар...
Һәр күлмәккә – аерым туфли, өем-өем яталар.
Кием-салым, хушбуйлар да... – Бөтен нәрсә «фирменный».
Көнләшә күпме хатын-кыз, «Миңа кирәк, дип, шундый...»
Карыйм да мин көзгеләргә – үз-үземне танымыйм...
Кай арада юкка чыкты унҗидедә чагым, дим...
Иреннәрем – алсу алма, әле беркем үпмәгән.
Унҗидедә, әйтегезче, кемнәр сөю көтмәгән?!
Сөюнең дә иң чистасын, беркемдә булмаганын,
Егетләрнең акыллысын – сафлыкны зурлаганын.
Туксан, алтмыш, туксан иде нәфис гәүдәм үлчәме.
Әнкәм теккән күлмәгемнең алты клин итәге.
Кая алтын? Көмеш алка керми иде төшкә дә...
Туфлиләрем түгел иде нәфис биек үкчәдә.
Кия идем туфлиләрнең апамнан калганнарын:
Размер ярымга кечкенә... Чын әйтәм, ялганламыйм!
Сумкалар да, пәлтәләр дә апамнан кала иде.
«Яңа кирәк!» дими идем, тыңлаулы бала идем...
Бөтен уем уку иде, чит уй кермәде башка.
...Бер егет миңа эндәште, урамнан барган чакта.
Диде: «Мондый асыл затны кайсы әни үстергән?!» –
Җанымны тойды микәнни иске пәлтә эченнән.
Кояш кебек елмайды да туктатты барыр юлдан.
«Танышырга мөмкинме?» дип тотмакчы булды кулдан...
Оялудан үлә яздым пәлтәм, туфлием өчен...
Корт чаккандай йөгереп киттем, эшкә җигеп бар көчем...
Йортлар арасына кереп, калдым егеттән качып... –
Аңламадым – юл чатында язмыш калганын басып.
Язмыш кына түгел әле, бәхетем басып калган...
Ул чак моны аңлар өчен җитмәгән акыл чамам.

Карыйм да мин көзгеләргә... Хәтер яңара һаман.

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА (1951) – *шагыйрә, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты; «Төсле моң», «Якты сагыш», «Илаһият» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Каршы ала мине Казаным

Поезд вагонының тәрәзенә
Куеп яшь чылаткан яңагым,
Минутларны санап кайткан чакта,
Юлларыма сибеп карларын,
Аклык белән, пакьлек, сафлык белән
Каршы ала мине Казаным.

Җир читенә кадәр барып җитеп,
Поляр йолдызларның койрыгыннан
Үрелеп кенә тоткан чагында,
Туган җирдә калган йолдызларны –
Асыл егетләрне һәм кызларны,
Казанымны өзелеп сагынам.

Юлда күп йөрелә. Кайткан саен
Чыгып китәм тагын-тагын да...
Дәрья сулар, урман-таулар гизәм,
Киң Иделем, Казансуым белән
Ак Казаным, гүзәл, саф Казаным
Чыга мине каршы алырга.

## Әнкәм йоклап китте...

Бар тереклек кинәт тынып калды,
Сулар торды агышыннан туктап, –
Нәни бала кебек башын кырын салып,
Әнкәм бүген көндез китте йоклап.

Җәен-кышын күргәнем юк иде
Әнкәемнең эштән туктаганын.
Хәтерләмим көндез түгел, хәтта төнен
Уянмыйча тыныч йоклаганын.

Гомер буе һаман дөнья куды,
Җигелде ул аттай, куеп көчен,
Дүрт кызының һәрчак кияр киемнәре,
Җыяр ризыгы булсын өчен.

Шатланырга сәбәп булмаса да,
«Шөкер...» – дия-дия гомер итте...
Тын кал, Җиһан! Гомерендә беренче кат
Әнкәм көпә-көндез йоклап китте...

## Туеп киттем әле кешедән

Танышасым, күрешәсем килми,
Туеп киттем әле кешедән. –
Җылы тапмыйм нәүмиз күңелемә,
Калтыранам, туңам, күшегәм...

Байлык, акча, мөлкәт кирәк түгел,
Акыл үземдә дә җитәрлек...
Шулай булгач, кеше дигәненең
Нәрсәсе бар исең китәрлек?!

Күрдек инде... Ияртеп тә йөрдек
Түбән дигәннән дә түбәнне...
Ышанылды шушы буладыр дип,
Өлешеңә – көмеш дигәне.

Нинди көмеш, ди, ул! Тутык тимер!
Күпме чистартсаң да, агармас...
Изге гамәлләрең бәяләмәс,
Сиңа кеше итеп карамас.

...Күңелемә тимер йозак элде
Кешелексез кырыс бу заман.
Рас килде әнкәм әйткән сүзләр:
«Бер яхшыга, кызым, бер яман...»

## Калдыр мине язда

Гомер кышы озак тоелса да,
Алда әле кыска язлар бардыр.
Күңелемдә гөлләр бөреләнә...
Калдыр мине шул язымда, калдыр!

«Язлар кирәк түгел инде, дисең,
Мине гомер кышларымда калдыр». –
Гомерләрнең көзе узып киткәч,
Кышның да үз матурлыгы бардыр...

Бу дөньяда кышлардан соң язны
Көтеп яшәүчеләр тагын бардыр...
Беребез – кышта, беребез язда булыйк,
Калдыр мине язда, зинһар, калдыр!..

## Киткәннәргә җиңелдер дә...

Киттең...
Әле яңа... бүлмәм синең сыныңны күргән иде...
Суынганчы эч әле дип, чәй ясап биргән идем.
Озак түгел! Үтте бары күз ачып йомган ара...
Күрми шул сине күзләрем никадәр караса да!
Киттең...
Борылышка җиткән чакта әйләнеп, кул болгадың...
Синең арттан әрни-сыкрый йөгерде уй-моңнарым.
Киттең...
Озак тордым, бәлки тагын борылып карар диеп...
Юк шул! Киттең! Киттең? Киттең... Горур башыңны иеп.
Бергә чакта ник туйганчы карамадым, сөймәдем?!
Хәзер күпме караса да, күрмәс сине күзләрем...

...Мин тагын хаталандым шул! (Инде ничәнче кабат?!)
Әйтсәләр дә: «Юләр булма! Күзеңне ачып ярат!»
Мәхәббәттә – бар да юләр! Мин генә үзгә булмам.
Сәбәпләргә, гайбәтләргә тотам да күзем йомам!
Һәм яратам! Үлеп-үлеп! Җанымны телә-телә!
Сөюнең бар ләззәтләрен тик яратканнар белә!
...Киттең!
Хисләр генә бөтерелә җанымда өер-өер...
Кемнәр мине елатыр да кемнәр көлдерә белер?!
Киттең...
Инде менә ничә минут ишетелми тавышың...
Киткәннәргә җиңелдер дә... Калганнарга авыр шул...
Киттең...
Әле бик-бик озак сине назларым озата барыр!
Мәңге җуелмас сурәтең, җанымда уелып калыр...

## Зарурлык һәм мохтаҗлык

Мохтаҗлыкмы кем беләндер чәйләр эчеп утыру? –
Ризык тәмен татымыйча, корсагыңны тутыру?
Мохтаҗлыкмы, ирем диеп, сөймәгәнгә тән терәү? –
Көнләшмәс өчен, үткәндә яныңнан ирле берәү...
Мохтаҗлыкмы булу бүген кемнеңдер сөяркәсе? –
«Минеке бар!» дияр өчен, кемнедер сөялтәсе...
Эзләмим андый терәүне, теләмим аркадаш та –
«Ирем яклар!» дияр өчен дөньяви якалашта.
«Алар юк шул...» дисәләр дә, бар әле чын ирләр дә. –
Зарурлык шундый: бер ирне онытылып сөяргә!
Зарурлык кына түгел шул, бу – мәңгелек мохтаҗлык!
Артык хыялланма, диеп җиңем тарта чынбарлык...

## Җирдә яшәп тору нигә кирәк

*Әз дә җитә, күп тә бетә...*
Халык сүзе

Кемгә җитә, кемгә җитмидер шул...
Ризалашам, бәхәсләшмим һич тә.
Бер күрергә нәүмиз яшәгәндә,
Барлыгыңны белү миңа җитә.

Барлыгыңны белү миңа җитә
Үзеңне бер күреп сөйләшкәнче.
Ә сөйләшкәч... яратасым килә –
Көнләшмәүчеләр дә көнләшкәнче!

Татыйсым һәм татытасым килә
Әле беркем татымаган назны...
Җиһанны бер тетрәтәсем килә
Шарран-яра ачып сиңа җанны!

Курыкма син «көнләшерләр, диеп,
Кеше күзләреннән качып булмас...» –
Борчылма ла, ул назларны, җаным,
Синнән, миннән башка беркем тоймас!

Тояр иде, бәлки, тик ул хисләр
Бөтен кешегә дә бирелмәгән,
Аны безгә күктән иңдергән бит
Илаһи зат – күзгә күренмәгән...

Саклый алсак иде шул хисләрне
Соң көнгәчә, актык сулышкача...
Җирдә яшәп тору нигә кирәк
Җанда мәңге дөрләр ут булмаса.



Рәҗәп
Бәдретдинов

# НАМАЗЛЫКСЫЗ НАМАЗ

хикәя

1

Иртәнге намазын озаклап, бик ихластан Аллаһка буйсынып, бирелеп укыды Рамазан. Намаздан соң бөтен әрвахларга аерым-аерым дога кылды. Аерым алып, Шаһидулла кызы Зифа апасына Аллаһтан сәламәтлек, җан тынычлыгы, бәрәкәтле озын гомер сорады. Соңыннан намазында киткән кимчелекләре өчен Аллаһтан гафу сорап ялварды. Кимчелекле намаздан гына була күрмәсен иде дип, бөтен намазын бик дикъкать белән, ашыкмыйча укый башлады ул хәзер. Тырышып, гарәп хәрефләре өйрәнде, Коръән укып, аның могҗизаларына таң калып, китап кушканча гамәлгыйбадәт кылып яшәргә омтылды. Соңгы вакытта ул бигрәк тә Аллаһка нык сыенды. Кешеләр арасында яшәп тә, кешеләрдәге кешелеклелек сыйфатлары булмауга, булганнарының да отыры югала баруына борчыла иде ул. Кешелек җәмгыятендә кешелек кагыйдәләре өстенлек итәргә тиеш тә бит! Шуңа җавап таба алмый изаланды ул. Кешеләр арасында яклау тапмаганга, ярый Аллаһым бар, дип сөенде. Гаҗәп бит, сыеныр кешең булмаса да, Аллаһы Тәгалә сине саклый, яклый. Аллаһтан теләгәнеңне сора гына, кулларыңны күтәреп, ялварып сора. Сорасаң, теләгәнеңне бирер. Сорамасаң – юк. Моны аңлавына мең кат шатлана, мең кат Аллаһка рәхмәт укый Рамазан. Ә бит бу гаделлекне аңламаучылар күпме?! Моңарчы да инде күпме вакыт шайтан коткысына «биелгән». Фани дөнья вакытлы, ә ахирәт – мәңгелек сәфәр бит югыйсә. Беренче пәйгамбәр Адәм галәйһиссәламне дә Аллаһ кызыл балчыктан бар иткән, ахырда һәммәбез кызыл балчык булып бетәбез бит. Җир барысын да тигезли. Ә бит аның да намаз укыганын өнәп бетермәүчеләр, бу юлга басуын кабул итмәүчеләр булмады түгел, булды. Үз туганнары арасында да булды. Шунысы йөрәкне бик телгәли, сулышны кыса.

Шулай берчак, өйдә кеше юк вакытта, тиешенчә тәһарәт алып, икенде

Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ (1971) – *язучы, филология фәннәре кандидаты. «Каһәрле еллар корбаны», «Төнге яктылык» исемле китаплар авторы. Балтач районында яши.*

намазын түр якта укырга ниятләп, намазлыгын зал яктагы бүлмәгә җәеп, азаннар яңгыратып, ихластан намазга кереште ул. Якты, кояшлы җәйге көн иде. Бүлмәгә төшкән кояш нурларының назыннан эреп китәрлек булып, җиһанга рухи сафлык бөркелә. Бүлмәгә генә сыеша алмыйча, уйнаклашып чапкан нур тамчылары бөтен гәүдәгә урала. Аллаһы Тәгалә белән пәрдәсез сөйләшү шушы буладыр инде. Калебләр нечкәреп, Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген тоеп, ниятләп, бисмиллаһ әйтеп, «Фатиха» догасын укый башлады Рамазан. Тоташтан нурга төренеп, ишектән кеше кергәнен дә шәйләмәслек булып, Аллаһка сыенып, намаз-догалар укыды ул. Һәм кинәт каршысында шактый ук «төшереп» алган абыйсы пәйда булды. Әллә нигә бер эчсә дә, бу юлы нык кына чайкала иде. «Дебил, – дип, тамак төбе белән акырды ул Рамазанга, – дебил, ахмак, тиле». Нур тамчылары шулчак тәгәрәшеп коелды, каядыр югалды. Иреннәр дога аятьләрен әйтүдән шып туктады. Фәрештәләрне качырып, дөрес эшләмәде абыйсы. Үзенә кычкырсалар да, аларга каты бәрелмәсен иде инде. Намазны бозарга, туктатырга, өзәргә ярамаганын белә иде Рамазан. Түзде, Аллаһ сабырлык биреп, тыеп торды аны. Энесеннән шушы мизгелдә каршы бер сүз дә ишетмәгәч, бармагы белән баш тирәсен боргалап күрсәтте дә чайкала-чайкала чыгып китте. Әтисе урынына калган якын туганы – абыйсыннан мондый сүзне ишетермен дип, һич тә уйламаган иде ул. Ярдәм итәргә теләп, янында һәрчак бөтерелеп йөргән абыйсын шайтан алыштырганмыни? Чарасыз калган ир, намазын тәмамлап, тәсбих тартырга кереште, догалар кылды. Кемгә комачаулый соң аның диндә булуы, кемгә зыяны тия, кемгә?..

**2**

Намазлыгын җыеп алырга иелгәч тә, торып китмичә, бик озак карап, уйланып утырды ул. Аллаһка сәҗдәләргә китеп ялвару өчен аяк асларына салына торган бу намазлыкны кем уйлап тапты икән? Чисталык һәм сафлык билгесе дә бит әле ул. Кыйбла ягына Кәгъбә рәсеме төшереп ясалган, иң өске башына көньякны күрсәтеп торган компас урнаштырылган кадерле тукыма, намаз укыганда таяну ноктаңны билгеләүче, Аллаһка якынайтуда сиңа көч бирүче, намаз уку өчен генә кулланылучы, чисталыкны саклаучы, фани дөнья белән ахирәт дөньясын аерып торучы, иманлы бәндәләрнең җәннәт ачкычы да бит әле ул намазлык. Аннан башка намаз укып буламы икән ул? Юктыр, юктыр. Укып булса да, кабул кылынмас шул. Намазлыклар җәеп, башыңны Аллаһ каршында иеп намаз укуларга җитәме соң инде?!

Намазлыкның маңгай, аяк һәм тез башы тигән урыннары инде таушала башласа да, ул бик кадерле, якын иде аңа. Хаждан Зифа апасы алып кайткан намазлык шул бу. Әй, гомерләр диген. Әнә шул хатирәләренә бирелеп, тәкъдирдә язылганнарны барлый башлады Рамазан. Ашыкмыйча, кабаланмыйча, гомер йомгагының чуалган урыннарын сүтә-сүтә барлады. Кая ашыксын инде ул, елап утыра торган балалары да, һәр сүзен җөпләп, карашыннан аңлап алып үсендерә торган үз насыйп яры да юк. Булды бит алар. Тик нигәдер парлы язмыш корулары гына барып чыкмады, нишләмәк кирәк. Аллаһы Тәгаләнең эше. Язылган яралы язмышлар да гыйбрәт өчен кирәк бит ул Аллаһка. Намазлык бер тарихи истәлек кенә түгел, ә җан тынычлыгын да ирештерә торган серле бер әйбер булып

калды аңа. Мәктәптә эшләгән еллар истәлеге дә әле ул. Эшләде дип, Рамазан хәзер дә эшли алырлык әле. «Выслуга» белән иртәрәк пенсиягә чыкты да, мәктәбеннән таякка таянып дигәндәй, титаклап качты. Качмас та иде, юк шул, юк аңлаучы, эшен тиешенчә бәяләүче чын ихлас олпат затлар – җитәкчеләр калмады. Ярдәм итмәсәләр дә, һич югы эшләгән кешегә комачау итмәсеннәр иде инде. Мәктәпләрне эреләндереп бетергәч, авыл җирендә эш табулары бер дә җиңелләрдән түгел хәзер. Авылда да балалар азайды. Эшсезлектәнме, җиңел тормыш эзләпме, авыл халкына булган карашның соң дәрәҗәдә түбәнәюеннәнме – яшьләр шәһәргә агыла башлады. Иман орлыклары салучы авыл укытучыларына булган җылы караш, уңай мөнәсәбәт юкка чыкты. Авыллар мескенләнеп, моңсуланып калды. Әй, бигрәк әрсезләр басты шул дөньяны, эш күрсәтәме, юкмы, анда эшләре юк, тик түрә генә булсыннар да синең өстән идарә итсеннәр. Аларга «подчинённый» булып ятканчы дип, вакытында эштән туктады ул.

Авыр, бик авыр булды аңа кисәк кенә эштән туктау. Чабышкы атны тыеп торуга тиң иде. Җимертеп эшли алырлык көч һәм мәктәп белән идарә итәрлек куәт, тумыштан бирелгән сәләт, тырышлык, үҗәтлек тә бар иде бит әле аңарда.

Идарә итү сәләтенә Зифа Шаһидулловнадан өйрәнде Рамазан. Кырыс булырга да, таләп итәргә дә, сүзен курыкмыйча әйтә белергә дә. Гадел булды. Булсын дип эшләде. Үзенә дә, эшенә дә хилафлык китермәде. Кирәк вакытта таләпчән дә була белде. Бүген шунысы өчен куана Рамазан. Мәктәптән саубуллашып чыгып киткәндә дә: «Берәрегезне рәнҗеткәнем булмадымы, рәнҗеткән булсам, зинһар, гафу итегез», – диде.

**3**

«Зифа апаның хәлен белеп кайтырга кирәк әле», – дип уйлады ул. Авырмаса да, ялгыз гомер итүче авыл апасына болай да авыр. Кайчак аның мондый хәлгә төшүенә үзе дә аптырый Рамазан. Кияүгә чыкмады, балалары булмады. Нәрсә өчен яшәргә соң алайса? Эшли белде Зифа апасы. Ир-атларга биргесез иде. Ыргылды шул ул, һәрчак алга ыргылды... Ыргылды – барыбер егылды... Әй заманалар. Аның мәктәбе генә алдынгы урыннарда барсын да мактау тактасыннан төшмәсен. Беренчелек авырлыклар аша бирелүен белмиме ул? Белә. Тик ничек? Нәрсә бәрабәренә? Яктылыкны караңгылык алыштыра бит. Тик тору халәте юк. Тик тору өчен дә алга барырга кирәк. Беренче булу өчен эш күрсәтү сорала. Томырылып чапкан җиреңнән абынып егылсаң да торып чабасың, чаба алмасаң – шуышасың, аягыңның хәле бетсә – кулларың, телең, бар вөҗүдең белән куйган максатыңа таба хәрәкәт итәсең. Шуннан, син финишка беренче килеп җиттең – аннан нәрсә? Ярый, мактадылар, ди. Ниятең шул икән – теләгәнеңә ирештең. Эгоистларга шул мөһим икән, димәк, булды. Аннан ни?

***

Туксанынчы еллар уртасы иде. Зифаны Таллык мәктәбенә директор итеп билгеләделәр. Мәктәп үзе юк әле, салына гына.

Казаннан уку йортын яңа тәмамлап кайтучыларны бергә туплап,

өр-яңа кадрлар белән эшли башлады Зифа Шаһидулловна. Моңарчы башка мәктәптә директор урынбасары вазифасын башкарган ханымга яңа эшкә кереп китүе артык авыр булмады. Тартынып торырга урын да калдырмадылар аңа:

– Яңа мәктәпне шушы җәйдә җиткереп, балалар кабул итәрлек итеп ясап бетереп, уку елы башлануга өлгертәсең, – диделәр. Кайда ул өч айга сузылган җәй? Ике айда җиткерергә, диде район башлыгы. Ерак аралардан башка мәктәпкә йөреп укучы Таллык мәктәбе укучыларына җай чыга анысы, үз авылында мәктәп булу кемгә тәтегән әле?! Җитмәсә, өр-яңа мәктәп. Дөрес, биредә башлангыч мәктәп бинасы бар-барын, анысы да бик нык тузган. Бер ишегалдындагы балалар бакчасы да кызыгырлык хәлдә түгел. Урта мәктәп кирәк тә кирәк бу авылга. Тик барлы-юклы ике айда нигезе дә булмаган мәктәпне ничек җиткермәк кирәк тә, яңа уку елына ачарга кирәк, ди? Җитмәсә, суы, газы, уты да кирәк була бит әле аның. Ай-һай, булырлык әйбер турында сөйләшәме икән бу җирлек рәисе Миңсур абый да, өстәгеләргә кушылып. Ул үзе алып килде дә инде Зифаны Таллыкка, үзе директорлыкка тәкъдим итте. Бар ышанычы шул Зифа иде.

– Утыр машинага, киттек Таллыкка, – диде авыл җирлеге башлыгы.

Бер сүз эндәшмичә барды алар. Фикерләрен тупладылармы, әллә инде сүзне нәрсәдән башларга белмәделәрме. Кайчак эндәшмәвең дә хәерлегә була бит. Зифа да шулай тиеш икән дип, артык авыз ачмады һәм, риза булмыйча хәл юк дип, артык киреләнмәде дә. Таллыкка килеп җиткәч:

– Килеп җиттек, төш машинадан, кабул итеп ал мәктәбеңне, – дип коры гына сүз катты Миңсур абый авылдашына. Әйтәсе сүзнең кайчак коры булуы да ярап куя шул. Хис белән түгел, акыл белән эш итә торган мәсьәлә бу. Шуңа да ике җитәкче дә, сүзсез генә аңлашып дигәндәй, салынасы мәктәп урыны белән танышырга китте...

***

– Җитешәбез, дип сүз биргәнбез икән, җитешәбез, – дип тынычландырды колхоз рәисе Мидхәт Гайсин яңа мәктәп директорын, чираттагы идарә җыелышында. – Түбә ябылган, идән-түшәмнәр бар, ишек-тәрәзәләр куелган, щитовой мәктәп өчен тагын ни кирәк?

Артык кабаланырга ярамаганын да белә Зифа Шаһидулловна, тик менә күңеле тыныч түгел. Мәктәп кадәр мәктәпне бер җәйдә төзеп бетереп, беренче сентябрьгә өлгертеп булырмы? Җиһазларга да заявка бирелгән, су да булырга тора. Газ өчен мәктәп артына кечкенә генә бер будка ясарга кушалар, анысын да укытучылар, хезмәткәрләр белән эшләп чыгып булыр. Тик әле тулаем кадрлар составы да тупланмаган бит, методик әсбаплар бөтенләй юк. Читтән килүчеләр булса нишләргә, ерактан килгән укытучыларны кайда урнаштырырга? Исәбе-хисабына чыга алмый торган йокысыз төннәре башланды Зифаның. Терәге – әнисе барлыгына куанып бетә алмый ул. Өйдән тактасын, кадагын, шиферын дигәндәй, мәктәпкә ташып торуына да күз йома әнисе. Өйдәге эшләрне эшләргә дә көндез вакыты калмый аның. Кичләрен, төннәрен эшләргә күнекте ул хәзер. Шуңа да ялт итеп, вакытында каралып торган өй эчләре, ихаталары авылга, күршетирәгә ямь биреп тора. Гүзәл гамь бөркелгән бу өйдән һәрчак яктылык сирпелә.

Кайчак, әнисе авырып китеп, күз алларын караңгылык та каплый. Кулдан эш төшкән вакытлары да була. Аның да әнисе – күпне күреп картайган авыл карчыгы. Авылда озак еллар фельдшер булып эшләгән, алны-ялны белмичә чапкан да чапкан. Үзе янында калган кызы аның өчен терәк тә, куаныч та хәзер. Тик таяк ике башлы шул. Кызы кияүгә чыгып китсә, бу ана ялгыз калып, гомерен моңаеп, зарыгып, саргаеп үткәрер иде. Бу очракта ана кызы белән, тик кызы гына ялгыз. Янында – әнисе, эштә – хезмәттәшләре. Шулай берчак, классташлар очрашуына баргач, Зифа бик матур итеп, истә калырлык итеп әйткән иде гаиләләре, балалары, ирләре белән мактанышып утырган элеккеге сабакташларына.

– Кемдер мине бәхетсез, дияр. Ялгыз яшәү авыр, дошманыма да теләмәс идем мондый картлыкны, дип уфтаныр. Бәхетсезләр рәтендәгеләргә мескен итеп карар. Ләкин мин бәхетсез түгел. Мин бик бәхетле. Аллаһка шөкер, янымда әнием бар. Яраткан эшем бар. Мәктәбемдә 150 дән артык балам – укучыларым, 20ләп укытучым, хезмәткәрләрем бар. Алар минем белән исәпләшә, хәлләремне белешә. Алар өчен мин дә кирәк. Аларның һәркайсы өчен борчылам. Кирәксә, киңәш бирәм, яклыйм, саклыйм. Иң мөһиме – алар миңа, мин аларга ышанам. Укытучылык – минем язмышым. Эшемне яратам. Бу бәхет түгелмени? Мондый зур гаилә тагын кайсыгызда бар?

Аның бу сүзеннән күпләр үзләренә сабак алды, кайсылары авыр көрсенде, тик күпләр, гадәттәгечә, җилкә аша гына карап, «подумаешь» дигән кыяфәт чыгарып, үз фикерендә калды. Бәлки, чыннан да, карашларын эчкә төбәгәннәр бәхетледер, үз дөньяларын корып, үз законнары белән яши алганга бәхетледер. Зифа да бәхетлеләр бәхетенә тиенеп яшәмәс иде дә бит. Булмады шул. Яшьлек дигәннәре арткы ишектән борылып кергәнче үтте дә китте.

* * *

Ил төкерсә, күл була дигәндәй, авыл кешеләрен, әти-әниләрне дә булачак мәктәп эшенә тарта алды Зифа ханым. Матур сөйли иде ул. Ышандырып, инандырып, әйтәсе фикеренә туры китереп, сүзен таба белә иде. Иске мәктәп ремонтын да бергә алып бардылар. Анысы да кирәк бит әле, яңасына гына сыймаслар иде. Җитмәсә, балалар бакчасын да мәктәп белән бергә беркетмәкчеләр. Район арасы да якын түгел. Көндәлек җыелышы да булып тора. Хакимияткә, юк әйберне сорап, кайчак көнгә ике тапкыр да, өч тапкыр да барырга туры килә. Очраклы машинага утырып йөрүләрнең михнәтен, Аллаһым, үзең генә беләсең. Район үзәгенә чаклы да егерме биш чакрымга җыела. Аннан әле бигрәк кире як та бу Таллык дигәннәре. Юл уңае булса, тегесе-монысы утыртыр, кертеп тә чыгарлар иде.

**4**

Рамазанның югары уку йортын тәмамлаган елы иде. Казанда аспирантурага кереп, борынгы әдәбият белән шөгыльләнергә, кандидатлык диссертациясе язып, шул кафедрада укытырга калдырырга иде исәпләре. Борынгы әдәбият егетнең үзен дә иләсләндерде. Үзгәртелмәгән, шомартылмаган, өстәлмәгән әдәбият ничектер күңеленә, рухына туры килә иде аның. Асылташ кебек бит ул борынгы әсәрләр. Коръән сюжетыннан алынган «Кыйссаи Йосыф» әсәре үзе генә дә ни тора! Әдәбиятның бөтен

кануннары буенча, кеше дигән зат рухы белән кабул кылырлык итеп язылган борынгы әдәби әсәрләрдә күпме матурлык, бәхет-сәгадәткә яраклы яшәеш үрнәкләре! Бәхетле тормыш итү өчен һәм кеше белән кеше арасындагы җылы мөгамәләгә яраклы ачкыч кебек ул чор әсәрләре. Хәзерге әдәби әсәрләр әсәрмени? Укып чыгуга онытыла торганнары күпме? Шигърияттә бераз икенчерәк, ичмасам. Кыска итеп, шома гына, бер калыпка салып, бөтен фикереңне дуамал бер хис белән әйтеп бетереп була шул шигърияттә. Синең табышың – башкалар игътибар да итмәгән нәрсәләрне күрә белү һәм, фикереңә тузан бөртеге дә кундырмыйча, үз вакытында халыкка җиткерү. Халык дигәндә дә, ул әле синең каршыңдагы якының, бакчаңдагы алсу алмаң, сайрар сандугачың, ялгыз таганың... һәм тагын әллә кемнәр, әллә нәрсәләр. Киң Иделең, кыя-тауларың, яу кырындагы соңгы ядрәң, туган якның арыш басулары... Шуларга тәкъдим иткән мантыйкый фикереңне ритмга саласың да эчтән генә матур бер көй табып моңланасың. Шигырь шулай туадыр. Асылы да шунда бит инде аның: үз күңел халәтеңне хисләр аша белдерү. Оста итеп җиткерә алу. Менә шул кирәк тә инде Рамазанга. Туйдырды күп сүзлелек. Гарык була иде ул озын-озак нотыклар сөйләп уздырган җыелышлардан да. Җаны белән сизә иде шул ул матурлыкны. Шуннан шигърияткә тартылды. Рухы шул якка борылыш алды. Борынгы әдәбиятның да чыганагы шигърият бит инде. Бу да юкка түгел. Изге Коръән дә шундый матур телдә иңгән бит. Бер артык сүз, бер артык хәреф юк анда.

Шул матур тәэсирләр, татлы хыяллар белән уралып йөргән көннәрнең берсендә Зифа Шаһидулловна, икеләнергә ирек бирмичә, мәктәпкә эшкә чакырды Рамазанны. «Киләсең. Сине урынбасарым итеп алам», – диде.

Таллык үз авылларыннан егерме биш чакрым ераклыкта булса да, ризалашты егет. «Калада сасы тулай тораклрда яшәп, ачлы-туклы яшәүләрдән бераз туелган да инде анысы. Әле бераз акча да туплап булыр. Тагын каян эш эзләп йөрисең? Булыр әле, өйрәнермен мәктәп эшенә дә, җитәкчелек эшенә дә», дип уйлады ул. Һәм ялгышмады. Барысы да әнә шул Таллык мәктәбендә үтте: борчулары да, шатлыкка уралган мизгелләре дә, беренче саф мәхәббәт утларында «иләсләнеп» йөрүләр дә. Намазга басып, Аллаһка якынаюлары да.

**5**

Директор белән аңлашып, иңгә-иң торып эшләде алар. Икесен дә уртак фикерләр, уртак сүзләр берләштерә иде. Икесе дә университетта бер үк факультет тәмамлаган. Икесен дә шул ук укытучылар укыткан диярлек. Тырышты Рамазан, күп укыды, күп нәрсәгә Зифа апасы өйрәтте, белмәгәннәрен белгәннәрдән өйрәнде. Карусыз иде шул ул. Дәресләр бүлгәндә дә, укытучыларга премияләр язганда да артык кысылмады. «Тиешен үзе беләдер, шуңа да ул директор», – дип уйлады. Эшләү дәверендә бер-ике күңелсез хәл дә булмады түгел, булды. Яктылыкны каплаган караңгылык кебек, көннәрдән бер көнне Зифа Шаһидулловна өстеннән әләк яздылар. Рамазан өчен көтелмәгән хәл иде бу. Кем? Нигә? Ай-һай, ат йөрәкләре бар икән бу кара хатны язучыда. Мәгариф министрлыгына юлланган бу шикаятьтә нәрсәләр генә язылмаган иде. Зифа апасын яклаудан түгел, бу эшнең, ничектер, яман, килешми торган әйбер булуына йөрәге

авыртты Рамазанның. Ничек инде шулай итеп астыртын эш йөртәләр. Барлык кешенең тынычлыгын алып. Җитмәсә, менә диген итеп эш күрсәтүчегә, эшен җиренә җиткереп эшли торган директорга. Эшләсәң дә, ярамыйсың, эшләмәсәң дә, ни хикмәт. Кемнең юлына аркылы төште икән Зифа апасы? Рамазанның күз алдыннан Таллык авылы, аның җитәкчеләре узды. Авылның картларын: бәйрәм саен мәктәпкә кунакка чакырылучы әби-бабайларын уйлады ул. 150дән артык баланың йөз-кыяфәтен, үз-үзләрен тотышын, яңа мәктәпкә мөнәсәбәтләрен барлап, читтән генә күзәтеп, һәрберсен уе белән йөреп чыкты. Аларга да таләп зур булды. Авыл балаларына таләпчән булмасаң, алар белән коры сөйләшмәсәң, алар сиңа үз иптәшләредәй карый башлый бит. Берәр бала кулы белән шулай эшләгәннәрме? Әллә берәр укытучы эшеме? Аларга да таләп каты куелды. Эшкә вакытында киләсе, дәрес бетүгә өйгә чабасы түгел. Атна саен ике чара үткәрәсе. Олимпиадалар, концерт-театрлар, класс сәгатьләре... Атналык эш алдан раслатылган булырга тиеш. Атнага бер үткәрелгән планёркада үтәлгән эшләр турында сөйләгәндә оялып торырлык булмасын дип эшләде укытучылар. Тукта, кем эше бу? Клуб мөдиреме? Китапханәчеме? Әллә берәр әти-әниме? Алай дисәң, мәктәп эчендәге хәлләрне алар каян белсен? Берәр укытучыдыр, мөгаен, дип уйлады Рамазан һәм ялгышмады.

Укытучылар яшь булса да, араларында төрлесе бар иде. Эш булсын дип йөрүчеләре дә. Хезмәт хакына, эш сәгатьләренә карамыйча, балалар арасында мәш килүчеләре дә. Директор янында бер төрле, синең белән икенче төрле, урамда өченче төрлеләре дә булмады түгел. Биредә эшләгәндә, ике елга Казанга китеп алырга да, кандидатлык диссертациясе якларга да өлгерде егет. Тик менә авыл мәктәбендә эшләү генә канәгатьләндерми иде Рамазанны. Авылда һава җитми башлагач, Казанны бер урап кайтса, дөньялары түгәрәкләнә иде аның. Шуңа калада уза торган барлык конференцияләрдә, семинарларда, бәйгеләрдә катнашырга тырышты. Аннан кочак-кочак китаплар белән бергә грамота, диплом ишеләрне дә кыстырып кайта иде. Әмма бу мактау кәгазьләренә элек-электән исе китмәде аның. Шуңа да хәзергәчә бер мактаулы исеме дә булмады. Әллә ничә талпынып та, калага китә алмагач, хәерлесе шушыдыр дип, төпләнеп эшләп калырга булды ул авылда.

**6**

Таллык мәктәбенә яшь кадрларны бөртекләп җыйды Зифа Шаһидулловна. Районнан ерак урнашкан бу авылга барырга атлыгып торучылар да бик күренми иде бугай ул чакта. Рус һәм инглиз телләреннән укытырга район үзәгеннән яшь кызлар килде. Илһамга ул география фәнен бирде һәм аны икенче урынбасары итеп билгеләде. Күрше авыллардан җыелган физик та, физкультурник, технология, математика, татар теле һәм әдәбияты укытучысы да яңа гына педагогия институтын тәмамлаган егет-кызлар иде. Кайсылары, педкөллият бетереп, читтән торып югары уку йортларына укырга кергән. Араларында атна-ун көнгә чираттагы сессиягә китүчеләр дә булгалады. Педколлектив тупланды туплануын, әмма ерып чыгып булырмы? Район, республика олимпиадаларында урыннар тәтерме? Конференцияләргә балаларны тартып булырмы? Авыл халкы, бигрәк тә

ата-аналар белән уртак тел таба алырлармы? Шушы мең төрле сорауга җавап эзләп йокыга китә һәм шул мең сорауга җавап эзләп йокыдан уяна иде Зифа Шаһидулловна. Авыр, ләкин мактаулы эш корбаннар сорый иде кайчак. Нишләтәсең, кем әйткәндәй, үзебез сайлаган язмыш.

**7**

Яңа мәктәптә укулар башланып, җитмәгәнне җиткереп, матур гына эшләп киттеләр үзе болай. Һәр укытучы үз урынында иде. Балалар да, күрше авылга йөреп арыгангамы, үз итеп, яратып йөрделәр яңа мәктәпкә. Моңа бигрәк тә балаларның әти-әниләре шатланып туя алмады.

– Юлда йөреп, тәмам арып-талып кайталар иде балалар. Кайткач, өй эшләрен эшләрлекләре дә калмый. Бу мәктәп бик шәп булды әле. Тамаклары тук. Вакыты җиткәч кенә баралар мәктәпкә. Аллаһка шөкер. Исән-сау эшләгез генә, – диде әниләр бертавыштан.

– Язгы-көзге пычраклар үзәкләренә үткән иде, – диде әтиләр. – Безгә мондый мәктәпләр эләкмәде инде.

Уку елы башланып, озак та үтмәде, мәктәпнең әти-әниләр комитеты сайланды. Балалар арасында да укучылар үзидарәсе эшен башлады. Тәртипкә салынып, эш җайланып китте, авыр эшләр бетте, дисәң дә була. Тик юк икән, ашханә төзелеп кенә килә бит әле. Бу уку елында өлгермәс, ахрысы. Хәер, монысыннан да чыгу юлын таптылар. Ашауны Мөслимә апа өендә пешереп алып килә дә, коридордагы тар озын өстәлгә клеёнка ябып, табынны шунда әзерли. Шулчак бөтен мәктәпкә тәмле аш исе тарала. Димәк, озын тәнәфес вакыты җиткән. Чыннан да, озын тәнәфескә кыңгырау чылтырауга, өстәлгә кайнар ашлар салынган тәлинкәләр тезелгән була инде. Элек башлангыч сыйныф балалары, аннан югары класслар, ахырдан укытучылар утырып ашый. Директор да шул коллективтан аерылмый. Ашауның ояты юк ла аның. Дөрестән дә, уку елы ахырына таба яңа ашханә дә өлгерде. Пешерү, савыт-саба һәм кул юу, утырып ашау урыннары җитәрлек булган бу ашханәгә бер генә санитарның да теше үтәрлек түгел иде. Пешекчеләр дә менә дигән. Осталыклары, тәҗрибәләре дә бар дигәндәй, карусыз эшлиләр. Балалар бәхете өчен тагын ни кирәк дигәндәй.

Коллективтагы ихласлыкны күреп, куанып бетә алмады яңа директор. Барысы да яшьләр, матурлар. Балалар матурлыкны, яшьлекне ярата шул. Яшь кешенеке яшь кешегә керә шул, әйткән сүзе үтемле була. Үзләре дә балага әйләнә иде яшь укытучылар укучылары югында. Уен-көлке, мәктәпкә генә сыймыйча, урамга, авылга ташып чыга иде кайчак. Нинди матур вакытлар! Хәмерсез бәйрәм итүләр, җыр-бию, бер-береңә төрттереп алулар, тәнәфесләрдә һәм дәресләрдән соң, кичләрен шуклыкка корылган әңгәмәләр. Театр, КВН уйнаулар, спектакльләр, концерт куюлар, дисеңме! Яшьлек ташып торган чак дип, юкка гына әйтмәгәннәр инде бу вакытны. Кызлар белән очрашулар, дисеңме! Иң кызыгы – кичке ашны әзерләү булыр иде. Мәктәп директоры Зифа апаларына анысы өчен дә рәхмәтле алар. Мәктәп ашханәсен дә укытучылар карамагына тапшырды ул. Егетләр, мәктәп лабораториясендә торганлыктан, мәктәп ашханәсендә туклана. Дәресләрдән соң, ашханәгә барып, калганны ашыйлар, кичкә үзләре пешерә иде. Шулар янына фатирда торучы кызлар да кереп кушылып, гөж килеп

ятарлар иде. Менә кайда ул романтика, менә кайда ул яшьлектәге кадерле минутлар! Бергәләп дәрес хәзерләүләр. Дәрес планнары, конспектлар язулар. Шулар арасында булган завучлар да нәкъ синең иптәшләрең иде бит.

– Иртәгә дәресеңә керәм, ныклап әзерлән, – дип хәбәр итүгә, тагын да ныграк итеп әзерләнә башлаучы укытучы кызларны карап утыру үзе бер тамашага тиң булыр иде.

Күпләп китап, газета-журнал укулар. Зифа апалары укыганны ярата иде. Шунлыктан Татарстанда чыга торган барлык газета-журналларга да язылa иде. Каян мөмкинлек тапкандыр? Укытучылар өчен методик кирәк-яраклар да күпләп алынды яңа мәктәпкә. Китапханәгә укытучылардан, балалардан, әти-әниләрдән өстәмә китаплар җыелды. Иш янына куш булсын дигәндәй, анысы да ярап куйды. Методик китапларның күбесен Чаллы укытучылар белемен күтәрү институтында эшләүче якташы аша китертте яңа директор. Менә эш җайланды дигәндә генә, бер проблема чыгып, барлык эшне чәлпәрәмә китерерлек, башлар Себер китәрлек хәлләр дә булып алды әле.

**8**

Мактаулы кыз туйда пырт иткән, дигәндәй, унберенчедә укучы бер кыз корсакка узды. Авыл җире өчен сәер, бик сәер күренеш иде бу. «Ничек шулай булган?» дип аптырады укучылар. «Әти-әниләре кая караган?» диеште өлкәннәр. «Позор» дип сөрән салды директор, өстәл сугып. Тик, Нәби малае әйткәндәй, «поздно» иде шул инде, эш эшләнгән, фактлар күз алдында. Вакыт узган. Нишләргә? Кыз да, егет тә начар гаиләләрдән түгел югыйсә. Тик менә аларның мәктәп яшендә булуы гына борчый. Әнә шунда директор Зифа апаларыннан да дөрес карар кабул иткән кеше булмагандыр. Аның бу адымын «ход конём» дип атап та булыр иде. Күпләр өчен мәгънәле чишелешкә корылган бу вакыйгада директор белән район мәгариф бүлеге җитәкчесенең ихлас сөйләшүе булмаса, әлеге маҗаралы роман ничек тәмамланыр иде икән? Бу очракта район мәгариф бүлеге башлыгының да теләсә нинди директордан көчлерәк булуы сорала шул. Менә кайда сынала ул «крышаң нык булу» дигән гыйбарә. Аңлады мәгариф вәкиле директорның ни әйтәсен. Килеште дә. Кабаланып, мөгез чыгарырга ярамаганын бик яхшы белә Зифа. Аннан бу эшләр өчен ни буласын да чамалый. Укучы кыз баланы, тиз генә гариза яздырып, өйдә торып укуга күчерделәр. Ярый торган эшме? Ярый, законга каршы килми. Тик бала алып кайтырга вакыт җитеп килгәнен генә белмәсеннәр. Баланың булачак әтисе дә укучы бит әле. Хәер, егет кешегә ни, аның проблемасы юк. Кияүгә алам, дип тора. Шыпырт кына никах укытырга да, тора бирсеннәр бергә, шулай теләгәч. Нәкъ шулай булды да. Кыз өендә имтиханнарга да, бала табарга да әзерләнде. Егет исә хатынлы булып куйды. Ничек зурга җибәрмәгәннәрдер. Әти-әниләр дә, авыл халкы да, укытучылар, укучылар, хезмәткәрләр – берсе дә чүпне тышка чыгармады. Ниһаять, мәсьәлә хәл ителде. Әйе, башларың Себер китәрлек эшләрне дә җайлы гына майтарып була икән. Әнә шуны белмичә изаланабыз кайчак. Юкса бөтен нәрсәгә дә чишелеш табып булуын, фәкать үлемгә генә чишелеш юк икәнлеген аңламыйбыз. Менә бит мәктәп җитәкчесенең үтемле сүзе аркасында хәтта мәктәп бакчасындагы ялгыз усак та яфрагын кыштырдатмады. Ә

бит берәүнең ялгыш фикере, тиеш булмаган адымы аркасында никадәр күз яшьләре коелыр иде. Фаҗигагә этәргән сәбәпләрнең берсе итеп, психологлар да нәтиҗәсен күрми торып сүз башлауны әйтә. Монда да, бер караганда, җинаятькә торырлык эш кылынган. Закон сагында торучылар хәл кылу юлын ничек чишсәң, хәерлерәк булудан чыгып эш итми, аларга фактлар мөһим, бөтен бәла дә менә шунда. Аларны гадел диген инде шуннан соң. Бу мәрәкәнең исән-имин генә төгәлләнүенә Аллаһка мең кат шөкер итте Зифа Шаһидулловна. Шуннан намазлыкка басты. Аллаһы Тәгаләгә ялварып, рәхмәтләрен җиткерде. Күңеле, йөрәге белән ялгышкан яшьләргә болай да авыр минутларында җанны эретерлек сүзләр таба белде. Әгәр шулай булмаса, ике якның да ата-аналарын инандыра алыр идеме икән ул? «Җылы сүз – җан азыгы», диләр бит. Таш кыяларны да эретерлек ихлас сүзләр алдында кем генә каршы тора алыр иде икән? Чыгарылыш имтиханнарына кадәр бәбәй табып, әни буларак төгәлләде бу кыз бала мәктәпне. Чыгарылыш тантанасында ире белән иңгә-иң куеп биегәннәрен күреп, Зифа апасы бу матурлыкны тудыра алуына һәм яшь парларның бәхеткә төренгән мизгелләренә куанып, күңеле тулып, читкә китеп, балавыз да сыгып алды. Ничектер якын итеп, үз балаларына хәер-фатиха биргәндәй тойды ул үзен. Булган – беткән. Тормыш дәвам итә.

**9**

Мәктәптә беренчеләрдән булып әхлак дәресләрен укыта башлау да Зифа Шаһидулловнаның зур табышы булды. Укытырга кешесе дә табылды. Чаллы шәһәрендәге мәдрәсәне яңа гына тәмамлаган күрше авыл егете Илфатны гарәп теле укытырга чакырып, бик дөрес эшләде ул. Район хакимиятеннән рөхсәт алгач, документлар белән раслаткач, әхлак дәресләрен расписаниегә кертеп укыту да авырлык тудырмады. Беренче класстан алып тугызынчы сыйныфка кадәр атнасына бер сәгать укытылган бу дәресләрне карарга-тыңларга тирә-як мәктәпләрдән, төбәкләрдән кеше өзелмәде. Эксперимент барып чыкты. Мәктәп белән ифтарлар, Корбан ашы уздырулар, Гает бәйрәмнәре – берсе дә калмады. Мәктәп яңа сулыш белән, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, иҗат киңлекләрен арттырып, ихласлык, мәрхәмәт төшенчәләрен өлге итеп алып эшли башлады. Шул батырлыклары, дини юнәлештә башкарган хезмәтләре өчен директор ханымны хаҗга да җибәрделәр.

– Мине Казанга аэропортка озатырсыз әле, – диде директор урынбасары Рамазанга. Озатмыйлармы соң инде шундый изге юлга!

– Әлбәттә, илтеп куябыз, кирәксә, барып каршы да алабыз, – диде Рамазан.

Директор апаларының бик нык күңеле булды. Коллектив егетләре үземнән дә әйбәт дип, елмайды ул. Билгеләнгән көнне, тагын бер укытучыны шофёр итеп алып, изге сәфәргә кузгалдылар. Әлбәттә, Рамазан паспортын да үзе белән алды. Кирәк булса, күрсәтермен, юл хәлен белеп булмый. Исән-имин генә аэропортка да барып җиттеләр. Бераз йөреп алгач, Рамазанның кесәсендәге паспорты юкка чыкканлыгы беленде. Кая китәр соң бу? Хәерле булсын, бәлки әле, йөргән юлларны сүтеп, йөреп карасам табармын дип, апаларын озаткач, кабат шул эзләрдән йөреп

чыктылар. Юк, тапмадылар. Инде кайтып, тиешле органнарга хәбәр итеп, гаризалар язып илттеләр. Рамазанның барыбер кабат аэропортка барып әйләнеп, карап, йөреп, эзләп кайтасы килде. Шунда гына ятадыр кебек тоелды аңа паспорты. Кабат барып, йөргән юлларны берничә әйләнсә дә, тапмады егет. Ярый, алды-арты хәерле булсын. Өстәвенә әле шундый вакытта югалып торуын әйт. Директор апаларын изге хаҗ сәфәренә озатканда диген. Күңелен пошаманга салып, әллә нинди уйлар килде башына, җитмәсә.

Директор апалары да, санаулы көннәрен тутырып, хаҗия булып изге җирләрдән кайтып та җитте. Аны барып алуны да оештырды Рамазан. Кылган хаҗлары кабуллардан булсын иде. «Лаек, бик лаек сез андый хөрмәтләүгә, хөрмәтле директорым», – дип уйлады ул. Әнә шул вакытларда Рамазан директор булып торган көннәр дә тыныч кына узды. Мәктәптә дә әллә ни үзгәрешләр булмады. Көндәлек мәшәкатьләр белән үтте дә китте җитәкчелек эше. Зифа Шаһидулловна да буш кул белән кайтмаган булып чыкты. Күчтәнәчләрне һәркемгә мулдан өләште ул. Зәм-зәм сулары барысына да эләкте. Рамазанга бүләккә Мәккәдән алып кайткан намазлыктан да кадерлесе булмады. Намазлыкны догалар укып, салаватлар әйтеп кулына алды ул. Бөтен күңеле, җаны-тәне белән ихлас рәхмәтләрен белдерде. «Намазлыкларга басып намаз укулар насыйп әйләсә иде», – дип теләде.

Әнә шул көннән Рамазан намазлыкка басты. Намаз укырга әхлак укытучысыннан өйрәнде. Илфат кардәше бик теләп, ихласлык белән өйрәтте Рамазанга догаларны. Аның мәдрәсәдән алып чыккан белеме Таллык мәктәбендә узган барлык дини һәм гадәти чараларда да кирәк булды. Рамазан һәрвакыт Илфат кардәшенә хөрмәт белән карады. Укытучылардан, укучылардан, әти-әниләрдән – берсеннән дә Илфатның күңелен төшерә торган сүзләр әйттермәде. Бергәләп, мәчеткә балаларны тарттылар. Намаз бәйгеләре үткәрделәр. Гомумән, мәктәп мохитендә дә теләгән кешегә намаз укып булуның ачык үрнәген күрсәтте егетләр. Намазлыгын мәктәпкә алып килеп-китеп йөргән Рамазанны Илфат, ниһаять, туктатырга ниятләде.

– Намазлык намаз укуда алшарт була алмый, – диде мөселман кардәше. – Намаз синең күңелеңдә, калебеңдә булырга тиеш. Кая басып укысаң да, ниятең дөрес булсын.

Рамазан, әлбәттә, авырлык белән килеште. Намазлыксыз намаз була алмый дигән катгый фикер аның миенә кереп утыргангамы, йөрәге тиз генә кабул итмәде.

Намазга бассаң да, күпме белмәгән нәрсәләр күләгәдә кала икән әле. Аллаһы Тәгалә юлы да синең иман ныклыгыңны сыный кебек. Моның белән килешеп бетмәгән көннәрдә күрше апасы иске, югалган паспортын табып кертеп бирмәсә, Рамазанга тагын күпме көннәр кайгырып йөрергә туры килер иде икән? Карлар эри башлагач, кар астыннан килеп чыкты паспорты. Машинага утырганда төшеп калган булса кирәк ул. Изге юлда йөргән өчен,Аллаһы Тәгалә бу кысыр кайгыны да юкка чыгарды. Паспорт табылуны ул әнә шулай юрады. Тели икән, Аллаһы Тәгалә, соң булса да, тиешлесен барыбер бирә. Әнә хаҗга да шул теләк теләп ялвару һәм Аллаһтан кирәклесен сорау өчен баралар бит. Кабул буласына шикләнмичә дога кылалар. Аллаһы

Тәгалә, югары күтәреп сораган кулны беркайчан да буш төшермим, дигән. Моның кайчан кабул буласы бер Аллаһка гына мәгълүм.

Тик менә ничек итеп, Аллаһка тагын да якынаеп булу юлларын да күрсәтсә иде ул. Намазлыксыз намаз була аламы икәнни? Бу Аллаһтан ерагайтмасмы? Намаз уку өчен намазлыкның мөһим әйбер түгеллеген озаклап, бик озаклап аңлаттылар аңа. Синең күңелең, рухың Аллаһка тартылсын. Аллаһы Тәгалә җирләрне безгә түшәк итеп җәйде, тагын ширек кылып, алар өстенә намазлык куеп уку шартын да өстәсәң, бидгать гамәл керткән буласың, диде диндәге иптәшләре. Ишетәсеңме, башта Аллаһны таны, аннан намаз укы. Монда намазлык турында сүз юк. Кешеләр аны үзләре уйлап чыгарган, үзләре керткән түгелме соң алайса?

– Син намазлыкка бассаң да, басмасаң да Аллаһка якынаюың мөһим, – диде бер кардәше.

Аңламады аларны Рамазан. Безнең телдә сөйләмиләр бугай алар, дип уйлады. Намазлыкта сәҗдәгә китүең гел икенче бит инде! Тагын ничек укып була соң намазны? Коры җиргә басыпмыни? Намазлыксыз намаз – ихлас, пәрдәсез, каршылыксыз булу өчен синең күңелеңдә беренчел Аллаһка ышану булырга тиешлеген белми иде шул әле Рамазан.

**10**

Таллык мәктәбендә укытучыларның да, укучыларның да дингә тартылуында Зифа Шаһидулловнаның шәхси үрнәге сәбәпче булды. Балалар арасында Коръән һәм намаз укучылар бәйгеләре үткәрүне дә башлап җибәрде ул. Бер елны мәктәп белән ураза тоттылар. Озын тәнәфестә ашарга беркем төшмәде. Менә монысында директорның катнашы юк та юк инде. Иртән иртүк, өйләренә барып, сәхәргә уятып йөрмәгән бит ул аларны. Авыл, мәчет белән дә араларны тагын да ныграк якынайтты директор. Бу вакытларда Рамазан да, башка укытучылар да намаз укучылар рәтендә иде. Мәктәпләрдә дин укытылмаса да, әхлак укытылып, дингә кереп китүнең үзгә бер юлын таптылар Таллыкта. Әхлак белән дин аерылгысыз төшенчәләр бит. Аерып карагыз сез аларны бер-берсеннән. Тик менә барысы да син уйлаганча гына бармый икән шул. Район мәгариф бүлегенә яңа җитәкче килгәч башланды да инде хәлләр. Ялт-йолт яшеннәр яшьнәтеп килеп керде тәүге эшенә яңа башлык. Каяндыр кайткан кеше икән, исемен татарчага алмаштырган марҗа икән, диде кайберәүләр. Анасы башка милләттән булса да, атасы татар, диючеләр дә табылды. Кыскасы, Зифа Шаһидулловна заврононың беренче мушкасына эләгүчеләрдән булды.

**11**

Корбан бәйрәмен уздыру өчен алдан әзерләнде директор. Мәктәпкә дин эшлеклеләрен дә чакырасы булыр дип планлаштырды. Ашау-эчүне дә мулдан әзерләтте. Балалар да ныгытып әзерләнде. Коръән сүрәләрен тырышып ятладылар. Тик менә бәйрәмне мәктәптә үткәрүне генә дөрес аңласалар иде, дип уйлады директор. Дуслардан бигрәк дошманнар күп хәзер. Яхшылык эшлим дип йөрүеңне аңлап бетермәүчеләр дә булырга мөмкин. Аллаһ юлында да проблемалар чыгып торуын белә Зифа. Бу юлы да шулай булды, заврono

белән артык вакланырга теләмичәме, әллә рөхсәт ала алмаудан шүрләпме – хуҗага хәбәр итеп торасы итмәде. Бәйрәмнең ямен җибәрер, йә булмаса бөтенләй каршы килер дип әйтеп тормаска булды һәм ялгышты.

– Сез нәрсә монда мәктәптән мәчет ясап ятасыз? – дип ыжгырып килеп керде завроно. – Әнә мәчеттә үткәрегез мондый чараларыгызны. Дин дәүләттән аерылган, сез бит директор, шуны да белмисезме әллә, Зифа Шаһидулловна? – дип, гаеплене табып, өстенә сикергәндәй итте. – Иртәгә җидедә кабинетымда көтәм. Таратыгыз бу кәмитне.

Табында Коръән укып, елларның тынычлыгына, башларыбызның, тәннәребезнең саулыгына багышлап догалар кылынып, бисмилла әйтеп, җыелган халык тәгамгә үрелгән генә иде әле бу вакытта. Кайберәүләрнең кулыннан ипиләре төшеп китте. Кемнәрнеңдер чәйләре түгелде. Башкалар имамга карап аптырап калса да, шома итеп үткәреп җибәрә белде авыл мулласы бу тамашаны.

– Кемнәрнең тере шайтан күргәне юк иде әле. Менә үз күзләрегез белән күрдегез. Иманың нык булмаса, суга да ега, телендә сандугачлар сайрата. Борчылмагыз, җәмәгать, дәвам итик, – диде күпне күргән авыл мулласы.

Зифа Шаһидулловна да бу мәзәкне күтәреп алды:

– Әле иртәнге җидегә кадәр вакыт күп, утырыйк иркенләп, бирелмәгез берүк шайтан коткысына, – дип дәвам итте ул. Йөзендә бераз аптыраулы караш шәйләнсә дә, башкаларга сиздермәде. Тагын бер кат догалар укып, мәҗлеснең әһәмиятен арттырырга тырышты алар мулла белән. Җиңелделәр дип уйламасыннар. Халык аларны хөрмәт иткәнгәме, күңелләргә үтәрлек ихлас сүзләренәме – беркем дә аш табынын ташлап китмәде, киресенчә, тора-бара заврононың килеп, тамак төбе белән акырулары да артка чигенде, көлкеле төсмер алып, мәгариф җитәкчесенең җилбәзәклегеннән кайберәүләр көлемсерәп кенә куйды.

Иртәгесен Зифа Шаһидулловнаны «кызу мунча» көтә иде. Үзенең бер дә исе китмәде аның. Гафу үтенмәде, ялгышканмын, кичерегез, дип бил бөкмәде. Ярамаган берни дә юк иде бит монда. Балаларны укыткач, ашханәләр бушагач үткәрелгән чарадан кемгә зыян?

– Әхлаклы балаларны әхлаклы әби-бабайлар, әхлаклы әти-әниләр генә тәрбияли. Әхлак белән дин – аерылгысыз төшенчәләр. Берсе булмаса, икенчесе булмый, – дип, җайлап кына аңлатырга тотынган иде Зифа, бүлмәсендә акны-караны аера алмас дәрәҗәдә каралган, бөтен бите бүртенгән завроного берни дә кирәк түгел иде бу минутта һәм ул русчалатып:

– Вон, – дип акырды, – вон отсюда!

– Китәм, китәм. Калырга дип килмәдем. Сезнең урынга да дәгъва белдермим. Татарча өйрәнегез башта, аннан сөйләшерсез, – диде Зифа тыныч кына.

– Больше курьмәс сине, не появляйся! – дип калды завроно, чак-чак татарча сүзләрне тупалап.

Шуннан бирле аларның арасы ныклап бозылды. Ерганаклар тирәнәйде, киңәйде. Шулай да эштән кумадылар Зифа Шаһидулловнаны. Ләкин татар марҗасының бәйләнүләренә чик-чама калмый иде кайчак. Түзде Зифа, тешен кысып түзде. Эшләвен дәвам итте, ләкин бил бөкмәде.

## 12

Шулай көйле генә итеп уку еллары берсе артыннан икенчесе алышынып торды, менә тагын бер уку елын төгәлләп куйдылар. Уку елын башлап кына җибәрәсең, йомгакларга да вакыт килеп җитә. Вакыт шулкадәр тиз уза. Кем әйткәндәй, көннәр кыскара – еллар озыная. Таллык мәктәбендә эшләүчеләрнең дә уртача яше 33 кә җитте. Кемнәрдер гаилә корды, кемнәрдер үзләренә якынрак мәктәп эзләде. Тик Рамазан гына һаман да биредә, иялэнгән җир дип эшләде дә эшләде. «Ел укытучысы» конкурсларында катнашып, призлы урыннар алды, конференцияләрнең, семинарларның исәбе-хисабы булмады. Ул директорның уң кулы, алыштыргысыз хезмәткәре иде. Рамазанга ышаналар, аның белән исәпләшәләр, киңәшләшәләр иде. Иманлы булуы, дин тотуы аның иптәшләре арасында абруен бермә-бер күтәрә иде. Үзе дә сабыр булды, карусыз эшләде, масаюны белмәде. Әле дә әнә иптәшләре, ягъни ир-ат укытучылар белән бергә, мәктәп өчен яшелчәләр үстерә торган теплицаны бергәләп корып та куйдылар. Башта якындагы урманнан киштәлекләр кисеп ташыдылар, аларны кагып, ныгытып, аркылыга-буйга рейкалар телеп суктылар, ахырдан полиэтилен белән төрделәр. Менә дигән итеп мәктәпнең тәҗрибә участогын барлыкка китереп, күз ачып йомганчы чыгымнар чыгармыйча гына тергезеп тә куйдылар. Ел саен язын алар җыелышып, теплицага «җан өрә». Бер булып, бердәм булып.

Әнә шулай теплицаны төреп, соңгы кадаклар кагып ятканда, кайчандыр биредә үзләре белән бергә эшләгән һәм мавыгулар эзләп, шәһәргә киткән, аннары каладагы мәктәпләрнең берсендә директор урынбасарымы, тарих укытучысымы булып эшләгән Гөлшаһидә шалтыратты. Ара-тирә генә сөйләшеп торсалар да, аларны бергә эшләгән еллар истәлекләре генә бәйли иде.

– Рамазан, ташла эшеңне, минем компаниягә күч.

– Ничек? Син мәктәптә эшләмисеңмени?

– Юк ла инде. Минем аннан киткәнемә бишбылтыр. Күптән китәсем калган.

– Кайда соң син?

– Мин бер компаниядә. Төрле дәвалау әйберләре сатабыз.

– Кит әле моннан. Дин тоткан кешегә килешмәс.

– Үзең сайларсың. Менә мин үземә бүләк ителгән өр-яңа машина янында басып торам.

– Нинди машина? Кем бирде?

– Яхшы эшләгән өчен компаниям бүләк итте. Син мәктәбеңдә чәчең белән җир себерсәң дә – «кукиш». Ә менә монда эшләгәнеңнең кадерен беләләр ичмасам.

Рамазан сүзсез калды. Кайчандыр үзе белән бергә, бер мәктәптә эшләгән укытучыга яхшы эшләгән өчен дип, машина тоттырсыннар әле. Монда сыңар мактау кәгазен дә күпсенәләр түгелме? Кайчандыр Рамазаннар белән бергә укучылар арасында кайнаган, бергәләшеп, мең дә бер чара үткәргән, сайлау кампанияләрендә бергәләп эшләгән, дәресләрен районда гына түгел, республика дәрәҗәсендә дә лаеклы итеп үткәргән укытучыдан мондый сүзне ишетермен дип һич уйламаган иде ул. Хәтта мәктәптән китәр дип тә башына китермәде.

– Намаз укучылар да бар бездә. Ул дин тотуга һичничек комачауламый. Әле син дәрес вакытларына туры килгән намазларыңны казага калдырып укыйсыңдыр, монда үз вакытында укый аласың. Намазны үз вакытында уку – фарыз гамәл. Аннан син үзеңә үзең хуҗа. Артыңнан тикшереп йөрүче дә, вакланып, кайчак кабат-кабат бәйрәмнәргә-кичәләргә сценарий яздыртучы да, дәресеңә кереп билге куючы да, ЕГЭ, ОГЭ дип баш катыручы да юк. Туймадыңмыни әле кәгазь боткасыннан, күсе күк көне-төне кәгазь арасында казынып ятудан. Мәктәп сазлык кебек бит ул. Торган саен отыры аска суыра. Ирекле тормышның нәрсә икәнен белерсең бераз. Сал богауларыңны, ике дә уйлама.

Рамазанга көчле удар булды бу. Андый эш тә бар икән! Дәүләт эшен җиренә җиткереп, кайчак арттырып үтәсә дә, премия бирүче бер дә күренми бит, әллә уйлап карыйсы инде, дип корт йөгерде аның миенә. Бүтән эшнең бар икәнен белмичә эшләде дә эшләде бичара.

– Гөлшаһидә, мин синең командаңа керәм, – дип әйткәнен сизми дә калды Рамазан. Тик менә директорын ташлап китү дөрес булырмы икән?

Китү турында сүз кузгаткач, Зифа Шаһидулловна артык төпченеп, каршы килеп тормады. Киләсе уку елында, бернигә карамый, Рамазан эшеннән китте. Мәктәп һавасын ничә еллар сулап тарайган үпкәләре киңәеп калды. Намазларын да акрынлап, намазлыксыз укый башлады. Дөрес, өйдә, офиста булганда, намазлыгын җәя дә укый. Ә менә юлда, саф һавада булганда яки җиләккә-гөмбәгә баргач, намаз вакытлары җитсә, йә чиста кәгазь кисәге җәя, йә чиста нәрсә бар, аяк астына шуны салып укый. Намазы да вакытында укыла, ихлас та кебек килеп чыга. Шуңа да Аллаһка тагын да якынайган, тагын да береккән кебек булды Рамазан соңгы вакытларда. Иң мөһиме: ул азат, һичкем алдында хисап биреп йөрисе юк. Иркенлек яшәтә икән шул безне. Рамазан да шуны тойды, сизде. Ә моны тойган кеше кабат коллык богавын кимәс шул. Намазлыксыз намазның да рәхәтен татымас.

Бер елдан Рамазанның шәһәр читеннән фатир алуын ишетеп, Зифа Шаһидулловна да авыр көрсенде. Юк, көнчелектән түгел, ә үзенең заяга узган гомерен кызганып. Белеп яшәлмәгән икән, дип көрсенде.

Яшьлеген генә түгел, бөтен гомерен мәктәпкә, кеше балаларын тәрбияләүгә багышлаган Зифа Шаһидулловнаның әнисе бакыйлыкка күчеп, үзе генә яши башлавына да хәйран вакыт үтеп китте. Рамазан апасын бервакытта да онытмады. Зифа Шаһидулловна да аны өендә үткәргән Коръән ашларына гел чакырып торды. Барды аларга Рамазан. Зифа апасына күчтәнәчләрен дә кызганмады. Дин юлына басуына сәбәпче булган директор апасына гомер буе бурычлы санады ул үзен. Нәтиҗәсен генә Аллаһы Тәгалә ясады. Шуңа да тәвәккәлләргә кирәк, сәбәп итмичә торып, нәтиҗә көтеп булмаганын яхшы аңлады Рамазан.

## 13

Иртәнге якта укылган догаларның кабуллыгына тәмам ышанган хәлдә намазлыктан торып килгәндә, телефоны шалтырады. Минем кебек иртәләүчеләр бар икән әле, дип уйлап, телефонны алса, анда Зифа Шаһидулловнаның борчулы, ярсу тавышын ишетеп сискәнеп китте:

– Тиз генә безгә кил. Бергә мәктәпкә барабыз. Сүтәләр икән бит

мәктәпне. Ишетәсеңме, сүтәләр... Тиз бул... Саубуллашып кайтыйк, – диде үз фикерен белгертергә сүзләр таба алмаган һәм аларны бер-берсенә ялгап җибәрү турында уйлап та карамаган, ләкин бик мөһим әйберне тиз генә әйтеп бетерергә азапланган әрнүле таныш тавыш. – Сүтмәсәләр булмыймы икәнни соң, җан җылыбыз белән төзегән идек бит?!

Директорының нәрсә әйтергә теләгәнен ярты сүздән аңлап алган Рамазан, шунда ук машинасын кабызып, укытучысы, аннары мәктәп директоры булган, бергә эшләгән хезмәттәше, хәзер инде ялгыз гына гомер итүче, тыныч картлыгын кичерүче Зифа Шаһидулловна торган авылга ашкынып чапты. Мондый халәтне тагын кайда күргәне бар иде соң әле аның? Шундый үзәк өзгеч тавыш ишетсә, аны беркем дә туктатып кала алмый иде. Ә-ә-ә, исенә төште. Мәктәптә укытып, мәш килеп йөргән вакытта, кисәк кенә, уйламаганда аңа әнисе шалтыратып, авыруы көчәеп китүен әйтер иде дә, Рамазан, укыта башлаган дәресен шундук өзеп, өстәлдәге ачылган дәреслеген дә япмыйча, хәтта класс ишеген дә ябарга өлгермичә, өенә чыгып чабар иде. Машинасы нинди тизлек белән баргандыр, егерме биш чакрымны җиде-сигез минутта кайтып җитеп, әнисенә уколын кадап, даруларын биреп килер иде. Аның хәле җиңеләеп китмичә, кире мәктәбенә бармас иде. Шулай ничә еллар кабатлангандыр... Кан тамырлары тыгылган, кан аз хәрәкәтләнгәндә шулай була дип, врачлар әйтсә дә, әллә ничә тапкыр ятып дәваланса да, һаман бу зәхмәтле авыруы бетми иде. Рамазанның болай чыгып чабуын хезмәттәшләре дә, директор үзе дә белә булса кирәк. Кайчак ул чыгып чабуга, дәресне китапханәче Тәүхидә апалары дәвам итәр иде. Йә булмаса класска берәр китап алып кереп укыр, яки бушрак булган башка укытучыга, дәрескә кереп, дәвам итүен сорар иде. Моны белгән Зифа Шаһидулловнага да рәхмәт, сүз әйтми.

– Алай кызу чапма, машинаң белән капланырсың, әниеңә кирәк вакытта дару бирүче дә калмас, ишетәсеңме, әкрен йөр, – дип, Тәүхидә апасы ничә тапкырлар әйтсә дә, барыбер тыңламый иде Рамазан. Әни бит ул. Даруын эчә дә алмыйча өзелеп китсә? Аллаһ сакласын. Әнә шулай машина тәгәрмәче машинадан алда чапкан вакытларда да, аны Аллаһы Тәгалә саклый, борчулар бирми иде. Бу юлы да Аллаһка тапшырып, хәерлесен сорарга кирәк, дип уйлады Рамазан, директоры янына барып, аны машинасына утыртып, Таллыкка кузгалганда. Берара сүзсез бардылар. Бергә эшләгән сукмакларга күз ташлап, эшләгән елларын искә төшерделәрме, ничә буын балаларга белем һәм тәрбия биргән, авылның мәгърифәт, мәдәният, миллият үзәге булган мәктәпнең болай тиз юкка чыгуын калебләре белән күтәрә алмаслык дәрәҗәдә иделәрме, кыскасы, машина эчендә авыр тынлык урнашып, һәр икесе дә күзләре белән тәрәзәдән сөзеп карап, тизрәк барып җитү турында уйлый иде. Туктатып калырга! Сүттермәскә! Мәктәп бетсә, авыл да бетә, яшәеш бетә бит. Юк, бу алай булырга тиеш түгел. Ничек тә өлгерергә кирәк, туктатып калырга кирәк.

Алар барып җиткәндә, мәктәп әле шул килеш иде. Зифа апасы урынына калып, яңарак кына эшли башлаган яшь директор кыз да күзгә чалынмады. Тиз генә мәктәп эченә үтте алар, һәм андагы мәхшәрне күреп шаккаттылар. Чак кына егылып китмичә, эче тәмам тар-мар ителгән мәктәпне күреп, җиһазларын алганда җимереп ташланган стеналарга сөялеп калдылар.

– Мәктәбем, – дип үкседе Зифа Шаһидулловна, – үз кулларым, бөтен барлыгым, йөрәк җылым белән салдырган мәктәбем. Ник соң бу болай? Ник тиясез мәктәбемә? – дип, бирегә мәктәпне сүтәргә җибәрелгән «ХЭС» оешмасы эшчеләренең кулларына барып асылынды директор.

– Апа, без кушканны эшләүчеләр генә, безгә рәнҗемәгез. Балалар азайгач, чыгымнар күп сорыйдыр инде, шуңа сүттерәләрдер, – диде эшче егетләр.

– Күрше авылдагы яңарак кына салынган мәктәптә дә балалар аз, диләр, автобус белән шунда йөреп укырлар. Ник борчыласыз, мондагы мәктәп урынына кемдер кафемы, туйлар-юбилейлар үткәрү өчен берәр төрле үзәкме ачмакчы була, диләр, дөрес булса, – диде берсе.

– Башыгыз бармы сезнең, мәктәп нигезенә шундыйны салалармыни? Иң изге җир бит ул мәктәп, – дип елый-елый, илереп ялваргандай, кемгәдер нидер аңлаткандай, һәрберсенә якын килергә тырышып эндәшкәндәй итте элеккеге директор. – Киләчәкнең күзенә ничек күренербез?

– Сез бит инде пенсионер. Авыл халкы кайгырсын. Хәер, бу эшкә ясин чыгылган инде. Нишләсәгез дә каршы тора алмыйсыз, – диде әлеге оешмада эшләүче авылдашы Рәсим тыныч кына.

– Биредәге документлар кайда, кайда без ясаган альбомнар, авыл тарихы, ветераннар папкалары, мәктәп тарихын кая куйдыгыз? – дип өзгәләнде Зифа апалары, директор бүлмәсенә атылып.

– Соң, сүтеләсе булгач, алдан җыеп алганнардыр, – диде олырак кына бер эшче.

– Курыкмагыз, апа, сезгә аларның берсе дә кирәк түгел бит инде. Ник баш ватасыз соң, ник борчыласыз бер кирәкмәгән өчен, – диде тагын бер яшьрәге.

– И энем, – диде Зифа Шаһидулловна, чак кына тынычланып, – документлар саклансын иде инде. Алданрак белмәдек шул, килеп, үзебез барлап, җыеп куяр идек. Алар арасында архивка тапшырасылары да була, кайсылары егерме биш, кайсылары җитмеш биш ел сакланырга тиеш бит. Пенсиягә чыгучылар теге яки бу документны сорап килүчән була, – дип, авыр сулады элеккеге мәктәп җитәкчесе. Тагын нәрсәнедер исенә төшереп, кинәт кабынып та китте: – Сүттермим мин бу мәктәпне. Ишетәсезме, сүттермим, кайтып китегез, нишләттегез мәктәбемне? – дип, тагын ярсыды Зифа Шаһидулловна. Аннары идәндә аунап яткан, өстеннән кешеләр үтеп, аяк эзләре төшеп калган, күбесе ертылып, танымаслык хәлгә килгән, стендтан төшеп калган фотокарточкаларга ымлады. – Ник, боларны җыярга буладыр бит?!

Мәктәп коридорыннан атлап барганда коелып калган документларга, кәгазь өемнәренә, ярым җимерек стендларга, алганда җимерелеп, ярты юлда ташлап калдырылган стеллажларга кагылып узды элеккеге директор һәм һәрберсен кулына эләктерергә, һәрберсен кочагына җыярга тырышты, кайсыларын сыйпап узды, кайсылары кочагыннан кабат коелды.

– Ничек кулларыгыз бара, сүтүе генә җиңел, ә бит без аны ничек итеп төзедек, булдырдык. Кара, әнә бит, бу стендтагы бер фотоны да җыймаганнар? Анда бит без мәгърифәтчеләр дәвамчылары булган авыл муллаларының нәсел җепләрен барлап, тарихларын өйрәнеп, элеккеге фотоларын архивлардан, туганнарыннан алып төзегән идек. Бер селтәнүдә

юкка чыгармакчы буласыз, барып чыкмас, – дип пышылдауга күчте Зифа ханым, тавышы карлыгып. Бераз хәл кергәч, аны мәктәпнең бер тыныч почмагына – намаз укый торган бүлмәсенә култыклап диярлек алып китте. Шунда Рамазанның уен сизепме, Аллаһы Тәгалә белдертепме:

– Рамазан, син «Ясин» сүрәсен беләсеңме? – дип, сорады бераз тынычланып калган директор.

– Беләм, апа, – диде, үзе дә көчсезләнеп, кыюсызланып калган Рамазан.

– Укы шуны. Кычкырып укы. Мәктәпкә ясин чыгабыз.

Рамазан шунда ук ниндидер татар мәкамен табып, көйләп ясинны укый да башлады. Аның тавышы көчәйгәннән-көчәя барып, бөтен күзәнәкләр аша үтеп, биредәге барлык тере затның фикерләвен дини яссылыкка күчерде. Мәктәп сүтәргә килгән «ХЭС» эшчеләре башта аптырап калды, аннан, берәм-берәм коралларын ташлап, кайсы кая идәнгә чүгәли башлады...

Ясин тавышыннан гайре бер шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Барысы да шым калып, Коръән аятьләрен тыңлады. Хәтта удмурт милләтеннән булган Михаил да, күзен бер ноктага төбәп, озаклап уйланып утырды. Көчле сихри тавыш сүтелә башлаган мәктәп хәрабәләре арасыннан урамга, авылга таралды. Ясин укучы Рамазанның тавышы, манара башыннан намазга чакырып әйтелгән азан тавышы кебек ишеткән берәүне дә битараф калдырмыйча, мәктәпкә дәште. Күзләре яшьләнгән, яулык читләре белән авызларын каплаган әбиләр дә, Коръән авазын ишетеп, тиз генә өйләренә кереп, түбәтәйләрен эләктергән һәм нык адымнар белән сүтеләсе мәктәпкә ашыгучы бабайлар да бар иде арада. Тик ник бер җитәкче күренсен?! Кая качып яталар диген? Шулай да булмаулары хәерле, барыбер биредә алар артык иде. Милләт, тел, дин өстенлеген шушы мизгелдә берни дә алыштыра алмас кебек булып, Таллык мәктәбендә Коръән аятьләре яңгырады. Аллаһы Тәгаләгә сыенып утыручылар янына, ясин тавышларын ишетеп, шушы тирәдә торучылар, якында гына урнашкан колхоз идарәсе кызлары, ферма эшчеләре, машина-трактор паркында эшләүче ир-атлар, укучы балалар да килеп кушылды. Мәктәп эче халык белән тулды. Берәү дә «килегез» дип чакырмады, әнә шул ясинның могҗизаларга тиң серлелеге дәште аларны бирегә. Шул җыйды халыкны, шул берләштерде.

Каерылган кабинет ишекләрендәге «Кабинет паспорты» дип исемләнгән язу астында булып, шушы мәхшәрдә идәнгә шуып төшкән Аятелкөрсиләрне җыеп, мәктәпкә керә торган авылдашларына юл әзерләде Зифа Шаһидулловна. Тиз генә коридордагы чүп-чарны җыештырырга кереште. Каяндыр сулы чиләк табып алып, татар теле һәм әдәбияты кабинетында такта белән парталар алдындагы берничә метр араны юарга да кереште. Рамазан белән Илфат әлеге кабинетның парта-өстәлләрен коридорга ташыды. Халык сәерсенеп тә, теләктәшлек белдереп тә, элеккеге директорның гомерләрендә дә күрмәгән мондый халәтен күзәтте. Аларга башка иярүче, кушылучы гына булмады. Берничә чиләк су китереп бирделәр үзе. Анысы да биредә белем алган укучылар иде. Тик нигәдер пенсионер директорга кушыласы итмәделәр. Ясин укылып бетүгә, Зифа Шаһидулловна үтенүгә дә охшаган тонык тавыш белән:

– Намаз укыйбыз. Барыбыз бергәләп. Сафларга басыгыз, – диде. – Алга ир-атлар баса, алар артына хатын-кызлар, аннан балалар... Намазны Рамазан имам булып укытыр.

– Шушы татар теле кабинетындамы?

– Әйе, шушы кабинетта уку дөрес булыр, – диде элеккеге җитәкче.

– Безнең намазлыклар юк бит, – диеште арттагылар.

Кемдер:

– Ак кәгазьләр бар менә, шуларны салып укыйк, – дисә дә, Рамазан, берәүгә дә игътибар итмичә, сафларның тигезлеген карап чыкты. Аллаһка безнең инану, ышану гына кирәк, намазлык булу-булмау мөһим түгел, дип әйтәсе килгән иде, никтер тукталып калды. Юылган идән чип-чиста иде. Кемдер, каяндыр табып, идәнгә палас та китереп салды. Коридорда аяк киемнәрен калдырып, барысы да татар теле кабинетына кереп тулды. Ир-атлар артына хатын-кызлар, алардан соң балалар тезелде. Барысының да күзләре моңсу, карашлары аптырашлы, адымнары салмак, йөзләре ялварулы иде.

– Илаһи ният кылдым, бер Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен, Алаһы Тәгаләдән хәерлесен сорау намазын укымакка. Халисән-лилләһи Тәгалә. Аллаһу әкбәр.

Сүтелә башлаган мәктәп эчендә укыла торган бу намазга басмыйча калучы булмады. Намазлык кирәк дип, кырыйга китүче дә күренмәде. Ничектер бердәм килеп чыкты бу гамәл. Аллаһ белән сөйләшүгә хәтта биредәге эшчеләр дә авыл халкы белән бердәм булып басты. Үзләреннән дә өстен, үзләреннән бөек Зат – Илаһ барлыгына ышанып бастылар намазлыксыз намазга. Монда бернинди нәчәлникнең әмере, боерыгы да кирәк булмады, үзеннән-үзе, ничек тиеш булса, шулай килеп чыкты. Аллаһ хәерлесен кылсын дип, дога кылганда да, халык таралмады. Намаз укылып беткәч, мәктәп сүтәргә килгән эшчеләр башта акрын гына инструментларын җыя башладылар, аннары җай гына, башларын бераз ия төшеп, машиналарына утырып, Таллык мәктәбен калдырып китеп тә бардылар. Алар артыннан авыл халкы сүзсез генә таралышты. Тып-тын калган мәктәп хәрабәләренә каяндыр яктылык иңгән кебек тоелды. Ничектер, үзләре эшләгәндәге мәктәп төсе кире кайткандай, төнлә белән кояш чыккандай, тирә-як яктырып, ачылып киткәндәй булды. Үзе гайре, үзе рәхәт, үзе илаһи, үзе табигый...

– Апа, кайтыйк булмаса. Туктата алдык бит. Мәктәпне сүттермичә калдык бит, – диде Рамазан. – Намаз укып, Аллаһтан хәерлесен дә сорадык. Аллаһ кабул итсен. Безгә ярдәмче булсын. Апа, дим, кайтыйк. Ял итәрсез кайткач.

Зифа Шаһидулловна сүзсез генә машинага чыгып утырды. Бер ноктага төбәлгән карашыннан, кысылган иреннәренең кайчак кыймылдап-кыймылдап алуыннан, аның чынлап та кемгәдер нәрсәнедерраслап баруын, алай түгел – болай ул, дип аңлатырга тырышуын сиземләп була иде. Боларны Рамазан, әлбәттә, белә алмады...

Икенче көнне иртәнге намаздан соң Рамазан Зифа апасына әллә ничә шалтыратса да, телефонны алучы булмады. Таң белән Таллык мәктәбенә чыгып чапты ул. Мәктәп тәрәзәләрендәге кабат куелган пәрдәләрне, стендларның кабат урнаштырылуын, ялт иттереп җыештырылган идәннәрне күреп: «Зифа Шаһидулловна эше бу», – дип, мәктәп буенча чабып, апасын эзләргә тотынды Рамазан. Димәк, кичә ул кире Таллыкка

киткән, төне буе мәктәпне рәткә китергән, юган-җыештырган, төзәткән, каккан-суккан... Элеккеге директорның бу гамәлен күреп, Рамазан телсез-өнсез калды. Ничек көче җиткән? Ир-атлар да көчкә күтәрерлек өстәлләрне кабат үз урыннарына тезгән. Әмма Зифа Шаһидулловна үзе кая соң, үзе? Тыны кысылды Рамазанның. Кая китте икән соң? Эзли торгач, директор бүлмәсенең бер почмагында ярым бөкрәеп яткан Зифа апасын күреп имәнеп китте ул. Янына мәктәп альбомнарын матур итеп тәртипләп тезеп куйган, бер якка документлар өелгән өстәл урнаштырган. Анда мәктәп коллективы белән төшкән фотокарточка тора. Үзе башындагы ак яулыгын гәүдәсенә япкан, әллә чүгәләгән, әллә җайсыз килеп төшкән, ничектер уңайсыз ята иде ул. Куллары салынып төшсә дә, намазлык җәеп, шунда Коръәнне тотыпмы, укыпмы утырган булса кирәк, янында каләм белән дәфтәр дә бар иде. Зифа Шаһидулловнаның тын алуын ишетергә теләп, Рамазан аның пульсына үрелде. Ә үзенең күзеннән шыбырдап яшь тамчылары тәгәрәде.

– Нишләттеләр сезне, апа? Сезнең хезмәтегезне? Болай тәмамланыр өчен бил бөктегезмени сез гомер буе? – дигән яшь аралаш өзек-өзек ярсыган тавышлары ишетелде Рамазанның. Ишек ягына борылып, бирегә таба килүче татар маржасы – заврононы күреп алгач, сабырлыгы тәмам ташып, аңа каршы китте.

– Нишләттегез сез мәктәпләрне, белем-мәгърифәт учакларын, авылның йөзен, туган телебезне?.. Бөтен тормышларын, гомерләрен мәктәпкә багышлаган олпат директорларны, андагы сабый халәтендәге ихлас укытучыларны?.. Нишләттегез? Ник болай туздырдыгыз бу изге урынны? Моңа кайчан да булса бер җавап бирерсез, ишетәсезме, җавап бирерсез, – дип, Рамазан үрсәләнеп-үрсәләнеп кычкырды да, язгы ташу ерганакны җимергәндәй, бераз басылып, аннан тынып калды, шуннан кинәт кенә агарынып, кичә төнлә укытучы апасы җәйгән палас өстенә уңайсыз рәвештә авып төште.

* * *

«Ашыгыч ярдәм» машинасында заврono татар мөгаллимнәрен хастаханәгә кадәр озата барды. Борчылуына куркуы да килеп кушылгач, ул тәмам югалып, каушап калды. Әле Зифа Шаһидулловна, әле Рамазан янына килеп:

– Сез исәнме? – дип өтәләнде. – Сезгә хәзер ярдәм итәрләр. Бераз гына көтегез. Барысы да яхшы булыр. Ничек болай килеп чыкты әле ул? Мәктәпне сүттермибез аны. Ишетәсезме, шул килеш саклanaчак Таллык мәктәбе. Башлангычка калдырабыз да... Бер бала булса да, укыячак анда, менә уңайланыгыз да кабат үз эшегезне дәвам итәрсез. Белмәдек бит, шулай авыр кабул итәрсез дип, белмәдек. Идарәдәгеләр дә, үзегезгә карагыз, диделәр. Шул карарны җиткерергә килә идем дә бит инде мин сезгә, бераз гына соңга калганмын шул, бераз гына соңарганмын...

Тәмам үзәкләренә үткән татар маржасының бер кәлимә сүзен ишетмәсә дә, йөзләренә аз гына кызыллык йөгергән мөгаллимнәр бераздан акрын гына күзләрен ачтылар.



Ленар
Шәех

# Ә ЮГЫЙСӘ ЯШӘҮ БӨЕК ИДЕ...

## Язу карасыдай төннәрдә

Миннән акыллырак кешеләр бар,
Ә мин үзем кемнән акыллы?
Кара төнне ярып, кара көздә
Сократ үзе гүя чакырды.

Китапларга кемнәр табына соң
Кара шомга чумган заманда?
Язылмыйча калган китапларны
Уйлап йөрим әле һаман да.

Уйлап йөрим юкка чыкканнарын,
Янганнарын дәһшәт эчендә.
Кулъязмалар янмый, дисәләр дә...
Кәгазь бит ул түзә, кичерә.

Таш гасырның таш битләрен ачам,
Тузаннарын коям тузларның.
Ап-ак папируслар эләкмәгән
Каләм ияләрен кызгандым.

Күпме сүзләр калган һаваларда,
Күпме фикер калган эленеп.
Язар өчен кәгазь җитешмәгән,
Каралары калган күмелеп.

Кәгазь дә бар хәзер, кара да бар,
Вакыт кына юкка тоташа,

---

Ленар ШӘЕХ (1982) – *шагыйрь, филология фәннәре кандидаты; Муса Җәлил исемендәге республика, Абдулла Алиш премияләре лауреаты. «Казан – Мәскәү», «Гасырда фасыллар буталган», «Үзем белән очрашу» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Ак кар кебек эреп юкка чыга,
Ялган белән чын тормыш аша.

Югалалар җаннар, уралалар
Кара күздә кара төннәргә.
Әлмисактан Сократ тавыш бирә,
Таянырга, диеп, кемнәргә
Язу карасыдай төннәрдә?!

## Яшем дә бар, яшьлегем дә!

Яшем дә бар, яшьлегем дә –
Бер казанда икесе.
Чәчләремдә җилләр төсе,
Күзләремдә – ил төсе.

Уем да бар, сүзем дә күп,
Ага ул елга кебек.
Дулкын булып бәрелә дә,
Шигырь дә җыр да кебек.

Узган да күп, узасы да –
Оч-кырые күренми.
Елмайган чакларым байтак,
Бар түзгән чак сүгенми.

Яшем дә бар, яшьлегем дә –
Икесе дә бер очтан.
Күңел түрем бәхет белән
Һәм моң белән тулышкан.

* * *

Ахырзаман җиттеме соң әллә? –
Бөтен җирдә тимер өеме.
Боз шикелле ташның салкынлыгы.
Бу дөньябыз туңлык өеме?

Кешеләр юк кебек. Яшәмиләр.
Утыралар тимер эчендә.
Йә булмаса, ташлар арасында
Масаялар байлык көченә.

Тимер туңы, ташның салкынлыгы
Җаннарын да гүя катырган.
Кем булышыр, ярдәм кулы сузар
Яшәешнең өске катыннан?

Өмет бармы? Соң да кебек инде...
Җаннар кайда? Әллә үлеләр?..
Яшәешнең соңгы талпынуы.
Карап йөри тимер бүреләр.

Ә югыйсә яшәү бөек иде,
Гөрли иде монда кайчандыр.
Хакыйкатьне күрми мөмкин түгел –
Ясандырма аны, ясандыр,

Мәгънәсе юк. Ул – чын һәм мәңгелек!
Хакыйкатьнең юлы бер генә.
Тимер һәм таш тавы арасында
Авыр сулап йөри җил генә.

* * *

Зәңгәр күкне тимер кошлар иңли,
Җирдә чаба тимер хайваннар.
Ярый ла бит зыян салмасалар... –
Ә кешеләр хәлдән тайганнар.

Арыганнар сугыш ачысыннан,
Тимер ярчык очкан дәвердән.
Мең үлемне йөрткән ракеталар
Кубарыр күк чорны кабердән.

Сугыш туктап торган гасырларны
Тарих белми, юк ул хәтердә.

Тынычлыкка сусау – җан түрендә,
Ук шикелле үткән бәгырьгә.

Сынган гомер һәм өзелгән яшәү
Кире кайта алмый ничек тә.
Сабыйларның йокылары тыныч
Булса икән бәллү бишектә.

Аналарның җаны тыныч булсын,
Аталар да ешрак елмайсын.
Кеше булу арткан саен җирдә,
Киләчәкне ныграк тыңларсың.

Өмет, бәхет, изге сөю яшәр,
Иман, намус йөрер янәшә.
Киләчәктә гел яктылык булыр,
Сугыш утын адәм белмәсә...

Җирдә йөри тимер машиналар,
Күктә оча тимер очкычлар.
Кеше кулларында сәгадәткә,
Тынычлыкка илтер ачкычлар.

* * *

Бурычка баттык без, бурычка,
Яшибез бит коллар шикелле.
Нигәдер күбебез дөньяда
Аяклар һәм куллар шикелле.

Туктаусыз уйлаган баш кебек
Хис итә үзләрен кемнәрдер.
Андыйлар күпме соң бу җирдә? –
Йөзләгән, меңләгән меңнәрдер.

Авыз да, корсак та без түгел,
Йомшакка күнеккән арт сан да.
Чабабыз, уйлыйбыз, эшлибез... –
Шул халәт: торсаң да, ятсаң да.

Кояшны күрергә вакыт юк,
Зәңгәр күк югыйсә якында.
Ни җитми, диярсез, ни кирәк
Бу җирдә яшәгән акынга?

Җитми бит, кесәдә чылтырый
Вак кына, сак кына тиеннәр.
Түбәнгә караган карашлар...
Ят сүзләр пышылдый иреннәр.

Без уйда, без гамьдә һәрвакыт,
Туктаусыз көрәштә, хезмәттә.
Бу дөнья кигезгән камытка,
Тагарак ярыкка түзмәктә.

Уйласаң, уйлардан баш китәр –
Без гүя йомычка шикелле.
Яшәргә бирелгән гомер дә
Нибары бурычка шикелле.

## Әлфирак

*Әлфира Мәһдиева рухына*

Кайчан гына безнең янда идең,
Әле генә йөрдең елмаеп.
Аяз көнне яшен суктымыни –
Синең кояш китте тиз баеп.

Баеган шул, башка чыкмас өчен,
Кабат кайтмас өчен дөньяга.
Изге җаның яктылыгы белән
Бүген, әнә, кара төн яна.

Дөрли генә чиксез ерак офык,
Ак нурларын гүя озата.
Син башкарган эшне искә алсаң,
Гамәлләрең – тауны кузгата.

Телем диденң, халкым диеп яндың,
Яна-яна киттең үзең дә.
Сагышларың, кайгы-борчуларың
Чагылмады нурлы йөзеңдә.

Рәхмәт сиңа, газиз милләт кызы,
Урыннарың булсын җәннәттә!

Килер буын кадереңне аңлар
Әдәбият дигән сәнгатьтә!

Татар акыллары – төн чыкканчы,
Изге мирас – таудай өелгән.
Эчтән генә: «Әлфирак!» дип елыйм,
Аерылалмый сагыш көеннән.

* * *

Уен-көлке түгел. Түгел инде.
Хәлләр түгел биеп йөрерлек.
Бүре булып улар хәлләрдә без,
Хәлләребез эттәй өрерлек.

Кеше яши җирдә. Һәм ни өчен
Яшәгәнен аңлап бетерми.
Кемдер күктә бөркет булып оча,
Кемдер күсе кебек кетерди.

Кем уйлаган, мескен хәлләренә
Төшәр диеп җирдә бар халык.
Таң калудан узган инде хәлләр,
Ятар чаклар түгел мактанып.

Без бары тик киек. Алар да бит
Кешеләрдән күпкә акыллы.
Ризасызлык ташны ярып чыкты,
Ак намусым алга чакырды.

Нишләде бу адәм балалары,
Әллә алар бары җеннәрме?
Ак биләүгә биләп, көйләр көйләп,
Үстердек без әллә кемнәрне.

Ахырзаман, әйе, бер булачак,
Ә яшисе килә кешечә.
Тыныч күңел, ап-ак намус белән,
Хайван хәлләренә төшмичә.

* * *

Чүлнең уртасында чүлмәк таптым,
Коры-сары җыйдым, учак яктым.
Чүлмәк эче ризык белән тулган,
Мин курыкмыйм аны югалтудан.

Аллаһ биргән, бар да – Аллаһ ирке,
Комның бөртеге дә – Аның милке.
Җитә безгә, җитә һәммәсе дә!
Ә тормышның асыл мәгънәсенә

Төшенергә һәрчак вакыт җитми,
Яшәү матурлыгын гомер чикли.
Аллаһ шөкер, кияр күлмәгем бар,
Сөбханаллаһ, балчык чүлмәгем бар!..

Чүлмәк эче нигъмәт белән тулган,
Һич курыкмыйм аны югалтудан!
Берсе китсә, икенчесе килер,
Аллаһ хозурында – безнең өйдер.



Габдулла
Вафин

# ТУКАЙ

хикәя

Үзем эшләгән такси фирмасыннан алган чираттагы заказыма килеп, машинамны сүндерүем булды, «Әфәндем, мине Печән базарына илтеп куймассыз микән?» – дигән тавыштан сискәнеп киттем. Кем шаярта мине болай? Күтәрелеп карасам – янәшәмдә бер адәм аламасы басып тора. Кыяфәтенә күз йөгерткәч үк, барлы-юклы кәефем чәлпәрәмә килде: юкка гына шушы бистәгә килгәнмен икән. Ул, уемны аңлагандай, кулына бөтәрләп тоткан акчаларын суза. Эчемә җылы йөгерә – димәк, юкка гына түгел икән. Шушы заказны үтим дә өйгә хатын һәм балалар янына шылам. Тик бу бәндәнең кыяфәте генә ошап бетмәде. Акча кирәк булмаса, мондый адәм аламаларын йөртер идеммени? Җитмәсә, монысыннан чир-фәлән йоктырып куймасам ярый да бит. Машинамны борып китә алам да, тик кем миңа юл хакын түләр?

Утырырга кыймый басып торган шәүләгә, ни булса да шул булыр дип, ишегемне ачам. Ул тартынып кына, янәшәмдәге утыргычка чүгә. Ишеген дә юньләп япмый – терәп кенә куя. Шул сәбәпле үрелеп, үземә шаплатырга туры килә.

– Каеш, – дим ачулы гына.

– Нинди каеш?!

Моның томаналыгына исем китә. Күктән төшкәндер бу, йә машинага беренче генә утыруыдыр.

Чәмләнеп, газга басам. Машинам төн караңгылыгын ярып, ажгырып, алга китә.

Руль артында йоклап китмәс өчен сөйләшергә кирәк.

---

Габдулла ВАФИН (1967) – *язучы, журналист; Башкортстан һәм Россия Язучылар берлекләре әгъзасы. «Солдат мажаралары», «Алдау көне галәмәтләре» исемле китаплар авторы. Актанышта яши.*

– Сез кайсы якныкы, йөзегез таныш күренә, – дип, көненә дистәләрчә тапкыр әйтелгән кизү сорауны бирәм.

– Арча якларыннан мин. Кушлавыч авылыннан. Габдулла атлы булам.

Боларны ишеткәч, тормозга басуымны үзем дә сизми калам. Шып туктагач тегене, нафталин исе килеп торган киемнәреннән җирәнә-җирәнә булса да, каеш белән эләктерүемә сөенеп куям. Чөнки берсүзсез тәрәзәмне ватып чыгып очасы иде ләса. Үзе кызганыч түгел дә, тик кыйбат хакка пыяла алыштырасы булыр иде.

Пассажирыма күтәрелеп карыйм да, карашларыбыз очраша. Шулчак сискәнеп китәм, билләһи, Тукай бит бу! Тик мин моңа һич кенә дә сөенмим.

Аягымны тормоздан алып, газга басам. Шулчак машинама яңадан җан керә.

Нәрсә булыр бу? Миңа, исәпләвемчә, әле исәрләнергә иртәрәк. Руль артында йоклап киткәнмен, дисәм, әнә эңгер-меңгер булуга карамастан, бар дөнья ап-ачык күренә бит – тирә-яктагы өйләр дә, эшләп утырган навигаторым да. Уйлап таптым, ул, бәлки, Газраилдер. Язучы халкына, кем белә, махсус Тукай кыяфәтлесен җибәрәләрдер.

– Фатих  әфәнделәрдән кайтып барам әле, – диде юлдашым, уйлар пәрәвеземне өзеп. – Берәр атна аларда тордым. Бәрәңгеләрен алыштым, бакчаларын чокыдым. Акчаларын да кызганмадылар, кесә тутырып бирделәр.

Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас – янәшәмдә Тукай утырып бара. Коеп куйган Тукай!

– Үзем дә бик аптырыйм, – диде ул, уйларымны укыгандай. – Клячкин хастаханәсендә үлеп ята идем, ә әле килеп күзләремне ачсам, бөтенләй бүтән дөнья. Үлеп, яңадан терелгәнмен дияр идем, тәмугын да, оҗмахын да тамчы да хәтерләмим. Ә сират күперләрен әйткән дә юк инде.

Аннан ул: «Әфәндем, исемегез ничек, кем атлы буласыз?» – дип, миңа мөрәҗәгать итте. «Габдулла», – дияргә авызымны ачтым. Тик булдыра алмадым. Чөнки, Габдуллалар татарда бер генә булырга тиеш. Шушы уйлар белән Габдулла Тукай тиклем Габдулла Тукайны «Мәхмүт», – дип алдадым, этиемнең исемен әйттем.

– Туган, – дип, сүзен дәвам итте ул әллә миңа ышанып, әллә ышанмыйча. – Тар бүлмәмдә күзләремне йомган идем. Җаным да чыккан кебек тоелган иде. Әле күзләремне ачсам, яп-ят җирдә ятам. Бөтен тирә-ягымны эреле-ваклы баулар уратып алган. Беләкләремә әллә нинди ялтыравыклы беләзекләр кидерелгән. Бүлмә тулы нindidер шкафлар гөрелдәп утыра. Ә үзем япа-ялангач. Тирә-ягымда адәм заты да, шайтан заты да күренми. Оят җиремне каплап эндәшеп тә карадым, тик файдасыз – яныма килүче булмады. Шуннан бар көчемне җыеп торып утырдым. Янәшәдә яткан нindidер ак чүпрәкне билемә урадым. Ә тирә-якта бихисап бүлмәләр. Шуларның берсенә күзем төшсә – өчәү аракы эчеп утыра. Моны күргәч, кая инде яннарына бару, тиз генә сызу ягын карадым. Колагыма бары берсенең: «Безнең Нобель премиясе алуыбыз өчен», – дигән сүзләре генә сеңеп калды.

Шулчак үземнең уйларымнан үземнең башыма сугып куям. Тукай чыннан да тере ич. Мин милләт, тамак, балалар дип йөргән арада әнә

фән ничек алга киткән. Тик, иманым камил, алар да Шагыйрьне бөек булганы өчен түгел, ә Тукай тиклем Тукайны терелттек дип лаф орырга һәм шапырынырга гына терелткәннәр. Монысы сантыйга да аңлашыла.

– Галәмәт зур ишекне ачып җибәрсәм, шаулап торган урамга барып чыктым, – дип, сүзен дәвам итте Тукай. – Урам уртасында басып торгангамы, этәләр дә төртәләр. Шулчак мине жандармнарга тартым өчәү сырып алды. Бар җиремне дә тентеп чыгып, үзләренә кирәк әйберне таба алмагач, алары да арт шәрифләремә тибеп китеп барды. Тегендә барып карыйм, монда барып карыйм, беркая да кертмиләр. Каһәрең, хәтта сөйләшергә дә теләмиләр. Шулчак мине ниндидер пычрак бәндәләр сырып алды һәм көчләп диярлек үзләре белән алып киттеләр. Тимер каплавычны ачып, галәмәт зур базга төштек. Миңа киемнәр бирделәр һәм туйганчы ашаттылар. Тик алары да җыелышып, шайтан суы эчә башлагач, бу тирәдән качуны кирәк санадым.

Урам буйлап бара торгач күземә зур мәчет чагылды. Эченә керим дигәндә аннан да эт куган кебек кудылар. Ышанасызмы, хәтта аның манарасыннан яңгыраган азан да чын булып тоелмады.

Аз гына эндәшми баргач, Шагыйрь миннән кәгазь кисәге сорады. Моны ишеткәч, машинамны пычратып куя күрмәсен дип, хәтта борчылып та куйдым. Тик Тукай гына кулына бер төргәк туалет кәгазе тоттыргач та ишекне ачып, тышка чыгарга ашыкмады, кул сырты хәтлесен генә кадерләп ертып алгач, кесәсеннән каләм чыгарып нидер язарга кереште. Үзенә сиздермичә генә күз төшердем. Гарәпчә икән. Аннан, «Нинди гарәпчә булсын, татарча, тик алфавиты гына гарәпчә», дип, үземне тиргәп алдым. Аның үзен тотышыннан, илһамланып шигырь язуын аңладым. Тик, кызганыч, бик кызганыч, аның ни язуын гына төшенмәдем. Тукай 10 юллап язгач, кәгазе белән каләмен кесәсенә тыгып куйды да тәрәзәгә төбәлде.

Аннан без байтак кына сүсез бардык. «Әфәндем, әле 2030 ел диләр, бу чыннан да шулаймы?», – дип сорады Габдулла Тукай.

– Әйе, – дидем, аның сүзләрен җөпләп.

– Димәк, миңа 144 яшь булып чыга?

– Әйе.

– Тик, беләсезме, әфәндем, мине шул яшькә җитүем дә, урам тулы меңнәрчә автомобильләр булуы да, кешеләрнең әллә нинди кечкенә җайланмалар аша сөйләшүе дә түгел, ә милләтебезнең юкка чыгуы аптыратты. Казан тиклем Казанда татар теле беткән бит. Миңа иң авыры – бай тарихлы хозур милләтебезнең тәмам юкка чыгуын аңлау. Боларны күрмәсәм, миңа күпкә җиңел булыр иде ул, – диде дә Шагыйрь тынып калды. Шулчак мин, аңа борылып карамасам да, Тукай тиклем Тукайның елавын аңладым. Тик иңеннән кочарга батырчылык, юатырга сүз тапмадым. Ярый да, шул чакны минем телефон шалтырады. «Җаным, кайт инде, без сине сагындык. Балалар да йокламый – әтиләрен көтә», – диде теге яктан хатынның тавышы.

– Кайтам, матурым, кайтам. Тик, берүзем түгел, ә кунак белән.

– Үзеңә яшь хатын гына алып кайта күрмә, җаным, – дип көлде хатыным теге очтан.

– Тукай, Габдулла Тукай белән кайтам, – дип әйтергә теләдем. Тик, хатынымның моңа ышанмавын аңлап, телемне тешләп калдым.

Сөеклем тәмле итеп аш пешереп куйгандыр инде. Моны уйлагач төкерекләремне йотып куйдым хәтта. Кем белән килеп керүемне күргәч, исләре китәчәк аларның. Малаем оялуыннан хәтта шкаф артына кереп качачак. Аннан тәмләп сыйланачакбыз. Тамак туйгач, матраслар җәеп, идәнгә йокларга ятачакбыз. Кем-кем, ә Тукайның үзе белән. Балалар шагыйрь абыйларын арытып бетермәсәләр ярый да бит. Аннан фотога төшерергә керешерләр инде.

Боларны уйлап елмаеп җибәрдем хәтта.

Тукайны ияртеп, Тукай клубына бармыйча булмастыр. Башта барчасының исе китәр. Кунакка да йөрткән булырлар, исем һәм шапырыныр өчен. Ә бераздан исләре дә китми башлардыр. Иманым камил, Габдулла Тукай китабын да чыгара алмас. Чөнки, блат, йә акча кирәк безнең заманда. Тукайга Тукай премиясе дә тәтемәячәк. Чөнки ул хакимият алдында ялагайланып йөрмәячәк, ә аларны тәнкыйть утына тотачак һәм татар халкы язмышы өчен көрәшәчәк. Ә монысы кемгә ошасын безнең заманда. Шуның өчен Тукайны эшкә дә алмаячаклар. Паспортың йә социаль номерың юк дигән сылтау белән. 144 яшьлек булуына карамастан пенсиясен дә түләмәячәкләр. Стажың юк дип. Нишләргә? Мин үзем дә аны озак тота алмаячакмын. Чөнки хатын һәм ике бала. Өч ел элек Казанны шаккаттырам дип килгән идем дә, исләре дә китмәде. Хәтер көнендә чыгыш ясаганым өчен эшкә дә алмадылар хәтта. Таксист булып йөрим менә. Көннеке көнгә ашарга җитә.

Шулчак уйларымны бүлеп, каршыга «Газель» машинасы килеп чыкты. Юлның уртасыннан җилдерә генә. Барып бәрелмәс өчен җан ачысы белән рулемне уңга борам һәм кабырга астында авыртудан һушымны югалтам.

Күпме ятканмындыр, хәтерләмим, әмма аңыма килү белән иң беренче сүз итеп: «Тукай кая?» – дип сорыйм. Моны ишеткәч, хатынымның коты оча хәтта.

Хастаханәдә ятканда ук, үземне китергән ашыгыч ярдәм машинасын эзләп табам. Алар бар да кабинада үзең генә идең дип бара. Шәфкать туташларының берсе генә машина читендә ниндидер бомж кыяфәтле берәүнең елап утыруын күрүен сөйли.

Ә иртәгә мине хастаханәдән чыгаралар. Таягыма таянам да Казан буйлап Тукайны эзләп китәм. Кем белә, бәлки ул урам себереп, йә йөкче булып йөридер әле. Ул эчкегә салышканчы, йә муенына бау элгәнче, табарга, аны ничек тә эзләп табарга кирәк!



*Чатыртау сыман горур, ялкын теле сыман җирән чәчле, үзе дә тормышта ут чәчеп торучы, ир-ат холыклы, әмма иҗатта самими хатын-кыз була белгән Азнакай тумасы – Гөлназ Газизованы (25.07.1991.) күптән беләм. Шулай да, аның «үз дулкынында» иҗат ителгән «җирән» рифмалы поэзиясен, моңарчы «Казан утлары» укучысына тәкъдим итәргә кул вә йөрәк җитми йөрде.*

*Ул арада, кайчандыр Азнакай төбәгендә радио тапшырулары алып барган Гөлназ, башкалабызга улы Илназны җитәкләп килеп, Казанны яулап кына калмады, туйлар алып баручы буларак та, банк өлкәсендә дә үзенә карьера ясарга, кабат тормышка чыгарга, янә әни булырга җитеште; аның «Ышандыр!» атлы тәүге шигырьләр җыентыгы басылып чыкты.*

*Поэзия дөньясына Гөлназны шагыйрә Луиза Янсуар җитәкләп алып килде, ул аның остазы гына түгел, ә җан дустына әйләнде. Үз чиратыбызда, без дә, ике шагыйрәне журнал битләрендә өйдәш итәргә, күрештерергә булдык.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

## Гөлназ Газизова

# Ә ОФЫКТА АЛ ҖИЛКӘННӘР ЙӨЗӘ...

***

Син минем бик ерак якыным.
Ялкыным. Җанымда дөрләгән.
Янымда үткәргән көннәрең аз алар.
Калалар аерган чак булды.
Чакрымнар һәм юллар чакырды.
Күп булды Күк аша серләшкән чагыбыз.
Чабабыз язмышка каршымы?
Карышып, үтәли җилләргә.
Хисләргә. Янабыз. Әле дә.

Якыным. Шул кадәр якынсың.
Дәвамым төсле син. Көчле син. Көчле мин.
Без – ике гарасат, кавыша алмыйча
язмышлар җиһанын иңләдек.
Килмәде, язылган ул бер көн килмәде...

Күк белә: бу икәү очрашкач
Галәмдә мең йолдыз кабыныр.
Табылыр әлегә тирәндә яткан сүз.
Ярый, уз, уз әйдә
Ходайдан бирелгән бер көнем!
Төннәргә тоташ та,
тоташтан яңгырлар яудыр син!

Югыйсә ул – давыл, һәм аның йөзенә
тик яңгыр тамчысы эленер,
һәм эңгер яшерер сагышын.
Пышылдар: «Бердәнбер. Бердәнбер...»

***

Таң җебе сузылган офыклар чигенә.
Чигенә-чигенә,
язмышым эзләре чигелә.
Куелган чик кенә.
Бүгенгем, үткәнем
һәм алда көткәнем,
арасы – таш дивар.
Диварлар янында кораллы сакчылар,
«Үт ,әйдә, тик япкач киләсен,
Кайтмавың үзеңнең беләсең.
Үткәнең бикләнсен.
Бүгенгең онытылсын.
Үт әйдә. Киләчәк башлансын!»
«Ә анда, димен, мин – бар әле.
Ул да бар. Ул миңа яр әле...»
Гөрселдәп ябылды шул чакта ишекләр.
«Күп алар, күп синең ишеләр!»
Ишегем артында убылып калдылар
кадерле дип йөргән көннәрем.
Син шундый... минеке
Һәм шундый өркеткеч.
Мин килдем. Киләчәк бүгенгем.

***

Мин сине
җанымның иң җылы нурына төрәм дә,
җибәрәм учымның түреннән.
Яшемне бишегең җырына үрәм дә,
ул җырны оттырам күгемнән.

Җыр түгел, ул – дога, ул – бәет, ул – сиңа
әйтелми йөрәкне тутырган
меңләгән иң назлы якты сүз,
ул – сулар тыныма төтендәй капланган
Өзелгән өметем, әйткән: «Түз!»

Ул минем күкләргә төбәлгән күземнең
иң кайнар яшеннән яралган.
Ул бишек җырлары – йөрәкнең зираты –
язылып та, җырланмый калган.

Ул – бишек җырлары күк сыккан яңгырда,
үтәли җилләрдә җырланыр.
Сабыем иң татлы төшләрен күрәдер.
Ул йоклый. Ул көтә. Яу, яңгыр!

Тик йөрәк кенә телем-телем...

***

Мин тома болытка уралып
Төшләргә юл алдым.
Төшләргә юрадым юлларны.
Шау-шулы шәһәрдән үземне табарга,
үземне эзләргә кузгалдым.

Мин качкын. Ә күкләр,
ә күкләр берүкләр,
былтыргы йолдызлар чигелгән.
Шул бер үк сагышым эзенә сокланып,
атылдым галәмем чигеннән.

Мин – ялган. Мин тоташ ялганган.
Мин – тоташ өзелеп бәйләнгән төеннәр.
Төеннәр дисбесен тарткалап санарга
Төннәрем сабырлык бирсеннәр.

Бу кичтә юк, һич тә,
Исәбем тагын бер төенне төйнәргә.
Бары тик болытка уралып,
киләчәк сагалый төшләрдә:

Синең дә чәчеңә чал кунган.
Чал кунган. Бәс сарган.
Юлыбыз кисешер берзаман.
Төенле дисбемне кесәмә яшереп,
гомерләр, дидем мин, аһ, узган.

***

Югалтулар һәм табулар аша
Йөрәк тибә әле, барыбер.
Тик ярату өчен язмыш биргән
бик аз вакыт: бары бер гомер...

***

*Җәй җирдә... Без киткән өйләрдә,*
*Без кайткан өйләрдә – җәй генә!*
Луиза Янсуар

Кыш әнә... Җир тулы.
Җан тулы кыш килгән.
Күрдеңме ул кучкыл карларның
Көпчәкләр астында эрүен?
Югалткан төннәрнең
бүтәннәр төшенә керүен?
Китүен, без тапкан җәйләрнең
җәйләүнең офыгы артына?
Күкләрнең каты да, әйтерсең,
бу кыштан ятсына...
Кайтасы юлларга кар ята,
аръякта, кемдер шәм кабыза,
җан сыза: хисаплар ябылгач,
табылгач һәркемнең үз өе.
Китмәсен җаннарның үз көе.
Табылган җәннәттә
бикләнми яшәүче кемнәр бар?
Уянып түгел лә... йокламый азга да?
Язгамы... әрнүем яңартам,
яңадан кайтмавын сагынам.
Соңарам.
Бу кышның җылысын тоялмый,
бер йомры көткәндә, үч итеп,
нигәдер чәйнегем кайнамый...



Әлфирә
Галиева

# САРЫ АТЫМ АЛТЫН НУКТАЛЫ

хикәя

**1**

Үрмәли алганы-алмаганы, яртылаш иңгән йортның койма башына үрмәләде: күрәсе иде күктән иңгән ике бөкреле җен карчыгын...

Маңка торыс Сәлим, ыштаны ертылып, аска очты, тагын өч-дүртесе әллә ни күрә алмады: кырмавык баскан йортта да, өйдә дә үле тынлык хөкем сөрә иде...

Йорт тирәсендә юк-бар йомыш юллап иснәнгән карт-корыга да «ике бөкреле» җен күрү бәхете тәтемәде: ни ут кабынмады, ни су чылтырамады, ни ишек ачылмады. «Гайре кызык хәл» күренмәгәч, халык гасырдан артык буш торган йортны урап уза башлады. Бик кирәк иде! Ике бөкреле җен генә кызыксындырган иде олысын-кечесен...

Ә күршедә... Ә күршедә туй гөрләде. Нәкыйп малае Илгизәр Миңсылуны урлап кайткан... Авыл бермәл тынсыз калды: бакчы, Илгизәр күрше авыл кызы Бикәне ярәштереп йөри, дигәннәр иде. Тегесе дә Илгизәргә чыгарга биш куллап риза булган, ди. Бик тә яратышалар икән берсен-берсе.

Хәзерге кәләш Миңсылуның да еракта-еракта сөйгән яры калган, ди, имеш... Ул да ярәшелгән булган, ди... Белмәссең бу яшьләрне...

Туйлар узгач, туннар тузгач, белде инде әпчи карчыклар: имеш, Илгизәр яратып йөргән күрше авыл кызы Бикәне дә кемдер урлап киткән. Тегесе эһ итәргә дә өлгермәгән, имеш. Кызны бер тәүлек урам аша салынган яңа йортта бикләп кундырып торганнар, ди. Илгизәр никадәр генә тырышса да, Бикәгә соңгы сүзен әйтә алмаган, үзенеке итә алмаган... Ак күбеккә баткан юргасыннан да төшмичә, урам ярып елаган да елаган, айга карап, ялгыз бүре кебек улаган да улаган. Азаккы исәптә, курайда ят көй чирткән... Бикәгә багышлап, үзе җыр язган, имеш, диделәр... Ир башы белән инде... Гадәттә, авыл мужигы бәбәк сидереп тормый, каты-коты әйтә, ордым-бордым кылана да бураннар туздырып китеп тә бара... Йә канга батып сугыша... Ә бу... «Онытмамын, Бикәм, онытмамын, гомерлек ярам булып калырсың, җаным мәңгелеккә сырхаулады...» – дип елаган, имеш... Килешмәгәнне...

Язмышына үч итепме, ачуын шулай чыгарасы иткәнме, холкын күрсәтергә теләгәнме, ай юктан чыра дипме, башы-күзе әйләнгән чак булганмы, практика үтәргә килгән мөгаллимә Миңсылуны, ай-ваена карамыйча, атка салып кайткан, имеш... Минем сөйгәнемне урладылар, мин дә кемнекендер урлыйм, имеш...

Менә шулай... Икесенең дә күз яшьләре кипмәгән чак әле. Миңсылу, ак келәткә чыгып, тавышсыз гына елап ята икән...

Илгизәрнең бу гамәле «астан кисеп, өстән ямау салу» кебек бер нәрсә булса да, гөрләп туйлар узды, йорт тәрәзәләрен чиккән пәрдәләр бизәде, сандык-сандык бирнә түрдә урын алды, кабартылган мендәрләр өй бизәге булып менеп кунакладылар. Ата-анага каршы әйтә торган заманамыни, мөгаллимә абруена да тап төшерергә ярамый – язмышың белән килешәсең дә яшисең. Яшисең, хәтта туйда кияү ялгышып, хатыны колагына Бикә исемен пышылдаса да, яшисең...

Шул көннәрдә «ике бөкреле җен» күрше йортка «иңде». Кеше күзенә күренергә ашыкмады: төтен чыкмады, өй юылмады, таба исе авыздан төкерекләр китермәде... Ничек бер ай буе җан вә тән асрагандыр ул, аннары гына нигезе тарала башлаган иске йортта тереклек әсәре күренде: таякка таянган, яртылаш җиргә иңгән «ниндидер бер шыксыз нәрсә» көн яктысына чыкты. Иң беренче итеп, Миңсылу белән Илгизәрнең җил капкасын шакыды «сәер җан иясе»:

– Братухалар, ничек көн итеп ятыш?

– Әйбәт кенә, әби, узыгыз.

– Нинди әби булыйм мин сезгә?!

Карчык ачуланып, таягын һавада уйнатып алды... Баз төбеннән килгән тавышы белән нидер әйтте...

– Йомышы булмаса да кирә бу, димәгез. Берничә кадак биреп торыгыз әле бурычка, кире кайтарам, шөлләмәгез... Баскыч төбенең иң зур тактасы купкан, шуны кадакларга исәп... Син, ир заты, йортыңда такталарыңны кадаклап тор, купмасын такталарың...

Баштанаяк карап чыкты Илгизәр: кара, моның тавышы да, сүзләре дә авыл карчыкларыныкына бер дә охшамаган, тач төрмәдән кайткан төксе ир-атныкы кебек яңгырый...

– Хе... Минем такталарым кадаклаган...

– Вәйт синең хатын – җайлы урындык: телисең утырасың, телисең этеп-төртеп җибәрәсең, әйеме, Илгизәр, мәлгунь…

– Аңламыйбыз, ни сөйлисез? Нинди урындык?

«Алагаем зур бөкре» шуышып килеп, Илгизәр кулыннан кадакларны тартып алды да ничек кергән шулай «тәгәрәп» чыгып та китте...

– Кәкрене төзәт, шайтан ояламасын!

Яшьләр берни аңламый аптырап басып калдылар...

Беренче танышу шулай үтте.

Яшь кәләш Миңсылу яңа тормышка ияләшеп килә. Мәктәптәге хәттин ашкан мәшәкате өстенә тавык чүпләп бетерә алмас мәшәкатьләр өйдә дә көтеп тора үзен. «Сәер җан иясе» ак келәт юлына күз салгалый: кирә дә елый, кирә дә елый Миңсылу шунда. Тавышсыз... Йорт тулы тавыкларны, оядагы этне, карт өянкегә кунган кара каргаларны куркытмый, имеш...

– Бурычымны керттем. Алмак күрке – бирмәк...

– Кирәкми иде, апа, кадак бар бит...

– Базара нет! Өйрәтмә мине, ак келәтеңдә тозлы елга юл яра, күз салгала, арт сабагыңны укытасы нәрсә! Быдла!

Берни аңламады Илгизәр: башы киткән, ахры, бу нәрсәнең... Нинди келәт, нинди тозлы елга, нинди базар, нинди төрмә жаргоны? Йөзен дә күреп булмый, ичмасам, ертык шәл белән чорнаган чыраен. Төрмә чыпчыгы! Һаман Илгизәрне ачулана...

– Тфү!

Укытучылар «Авыл хезмәтчәннәре көне»нә концерт әзерлиләр. Өстән шулай кушылды. Илгизәр дә курайда уйнарга тиеш булды – теге үзе язган көйне...

– Мин – кечкенәдән үк аю аяк, бии белмим, – диде Миңсылу, оялып кына. Яшь мөгаллимә директорга каршы сүз әйтергә кыенсына иде.

– Аю да биергә өйрәнә, өйрәнерсең, буй-сының бар, аякларың төз, үзең тыпырдап торасың... Бии-бии остарырсың, биюче булып китәрсең әле бер...

– Юк-юк, мин – бишектән үк аю аяк. Калганнар биегәндә, почмакта утырып тора идем... Ап-ак күлмәк кигән, ак бантик куйган, ак сандали кигән кызчыкны биетергә маташалар, ләкин берничек тә биетә алмыйлар, бер-ике генә атлый да үз аягына үзе абынып егыла... Җырлый беләм, җырлармын берәр җыр...

– Алты дәрестән соң репетициягә. Аннары сайлаулар буенча җыелыш, син – комиссия әгъзасы...

Тәки биемәде Миңсылу... Җырына да кул чапмадылар, җыры күбрәк ыңгырашуга гына кайтып калгандай тоелды. Ә Илгизәргә чатнатып кул чаптылар...

– Елама, олан, ирең Илгизәр иске мәхәббәтен берчак онытыр, сине сөя башлар... Тормыш гел арты белән тормас! Сөймәслек хатын түгел син... Ә биергә тормыш өйрәтер... Тормыш ишкәкләрен ялгыз ишкәннәр «биеп» яшиләр...

Инде малай туды, кыз туды. Тормыш тәгәрмәче туктаусыз әйләнде дә әйләнде...

Карчыкның таягы тынып тормады:

– Мәхәббәттән башка кеше тере мәет булып яши. Әйе, Миңсылу эшли, йөри, ашый, эчә, йоклый. Йортта да, мәктәбендә дә үз вазифасын башкара, ләкин тончыга!

Илгизәрнең бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты бөкре сүзләре... Үз хәле хәл әле монда – Бикә сагындыра, каһәр. Ирнең күзләрендә сагыш кимемәде... Чиксез офыкка карап, Бикәсен уйлый һаман... Кулда – курай... Үзе хисләрен һич кенә дә Миңсылуга белдерми. Авыр сүз әйтми, авыр эш эшләтми, гел мактап үсендереп тора... Чәчкәләр бүләк итеп тора... Ә үзе беренче мәхәббәтенең исемен кушып җырлап йөри...

– Олан, ак келәткә кереп гелән елама, үтәр аның беренче мәхәббәте...

– Мәңге онытмас, ахры, Бикәсен. Кызга да Бикә дип исем кушты.

– Хе, Бикә, диген...

«Җен» сүз әйтмәде, таягын җирдә «биетте». Аягы аксый, куллары калтырый, үзе яшендәге таягы белән җиргә нинди генә хәрәкәтләр ясамый.

– Кипиш оештырам мин аңа, пасть порву!

Карчык татар әбиләренә хас булмаганча тамак ярып кычкыра, таягын тәртипсез рәвештә һавада болгаганнан соң, шыпырт кына җирдә биетә:

«Раз-два-три, шаг вперёд, раз-два-три – шаг назад!»

– Әби, тукта, бу бит бию хәрәкәте! Синең таягың бии!

– Минем таяк, синең аяк биесен, олан. Йөрәгеңдәге таш ватылып төшеп китәр... Бие, димен, бие! Акылдан шашмас өчен бие!

– Ни сөйлисең син? Безнең гаиләдә бар да яхшы...

– Липовый сүз, ялганың күзне яра! Беләм мин! Җайсызрак кагылсаң да, уалырга торган йөрәгеңә һава җитми! Иреңнең йөрәгендә икенче планда син, хатын, шуңа эчтән янасың!

– Юк, юк, юк!

– Тел астына дару сал, күгәрченем!

Карчык эченнән нидер мыгырдый-мыгырдый чыгып китте.

– Раз-два-три, раз-два-три... Шаг вперёд, шаг назад...

Нинди серле карчык соң бу, Миңсылуның эченә кереп караганмы, йөрәгендә актарынганмы? Каян белә аның бәхетлеме, юкмы икәнен, каян белә йөрәк серләрен? Бер галәмәт бу! Галәмәт! Ерып йөргесез пычрактан йөри, ә киеме чип-чиста! Төрмә жаргонын кушып сөйли, үзенең авызында – дога... Иске кием киеп, урамга чыга, ә өен оҗмах оясы ясап куйган. Намазлыгы гел җәелгән килеш тора... Кайчан юа ул кардан ак пәрдәләрен, ак күлмәк-яулыкларын? Юган керләр җептә җилфердәми лә...

Ни диеп сүз катсын иренә, яраткан Илгизәренә? Хыянәт итми, какмый-сукмый, сүгенеп кычкырмый. Хатынга тулы ирек куелган. Кая тели, шунда бара, нәрсә тели, шуны ала. Йорты бар, балалары бар, тормыш итәргә җитәрлек акчасы бар. Кадере булмаса да, яраткан эше бар. Тынгысыз эше аңа шәхси тормышка вакыт калдырмый. Кайчан карама, кәгазьгә чумган. Буй-сыны, матурлыгы бар, ил алдында абруе бар. Тәрәзә төбе тулы гөл, бакчасы тулы чәчәк, йорттагы фонтаннар янында камышлар буй сузган, аккошлар йөзә. Сукмагы – таштан, эшләр автоматлаштырылган. Ни җитми Миңсылуга? Ни өчен ул бәхетле елмаймый? Бу сөальгә җавапны кем белә?

Авылда җүләр исемен күтәреп көн итүче «ике бөкреле җен» белә... Сүз уңае әйтер әле... Теле белән түгел, таягы белән...

Исем дигәннән, чыннан да, әле һаман исемен белми авыл халкы – теле эшләми, тел урынына таягы эшли лә аның...

Хәер, паспортына Сахи дип язылган, диде, почта кыз.

Карчык йорттагы бәбкә үләненә таягы белән суккалап, ча-ча-ча бию хәрәкәте ясады.

– Йөрәк тибеше көенә бие. Яшисең килсә, бие, бие, димен, тыңла сүземне, тыңламасаң, башыңны ярырмын!

Күтәрелеп тә карамыйча тагын чыгып китте...

**2**

Таң беленгәндә, Миңсылуны шәһәргә ике атналык курсларга озатты Илгизәр. Капканы ябып өлгермәде:

– Абай булмыйк дип, кояш белән кузгалдым, дәшмә, мәлгунь ир заты,

бүлдергәнне яратмыйм! Дөресен әйт, матри! Алдасаң, авызыңны кан итәм! Глаза выколю! Шулай нык яраттыңмы Бикә исемле кыз баланы?

Карчык ике аягын нык терәп, шулкадәр туры баскан ки, әйтерсең бәдәнен ямьсезләп торган ике бөкре беркайчан булмаган да...

– Җавап бирмичә, мин сине беркая чыгармыйм. Тычкан уты яктысында Миңсылуның җазу-сызу белән утырганын күрдем. Контроль эш эшләде төнката! Таң беленер-беленмәс тукталышка кыяклады. Алдалама, дөресен әйт, алдаласаң, башыңны шушы таяк белән сугып ярам! Балдеж ясыйм мин сиңа! Сине генә җиңәм, кул белән йорт бурасын күтәрә алган хатын мин.

– Әйе, яраттым шул Бикәне, хәзер дә күз алдымда тора...

– Саф мәхәббәт иясе икәнсең. Шулай ярата алучылар сирәк. Мәхәббәткә киртәләр юк. Авыз суың корыды, Бикә дип. Ләкин, син гомер буе янып яшәрсеңме? Таякны катырак бөктең, ир тәресе, кыланмышың кылга сыймый синең. Хатының – парлы ялгыз! Сирәк хатын түзә мондый хәлгә. Гомер үтә. Тәне сызласа да, зарлана торган түгел Миңсылу. Тормыш китабының Бикәле битен яп, икенче битен ач! Анда үткәндәге Бикәгә урын юк, Миңсылу исемле искиткеч күңелле, сине өзелеп яратучы хатын бар, йөрәгеңнең түрендә аңа урын бир! Ярат син аны, каты ярат! Бер генә яшибез!

– Мин аны яратам!

– Юк, юк, тагын бер кат юк! Ул синең яратуыңны сизми. Күзләренә бак, утлы күмер булып янмый күзләре. Ә синең, шайтан таягының, күзләрең гелән-гелән сагышлы... Күзләрең әле һаман Бикәне яратуыңны әйтеп тора. Хатын-кызның күңеле сизгер аның, ул синең ни уйлаганыңны ашадан-аша сизеп тора!

– Миңсылу бит миңа берни дә әйтми.

– Теле белән әйтми, биюе белән әйтә. Ир дип сине зурлый, гел чәпчеми, чөнки ул сине ярата. Мең сынаулар кичте, бахыркаем. Аның да сөйгән егете булган, ләкин тормышының ул битен кире ачмаслык итеп япкан ул...

– Мин Бикәне оныта алмыйм. Ул да гомер буе мине генә ярата. Аның мине өзелеп яратуы тынгы бирми! Нишлим соң?

– Һаман ятратканын каян беләсең? Әллә кайчан оныткандыр инде? Әйткән иде диярсең...

– Күңелем сизә. Ярата ул мине!

– Ул да кеше кешесе хәзер, сине генә уйлап утырмыйдыр, мөртәт! Оныт аны! Уеннан уймак чыкмасын...

Карчык тагын таягы белән җиргә сыза башлады «Раз-два, налево, вперёд». «Раз-два – направо, назад». «Сынатырга ярамый, сынарга ярамый...»

Кемгәдер бию өйрәтәме соң?!

– Йөрәге янса да, дәшми Миңсылу. Чөнки гаиләне ватасы килми... Аннан, аннан... Ул – укытучы – ил күзендәге кеше – калганнарга үрнәк булырга тиеш ул... Балаларны да үз үрнәгендә тәрбияли: түзем, сабыр булырга, кеше хакын хакларга, калганнарны кайгыртырга! Ул – фәрештә җан, калганнарга яхшы булсын дип яши. Уйла, эштер-өштер генә түгел, ныклап исәплә, бизмәнгә сал, әле соң түгел...

Мизгел эчендә «ике бөкре» кире урынына кайтып утырды, карчык күзгә күренеп картайды, тиз генә гаип булды. Таяк белән сызган җирдә бәбкә үләннәре генә тырпаешып калдылар...

Хатын-кызга хас булмаганча көчле бу карчык, гади генә хатын түгелдер, Сахи...

– Кайгырма, бик бәхетле булырбыз хатын белән...

– Белмим... Бер генә төнен дә уйсыз йокламый хатының... Ул күз яшьләре кая сеңеп бара икән?!

Илгизәр уйга чумды... Авырткан җиргә кагылды Сахи карчык...

Әллә бер барып күреп кайтасы инде Бикәне? Күз кырые белән генә карап, ә? Бәлки, күзләренә карап, «Мине һаман да яратасыңмы?» дип сораргадыр, озын толымнарын сүтеп җибәреп, хуш исле чәчләренә чумаргадыр... Бер генә минутка күрсәм дә, сагышларым басылыр кебек. Кураемда уйнап, аңа багышланган җырны җырласам...

Бу уйлардан ирнең тәннәренә рәхәт җылылык җәелде. «Күңелем белән ничә барып, ничә кайттым икән, Бикәм, синең янга?!»

Таң беленгәндә, җил капканы «алагаем (әллә төн чыкканчы тагын да зурайганнар инде!) ике бөкре» төртеп ачты:

– Кояш күзен ачканчы, адәм уянганчы, күрше авылга кыякла, шайтан малае, күңелеңне бастырып күреп кайт, бөтен гөнаһлы уйларыңны баганалы юл буена сибеп кайт. Сагыну-сагышларыңны башлары күккә тигән биек наратлар арасында адаштырып кайт! Барганыңны Миңсылуга ишеттермәбез, үзем йомып калырмын. Бар, бар, чистарып кайт түлке... Уйларыңны тәртипкә сал. Багучылык итмәсәм дә беләм, төнката шуны уйладың, агач мылтык белән атасы нәрсә!

Чыннан да, пәри-җен бу, колагыңнан керә, җаныңны үтмәс пычак белән телә, аннары  табаныңнан чыга...

– Күпме газапланып яшәп була? Үзең дә газапланасың, Миңсылуны да газаплыйсың, авызыңа шайтан төкергән! Бер җан,бер тән булып яшәүгә ни җитә? Гомерләр бер генә, кадерен бел генә...

– Газапланмый ул, аңа авыр булса, ым белән булса да аңлатыр, бер кәлимә булса да, сүз әйтер иде... Ул дөнья куып, җир җимертеп эшли. Аңарда яшәү дәрте ташып тора, эшендә нинди зур исемнәр алды. Бер Мактау кәгазе алыр өчен җиде кат тиреңне чыгарырга кирәк! Ә балаларны ничек ярата ул, һәрберсенә зур шәхес итеп карый. Мактау кәгазьләре дә кирәк түгел инде укытучыга, укучылары кеше булып чыкса, шул җитә. Хөрмәт тулы күзләре белән карасыннар иде дә соң...

– Әйе, ләкин күзләре пыскып янган учак кебек кенә. Ялкын юк аларда, юк, ишетәсеңме? Синең күзләреңнең сагышы бәгыренә укмашкан төен кебек аның җанына ягылган, иркенләп суларга бирми! Сулый алмый ла! Үтәли күрәм хатын-кыз җенесен!

– Син боларны каян беләсең, җен карчыгы? Әй, тфү, Сәхи әби! Син таш кебек бит! Мәхәббәтнең нәрсә икәнен беләсеңме син?

– Әһ-һә, кармагыма каптыңмы, ир улак, мин күргәннәрне күрсәң, өч бөкрең булыр иде синең... Ишеттеңме, тау хәтле өч бөкре атланыр иде аркаңа!

...Урман аша гына элдертте Илгизәр. Җәяү генә йөгерде. Ләкин, карчык әйткәнчә, сагышлы уйлары юл буена коелып калмады, юлаучы биштәре кебек ияреп барды, ияреп кайтты...

Күрде ул Бикәне. Күрде дә танымады... Нык үзгәргән хатын Илгизәргә

сәлам дә бирмәде, лач-лач сагыз чәйнәп, күрше хатыны белән ләчтит сатып тора иде. Әллә бераз салмыш та иде...

– Син, син... Бикә?

– Бәрәччччч, бакчи, Мөнәвәруш ахирәт, егет чакта минем арттан йөргән нәрсә килергә батырчылык иткән! Урман асты авылында ни калган диең хәчтерүш иргә? Сине күрер дә балавыз булып эрер дип белдеңме әллә?! Бер укытучы кисәгенә өйләнгән дигәннәр иде, монда нишләп киләп сарып йөридер, Мөнәвәруш?

Тизәкле итәгенә шыңгырдатып, маңкасын сеңгергәндә симергән Бикәнең алдагы ике теше юклыгы да күренде:

– Актыгы булсын! Монда күренмә! Ирем акылга җиңел, акылы төштән соң, сугып, ботыңны сындырыр. Үземә дә эләгеп тора! Ха-ха-ха! Әйе бит, Мөнәвәруш, минем Алла колы бик көнчел. Баш исән чакта ычкын!

Йа Раббым, Бикәме соң бу? Алтын бәясенә торган, бер бите ай, бер бите кояш Бикә кая киткән? Әкияттәге урман кызы башыннан алып аягына кадәр дию пәриенә әйләнгәнме? Дөнья ничек бөккән! Бер дә сагынмый микән соң?!

Илгизәр хыялланган озын толымнар да, һаман яратам дип, муенга сарылулар да, башын әйләндергән зифа буй-сын да юк монда! Утыз яшь кенә булса да, дөньялардан киткән кебек битараф караш! Тәмам сазлыкка баткан бу... Тәмам... Сәбәбе нидә икән?

Кайтканда, салкын су белән коенды Илгизәр, уч-уч салкын су эчте, йөрәк януы, сөюе әз генә дә басылмады...

Шушы күренештән соң да гайрәте кайтмады ирнең: Бикәне сазлыктан ничек тартып чыгару уе белән яна ир. Хәзер инде әкияттәге гүзәл кызны түгел, маңкалы, тизәкле, шапшак, әшәке телле, буе-сыны бер Бикәне бөтен җитешсезлеге белән ярата башлады...

**3**

– Аны-моны карама, биюләреңне төп кәсебеңә әйләндер, Миңсылу кызым... Менә шулай... Йөрәгең янган саен җанга тансык шөгыль тап. Сары ат кебек саргайма...

– Эхе...

Ел артыннан ел үтте. Бәбкә үләненә шаулап бию коелды: хип-хоп, брейк-данс, локинг, хаста, танго, балет, вальс, полька, тектоник, хакка, джампстайл, фокстрот, контемп, самба, румба...

Бу биюләр – Миңсылуның күңел халәте. Ни гаҗәп, ул биюләрне бөкресе чыкканчы чиләнеп өйрәнмәде хатын, үзеннән-үзе килеп чыкты алар, гомердә бии белмәгән аякларга үзләре чорналдылар... Сагышыннан саргайган иргә караган саен, сабырлыгы беткән саен бер бию өйрәнелде... Сары атка әйләнмәс өчен йортның ышык урынында сикерде дә сикерде... Зур фикерләр әйтелде... Ул «фикерләргә» узып барышлый болыт малайлары колак салды, алар елап шешенеп беттеләр... Ә Илгизәр... Юк... Ишетмәде ул аларны...

– Бай программа синең, кызым...

– Миңа шулай «рәхәт»...

– Син үз тормышың күчәрендә түгел... Үз күлмәгеңә сыймыйча биисең бит, кызым...

«Ике бөкре» ауган диварны таягы белән төйде:

– Бию дигән нәрсә күңелендә бөредә килеш яшеренеп яткан, хәзер чәчәк атып маташа димәкче буласыңмы? Мәскәү калаларыннан махсус кайтып өйрәттеләр димәкче буласыңмы?.. Юк, хисләр биетә адәм баласын...

– Әйе!

– Биергә өйрәнгәнче, таш кыяга сукмак салу җиңелрәк!

Авылда Миңсылуның биюче даны таралды. Аның биюеннән башка бер генә мәктәп кичәсе дә узмас дигәннәр иде, ни тырышып та сәхнәдә бер генә бию дә башкара алмады өендә табаныннан ут чыгарган мөгаллимә хатын. Үзе йөзләгән балага бию өйрәтте, үзе чит-ятлар алдында бии алмады...

– Бу юлы хәрәкәтләрең үзгә, кояш нурына тиң җылылык бөркелми...

Тиз сизә иде «ике бөкре» Миңсылуның күңел халәтен...

– Бию кешенең холкы, шәхси бәхете турында сөйли. Тормыш итәргә көч тап! Үз-үзеңә бикләнмә! Калганнарга яхшы булсын диеп, бишкә бөгелмә, бит сыпырырга өйрән...

Быел яңа партия биюләр өйрәнде Минсылу. Рок-н-ролл, сальса, свинг, посадобль, краковяк, мазурка, кадриль, полонез, брейк-данс... Хәзер ул йортта бәбкә үләннәрен таптап биеми, ә Илгизәр салган артык кыйммәтле брусчаткада бии...

Кулыннан килмәгән эше юк иренең. Битарафлыгы гына үтереп сала инде хатынны, күңел коесен киптерә. Күпме парлар яратышмыйча яши, ләкин Миңсылу кебек саргаймыйлар... Сары атка әйләнмиләр... Башка хатынның битарафлыкка исе дә китмәс иде, киресенчә, гомер айнымаган, бугаз ертып кычкырган, ләкин ябышкак кебек ирләрен Илгизәргә, яки «көндез шәм яндырып табып булмый торган иргә» алмаштырып китәрләр иде. Пычагымамы аларга күзеңә генә карап тора торган эчкече яки хәерче ир? Мунча сукмагына хәтле брусчатка җәеп, джакузи куярлык ир булсын! Миңсылу башка камырдан әвәләнгән, күрәсең... Бодай арасында бер солы... Тормышта бернәрсәсе дә кирәкми ирнең, яратсын гына иде ул... Саф күңелле хатынга, өйдә дә, мәктәптә тә тәртип булсын...

Капка төбендә утырган карчык бүген «кабат» ачыласы итте иргә:

– Ир-ат мәхәббәте хатын-кызның йөрәген баета. Алҗытма аны... Үзен хатын-кыз итеп тойсын...

– Мин аны бик бәхетледер дип уйлыйм...

– Бәхетсезме, бәхетлеме – теле белән әйтми ул, биюе белән әйтә. Күз сал ак келәткә...

– Ак келәткә йозак куйдым күптән...

– Йозак кына киртә түгел,

Түгелгән яшьләремә...

Алдыңда ялтырап яткан, мәхәббәт белән түшәлгән юлдан барасың килми, сиңа абына-сөртенә атлау кызыграк, күрәсең...

Икәү балык тоттылар, ай нурында назланышып су керделәр, болыннан чәчәкләр җыйдылар, бәрхет үләндә аунап яратыштылар, тәгам ризыклары авыз иттеләр, су буйларында казлар, торналар карадылар – ә күңелдә бушлык, чөнки ир күзендә сары сагыш. Күзләр үзләре дә сизмәстән күрше авыл ягына карыйлар... Анда – сагыну, анда – гаҗизлек, анда – җавапсыз сөю...

«Йөрәгең белән минеке генә бул, бары минеке генә... Өченче берәүгә анда урын булмасын, очыр аны күңел читлегеңнән. Парым бар – үзем ялгыз. Яратасым, яратыласым килә...» Шашкан ай яктысында Миңсылуның күзләреннән шуны укыды Илгизәр...

**4**

Миңсылулар мәктәбенә күрше авылдан да балалар килеп укый. Ни гаҗәп, барысы да Миңсылу классына ашкына. Ярата шул ул аларны, гадел, кешелекле, юмарт. Балалар шуны тоя... Балаларны яратмасаң, мәктәптә эшләп буламы, йә?!

Инсаф исемле укучысы дәрескә соңга калып килеп керде. Миңсылу:

– Нишләп соңга калдың? – диде.

– Егылдым, кулымны сындырдым.

– Ни булды?

– Егылганда диварга таянып калып була иде, мин тотынмадым, Миңсылу Галиәкбәровна.

– Нигә тотынмадың инде, кулыңны сындырмаган булыр идең...

– Диварда пәрәвез эленеп тора иде, тотынсам, пәрәвез өзелә һәм үрмәкүчнең оясы җимерелә иде... Егылганда, ялгыш бер чикерткәнең аягын сытканмын, аңарга гипс салдым. Ялганмас инде аягы, каты сытылган... Аннары... Аннары... Бер чыпчык сусаган... Аңа су эчердем. Кер каптыргычының түгәрәк уентыгына су ташыдым... Ул уентык шундый-шундый нәни, су түгелә дә китә, түгелә дә китә. Чыпчык шуннан гына эчте, башка савытка якын килмәде...

Миңсылуның күзләренә яшьләр эленде:

– Син дөрес юлда, Инсаф!

– Минем туксан ике яшьлек Бибиәсма әбием әйтмешли: «Сабак бирүче хәлфәгез дөрес юлда сезнең! Тәрбия беренче урында торырга тиеш, гыйлемле кеше тәрбиясез икән – поты бер тиен!»

Шулай ел артыннан ел үтте. Чәчләргә чал кунды. «Ике бөкреле җен» бик бөтәшсә дә, тавышы нык чыга иде әле:

– Тыңла, шайтан малай, минем сүзне сүз итмәдең инде, янган утта көйдердең Миңсылуны. Яздан ак чәчәкләр өмет итә алмады хатын, көздән ак чәчәкләр өмет итми дә итми инде...

– Оныта алмадым ла...

– Яратып яшәргә өлгер димен, улым. Шайтан малай дигәнгә ачуланма. Мин бәхетсез хатыннарны күп күрдем. Алар – үзгә. Бәхетсез хатын-кыз әшәкелеккә сәләтле! Йә ул сине үтерә, йә үзе үлә. Йөрәге чересә, озак яшәми хатын-кыз...

– Син аны каян беләсең? Бик бәхетсез булып карадыңмы? Әллә бәхеттә йөздеңме?!

– Минем сүземне гомер буе ишетмәдең инде син. Йөрәгең ишетергә теләмәде...

– Син безгә беркем дә түгел! Тыгылма, аягыңны сындырырсың...

– Әйе, мин бу авылда беркем дә түгел. Мин сезгә бәхет телим, бары шул гына.

– Хе!

– Читтән караганда бар да күренә. Тикшереп йөрмәдем, ләкин Миңсылуның тормышы ак келәттә елап башланды. Мин сиңа әйттем, ак келәтеңдә елга юл ала, дип. Ул Миңсылуның күз яшьләре иде. Гомере елап дәвам итте...

– Турысын әйтеп каркылдарга идең, бар эшең һавада кәкре таяк болгау булды... Сүз боткасы ясап торасың. Үзеңнең бәхетең булдымы соң? Кая инде сиңа бәхет? Мондый хатынны кем яратсын?!

Төгәл образ бирүдән, карчыкны сүзе белән бәреп егудан, Илгизәрнең авызы чалшаеп китте... Чыраен яман сытып:

– Менә хәзер җавап бирә алырсыңмы? – диде.

Ә карчык... Карчык, Илгизәрнең артыгын әйтеп ташлавына игътибар итмәгән дә кебек кыланып, үтә йомшак тавыш белән:

– Исемем Сәхелбәян минем. Сахи дигән исемне колониядә тактылар. Настялар, Машалар, Катялар, Зәйнәпләр Сәхелбәян дип тулы исемеңне әйтеп тормаслар инде. Әйе, әйе, караңгы авыл кызы башкаланың зур төрмәсендә эшләде. Әле кем булып эшләдең диең, хатын-кызлар төрмәсендә тәрбияче булып! «Дөньядагы иң авыр эш нинди эш?» – дип сорасалар, мин, «Төрмәдәге тәрбияче яки карауччы эше» – дияр идем... Ни өчен дисеңме? Юк, аларның җинаятьләре куркытмады мине. Аларның чәчләрен кырку, киемнәрен тентү, камералар аша йөртү, ашарга китерү, урамга алып чыгу куркытмады мине, хәтта мизгел эчендә арттан пычак тыгу куркынычы да куркытмады. Аларның һәрберсендә яшереп саклаган үткен корал кебек нәмәрсә бар иде. Иреккә чыккач, үзеңне җәзалап үтерәбез, диделәр: кемдер суя, кемдер аса, кемдер бозлы суларда агыза мине... Үлемнәрнең төрлесе белән янадылар. Юк, мин аларның янауларыннан да, миңа киләсе әҗәлдән дә курыкмадым. Мин аларның кабат бәхетсез булуларыннан курыктым. Сурәтләргә сүз җитми торган бәхетсез язмышлар, мәхәббәтне татымыйча саргаюлары... Миңа ике бөкре берьюлы чыкты... Өсләренә карап йөрәгем бетте, йөрәк ягында – бер бөкре, ашый алмый торганга әйләндем – бавырым кипте – менә сиңа икенче бөкре. Юк, какмадылар, сукмадылар, сүгенү сүзләре әйтеп тиргәмәделәр Катя, Маша, Зәйнәпләр, Чайгонаалар...

– Чит кеше өчен бөкре үстермиләр инде...

– Укытучы өчен чит укучы булмаган кебек, минем өчен дә чит кеше юк! Барыбыз да Аллаһ бәндәләре!

– Әй, безнең Миңсылу һәр укучысына йөрәген ярып бирә ул! Без аларның киләчәген язабыз, ди. Яза, пычагым, җәмгыять ни кыланганны кылана алар! Әнә бер укучысы мәктәптә акчасын югалткан, төн уртасында әнисе бездән акча таптырды, җиде буынга хәтле эт итеп сүкте. Иртәнге алтыда шалтыратты әнисе: «Акчасы өйдәге чалбар кесәсендә калган булган икән. Баланың кесәсендәге акчасын да саклый алмагач, ни генә кырасыз соң сез мәктәптә? Тагын бер шундый хәл булса, туры министрга шалтыратам! Хөкүмәт акча түли бит әле шул мур кырган укытучы сәләмәләренә!»

Миңсылу, «Каян акча табыйм, дип түгел, кая хата җибәрдем икән?» – дип кайгырды... Кайчан югалттык без әхлакый йөзебезне?! Гомумән, укытучы үз тормышы белән яшәми ул... Укытучы хезмәтенең асылын бөтенләй дә белмәгән ата-ананың мыскыллауларына түзеп яши. Түзмәс иде, ата-ана сүзе һәрвакыт өстен!

– Кешенең тәнен табиб дәваласа, җанын мөгаллим дәвалый. Кызганыч, укытучы сүзе элеккеге кодрәткә ия түгел... Укытучы бит ул гамәлләре белән баланың киләчәген яза: соңыннан беленә инде – дөрес язганмы, юкмы? Мин дә заманында бик чибәр хатын идем. Бу сырхаулар соңрак килде. Ике ел элек кенә инвалид коляскасында биш тапкыр намаз укый идем. Аллаһының кодрәте булып аякка бастым, ләкин бөкреләрем үсеп киттеләр...

– Шундый матур булгач, битегезгә ертык шәл кисәге чорнап йөрисез...

– Ә, бу прикидны әйтәсеңме син? Тирә-ягымда  бәхетсез хатыннар булгач, мин генә бәхетемнән балкып йөрмәм бит инде...

– Җинаятьче хатын булгач, җүнле түгел инде ул...

– Бар да алма кебек хатыннар, мәхәббәт җитмәгәнгә әшәке гамәлләр кылганнар алар...Салкын хатыннар булмый, аларны җылытучы юк...

– Байлыктан сикергәннәрдер...

– Син сөйгәнеңнең иңнәренә төлке тун ташлама, иңнәрен кысып кочакла да кара яндырганчы үп. Ул синең яратуыңны аңласын...

– Мәхәббәт юк дип кенә ирләренә пычак кадамаганнардыр инде? Күңел дигән нәрсә бар бит әле... Йөрәк дигән нәрсә булмаса, бәхетле дә булыр иде адәм баласы... Төрмәләрдә саргаеп үлмәс иде! Миңсылу да...

– Мин Миңсылуны хөрмәт итәм, яратам! Без бергәләп гомер итәбез, бер пот тоз ашадык! Кулына пычак алмас!

– Сөйгән ярны хөрмәт итү аз, аны яратырга кирәк. Җылыга мохтаҗ ул. Ялгызлыктан җаны өши аның.Үткәнгә юллар юк икәнен аңламадың!

– Йөрәгемә әмер бирә алмыйм,Сәхелбәян әби!

Үзсүзле булды Илгизәр: кеше фикеренә колак сала белмәде. Яратып та кавыша алмаган парларның саны-исәбе юк. Шуларга карап, гыйбрәт ал! Гөлбакчамның гөлләре шиңгән, су сибәргә кирәк аларга. Әле соң түгел...

Илгизәр үзе дә сизмәстән карчыкка тартылып куйды, исемен саф татарча тулы әйтте.

– Сә... Сәхелбәян әби!

– Якут кызы Чайгонаа нәрсә диде: «Ирең тәмам санга сукмас дәрәҗәдә аракы эчсә дә, вакыт-вакыт яңагыңа кундырса да, урасаның (якутларча өй) иң түбән дәрәҗәдәге фәхишәсе янында төн уздырса да, бу хәтле авыр булмас иде, мөгаен. Ул минем җанымны имгәтте! Яратмаса, авыр икән лә... Эркинны шуның өчен үтердем. Яшьлектәге мәхәббәт корбаны булып яшәмәсен әле, дидем». Ир ышыгы җитмәгән Чайгонаага, чигенә җиткәч, пычак тыгып алган! Йөрәгенең нәкъ уртасына! Иртән елмаешып чәй эчкәннәр, өйлә намазына Эркинны күмгәннәр. Беренче мәхәббәтенең исемен әйтеп уянган, беренче мәхәббәтенең исемен әйтеп йокыга китә торган булган Эркин. Унике ел буе...

Карчык таягы белән һаваны шактый айкады әле.

– Әби, сине туксан яшьтә, диләр, бер аягың белән кабер якасына ябышкансың, ә үзең бик гайрәтле!

– Миңа мәхәббәт көч бирә! Сөю кешене яшәртә!

Нинди мәхәббәт турында авыз чайкый корткa? Без белгәннән бирле ялгыз лабаса...

– Мәхәббәтем – каен төбендә! Гаязым мине гомер бакый бик яратты, хәзер дә яратуын тоям мин аның. Беренче нәүбәттә мәхәббәт булды. Күзен

йомганчы минем исememне кабатлады ул. Мин елаганда, минем янда утырып тора иде. Нигә янымда утырасың дигәч, сиңа еларга булышам дия иде, җанашым. Үзем буйый алмагач, яткан килеш аяк тырнакларымны буйый иде минем Ромео. «Сине генә яратам, Сәхелбәян!» – диде...

– Сөю, сөю дисең, сөюең сине саклый алмаган: аркаңа бөкреләр кунган, ияге җиргә тигән, чәчләрең ап-ак булган, буын өстенә буын атланган лабаса...

– Бөкреләремә тимә, бу бөкреләрем миңа бик кадерле, алар минем сердәшемә әверелделәр, минем серләремне белделәр, миргә чәчмәделәр... Аларда меңләгән хатын язмышы... Катяларныкы, Машаларныкы, Зәйнәпләрнеке, Чайгонааларныкы...

**5**

Илгизәр, хиссез бер адәм кисәге түгел – кат-кат уйлый тормыш турында. Бөтенләй ят ике кешенең язмышлары бербөтен булып ябышып китә алмады. Яңа өйләнешкәннәргә хас җылылык булмавы да Илгизәрне бимазаламады. Яшьлектә калган ярны уйлап, гомере үтте. Миңсылуга мәхәббәттән кала бар нәрсәне бирә алды. Ә Миңсылуга байлык түгел, Илгизәр үзе кирәк булды. Ирдән узып, сүз әйтмәде, тегесен алып киям, монысы миңа кирәк димәде – кешене бәхетле итәр өчен яратылган зат. Ә барыбер... аның болытлар артыннан кояш чыкканны күрәсе килгәндер бит... Хатын-кыз нинди генә булмасын, аны яраталар икән, ул матур, ул назлы, ул бәхетле!

«Түгелеп бер елыйсы урынга бии хатының», – диде Сәхелбәян әби. Тукта, Миңсылу бит гомер буе биеде. Юкка да чыкмады, рәнҗемәде дә, хәтта кыек та карамады... Дөресрәге, ир аны бөтенләй күрмәскә тырышты...

Әле кичә генә бер тапшыру карады ир: анда ир белән хатын арасындагы мәхәббәт вә аның көче турында сөйләделәр. Бер ир хатынын шул дәрәҗәдә яраткан ки, кыр тутырып, көнбагышлар утырткан һәм аларны җыеп бүләк иткән. Уникe мең көнбагыш чәчәге! Ә кайсыдыр ил патшасы, хатыны үпкә авыруы белән авырып киткәч, 365 бүлмәдән торган йорт төзеткән. Һәр көнне яңа бүлмәдә йокласа, саф һава сулаган хатының терелә, дигән белекче. Хатыны 199 нчы бүлмәдә йоклаган көннән терелә башлый. Менә бит нинди мәхәббәтләр бар! Ә мин, хыялдагы Бикә диеп, Миңсылуның мәхәббәтен, тугрылыгын күрмәдем! Миңсылу ничек кенә үзенең мәхәббәтен күрсәтергә теләмәде, мин юл куймадым. Сөйләсә – ишетмәдем, караса – күрмәдем, егылса – торгызмадым, өшесә – җылытмадым, ул минем битләремә саф чык суы тидерде, мин сөртеп аттым... Ул гел сөю тулы карашы белән елмайды. Миңсылу булган җирдә болытлы көн чалт аязга әйләнә кебек. Аягыма җылы оек кигездe, ә мин беркайчан аягың өшемиме дип сорамадым. Миңа оҗмах тәгаме әзерләп ашатты, мин аңардан тамагың тукмы дип сорамадым. Ул мине яраткан, минем өчен генә яшәгән. Мәктәбендә дә шулай: укучыларын яраткач, аларның җитешсез якларын тыныч кына аңлаткан, ата-анасын бик борчымаган, ярсып бала өстенә килмәгән, шәхесен кимсетмәгән. Укучыны нинди сораулар борчыганын күзләреннән аңлаган, чын күңеленнән ярдәм иткән. Гел елмаеп торган укытучы апаның эчке халәте кемне кызыксындырсын?! Ә ул калганнарга яхшы булсын дип, гел елмайган да елмайган...

Ирнең битарафлыгы, салкынлыгы көннән-көн читләштерергә тиеш кебек. Ә Миңсылу сөю катыш елмаю бүләк итеп яши. Салкынлыгымны күргәч кенә, үзе түгел, йөрәге кычкырып елап җибәрә...

Нәрсәгә ирештем инде мин? Бәхетемне таулар артыннан көттемме? Үз-үземә абынып егылдым лабаса. Үземә үзем яратырга юл куймадым. Мин дә бик бәхетле булган булыр идем...

**6**

Бикәләр авылына яңа нигез котларга баралар Илгизәр белән Миңсылу. Илгизәр гомердә булмаганча елмайды, көлде, иң матур киемнәрен киде, букчага кураен тыкты. Моны күреп торган Миңсылу ни актан, ни карадан бер сүз әйтмәде. Беркайчан булмаганча, мәҗлесне Илгизәр курае, бәхет тулы елмаюы, шаяруы белән дә кыздырды. Һәм... Шау-гөр килгән халыкны гаҗәпкә калдырып, Илгизәр юкка чыкты.

Шыпырт кына Миңсылуга Бикә янына барып килергә теләге булуын әйтте.

– Син... ни... Ачуланма берүк. Бер минутка гына барып килергә рөхсәт ит.

– Бар... Ачуланмыйм...

Бу «бәхетле парга» сокланып карадылар. Миңсылу аш бүлмәсенә чыгып, дару эчеп куйды...

Мәҗлес бизәге булган Илгизәр, «һава суларга чыккан җирдән» кинәт моңсуланып килеп кергәч, халык аптырап калды. Кураен кулына алды да Бикә исемен кушып, елый-елый җырларга тотынды...

Җырдагы Бикәнең үз авылларындагы дүрт балалы Бикә икәнлеген Миңсылу белән Илгизәрдән  башка беркем белмәде... Җырдагы искиткеч чибәр Бикәне мәгърур таулар, челтерәп аккан чишмәләр, хәтфә болыннар арасында көн итүче әкият кызы дип белделәр. Аны сөйгәне үлеп яраткан. Бергә була алмаганнар икән. Ә җырдагы чын Бикә, Илгизәрнең бөтен гомерен урлаган Бикә, ике атна элек өченче ире урыс Дмитрийны һәм башкисәр дүрт малаен калдырып, бакыйлыкка күчкән икән...

...Курай моңы агылганда, чәчләре тоташ агарган Миңсылуныңниләр кичергәнен беркем белмәде...

Тәмам искергән кураен урман сукмагына куеп калдырды Илгизәр – кемгә атап җырулар җырласын, көйләр сузсын хәзер?

Ике көннән намазга басты. «Миннән башка Бикә рухына кем дога кылсын? Мин сиңа йомшак таң җиле юллыйм, Бикәм...»

Миңсылу Илгизәрнең намазга басуына чиксез шатланды. Җанына тынычлык табар, Аллаһка шөкер итәр, иярсез ат басылыр... Беренче мәхәббәте үлгән икән, урыны оҗмахта булсын... Иншаллаһ, намаз белән онытылыр, намаздан күңелләргә нур иңәр... Иртәгәдән үзем дә намазга басарга ниятләп торам. Парлап укырбыз намазны...

...Шундый матур таң ата. Әле кояш кузгалмаган – торыргамы-юкмы дип уйланып ятып тора хатын... Менә ул күрше бүлмәдә Илгизәрнең пышылдап дога кылганыннан сискәнеп китә: «Сөләйман кызы Бикәнең урыннары оҗмахта булсын, тар каберләре киң булсын... Күземне йомганчы синең рухыңа дога кылырмын...»

А-а-а...

Ике арадагы чакрымнар гына түгел, үлем дә мәхәббәткә киртә була алмый икән! Мәхәббәт үлгәч тә дәвам итә икән ул...

А-а-а...

**7**

– Сәхелбәян әби, иртәгә зур концертка кер…

– Ярар, кызым…

Төн буе күз дә йоммады карчык. Ярсуының чик-чамасы юк! Үзе дә сизмәстән, урт сөяген чәйнәгән карчыкның сыңар сөт теше өске иренен ярып керде. Күңелдә – шом! Пешкән чия кебек гүзәл затларны җир куенына салыр алдыннан шундый шом керә иде төрмәдә. Утыз-утыз биш яшьлек пәри кебек чибәр хатыннарны үз кулы белән кәфенләп озатты төрмәдән – аларны мәхәббәт җитмәү, хыянәт иртә алып китте ошбу җирдән...

Әсәренгән карчык керә-керешкә Илгизәргә таягы белән берничә тапкыр сыдырды. Бөкре шулкадәр кызган иде ки, өстенә су сипсәң, чыжлап пар күтәрелер иде, мөгаен. Юылудан төсе уңып беткән халатмы, күлмәкме, эчке киемме кигән, шуның астында искиткеч затлы күлмәк күренеп тора...

Берни белмәгән Миңсылу куркып китте:

– Нәрсә булды?

– Минем тарафтан аклау юк!

Илгизәр дәшмәде, угаланып, бүрәнә өстенә барып утырды.

Хип-хоп, брейк-данс, локинг, хаста, танго, балет, вальс, полька, тектоник, хакка, джампстайл, фокстрот, контемп, самба, рок-н-ролл, сальса, свинг, посадобль, краковяк, мазурка, кадриль, полонез, брейк-данс...

Өч сәгатьтән артык барды «концерт». Бөтен кимсенүләрен, әрнүләрен «әйтеп бетерде» хатын. Аңлашырлык, ачык итеп әйтте. Илгизәр хатынын беренче тапкыр күргәндәй карап утырды. Кара әле, ул гәүдә, ул төсбит – шакшы җир йөзенә бу матурлык хәрам. Күбәләк кебек очып-очып биегән хатынын барып кочаклау, тыны кысылганчы үбү теләге туды. Күңел төпкелендә сукыр тычкан уты кебек бер теләк кабынып маташа түгелме соң? Тукта, ярата түгелме соң Илгизәр Миңсылуны? Битарафлык битлеге артына сөюен яшергән булган, ахры, ул кирелеге аркасында сөю капчыгын чыгарып селкемәгән... Хатынына карата элек бер дә сизелмәгән ярату тойды. «Барлык җыерчыкларың, чал чәчләрең, үпкәләрең, күз яшьләрең өчен гаепне үз өстемә алам. Гафу итмәслек гонаһлы уй – гамәлләремне кичерә алганың өчен рәхмәт, чибәрем. Миңа хыянәт итмичә яшәвең өчен рәхмәт. Бүгенге көннән барысы да башкача булыр! Мин – бүкән, түмгәк!»

Румба биюенә музыка яңгырый башлагач, карчык аеруча бер җиңеллек белән бүрәнә өстеннән торды да, «сәхнә уртасына» чыгып басты, нәзакәтле генә итеп башын иде. Беренче түгәрәктә иске халатын, икенче түгәрәктә тишек күлмәген, өченче түгәрәктә төсе уңган эчке киемен салып атты. Затлы күлмәктән генә калгач, Илгизәрне биергә чакырды.

– Йөрәгеңне уеп-уеп уй яндырадыр, мәлгунь. Сөясең бит шушы асыл кошны. Яшереп маташма, барысын да күзләрең сөйли...

Карчык йөзендәге иске шәлен алып ыргыткач, ир белән хатын ах иттеләр.

– Сәхелбәян апа, син бит бигрәк чибәр! Нишләп чибәрлегеңне шыксыз кием астына яшердең соң?

– Калганнар бәхетсез булганда, мин генә бәхетле була алмыйм...

– Төрмәдә бәхетсез җаннарны күп күргәнсең инде, монда бит төрмә түгел, халык бәхетле.

– Дәшмә, син үзең дә беләсең... Җилләргә ияреп китәргә тели бит бу...

Карчык ияге белән Миңсылу ягына ымлады...

– Катялар, Машалар, Зәйнәпләр, Чайгонаалар кебек сагышыннан саргайган сары ат кына түгел бу... Алтын нукталы сары ат! Сөюе – алтын нукта!

Ә Миңсылу исә әлсерәп, «сәхнә уртасына» чүкте, бер-ике йотым су кабып куймыйча сөйләшә алмады... Агарып киткән хатын әллә нишләгән: карчыкны да, Илгизәрне дә күрми... Биеп арыганнан соң була торган илаһи бер тынычлык юк иде бүген...

– Мин дә төрмәдә кызларны биергә өйрәттем. Таш сынга әйләнмәсеннәр йөрәк парәләрем, дидем. Романтик кичәләр оештырдым, җитәкчелектән качырып, театр-концертларга йөрттем, йолдызлы төннәрдә ачык һавада йоклаттым. Аралашуга сусаган җаннарын бастырырга кирәк бит! Аздан да күңелләре була иде. Төрмә тәртипләрен бозган өчен әллә ничә кат штраф чәпәделәр. Үземне әллә ничә кат тотып, җир асты подвалына яба яздылар. Барыбер күңелләрен дәваладым!

– Хе...

– Хип-хоп музонын кабыз. Раз-два-три, раз два-три, поехали... Беренче чиратта, тоткын хатын-кызлар беләсезме нәрсә турында хыялланалар иде? Иреккә чыккач, безне яратсалар ярар иде дип! Раз-два-три, второй круг... Алар өчен ут йоткан ата-аналары да, хәтта балалары да икенче планда булды. Ә менә мәхәббәт сүзе, суккан саен калкып чыкты. Раз-два-три – третий круг...

– Хе...

– Менә шул! Арыдым мин, оланнар... Таягымны кичер, улым, әйтәсемне мин түгел, минем таягым әйтте... Башка кереп йөри алмам... Калганын үзегез карагыз...

Карчык, Илгизәрне гаҗәпкә калдырып, таягын күктә болгап тормыйча гына, кыйммәтле чуен капкага таба атлады...

Чуен капка биген ача алмый азапланган арада, Илгизәрнең кыргый тавыш белән кычкырганына борылып карады Сахи...

Ир Миңсылуның җансыз гәүдәсен кулларына алган да, илереп-илереп елый иде...

– Үлмә, үлмә, Миңсылу, яратам мин сине! Китмә, җаным!

Туктатучы булмаганга, бертуктаусыз хип-хоп музыкасыыңгыраша:

Сары атым алтын нукталы,
Туры атым көмеш нукталы;
Сагынмам дип әйтә күрмә,
Исләреңә төшәр, туктале...

# ТАУ ГӨЛЛӘРЕ ТАШТА ДА ҮСӘ

Студент елларында, җәйге каникул вакытында, Пермь якларында төзелештә эшләгән идем. Бездән ерак та түгел бер тау халкы мал абзары салып ята. «Чеченнар!» – диде алар хакында безнең бригадир Мостафа әбзәй. Тавышында соклану катыш хөрмәт иде. Чеченнар без яшәгән авыл халкы белән артык аралашмый; безнең ише «коллегаларына» да артык ачылып китмичә, үз дөньяларында тыныч кына яши бирә, гел эштә – иртә таңнан караңгы төшкәнче казганалар. Анысы инде без дә кимен куймыйбыз. Бригадаларында да яшьләр бездәге кебек үк күпчелек, тик алар кичен тиз генә тамак ялгап, клубтагы «танцы»га йөгерми... Иң гаҗәпләндергәне – намаз вакыты җитүгә, карты-яше тезелеп баса да сәҗдәгә китә. Андый чакта генетик хәтер уяна да, үзеңне уңайсыз хис итеп куясың... вакытлыча... Соң, без дә Хакның бәндәсе ләбаса! Идек...

Чал чәчле бригадирлары имам булып, алга баса.

Әлбәттә, мин ул чакта чеченнарның фаҗигале язмышы турында да, аларның сөргеннәрдә, төрмәләрдә мең сынауны үтеп, исән калулары, иң авыр шартларда бер йодрык булып туплана алулары хакында бик аз белә идем. Ислам диненең аларга төп таяныч булуын мин еллар үткәч кенә аңлаганмындыр, мөгаен.

Чеченнар ул вакытта кырыс, кеше сөймәс кебегрәк истә калган. Халыкка читтән карап бәя бирергә, тамга сугарга ярамый! Аның җырларын тыңларга, шагыйрьләренең әсәрләрен укырга, туган илләренә барып, чишмә суларын эчәргә, анда искән җилләрне ишетергә, туфрак пышылдавын тоярга кирәк.

Узган гасыр ахырында ике сугыш кичереп, аягүрә калган чечен халкы бөтен дөньяга танылды. Андый халыкның әдәбияты да үзенчәлекле булырга тиеш иде. Әйе, азатлык сөйгән хөр халыкның әдәбияты үзгә! Көрәш рухына биредә таулар олпатлыгын сеңдергән зирәклек өстәлгән.

Быел, сентябрь ахырында, Татарстан мәдәнияте көннәре кысаларында Чечен Республикасының башкаласында без, бер төркем язучылар да, булып кайттык. Һәр халык үзенчә кунакчылдыр инде ул, ләкин чеченнарның кунакчыллыгы бернинди чикләрне белми сыман. Андагы йола таләп иткәнчә, хуҗа өч көн дәвамында көтелмәгән кунактан ни өчен килүе турында да сорамый, имеш. Без инде чакырылган кунак исәбендә, ни өчен килгәнебез дә хуҗаларга сер түгел, ачылып сөйләшү, ихлас аралашу, истирахәт ике як өчен дә тансык иде. Шигырьләр яңгырады, тауларның иркен сулышы бүлмәләргә кереп тулды. Без сөйләдек, безгә Шәриф Цуруев кушылды, ике сугыш шәүләсен ике иңенә салган яугир Асламбек Тугузов ахырдан «Шәех Мансур» поэмасыннан өзекләр укый башлады.

Чечен язучыларының чәчмә әсәрләрен без юл капчыкларына салдык.

Тауга карап тау булмыйлар. Ләкин тау түбәсенә менеп, офыкларга күз салырга, ташта үскән тау гөлләренә кагылырга була. Иркенлек! Мондагы җилләр иренгә тоз тәме сөртеп китә.

Фаҗигаләр аша, мең төрле газаплар кичереп, киләчәккә кичү тапкан халыкның әдәбияты безнең басынкы рухка да нинди якын! Таныш әрнү анда, таныш, бик таныш.

Әйдәгез, хәзерге чечен әдәбиятының кайбер үрнәкләрен татып карыйк. Диңгезнең тәмен белер өчен давылдан соң чәчрәгән берничә тамчы да җитә.

Өч көннән соң без үз илебезгә, Идел буена кузгалдык.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

## Асламбәк Тугузов

# ТӨШ

*Д.Д-га*

Мин окопка чумдым гүя: тыйнак ялкын теле
Уйный, җир казылып, яны уемланган төштә,
Күр: шәм яна, нәни шәмчек, яна балавыз шәм,
Һәм зур күзле егет карый сәер генә көлеп.
Ачуымнан зәңгәр булып эндәшүен көтәм.
Син кая югалдың? – димен, читкә багам: – Әйт сүз.
Мин исемсез бер чокырда ятам, – ди ул, – күптән,
Егерме ел ятам, – ди ул, – сыңар хәрәкәтсез.
Шаярмакчы, юкны сөйли! Ә мин сулык-сулык,
Елмаюы иллә котсыз – җанга курку төшә...
Һәм шәм яна, нәни шәмчек, яна балавыз шәм,
Тән тиресен тырнап уза хәнҗәр сыман суык.
Ташла, – димен, – үлем юрап түгел, безне Илаһ
Ымсындырды сүрән өмет биреп ул чагында.
Юк, – ди, – гафу, йокым тирән, үтте байтак еллар,
Туфрак булып ойыйм куе тамыр кочагында.
Калыкты ай һәм яктысын төнге күккә сылап,
Сары тәнен йолып алды караңгыдан тагын...
Фу, – дип, ул йөз чытты – ну, картайгансың ла!
Ялгыш булган теге вакыт үлеп котылмавың.
Һәм кычкырып көлде: – Әйе, шома идең, мыштым,
Бер пуля да яратмады сине, тарып хискә.
Ә мин гарык булган хәлдә һаман кургаш йоттым,
Шул көенчә юрган сыман туфрак яптым өскә.
Бер мизгелдә юкка чыкты бар куркуым, бар шом,
Әйе, аккош мамыгыннан түгел минем түшәк,
Тик шәм яна, нәни шәмчек, яна балавыз шәм,
Югарыда кошлар сайрый, агач шаулый – яхшы!
Йә! – дип, өзде, – яман гадәт – борчу әрвахларны.
Синдәй дусны сыендырсам ярый торгандыр да,
Күңелем иркен, тик беләмәм – шушы куыш бары,
Аңлыйсыңдыр: икебезгә кысан булыр монда.
Бетте кебек... Омтылгандай шуңа гомер бакый,
Яшь һәм тере җанга игез, әверелеп төшкә,
Күр: шәм сүнә, нәни шәмчек, сүнә балавыз шәм,

Кансу кызыл ай ялгызы сары күкне айкый...

***

Тау иңендә шәфәкъ җемелдәүгә,
Җиргә иңеп кызгылт-сары моң,
Альп итәген баскан хуш гөлләрдән
Мин гөлләмә җыеп алырмын.

Кагып, чыгын койгач, бәллүр җамга
Челтерәвен салып кизләүнең,
Лалә-эдельвейслар тезәрмен дә...
Күз карашың, бәлки, үзгәрер.

Балкып, тажың кагышлары – тылсым!
Шул балкыштан кими караңгы.
Син, кызганыч, буй җитмәслек читтә
Бүләк итим, дисәм, аларны.
Арынганда җаным караңгыдан
Әйтер идем, басып ярсуны:
Юк, такыя түгел – бәхет юрап,
Таҗ кидертәм сиңа, таңсылу!..
Бу сәгатьтә күк гөмбәзе гүя
Манарадай, җиргә авышып,

Җәясеннән кулын ала Укчы,
Һәм Лираның тына тавышы.
Ә син ишетмисең, син күрмисең
Бәллүр җамда чәчәк бәйләмен...
Әнә Йөкче, атта чапкан килеш,
Күк томанга кинәт әйләнде...
Аһ, искиткеч тылсым – көн тууы.
Тау иңенә сарылып яткач таң,
Бел син: һичбер кайгы тимәс миңа.
Димәк, тажың шиңмәс һичкайчан.

***

Салкын иде. Сезнең өйгә җиткәч,
Арынгандай булдым өшүдән.
Янәшәдән әкәм-төкәм сыман
Уза торды арган кешеләр.
Хәтер өчен дошман да, дус та юк,
Кадерле һәм газиз барсы да...
 Япь-яшь көе басып тордык икәү
Тоташканда гасыр гасырга.
Алтын октябрьгә чал төс кунды,
Соңгы яшен сыкты бүз болыт.
Баш очында ике зәңгәр очкыч
Бөтерелде – безгә кызыгып.
Садә яшьлек! Аңлашылмый иде:
Кайчан дөрләп кабар чор уты?
Юк, ул сынау куркытмады мине,
Аерылуым синнән куркытты.

Сүзләр җитми аны сурәтләргә,
Һәм буяулар... гөнаһ шомлыгы...
Дөнья ишелүен күргәннәрнең
Иң куркыныч төше шул булыр.
Билгесезлек – йөрәк уртасына
Кергән шырпы кебек – әрнетә.
Чәчрәп чыкты синең дә күз яшең,
Иренем калтырангач: «Мин китәм...»
Ян капкага тонык шәүләң сеңде,
Бәхилләштек – гүя мәңгегә.
Тиле каза азынмаган булса,
Мин газапны белмәс идем дә.
Салкын иде. Ике зәңгәр очкыч
Зарын түкте – күккә сыймаудан.
Болытлады. Кичке эңгер төште.
Сугыш исе иде дөньяда.

***

Мин нәрсәдер үзгәртүдән гаҗиз.
Һәм карт –
Башлангычка кайтыйм, дисәм.
Әмма дәрья кичеп, каршы ярда
Өн салырга көчем җитә: исән!
Кабаланып йөзгәннәрне, беләм,
Өнәми су. Ишәм ипләп, аз-аз.

Беләк талды – шунысы начар менә...
Төпкә китәрмен дә эзем калмас! –
Тозын ялыйм кипкән иреннәрнең,
Колач салып, суны орам, орам.
Күрәм: ярда берәү, сабыр гына
Учак ягып, мине көтеп тора.

***

Ичкерия дә, Рум да юк инде.
Байтак булды ялкын сүнгәнгә.
Шәһәр идарәсе каршысында
Солых күгәрчене тук гавамнан
Туенырлык тәгам теләнә.
Төсе уңган, шыксызланган, әрсез.
Көн тончыккан чакта томанда –
Кеше һәм кош! – Берни үзгәрмәгән! –

Буш кесәңнән, Алла хакы өчен,
Ни булса да табып сон аңа.
Кубып төшә туңган бармаклардан
Һәм таш япкан юлга тезелә
Юмартлыкның соңгы бөртекләре...
Мең мәртәбә артып, мәңгелектә
Кире кайтыр өчен үзеңә.

**Рүзәл МӨХӘММӘТШИН** *тәрҗемәләре*

# Шәриф Цуруев

***

Бар хыяллар тереләй күмелгән,
Үткән гомер гүя гарештә.
Төрле якка китеп югалабыз:
Шәрык... Гареп... Аска һәм өскә...

Ләкин тормыш шундый гаҗәеп ул,
Әллә аны артык сөйгәнгә?
Югалсак та юл эзлибез кабат,
Тереләбез үлдек дигәндә.

Без китәбез. Ләкин безнең артта
Бушлык калмый... Җирне тигезләп
Җимерсә дә йортны явыз давыл,
Иман аваз сала юл эзләп.

Илгә таба! Һәм көч кирә безгә,
Туган җирне кирәк сакларга!
Ак канатлы коштай, канга батып,
Өмет оча безнең якларга.

***

Син аңлата алмадыңмы соң?
Әллә ишетмәдем сүзеңне –
Безнең жанны, безнең елларны
Тоташтырган җепләр өзелде.

Бәлки болар бар да буш сүздер,
Йолдыз тулы күкнең астында...

Йолдызлар да әнә нинди вак,
Ә шуларга күңел ашкына.

Бу мизгелне искәрмәсәк без,
Югалтырбыз кебек гомерне.
Тик кешедә җиһан ярала,
Һәм юкка да чыга түгелме?

***

Төнге тынлык, зәңгәр күк чатыры.
Йөрәгемдә мөлдерәмә тулы
Сөю хисе һәм азатлык җыры...
И Илаһи! Мин тик синең колың.

Тау чишмәсе эргәсендә һава
Шундый саф ул! Күңелемә дәва...
Янәшәдә ялгызлыктан качып
Чут-чут килә чечен сандугачы.

Ай яктысы җанга үтеп керә –
Үземнән дә гүя нур түгелә.
Эреп бетәм мин дә табигатьтә,
Җисемемне монда җуям хәтта.

Кисәкчәсе булам Галәмнең мин,
Мин – Аныкы! Фәкать мин – Аныкы...
Галәм кебек акыл сыймаслык киң,
Һәм төс түгел миңа ыгы-зыгы.

Кандаш түгел, миңа рухташ якын,
Якланмын мин даим алар хакын.
Хәрабәләр арасында тагын
Рухи туганлыкка җаям табын.

Мин чакырам, беркем ишетми тик...
Тавыш нечкә, гомер исә кыска.
Мин ышанам – сез дә килерсез бит...
Ни мәгънә бар юкса бу тормышта?!

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА** *тәрҗемәләре*

## Тәвәккәллек алпары ул – чечен халкы

Янгын булган сүнгән чаткы яралгысы,
Усал сәнгать тылсымчысы теләгеннән.
Тәвәккәллек алпары ул – чечен халкы,
Изге хисләр корбанына әверелгән.

Дөнья сөя залимнәрне, корбанны – юк...
Чечен дәгъва кылмады ла мәхәббәткә
Һәм шайтани лабиринтта булды корбан,
Канлы көчләр килгән чакта хәрәкәткә.

Үзфикергә чумган дөнья кабул итми
Йолаларын, кануннарын бабаларның.
Безнең өскә гаеп, яла белән бергә
Ыракшысы ява ядрә, бомбаларның.

Тормый тынып хатыннарның, карт-корының,
Балаларның аһ-зарлары, авыртынып.
Һәм көннән-көн азаядыр гади үлем,
Кешеләрне тоташ кыру тормый тынып.

Шулай да Бер Аллаһка тик бар мактаулар,
Ул яралтыр көл эченнән безне кабат.
Юкка чыгар – калмас эзе, даны, саны,
«Ят» кабихнең, «үз» кабихнең, сугар набат!

Явызлыкка бирешмәбез, ул – түбәнлек,
Дөнья йөзе килгәндә дә әвәрәнә...
Тәвәккәллек алпары ул – чечен халкы,
Изге хисләр ялчысына әверелә.

***

Чечен иле эче тоташ ялкын,
Тоташ дога, тоташ күз яше...
Набат сугу, чаң кагу юу ләкин,
Милли язмышыбыз, һай, әче.

Куылганбыз, изелеп, кыйналганбыз,
Гаепле без – чечен булганга...
Гаепле без тоташ үлмәгәнгә,
Рух коллыктан өстен торганга.

Мин ышанам: таң вакыты якын,
Аллаһ бөек! – Төшермәс төпкә.
Түбән җанлы мәсхәрәләүчедән
Халкым рухы күпкә биектә.

Минем оран – оныту үч хисен,
Асылыңа кайту һафасыз.
Тоташ җирәнүле караш ташлау
Барча җирбитләргә вафасыз.

Һәм йөрәккә якын алмый яшәү
Бар яланы безгә атылган.
Җиңү көнчел, мәҗүс, кол хисләрне,
Имин булу рухи ялкыннан.

Гафу итү безне гаепсез дип
Ялгышучы халык улларын.
Без – игелек белән көчле затлар,
Хөрлек улы, Аллаһ коллары.

Без үлмәбез – башкача һич булмас,
Йөрәклардән болыт таралыр!
Чәчәк атар изге чечен җире,
Бәхет иле булып яралыр!

***

Моңсулыгым яуга бәйле түгел,
Нәтиҗә дә кертмәс һич үзгәреш.
Моңсулыгым һәрчак үзем белән
Дәвам иткән чакта бу яшәеш.

Ямансулыйм җуелыр дип бар да,
Үтәрбез дип бер чак дөньялардан...
Сөйгәнең вә дустың китәр бер көн
Мәңгелеккә... Бу уй, ай-һай, яман.

Булмас беркөн якын кешеләрең,
Әҗәл якын, җиңелү күк яуда.
Күз яшендә түгел сагыш, сөю, –
Чагыла ул ихлас догаларда.

Эзләремнән калмый иярәләр
Ачы хакыйкатьнең сораулары.
Бу моңсулык яуга бәйле түгел,
Мөһим түгел нәтиҗәсе аның.

Ни ул сугыш? – Әтәчләнүләре
Колбиләүчеләрнең чит кул белән.
Сугыш – тоташ ялган, бәндәләр күк...
Тоташ күз яшь, нәләт, тоташ үлем...

Бер гаепсез үлә күпме инсан,
Ләкин сугыш
Асылда вак, «артык кешелекле...»
Моңсулыгым мәңгелекнең үзе,
Тугры һәм саф, фәкать үземнеке.

***

*Фәлсәфәче дәрвишкә багышлана*

Нигә юкка өмет баглыйсың син?
Кем диеп дәшүең Җирдә?
Соң йолдызың күптән янып сүнгән,
Караңгыга чумган ул, төнгә.

Бер киткәнгә кабат юк ялалу,
Үткән белән яшәү – үлем күк.
Ялгыз җанның килер көнгә атап
Җыр язуы үзе җүләрлек.

Китү – кайда? Барыннан да качар
Юл-сукмаклар юк ул, асылда.
Сиңа, баксаң, беркем түгел хаҗәт,
Гаҗәп, хаҗәт түгел барысы да.

Сөю – хыялыйлар зәгыйфьлеге,
Дуслык – хәерченең догасы.
Явыз түрәдән дә, коллардан да –
Һәммәсеннән килә косасы.

Дөньяда тик тоташ кайгы-хәсрәт,
Шатлык – очраклылык, сирәктер.
Моны аңлау өчен мең егылу,
Мең аякка басу кирәктер.

Һәм кирәктер өркеп калтыранмау,
Хакыйкатьнең карау күзенә.
Ник кычкыру, баш кискәдә чакны,
Котылу юк чакта үзеңә?

Күп аңладың... Үкенечең юкмы,
Караңгыны гизгәндә ялгыз?
Нигә, нигә синдә пыскый өмет?
Кем артыннан кая барабыз?

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәләре*

Аламахад
Ельсаев

# ПРОФЕССОР

ХИКӘЯ

Профессор нәкъ шәһәрне утка тотар алдыннан юкка чыкты. Хайваннар бәла-каза киләсен алдан сизә дип, тикмәгә әйтмиләр шул. Мин Грозныйдагы фатирымда берьялгызым торып калдым. Фатирда гынамы – бөтен Чечняда! Әнием инде ул вакытта Кабарда-Балкарда, абый янында; Лом-Эла шунда яши һәм шунда эшли иде. Ә менә калган абый-апаларымны, йорт-җирләрен ташлап, гаиләләре белән тизрәк чыгып китәргә күндерү бик җиңелдән булмады. Ләкин сугыш – соңгы еллар эчендә икенчесе, ул – инде бусага төбендә; хәрабә хәлендәге республиканың соры көзе, болай да җан асрап кына яшәгәндә, күңел төшенкелеген тагын да көчәйтә. Мин туганнарымны үгетләүдән туктамыйм:

– Зинһар өчен, китегез, тиздән соң булуы бар! Шәһәрдә бензоколонкаларны сүтеп, ташып бетерделәр, ут юк. Урамда мәетләр атыштан соң гына ятып калмый хәзер, кешеләр бер-берсеннән үч ала башладылар. Пычак кадалган ир-атны үзем күрдем. Җәяүләп бөтен туганнарыбызны йөреп чыктым. Кемдер китәргә ризалашты, кемдер баш тартты. Сез булса да кирегә сукаламагыз.

– Теге сугышта да өйдә калган идек, башка районнардан килгән качакларны үзебезгә керттек.

– Ул сугышта Урус-Мартанның Юсуп Эльмурзаевы бар иде шул (урыны җәннәттә булсын), ә хәзер ваххабитлар хуҗа булып йөри. Көткәннән дә яманрак булуы мөмкин монда. Мал-туарны биредә калучыларга таратыгыз, бөтен он-шикәрне Усманның автобусына төягез. Балаларның баш өстендә түбә булыр ичмаса. Сез дә, яңгыр-мазар яуса, машинада утырып тора аласыз. Снаряд астында калуга караганда, яңгыр астында калу хәерлерәк. Мурад Гадиев сезне каршы алыр, без аның белән бергә хезмәт иткән идек, Ингушетиядән ул. Аннан Лом-Эла килер, нишләргә кирәген хәл итәр. Иң мөһиме – Чечнядан китегез.

– Ә син? Үзең ник безнең белән бармыйсың?

– Барам, сезне илтәм дә кире кайтам.

– Ә синең белән бер-бер хәл булса?

– Мин журналист, бу чорның видеохроникасын эшләп калдырырга тиешмен. Рамзан, Шамил һәм мин бер-беребезгә шулай дип сүз бирдек. Безнең эшебез шундый. Без тиеш!..

Минем биш ир туганым һәм ике апам бар. Асламбектан калганнары барысы да миннән олыраклар, шуңа карамастан, теләр-теләмәс кенә булса да, сүземә колак салдылар. Мине тынычландыру өчен булса кирәк, һәрхәлдә үземә шулай тоелды. Ярар, анысыннан битәр, иң мөһиме – хәвефтән читтә булулары. Аларның бушап калган йорт һәм фатирлары эчпошыргыч сагышка сала, җитмәсә, Профессор да, җир упкандай, юкка чыкты. Каян гына эзләп карамадым үзен! Ул мәчене, әле нәни йомгак кына чагында, миңа дустым Мөслим Авторханов бүләк иткән иде.

Буш шәһәрнең төнге базарын күргәнегез бармы сезнең? Күрергә дә язмасын! Тонык кына булып газ янып тора, шул яктылык тирәсенә әле шәһәрдән китеп өлгермәгән берән-сәрән сатучылар, сатып алучылар һәм туйдыручысыз калган әллә никадәр этләр, мәчеләр җыйнала.

Кешеләр алыш-биреш белән мәшгуль – берсендә дә диярлек акча юк. Этмәчеләр ризык күтеп бөтерелә, алларына ыргытылган һәр кисәк өчен бер-берсен өзгәләп атарга әзер алар. Һәм барысы да – кешеләр дә, хайваннар да өрәккә әверелгән шәһәрнең кара урамнарындагы караңгы йортларына таралышырга куркалар. Тик алар күкрәкне изгән караңгылыктан түгел, теләсә кайсы мизгелдә шушы кара төн эченнән кемнеңдер яки кемнәрнеңдер гомерен тартып алырга сәләтле ут көлтәсеннән куркалар.

Шәһәрне утка тотулар дәвам итә. Мондый чакта ялгызың гына булу коточкыч авыр. Мин хәзер базардагы бөтен эт-мәчене диярлек таный идем, тик Профессор гына һичкайда очрамады. Башта фатирымда берүзем идем, тора-бара тугыз катлы йортта үзем генә торып калдым. Ризык та, акча да бетте, хәтта керосинканы кабызырлык чама да калмады. Ярый әле хатынымны (чечен халкында ир һәм хатын бер-берсенә исем белән дәшми) һәм алты айлык улымны апа-абыйларым белән җибәргәнмен!

Ишек шакыдылар.

– Әссәламегаләйкүм!

– Вәгаләйкемәссәлам! Кер, кер, Шамил!

– Әйдә, безгә күч, безнең йорт та бушап бетте, берничә гаилә генә калды, – диде Шамил. Шамил Гегаев – минем тугры дустым, бик талантлы инженер ул.

– Юк, Шамил, үпкәләмә. Миңа монда булырга кирәк. Профессор кайтып керсә, дим.

– Элек тә шулай дия идең. Әгәр кайтмаса? Шушылай бөтен йортта берьялгызың күшегеп утырырсыңмы?

Нәкъ шул вакытта мин ишек тырнаган һәм мияулаган тавышны аермачык ишетеп алдым.

– Профессор! – дип кычкырып, ишек ачарга ашыктым.

Ул минем кулыма сикереп менде дә, тәпиләре белән муеныма сарылып, кызганыч тавыш белән бертуктамый мияуларга тотынды. Мин аны ныгытып кочып алдым һәм... елап җибәрдем. Мәче кайтты, тиздән бөтен туганнарым белән бергә булуыбызга өмет уятып, әйләнеп кайтты! Якыннарыбызны һәм бер-беребезне ничек сагынуыбызны икебез дә шушы мизгелдә генә аңладык, ахрысы...

Дустым Шамилнең яшь тулы күзләрен абайлагач кына айныгандай иттем, миңа уңайсыз булып китте.

– Хәзер безгә барасызмы соң инде?

– Әйе.

Ниһаять, РТС буеннан дүртенче микрорайондагы Косиор урамына барып җиттек. Шамилнең хатыны да, ике яшьлек улы да безне күреп, бик куандылар. Алиса күпкатлы йортның ишегалдында кирпечтән әтмәлләнгән «мич» тирәсендә кайнаша башлады, кечкенә Билал исә Профессор белән әвәрә килергә тотынды. Мәчедән әллә нәрсә дә таләп ителми иде: аны йон уңаена һәм кирегә сыпырырга теләгән малайдан качып кына китмәсен, бары шул гына. Йонын кирегә сыпырганны Профессор өнәп бетерми шул. Алиса нигә шулай икәнен аңлатып караса да, кечкенә Билал бу хакта еш кына онытып җибәрә иде.

Кич шом белән өртелгән иде, төн исә бөтенләй тынгысыз узды. Атышлар көчәйгәннән-көчәя барды.

– Мөгаен, миңа да үземнекеләрне моннан җибәрергә кирәк булыр, – диде Шамил икенче көнне иртән моңсу бер кыяфәттә.

– Синнән башка кая барыйк без? – дип каршы төшәргә маташты Алиса, һәм миннән яклау эзләп: – Зинһар өчен, әйт әле үзенә, – дип өстәп куйды.

– Алиса, нәрсә дим? Мин үземнекеләрне озаттым, хәзер Профессорны да алар янына илтәм. Шулай кирәк.

– Рамзан да үзенекеләрне илтә, – диде Шамил. – Хәл ителгән.

Рамзанның «Волга»сына көч-хәл белән генә, «идән астында» эшләнгән бензин юнәтә алдык. Иртүк, намаздан соң ук, юлга кузгалдык.

Бу 1999 елның 29 октябрь җомгасы иде. Безнең белән машинада Рамзанның апасы – гомер буе телевидениедә эшләгән талантлы режиссёр Зәйнәп Шахбулатова да бар, бөтен дөньяга мәшһүр композитор, мәрхүм Аднан Шахбулатовның хатыны ул.

Безнең план буенча, аларны илтеп куябыз, Владислав Флярковский программасы өчен Чечняда төшергән видеоматериалыбызны ингуш телевидениесеннән ТВЦ каналына күчерәбез һәм эшне дәвам итү өчен Грозныйга әйләнеп кайтабыз.

Юл диярлеге калмаган җирдән барабыз. Халык телендә «бакинка» дип йөртелгән Баку трассасы гел чокыр-чакырдан гына тора. Озын чакрымнарга сузылган транспорт агымы Ингушетия ягына таба әкрен генә кыймылдый. Һәммәсендә диярлек ак тукыма күренә: яулыклар, сөлгеләр, җәймәләр, кемдер хәтта, исән калуына өметләнеп, кәфенлегенә тиклем элеп куйган. Чеченча «марчо» дип атала ул, берәрсе вафат булса, җиргә шуңа төреп иңдерәләр. Кызганыч, бүген андыйлар күп булачак, тик без әле бу хакта белмибез һәм юлыбызны дәвам итәбез.

Бер-бер артлы тезелеп, йөк машиналары бара, аларга вак-төяк мал-мөлкәт төялгән. Өстә кешеләр утыра: яшьләр дә, картлар да, хатын-кызлар да, балалар да бар. «Икарус»лар да күп, аларда авыруларны алып баралар. Носилкада ятучыларны утыргычлар өстенә тезеп куйганнар, җимерек юлда автобус селек-мелек килгәндә егылып төшә күрмәсеннәр дип, башка авырулар һәм табиблар аларны тотып барырга тырышалар. Бүген коридорны ачалар дип, бер көн элек хәбәр иткәннәр иде, кешеләр тыныч күк йөзе астында дәваланырбыз дип өметләнәләр. Чечняда анысы насыйп булмады шул.

Көч-хәл белән чик буена җиттек, тик качакларны шунда ук кире борырга тотындылар. Ялыну-ялварулар да ярдәм итмәде. Хәрбиләр белән сөйләшергә дип җибәрелгән аксакаллар да өметсез әйләнеп кайттылар:

– Компьютерлар урнаштырырга өлгермәдек, диләр. Кире кайтырга кушалар, тик шәһәргә кермәскә киңәш итәләр, – дип авыр сулады алар арасыннан өлкәнрәге.

– Ингушетия хакимиятеннән берәү дә юкмы анда? – дип сорады кемдер гөжләргә тотынган төркем эченнән.

– Ингушетия хакимиятеннән дә, Чечня хакимиятеннән дә беркем дә юк. – Аксакал янә уфтанулы җавап кайтарды.

– Ә кире борылсак, коридор вәгъдә итәләрме соң? Безгә атмаслармы?

– Посттан ике чакрым хәвеф-хәтәр булмас дип гарантия бирәләр.

– Ничек инде ике? Колонна унар чакрымнарга сузылган, очы-кырые күренми!

Аксакал берни дә эндәшмәде. Хатын-кызларның һәм балаларның күзенә карамаска тырышып, ир-атлар сүзсез генә борыла башладылар.

Кеше үзенең һәм үзе өчен кадерле булганнарның бу дөньяда артык җан икәнен аңлаган мәлдә, аны сәер бер тойгы биләп ала икән...

Без дә ничек кирәк алай кирегә борылдык. Бу тиклем кеше һәм техника тупланган, бер-берсе белән элемтә булмаган җирдә анысы да бер дә җиңелләрдән түгел иде. Ерактагылар, исән калу өмете белән дәртләнеп, һаман саен чик буена килә торалар һәм бу ноктадан өметләре киселеп, билгесезлеккә таба яңа юл эзләп борылганнарны кысрыклый баралар.

Берьялгызың булсаң, бик тиз куллар салынып иде, тик үзеңә башкалар өчен

җаваплылыкны йөк итеп алганда, алай мөмкин түгел. Шамил Алисаны һәм малаен туганнары янына машинага утыртты, хәзер үк әти-әниләре янына кайтырга кушты. Безнең машинада – Зәйнәп, Рамзан, мин һәм минем куртка астында күкрәгемә сыенган Профессор. Юл уңаенда тагын берәүне утырттык, ул үзен Мохади дип таныштырды.

Берара тыныч кына бардык. Зәйнәп безне кыздырылган ит кисәкләре белән сыйлады, соңгы запасларыннан юлга дип әзерләгән булган.

Тышта яз диярсең, яп-якты булып көләч кояш балкыды, бер афәт тә көтелми кебек тоелды. Ләкин кинәт кенә самолётлар һөҗүме башланды, алар, колонна өстендә уйнаклый-уйнаклый, берничә ракета җибәрделәр. Бер-бер артлы шартлау тавышлары яңгырады, тик алар бездән ерактарак иде. Тиздән юлда һәм юл читләрендә таралып яткан машиналар янына килеп җиттек. Аларның кайберсе дөрләп яна иде. Машинадан сикереп төштек. Рамзан Межидов (ул бик талантлы оператор, исеме республикадан читтә дә билгеле), йөгергән уңайга видеога төшерә башлады, Шамил белән мин аның янәшәсеннән чабабыз, сак булырга кушып, безнең арттан Зәйнәп белән Мохади кычкыра. Профессор бик каты курыккан иде, ул йолкынырга тотынды. Аны кабат куртка эченә тыгарга маташып, бераз арткарак калдым. Шул вакыт асфальтка килеп төшкән зур торба шыгырдавына охшаган тавыш һәм аның артыннан – шартлау ишетелде. Әле генә тынычлангандай тоелган мәче көтмәгәндә куенымнан сикерде дә, йоннарын тырпайтып, урман буена йөгерде. Мин аның артыннан ташландым, тик мәче биек үлән арасында бик тиз күздән югалды. Шунда ук, кайсы кая, котырган шикелле, куркынган атлар чабыша иде. Кемдер бияләр көтүен тынычрак урынга куаларга ниятләгән булган, күрәсең. Менә, үзләреннән колак та какты.

– Юлдан китегез, тагын самолётлар, – дип кычкырды кемдер.

Шул мәлдә мин ниндидер пышылдау ишетеп алдым һәм башымны боруга, гомеремдә дә онытылмас шундый күренешкә тап булдым: агач кәүсәсенә аркасы белән терәлеп, дер-дер килеп, егерме биш яшьләр тирәсендәге бер хатын утыра. Бер нарасыен үзенең куенына яшергән, дүрт-биш яшьләрдәге малаен каты итеп кочагына сыендырган. Гүя аларны бу дөньяның барча мәрхәмәтсезлегеннән яклап калырга теләве... Сабый баланың болай ялваруын моңарчы бер генә тапкыр да ишеткәнем юк иде.

– Әй Аллаһ! – Кечкенә иңнәренә кансыз бәндәләр зур сынаулар өйгән сабый бала елый-елый пышылдый иде. – Син бит моны туктата аласың. Әй Аллаһ, ярдәм ит безгә, әниемә дә, энемә дә берни дә булмасын!

Мин катып калган кыяфәттә аларга карап тордым. Шулчак вакыт авыр бер йөк булып җанымны сытты, бөтен гомерем яшен тизлегендә әллә күз алдыннан, әллә хәтер төпкеленнән сызылып үтте. Һәм, бүгенгәчә хәтерлим: әгәр исән калсам, һичшиксез какшамас тынычлык партиясе – сугышсыз дөнья партиясе төзиячәкмен дигән карар кабул иттем ул мәлдә (исеме, уйларыма нигезләнеп, үзеннән-үзе яралды). Аның максаты бер генә булачак: моннан соң хатын-кызлар һәм балалар җир йөзендә яшәүдән курыкмасын! Ә әлегә безне ни көткәне беребезгә дә билгеле түгел иде. Дөнья хәлен белеп булмый дип, мин кесәмдәге зажигалканы һәм башка кирәксез вак-төякне алып ташладым. Ул чакта әле начар гадәтемнән арынмаган идем, шулай да, гаиләмә алай-болай минем җәсәдемне юарга туры килсә, күреп алуларын, уңайсыз хәлдә калуларын теләмәдем.

Самолётлар очып киткән иде. Ләкин соңыннан, күрәсең, үз «эшләренең» нәтиҗәсенә карарга теләп, кире борылырга уйлаганнар – Ельцин чорының типик армиясе, СССР җитәкчелегеннән күңелләре кайтырга өлгергән, шул ук вакытта РФ җитәкчелегенә ышаныч белдергәнче, әле һаман тугрылыгын саклаган армия бу.

Кешеләр яшеренгән җирләреннән берәм-берәм чыга һәм бер-берсен кычкырып

барларга тотындылар. Мин дә шулай иттем. Зәйнәп белән Мохади бик тиз җавап кайтардылар.

– Монда гына көтеп торыгыз, – дип үтендем мин, – хәзер Шамил белән Рамзанны эзләп табам. Алар, мөгаен, юлның икенче ягындадыр, ишетмиләр бит.

Күз алдымда коточкыч күренеш пәйда булды: корымнан кап-кара булган юл олыларның һәм балаларның шундый ук кара корымга баткан мәетләре белән түшәлгән, аларның кайберсе шартлаудан капланган автомобиль астында калган. Шамил белән Рамзан балалар белән янәшә яталар. Ул балалар бая гына йөк машинасында, төенчекләр өстендә баралар иде, әрҗәдәге көрәк сабына ак җәймә бәйләнгән иде...

Һәлак булганнарны кырык сигез кеше дип санадылар, аларның унсигезе – балалар иде.

Кич белән Беренче каналда: «Шаами-Юрта районында боевикларның терәк пункты һәм кырык сигез бандит юк ителде», – дип хәбәр иттеләр.

Ул чакта дөньяда бездән дә хокуксызрак бер халык та юк иде...

Бераз аңыма килгәч, партия төзү турында уйлана башладым. Шул чакта Әхмәт-Хаҗи һәм Рамзан Кадыровларны якыннанрак белү бәхете тәтеде, алар төрле яклап тәртипсезлекләргә чик куярга омтылуларында бик тәвәккәл һәм ихлас иделәр. Тынычлык партиясе төзү турында уйлауның инде әһәмияте калмады, үз гомерләрен куркыныч астына куеп, тыныч тормышны якынайтучылар сафына кушылырга кирәк иде. Мин шулай эшләдем дә. Һәм моның өчен беркайчан да үкенмәдем...

**P.S.**

Ике меңенче еллар башында мин Грозныйда элек яшәгән урыныма килдем. Профессор шунда кайткандыр дип өметләнгән идем, тик ул да, өйләр дә юк иде. Сугыштан торып калган тугызар катлы өч йортны да омончылар шартлаткан. Имеш, бу йортларның кайсыннандыр аларга кемдер аткан булган...

Ике ел узды. Мин Гудерместа, телерадиокомпания барлыкка килгәч үк, фатирга кереп тора идем. Беркөнне өйгә кайтып кердем, Әнием белән хатыным мине ишек төбеннән үк каршы алдылар. Икесе дә бик дулкынланган иделәр.

– Ишек тырнаганны, мияулаганны ишеттек! Ачкан идек – нык охшаган Профессорга! Синең бүлмәңә керде дә мендәргә менде дә ятты. Берничә сәгать шунда инде.

Мин килеп кергәч, ул күзләрен ачты. Аларда, талчыгудан кала, бернинди хис-тойгы да юк шикелле тоелды миңа. Юындырдык, ашаттык. Теләр-теләмәс кенә ашады. Кассетаны алып, элекке видеоязма белән чагыштырырга тотындык. Төсе, таплары туры килә. Ә менә көнбагыш ашамый. Ә Профессор ашый иде, ашау гына түгел, чиертә иде. Ул чакта Әнием белән апам базарда көнбагыш саталар иде. Һәр кич саен без көнбагыш кыздыра идек һәм аны ашап карый идек. Профессор да безнең белән көнбагыш чиертә иде.

– Бәлки, оныткандыр, – диде Әнием, – күпме вакыт үтте бит.

– Бәлки...

Ул бездә нибары өч кенә көн торды, чыгып китә иде дә тиз генә әйләнеп кайта иде. Бары тик минем ятакта гына йоклады. Эшкә озатып калды, каршы алды. Иркәләнмәде, уйнамады. Кулга алгач кына моңсуланып карана һәм күкрәккә сыена иде. Ә беркөнне чыгып китте дә бүтән кайтмады.

Безне үтергәнгә 29 октябрьдә 22 ел була. Моның өчен мин русларны да, әлбәттә, чеченнарны да гаепләмим. Ләкин безне дә, аларны да кызганмаучыларны, кем генә булмасын, беркайчан да кичерәчәк түгелмен!

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА** *тәрҗемәсе*

Арби
Усманов

# ӘБҮБӘКЕР

## «ГОМЕР ДӘВАМЫНДА» РОМАНЫННАН ӨЗЕК

Новосибирск өлкәсендәге «Сиблаг» идарәсенә караган «Бугры» лагере «кызыл зона» санала. «Кара зона»да бөтен хакимият «пахан»нар кулында булып, анда чикләнмәгән башбаштаклык хөкем сөрә иде. Ә «кызыл зона»да, тулысынча булмаса да, инспекторлар һәм надзирательләрнең сүзе өстә.

Әбүбәкерне, төрмә вагонындагы озак сәфәрдән соң, кич белән шушы лагерьның 7 нче камерасына китереп тыктылар. Култык астында – матрас, кулында – букча.

– Яңа «пассажир»ны кабул итегез, – диюгә, сакчы, ачкычларын шалтырата-шалтырата, ишекне тыштан бикләп тә куйды.

Әбүбәкер бер адым алга атлап, камераны карашы белән айкап чыкты.

– Әссәламегаләйкем.

Күпмедер паузадан соң каяндыр икенче ярустан:

– Вәгаләйкемәссәлам, – дигән тавыш ишетелде.

Почмакта түбән яруста ятучы берәү татуировкалар белән капланган гәүдәсен күтәрде:

– Син кем?

– Исемем – Әбүбәкер.

Татуировкалы белән янәшә утырган сыер күзле «зэк» бармагы белән икенче яруска төртеп:

– Машку – на шконку! – диде.

Әбүбәкер тыныч кына аңа карап:

– Урысчалап әйт, – диде.

Камерадагылар шаркылдап көлеп җибәрделәр. Хәтта карта уйнаучылар да яңа пассажирга текәлделәр.

– Нәрсә? – «Сыер күзле» йодрыкларын төйнәп, урыныннан торды.

– Утыр, Меланхолик, – дип туктатты аны беренчесе, – син кайдан, милләтең кем?

– Мин – чечен, Кавказдан, ләкин хәзер Казакъстаннан.

Татуировкалы бераз тынып торганнан соң күзләре белән камераны сөзеп чыкты.

– Әй, мужик, күрмисеңме, өлкән кеше басып тора, – диде ул, аскы яруста ятучы берәүгә карап. Тавышы нык, каршы әйтергә мөмкинлек калдырмый торган. Тегесе сүзсез генә матрасын йомарлап, өске яруска күтәрелде.

Әбүбәкер татуировкалының мондагы «пахан» икәнен аңлады.

– Шконка – ятак, машка – матрас була, – дип аңлатты Әбүбәкергә «пахан». – Ул сиңа, матрасыңны ятакка урнаштыр, диде. Әнә шул урынга сал, – дип, бушаган урынга күрсәтте.

Әбүбәкер ул күрсәткән урынга матрасын салып, ятак кырыена утырды:

– Ә синең исемең ничек?

– Кушаматым – «Боксёр». Ә исемем – Алексей, – дип әйтеп куйды көтмәгәндә «пахан». Камерадагылар гаҗәпләнеп, бер-берсенә карап куйдылар.

– Ә кушамат нәрсәгә, нигә «Боксёр»?

– Синең, күрәм, монда беренче керүең, күп нәрсәне белмисең әле. Монда шулай... – Кисәк кенә кырысланып китте: – Һәм күп сөйләшергә ярамый.

– Менә бу дөрес! Мин үзем дә күп тел чарларга яратмыйм. Бездә әйтем бар: «Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың». Ләкин мин җырлый белмим.

Боларны тын гына тыңлап утырган камерадагылар тагын шаркылдады.

– Күңелне күтәрдең,– диде Боксёр, көлүдән туктап, – без синең турыда белештек, синең милләтең турында да ишеткән бар, тагын бер сорау: тормышың ничек?

– Әлхәмдүлиллаһ!

– Яхшы. Шөпшә, кунак өчен чәй оештыр, – диде Боксёр, малайга охшаган берәүгә.

– Бәлки чифир? – диде тегесе Әбүбәкергә.

– Чифир кирәкми, – диде Әбүбәкер һәм үзенең букчасыннан каклаган ит белән каткан чүрек чыгарып, өстәлгә салды. – Сезнең тәртипләрне мин белмим, ә бездә бар нәрсә дә уртак. Бу каклаган сарык ите, бик хароши.

Камерада гүләп алдылар.

– Аны ничек шамают? – диде Боксёр, кулына бер кисәк алып.

– Пешерергә дә, болай ашарга да була.

Боксёр кабып карады да: «Шөпшә, мамкага пешәргә куй», – диде.

Берничә кеше өстәл янына утырды. Болар, күрәсең, Боксёрның иярченнәре. Алар, чәй эчә-эчә, Әбүбәкерне өйрәнеп утырдылар. Аның киң җилкәле гәүдәсе, кыска сакаллы йөзе, таштан уйган кебек кәкре борыны ышаныч һәм хөрмәт тудыра иде. Камерадагыларга бигрәк тә аның күзләре тәэсир итте. Бу күзләрдә тирәнгә яшерелгән сагыш чагылса да, ниндидер эчке көч, үз-үзеңә ышану тоемлана.

Бу күзләр нәрсәседер белән үзләренә тартып тора.

– Ә кем монда мөселман? Кемдер минем сәламгә җавап биргән иде.

– Әй, бабай, бире кил, – дип, почмакка карап кычкырды Боксёр.

Өске ярустан кырык биш яшьләр чамасында, каракучкыл, җыерчыклы йөзле, кечкенә борынлы берәү төшеп, кыенсынып кына өстәл янына килде. Күренеп тора, бу «пахан» иярченнәренә керми һәм мондый игътибарга күнекмәгән.

– Утыр, Бабай, утыр, күрәсең бит, синең диндәшең синең белән танышырга тели. Шөпшә, чәй сал аңа!

Бабай, өстәл янына утыргач, чәй йотып куйганнан соң шулай ук Әбүбәкерне күзләре белән капшап чыкты.

– Син кайсы милләттән? – дип сорады Әбүбәкер.

– Татар мин.

– Ә без моңарчы нигәдер синең мөселман икәнеңне дә белмәдек, – диде Меланхолик, гаҗәпләнеп.

– Берәү дә сорамады бит.

– Ә ул минем сәламемне алды, чөнки мөселман сәламгә җавап бирергә тиеш, – диде Әбүбәкер, бабайны яклап. – Ул яхшы мөселман булачак, Инша Аллаһ!

– Синең исемең Әбүбәкер бугай, – диде Боксёр, кыенлык белән генә аның исемен атап.

– Әйе.

– Сиңа кушамат такмыйбыз. Әмма ләкин исемеңне кыскартабыз. Бәкер! Син каршы түгелме?

– Юк, шул ук исем инде ул.

– Ярый. Бәкер, менә сиңа сорау. Ник син безнең феняга каршы?

– Чөнки Аллаһ сүзе һәм феня – икесе ике әйбер. Ә мин мөселман.

Боксёр чыраен сытты, нидер әйтмәкче булды, ләкин кире уйлады. Тик тоны гына үзгәрде.

– Булды. Күп лыгырдадык. Йокларга вакыт. Иртәгә сезне туган илебездән ничек күчергәннәрен сөйләрсең, безгә кызык, – дип, сөйләшүне туктатты. Күрәсең, монда кем хуҗа икәнне күрсәтәсе килде. Шунда ук стенага борылып йоклап та китте.

Иртән коридорда надзирательләрнең ачкычлары шалтыраганы ишетелде. Камерага ике сакчы керде, берсенең кулында исемлек.

– Чистяков, Панин, Җиһаншин, Әлмирзаев... Егерме кеше, берәмләп чыгарга!

Коридорда торучы ике конвоир автоматларын күтәрде.

– Берәмләп! Стенага йөз белән!

Прикладлар белән төрткәли-төрткәли тезделәр.

– Алга, чыгышка! – Тоткыннарны, урамга чыгарып, тар гына төрмә ишегалды аркылы бытовкага алып барып, фуфайка һәм бияләйләр биреп, лейтенант һәм ике конвоир сагы астында капкага таба алып киттеләр. Һәр конвоирның өскә ташланырга торган эте бар. Капка артында башка камералардан җыелган тоткыннар командасы көтеп тора иде. Капка артыннан ук юл сыман, бульдозерлар тирән карны ерып ясаган ярмәк башлана.

– Икешәрләп колоннага тезелергә! – дип кычкырды лейтенант.

Соңрак беленгәнчә, аның фамилиясе Голубков булып чыкты. Тоткыннар тезелгәч, лейтенант алга чыгып басты: «Тезелгәнчә барырга! Сулга бер адым, уңга бер адым – шунда ук атабыз. Алга!

Үзе салкыннан шыгырдап торган карга нык-нык басып, алга кузгалды. Конвоирлар икешәрләп, ике якка бастылар.

– Урман егарга куалар, с..! – дип ысылдады ябык тоткын озын гына Әбүбәкергә карап. – Үләргә мөмкин бу суыкта!

– Еракмы?

– Биш чакрымнан да ким түгел, – дип, черт итеп төкерде күршесе.

Әбүбәкер «өчлеге» – юлда аның янәшәсендә барган үзе кебек үк озын буйлы Игорь һәм ни өчендер аңа тартыла башлаган татар Җиһаншин эшкә кереште. Җиһаншин нарат тирәсендәге карны чистарткач, Әбүбәкер белән Игорь, инструкциядә күрсәтелгәнчә, төптән утыз сантиметр чамасы биеклектә агачны кисә башладылар. Бөкрәеп, агач кисү бик уңайсыз, шуңа эш башта акрын барды. Бераздан җайлаштылар һәм бер сәгать тә үтмәгәндер, беренче төз, матур нарат җиргә ауды. Җиһаншин беренче наратны ботаклардан арындырган арада, икенче наратны да ектылар. Арканы аркага терәп, әле генә киселгән агач төбенә утырдылар. Әбүбәкер сизенде: Игорьга нидер ошамый иде.

– Ардыңмы? – дип сорады ул аңардан.

– Син, дустым, ашыкма. Братаннар ударникларны яратмый.

– Ник? – диде гаҗәпләнеп Әбүбәкер.

– Чөнки без бүген норманы үтәсәк, аны иртәгә тагын да арттырачаклар.

– Чынмы?..

– В натуре, дим бит.

Тирә-юньгә күз салгач, Әбүбәкер башкаларның хәтта бер нарат та екмаганын күрде. «Да, болар мондагы тәртипне беләләр», – дип нәтиҗә ясады ул.

– Алайса без дә башкалар кебек эшләрбез.

Ләкин монда бер каршылык килеп чыкты.

Ял итәргә туктауга зәһәр салкын һава, юка роба аркылы тәнгә үтеп туңдыра иде. Катып үлмәс өчен җай белән генә эшләргә кирәк. Ә аяклар эшләсәң дә,

эшләмәсәң дә туңа. Лейтенант та йә бер бригада, йә икенчесе янына килеп, ял итәргә ирек бирми иде.

Бер бригада, ял итәргә туктагач, чапкан ботаклардан учак кабызып җибәрде.

Җылынырга башка тоткыннар да килә башлады. Лейтенант башта бу башбаштаклыкны туктатырга уйлаган иде дә, аннары, киресенчә, үзе янында да учак тергезергә кушты. Бу учакка, чиратлап, конвоирлар да килә башлады.

Шуннан файдаланып, Әбүбәкер читкәрәк, кары чистартылган урынга китеп, көньякка карап, кулларын күтәреп намаз укый башлады.

– Аллаһу Әкбәр!

Лейтенант һәм конвоирлар учак янында мәшгуль булып, башта Әбүбәкергә игътибар итмәгән иде. Бераздан бер конвоир аны күреп, лейтенантка ымлады. Тегесе кобурасына тотынып: «Артка!» – дип кычкырды. Аңа арты белән торган Әбүбәкер намазын дәвам итте. «Артка, дидем!» – дип ярсып, лейтенант һавага атты. Әбүбәкер селкенмәде дә, тезләнеп намазын укый бирде. Лейтенант конвоирларга этләрне ычкындырырга команда бирде. Тегеләр һау-һаулап, Әбүбәкер ягына ыргылды. Менә шунда инде тоткыннар да, конвоирлар да гаҗәеп бер күренешкә шаһит булдылар. Бөтенесен узып, алга ыргылган беренче овчарка, Әбүбәкергә бер-ике адым кала, таш диварга төртелгәндәй, кисәк туктап калды һәм читкә сикерде. Икенчесе дә шуны кабатлады. Башкалар белән дә шул ук хәл кабатланды. Әбүбәкергә бер эт тә кагылмады. Ярсыган конвоирлар этләрне җыеп, яңадан «Фас!» командасы бирделәр. Тегеләр, өрә-өрә, узыша-узыша, алга ыргылды, ләкин Әбүбәкергә җитәр-җитмәс, кире борылып, үз урыннарына кайттылар. Бик гаҗәпләнгән конвоирлар үзара бу күренешнең сәбәпләрен ачыкларга тырышты.

Ул арада Әбүбәкер намазын тәмамлап, иптәшләре янына килеп, берни булмагандай, агач төбенә утырды. Әйтерсең әле генә аңа үлем куркынычы янамаган.

Гаҗәпләнүдән аңнарына килә алмаган тоткыннар да, конвоирлар да сүзсез калып, Әбүбәкергә карап торды. Аларның күп тапкырлар бу этләрнең бәйдән ычкындыруга тоткыннар өстенә ташлануын, тәннәрен йолкый-йолкый тешләгәнен күргәне бар иде. Ә бу юлы явыз этләр Әбүбәкерне иснәп тә карамады. Кеше сөйләсә ышанырлык түгел. Ләкин бит бу тамашага алар үзләре шаһит. Алар күз алдында булган хәл.

– Син нәрсә, изгемени? – дип сорады гаҗәпләнүен яшерә алмаган Игорь. Ул Әбүбәкергә, беренче тапкыр күргәндәй, йотылып карап торды.

– Нинди изге? Мин бары тик намаз укыдым.

– Ә нигә соң этләр сиңа тимәде?

– Белмим. Бәлки намаз укыгангадыр. Собаки бивают умни.

– Нинди акыллы! Болар бит кеше ботарларга өйрәтелгән ерткычлар.

– Алайса, белмим. Бары тик Аллаһы Тәгалә барысын да белә!

**Рифат ҖАМАЛ** *тәрҗемәсе*

Марсель
Бакиров

# КАРА ТАПЛЫ БӘХЕТ

## БИОГРАФИЯМ, ТОРМЫШ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ЮЛЫМ ТУРЫНДА БӘЯН

### Бер пот тоз ашауның тәүге нәтиҗәләре

Белүебезчә, халкыбыз телендә нииндидер җитдирәк максатка яки уңышка ирешүнең шарты рәвешендә әйтелә торган: «Моның өчен бер пот тоз ашарга кирәк», – дигән калыплашкан әйтем бар. Безгә дә, билгеле, үзебез укыта торган курсларны ныклап үзләштерү өчен әлеге кинаяле гыйбарәдә әйтелгәнчә, бер пот тоз ашарга, ягъни шактый вакытлар сарыф итәргә һәм күп көч салырга туры килде.

«XX йөз башы татар әдәбияты» курсын укытырга алынып, Мөхәммәт Мәһдиев моңарчы үзе укытып килгән «Татар фольклоры» предметын миңа тапшырды. Вуз тәрбиясен үткән агай-эне яхшы белә: җанлы һәм мавыктыргыч итеп сөйләү сәләте булмаган, җитмәсә, үз ачышлары һәм кызыклы фактлар белән баетылмаган текстын башын күтәрмичә уку белән шөгыльләнгән лекторларны студентлар тыңларга яратмый. Тәҗрибәле педагоглар исә лекциясе ялыктырмасын, озын обой кәгазе уралган төргәкне туктамыйча сүткәнгә охшамасын өчен, вакыт-вакыт бүленеп, тыңлаучыларның игътибарын бүтән бер фактка юнәлдереп ала. Ягъни ситуациягә ятышлы нииндидер кызыклы очрак хакында сөйләп яки мавыктыргыч хәл турында мәгълүмат биреп алганнан соң, кабат төп темасына әйләнеп кайта.

Мин мондый методны кулланунның уңышлы үрнәге белән Мәскәү университетына стажировкага, ягъни тәҗрибә алырга һәм белемемне камилләштерергә баргач, Х.Короглы лекциясендә таныштым. Соңыннан шуны үз практикамда кулланырга өйрәндем. Әмма дәреснең уңышлы үтүе сөйләү осталыгына гына түгел, ә лекция материалының эчтәлегенә, сыйфатына да нык бәйле. Хәмит Ярминең фольклорыбызның берничә генә жанрын эченә алган һәм алары да беренче якын килү рәвешендә өйрәнелгән «Татар халкының поэтик иҗаты» (1967) дигән китабы канәгатьләндермәгәнлектән (җитмәсә, журналда Мәһдиевнең әлеге хезмәтне нык тәнкыйтьләгән мәкаләсе дә чыкты), халкыбызның тел-авыз иҗатын басылып һәм төптән каерып, үзебезгә өйрәнергә туры килде.

Жанрларны тәфсилләп һәм системалы ысул белән өйрәнүне мин бәетләрдән башладым. Ошбу тикшеренүләрем һәм үзенчәлекле нәтиҗәләрем Альберт Яхин белән бергәләп чыгарган һәм аның мәзәк-анекдотлар хакындагы тикшерүен дә эченә алган «Фольклор жанрын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе» (1979) дигән китапта басылып чыкты. Шуннан соң Куйбышевтан (Самара) килгән хат буенча, бу китап белән әлеге шәһәрдә урнашкан һәм оригиналь хезмәтләрне пропагандалау белән шөгыльләнүче халыкара Үзәкнең дә кызыксынганлыгы ачыкланды. Әлеге оешма аша китап АКШ, Бөекбритания (Англия) һәм Германиягә җибәрелде. Бу минем белгечләрнең күзенә чалынган һәм «соавторлык»та чыккан беренче монографиям иде.

*Ахыры. Башы 11 нче санда.*

Лекцияләремне мин акрынлап, бер-бер артлы үзем тикшергән материалларга һәм үземнең табышларыма таянып укуны гамәлгә керттем. Ә 2008 елда шуларга һәм укыту тәҗрибәмә нигезләнеп, югары уку йортлары өчен «Татар фольклоры» дәреслеге төзеп чыгардым. Хәзерге вакытта татар теленә һәм культура мирасына мөнәсәбәтле бөтен уку йортлары да халкыбыз иҗатын фән буларак шушы дәреслек буенча өйрәнә.

Сөйләгәннәрем буш сүз генә булып калмасын өчен берничә дәлил дә китерим. Арттырып әйтмим: берничә жанрны беренче башлап, вуз таләбенә яраклаштырып, системалы анализлау яки аңлату эше дә безнең өлешкә туры килде. Әйтик, гаилә-көнкүреш йолаларына бәйле сүз-текстларның бер катламы – педагогик табу-тыюлар. Безгә кадәр беркем дә игътибар итмәгән һәм үрнәкләре дә тупланмаган бу фольклор жанры татар гаиләләрендә элек-электән бала тәрбияләү максатларында файдаланылып килгән. Менә конкрет үрнәкләре: «Өйдә туплы уйнама, өйгә яшен керер», «Аягыңны селкеп утырма, шайтан чакырасың», «Сыныгыңны калдырма, ирең (хатының) ташлап китәр», «Күп еласаң, ятим калырсың», «Керне сыгып бетер, ирең эчкече булмасын», «Идәндә чүп калдырма, ирең шадра булыр», «Көянтәне атлап чыкма, ике аяк араңа кыярак чыгар», «Сызгырып йөрмә, ут чыгарасың» һ.б.

Күрүебезчә, инандыруга гына корылган мәктәп педагогикасыннан аермалы буларак, боларда куркыту алымы да катнаша. Коръәндә дә бит шулай. «Аллаһыгыздан куркыгыз», «Тәмуг газапларыннан куркыгыз» кебек гыйбарәләр анда еш кабатлана. Димәк, баланы үз-үзен ничек тотарга яки эшен җиренә җиткереп эшләргә өйрәткәндә, ипле һәм үтемле итеп куркытып кую да үзен аклаган. Яшүсмер соңыннан кайбер тыю-табуларның уйдырмага, белә торып, юри куркытуга корылганлыгын аңлап алса да, максатка инде ирешелгән – ул тиешле тәртипкә өйрәнгән булып чыга.

Яки менә тагын бер без кулланган яңалык. Үзебез төзегән фольклор дәреслегенә без эшчеләр фольклорын да керттек. Халкыбызның тел-авыз иҗатында мондый катламның да булуын Мөхәммәт Мәһдиев яшь чагында Кузбасс шахталарында эшләгән Шәйхи Маннурның бәхәскә урын калдырмый торган сүзләренә нигезләп исбатлый. Ике арада булган сөйләшү авторның «Ачы тәҗрибә авазы» дигән истәлекләр китабында китерелә.

«Яр буенда һава сулап йөргәндә, Шәйхи абый сөйли.

– Менә син инде татар халык иҗатын укытасың, бу сорауга җавап бир: безнең татарда шахтёрлар фольклоры дигән өлкә бар. «Шахта көе» дә бар. Башка милләтләрдә андый фольклор юк. Шуның сәбәбе нәрсәдә? Ә? Белмисең?

Билләһи, үзем шул фәннән лекцияләр укыйм, үземнең бу турыда уйлап та караганым булмаган. «Әйе, Шәйхи абый, белмим. Валлаһи, белмим». Шунда ул безнең чорның диссертацияләре, монографияләр, аспирантуралар турында берничә тозлы сүз әйтте дә сөйләп китте.

– Татарның тимер юлда, станокта, элемтә системасында эшләрлек техник хәзерлеге юк. Бәхет эзләргә чыгып киткән татар егетенә бер генә юл бар – шахта. Чөнки анда техник әзерлек кирәк түгел ул заманда, тачка, кәйлә, көрәк белән эш итү өчен нибары физик көч кенә кирәк. Ә татар егетендә ул бар. Шуңа күрә шахтёрлык ул – безнең милли сыйфат. Әнә шулай аның үз фольклоры да туган.


Бу, әлбәттә, минем өчен ачыш иде. Бераздан мин моны, үз белгәнем итеп, лекция курсларында файдалана башладым».

Шушындый көчле «бомба»дан соң кайбер әдәбиятчыларның минем дәреслектәге эшчеләр фольклорына багышланган бүлекчәне артык яки кирәксез дип санауларының урынсыз булуы аңлашыла торгандыр. Өстәп, янә шуны әйтим: эшчеләр фольклорында әле башка иҗат төрләреннән аерылып тора торган тылсымлы сөйләк жанры да бар. Бер эпизодка корылган мондый текстларда забойда эшләүче шахтёр табигать хәзинәсенең яисә җир асты байлыкларының иясе белән очраша. Бу мифологик образ кеше, хайван, күсе, елан яки ут кыяфәтендә күз алдына китерелә. Байлыкка юлны ул йә үзе күрсәтә, йә булмаса шартлау, җимерелү-ишелүләр китереп чыгарып, байлык

табарга комачаулый. Бу жанр да, димәк, эшчеләр фольклорының үзенчәлекле катлам тәшкил итүен күрсәтеп, раслап тора.

***

Студентларның университетта фольклор курсын үзләштерүе җәйге чорда фольклор практикасында катнашу белән төгәлләнә иде. Халык иҗатын җыю белән бәйле бу практика күбрәк чит өлкәләрдә үткәнлектән, аны яңгыравык исем белән «Фольклор экспедициясе» дип йөртү гадәткә кергән. Университетта эшләгән дәвердә миңа студентлар белән Оренбург, Пермь, Ульяновск, Курган, Томск, Новосибирск өлкәләрендәге һәм Башкортстан якларындагы авылларны иңләп чыгарга туры килде.



*М.Бакиров студентларга шигърият серләре турында сөйли.*

Табып һәм язып алып кайткан фольклор материалларын ел да, зур папкага туплап, Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор бүлеге мөдире Илбарис Надыйровның кулына тоттыра идем. Ә ул ай буена бүлмәсендә шуларны үз дәфтәрләренә күчереп утыра иде. «Татар халык иҗаты» дигән уртак исем астында чыккан 12 томлыкның «Кыска җырлар» (1976), «Бәетләр» (1983), «Тарихи һәм лирик җырлар» (1988) дип исемләнгән томнарына урнаштырылган байтак текстлар безнең экспедицияләр вакытында язып алынды. Алар арасында хөрмәтле мөдиребез, төп чыганакны күрсәтмичә, үзе тапкан итеп биргәннәре дә шактый. Бу хакта мин, бәхәскә урын калдырмаслык итеп, аның үзенә дә әйткәнем булды. Бу, билгеле, хөрмәтле коллегамны бизәми торган ямьсез факт.

Әле генә аталган томнарның соңгысында заманында Буби мәдрәсәсен тәмамлаган, ә егерменче елларда Гыйльми үзәк белән тыгыз бәйләнештә булган археограф Зәйнәп Максюдованың үзе исән чакта шәхси архивыннан без фәкыйрегез язып алган «Кашан җыры», «Болгар ятимәләре» һәм «Болгарданмы киләсез?» дигән бик борынгы чорга караучы тарихи җыр текстлары да бар. Бу җырлар Болгар чорыннан ук башлангыч алулары белән үтә кыйммәтле һәм «уникаль».

Фольклор экспедициясендә катнашучылар, халык иҗаты үрнәкләрен җыю белән бергә, ата-бабаларыбыздан калган гарәп имласындагы язма материаллар, шулай ук кулъязма һәм басма китаплар эзләү белән дә шөгыльләнәләр иде. Шәхсән минем үземә Пенза өлкәсенең Йөзәй исемле авылында күптән вафат булган указлы мулланың бай китапханәсенә юлыгырга насыйп булды. Боларның өй түбәсендә тузанга батып яткан 80гә якын кулъязма һәм басма китапларны очсызга гына сатып алдым да, почтада дүрт төргәккә төрдереп, Казанга посылка итеп җибәрдем.

Кайткач билгеле булды: кулъязма китапларның берсе, калын күн белән тышланганы һәм бик борынгы булып күренгәне, болгар чорына карый торган хәзинә булып чыкты! Көнчыгыш телләр белгече, археограф Зәйнәп Максюдова ук ату һәм башка төр борынгы һөнәрләр турында гарәп телендә язылган әлеге китапны укып-өйрәнеп чыкты да шундый нәтиҗәгә килде. Аннары мин шул ук китапны Миркасыйм Госмановка күрсәттем. Ул аның борынгылыгын су билгеләре буенча билгеләде һәм XIII-XVI йөзләргә караганлыгын кистереп әйтте.

Посылка итеп салган китапларның барысын да мин республика Милли китапханәсенә тапшырдым. Шунда эшләүче Раиф Мәрдановның язып чыгуына караганда, ошбу кулъязма һәм басма китаплар Татарстан Милли китапханәсендә кулъязма һәм сирәк китаплар бүлеге ачарга нигез булган, ә сүз барган болгар чоры кулъязма китабы исә китапханәнең горурлыгына әверелгән.

Фольклор практикасы, экспедицияләр турында сөйләгәндә, студентларны исләрендә калырлык итеп ашату һәм өйләренә кайтканда кесә чыгымнары, якыннарына күчтәнәч алырлык азрак акчалары булсын өчен, урыннарда үзебез ясаган билетлар белән концертлар да куюыбыз хакында әйтми калу мөмкин түгел. Авыл халкы безне «Казаннан килгәннәр» дип, алдыбызда түшәлердәй булып каршы ала, көндез үз якларындагы йола һәм тел-авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыра, ә кичен концертыбызга килә иде.

Һәм ышануы да кыен – концертыбызны ошаталар иде. Чөнки мин үзебезнең группа белән ел саен композитор һәм баянчылардан Котдус Хөснуллин йә Марс Макаровны һәм бер җырчы артистны да алып чыга идем. Шул исәптән хәзерге вакытта республикабызның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты исемнәренә лаек булган, Дәүләт фольклор ансамблен күп еллар буена җитәкләгән Айдар Фәйзрахманов та җырчы буларак, беренче чирканчыкны, безнең белән чыккач, авыл сәхнәсендә алды. Ул гынамы, шул экспедиция вакытында гашыйк булып, безнең студент кызыбыз Халисәгә өйләнде.

Туйда кырмыска да канатлана дигәндәй, үзем дә артистка әйләнеп һәм кат-кат сәхнәгә чыгып, халыкны көлдерә торган скетчлар сөйли идем. Шулай ук, ничек җөрьәт иткәнмен диген, бер кыз белән чыгып, «Җизнәкәй» җырында мут җизни куплетларын җырлый идем. Студентларның һәм без фәкыйрегезнең чыгышларына – студентлар арасында, әлбәттә, шактый талантлылары да була – безнең белән чыккан профессионалларның да чыгышын кушкач, концертыбыз, чыннан да, күпне күреп бозылмаган тамашачыларны канәгатьләндерә иде.

Талантлы студентлар дигәннән, шактый матур җырлый торган кызлардан тыш, шигырьләре белән сәхнәне тоткан ике яшь шагыйрьнең чыгышлары истә калган. Беренчесе – хәзерге көндә югары дәрәҗәләргә ирешкән, Тукай премиясе лауреаты Ркаил Зәйдулла. Маяковский шикелле аякларын аерып басып, яңгыравыклы көр тавышы, социаль яңгырашлы милли шигырьләре белән ул залдагыларның бөтен вөҗүден айкап, «аһ» иттерә иде. Ә икенчесе – Илсөяр Иксанова хатын-кыз табигате өчен хас нечкә лиризм белән сугарылган шигырьләре белән алдыра, тамашачыларны шулай ук әсир итә иде.

Сүз уңае белән концерт вакытында булган бер кызыклы хәл белән дә таныштырып китим, дим. Җәй башында ачлы-туклы килеш баш күтәрмичә имтиханнарга әзерләнеп алҗыган студентларның күңелен табу өчен, алда торган экспедиция төбәген һәм маршрутын билгеләгәндә, мин кымыз ясый торганякларга да игътибар итә идем. Бер елны Оренбург ягындагы авылда, кымыз ясаучы бабайның искәртүенә карамастан, сезне гаепләмәбез дип, өлгермәгән кымыз сатып алырга туры килде. Һәм без кичке аш вакытында туйганчы бу затлы эчемлек белән кинәндек.

Шуннан соң ни булды дисезме? Гөнаһ шомлыгына күрә, җитлекмәгән кымызның эчне борып алуы нәкъ концерт башланган вакытка туры килде, әй. Сәхнәдә тезелеп, хор белән халык каршында җырлап торучы студентлар, артларына ут капкандай, «беттем-беттем, Марсель абый» дип, бер-бер артлы чыгып тая башладылар. Концертыбызның «прелюдия» өлеше менә шулай кәмит күренеш белән башланса да, халык безне аңлап, ары таба җайга салынган чыгышларыбызны ошатып кабул итте.

Ә имтиханнарга әзерләнеп алҗыган, ябыккан студентларның күңелен табам дип эшләгән икенче бер гамәлем яки «изгелегем» аянычлы кәмит хәл тууына китерде. Башкортстанның Дүртөйле районының Әсән авылына барып төшкәч, фермадан юллатып, һәр студент башына мин берәр зур табык суйдыртып китерттем. Шуларны пешертеп, кухня өстәленә өйдертеп куйгач, студентлар шуңа ябырылдылар. Ахыры кызык булып бетте: ике егет, үтләп, группадаш кызлары янына килә алмыйча, бер атна буе кикереп йөрделәр.

Фольклор практикасының иң кирәкле һәм иң җитди нәтиҗәсе, билгеле – булачак

укытучылар, милли белгечләрнең бай һәм күпкырлы иҗат үрнәкләрен тудыручы халык талантларын үз күзләре белән күреп һәм үз колаклары белән ишетеп язып алуы, аларда милли мирасыбызны җыю, саклау һәм киләчәк буыннарга түкми-чәчми тапшыру тойгысының тәрбияләнүе. Төрле якларда язып алынган текстлар арасында халкыбызның «халәте руханиясен» чагылдырганнары һәм «әдип вә шагыйрь» (Тукай) булуын раслаганнары күңелгә ифрат көчле тәэсир итә торганнары шактый. Менә мисалга элгәре заманга карауча интим-эмоциональ һәм фәлсәфи-интеллектуаль характердагы берәр генә строфадан торучы ике мисал.

*Агыйделнең аръягында болыт тора,*
*Яңа ярлар иске ярны оныттыра,*
*Яңа ярлар табак белән аш китерә,*
*Иске ярлар, искә төшеп, яшь китерә.*

*Карт куенында калач бар,*
*Яшь куенында камчы бар,*
*Калачыннан бал татыр,*
*Камчысыннан кан татыр,*
*Калачыннан бизәрмен,*
*Камчысына түзәрмен.*

Үтә отышлы оппозицияләргә һәм гаҗәеп хисле-хикмәтле образларга корылган бу текстлар күңелне парә-парә җилкендерә. Тукай әйткәндәй, ошбу шигъри юлларның астына теләсә кайсы сәләтле шагыйрь дә кул куюдан тартынмас иде.

Ә болары – гаиләләрдәге, гайре табигый мөнәсәбәтләргә карата халыкның юмористик (беренче мисал) һәм сатирик (икенче мисал) мөнәсәбәтен чагылдырган шигъри текстлар.

*Килен кеше эштән кайта,*
*Берлинны алган кебек;*
*Каенанасы калтырап тора,*
*Пленда калган кебек.*

*Бусы – кызым баласы,*
*Балдан татлы анасы;*
*Монысы – улым баласы,*
*Кара елан анасы.*

Фольклор практикасы, экспедицияләр вакытында студентлар тапкан һәм язып алган материалларның бер өлеше Г.Ибраһимов исемендәге фәнни-тикшеренү институты бастырып чыгарган 12 томлыкта урын алган булса, икенче бер өлеше шушы ук институтның мирасханәсенә тапшырылды.

***

Сүзнең студентлар практикасы турында баруыннан файдаланып, кыскача булса да, студентларның музей практикасына да тукталып китәргә кирәктер. Бу практиканы татар бүлегенең уку-укыту программасына университетның игелекле ректоры Михаил Тихонович Нужин керттерде. Шундый практиканың берсенә без Хатыйп Миңнегулов белән икәү җитәкчелек иттек һәм бишенче курс студентларын кышкы каникуллар вакытында Кавказ арты республикаларына алып бардык. Башта Азәрбайҗан башкаласы Бакуга самолёт белән очтык. Анда берничә көн торып, музейларын һәм истәлекле урыннарын тамаша кылганнан соң, поезд белән Ереванга барып төштек.

Монда без бөтен белешмә чыганакларда рус художнигы дип күрсәтелгән атаклы әрмән рәссамы И.Айвазовский (Хайвазян) музеенда булып, диңгез пейзажлары остасының аз билгеле булган картиналары һәм үз туган телендә язган хатлары белән таныштык. Безне шулай ук Матенадаран исемендәге дөнья күләмендә билгеле булган мирасханә һәм институт белән дә таныштырдылар. Тышта, ачык һавада тупланган музей экспонатлары – «хачкары» (безнеңчә, «тәреле таш», «Кызыл хач» җәмгыяте (гыйбарәсендә шул борынгы хач – крест сүзе катнаша) дип аталган һәйкәлләр үзләренең ташка уелган һәм бер-берсен кабатламый торган үтә нечкә, нәзакәтле бизәкләре белән туристларны гына түгел, безне дә гаҗәпкә калдырды.

Грузия башкаласы Тбилисидә исә, вакыт аз калганлыктан, күп йөреп булмады. Шулай да студентларның үз гомерләрендә беренче тапкыр фуникулёр дигән һава юлы белән канатка асылган вагонеткада якындагы тауга менүләре һәм шунда төнге утлар балкып торган манзарага – шәһәр күренешенә карап хозурланулары яшь җилкенчәктә онытылмаслык тәэсирләр калдырды.

Икенче бер елны мин студентларны (баручылар арасында бер группаның кураторы Флёра Ганиева да бар иде) ике Балтыйк буе республикасына алып бардым. Монда безгә мөнәсәбәт Кавказ арты республикаларына караганда шактый кайтышрак булды дигән тәэсир калды.

Башта самолёт белән Латвиянең башкаласы Ригага барып төштек. Университет җитәкчелеге безне, кышкы каникул булуга карамастан, тулай торакларына урнаштырмады, ә каядыр шәһәр читендәге җәйге лагерьга җибәрде. Без урнашырга тиешле бүлмәләр сап-салкын, краннарда су туңган, бәдрәфләре дә тышта иде. Мин студентларны кире борып, алдан ук буш урыннар булуы белешенгән шәһәр кунакханәсенә урнаштырдым.

Икенче көнне җыелышып, үзебезчә сөйләшә-сөйләшә, шәһәр урамыннан барганда, баласын иярткән яшь кенә ханым, каршыбызга чыгып, безне туктатты. Аның кояштай балкып, шатлыгын яшермичә безгә мөрәҗәгать итеп әйткән сүзләре саф татарча иде.

– Ой, сез татарлар икән бит, үзебезнең кешеләр. Без дә татар...

Казаннан килгәнебезне белгәч, ул безне, ихлас күңелдән кыстап, өйләренә кунакка чакыра башлады. Без вакытыбыз булмавын, әле шәһәрне карарга, кибетләргә керергә дип чыгуыбызны әйткәч кенә, ул тынычланды. Шунда ул аерылышканда, без «килмешәк»ләрнең күзен ачты:

– Кайда гына барсагыз да, үзебезчә сөйләшеп йөрегез. Монда өлкән туганыбызны һәм русча сөйләшкәнне өнәп бетермиләр, – дип кисәтте.

Һәм, чыннан да, кемнәрдер биргән заказларны үтәргә дип янтарь кибетенә кергәч, сатучының әлеге күркәм таштан эшләнгән муенса белән кызыксынган рус хатыны белән коры гына сөйләшүенә игътибар иттек. Ул чыгып киткәч, безнең башка милләттән икәнебезне аңлап алган сатучы ачылып сөйләшә башлады. Прилавка астыннан чыгарып, зиннәтлерәк янтарьдан эшләнгән бүләкләр сайлап алырга булышты.

Ары таба без Риганың үзәк музейлары белән таныштык. Орган урнаштырылган борынгы дини соборларында Бах һәм башка композиторлар язган орган музыкасын тыңладык. Шулай ук безгә Рига диңгез култыгы зонасында урнашкан атаклы Юрмала шәһәрен күрергә дә насыйп булды. Монда күренекле артистларыбыз шул чорда килеп чыгыш ясый торган концерт залын һәм латыш халык шагыйре Я.Райнисның музей-дачасын тамаша кылып йөрдек. Янә килеп, туристлар үтә дә кызыккан һәм су коена торган «алтын» комлы пляжларында, мәһабәт наратлар үскән калкулык белән чикләнә торган диңгез буенда эзләребезне калдырдык.

Шушыннан соң аяк баскан Эстония Республикасының башкаласы Таллин, бигрәк тә аның Иске Таллин дип йөртелгән өлеше, безне бер-берсенә терәп салынган һәм стена кебек буйдан-буйга тезелеп киткән йортлар тезмәсе һәм тар урамнары белән гаҗәпләндереп каршылады. Эстонлылар үзләре мондый үзенчәлекле, «европача»

стильдә төзелгән шәһәрләре белән горурланалар. «Иске Таллин» дигән исем белән бәлзәм һәм спиртлы эчемлек чыгарулары, төрле товарларын да шулай атаулары да шуны раслап тора. Музейларын йөреп чыкканнан соң, биредә безне заманында Пётр Беренче һәм сарай даирәсе өчен Санкт-Петербургтан килеп дару ала торган һәм хәзергә кадәр эшләп яткан шактый борынгы даруханәләре белән дә горурланып таныштырдылар.

Һәм тагын бер кызыклы факт: Пугачёв күтәрелеше бастырылганнан соң, Салават Юлаевны әтисе һәм бер төркем баш күтәрүчеләр белән гомерлеккә Балтыйк буена сөргенгә җибәрәләр. Башкортстаннан барган вәкилләр, ишетеп белүемчә, Салаватның шактый еллар узганнан соң да исән булганлыгын раслый торган архив материалы табып кайттылар. Ә Эстониядә булган чагыбызда гид-экскурсовод безгә, машинада шактый ерак урынга алып барып, – дөрестерме-юкмы, – шунда рудникта эшләгән чагында Салаватның ике тау арасындагы тирән чокырга («ущелье») ташланып, үзен-үзе һәлак иткәнлеге турында риваять сөйләде. Кем белә, бәлки, бу үзләрен безнең җирлек һәм тарих белән бәйләп, туристларга сөйләү өчен уйлап чыгарылган «фейк» булгандыр.

Җыеп әйткәндә, студентларның без – укытучылар җитәкчелегендә уза торган фольклор һәм музей практикалары халкыбызның иҗат мирасы һәм җанлы иҗат процессы белән якыннан таныштырып, шулай ук төрки һәм башка кавемнәрнең тормышын, культура казанышларын үзара чагыштырып үрнәк яки гыйбрәт-сабак алырга мөмкинлек тудырып, әзерлекле, җитлеккән кадрлар тәрбияләүгә нык ярдәм итә торган иде. Кызганычка, хәзерге студентларыбыз дөньяга карашларын үстерә һәм киңәйтә торган музей практикасыннан мәхрүм инде.

## «Асылынсаң, асылын агачның асылына...»

Бу мәкальнең төбендә төрле, әмма кайсыдыр яклары белән аваздаш ситуацияләрдә кулланырлык күчерелмә мәгънә ятканлыгын күпләр чамалый торгандыр. Темасы «Мәкаль һәм ситуация» дип исәпләнгән һәм мин җитәкчелек иткән диплом эшендә якташым Факил Сафинның тормыштан, шулай ук аерым әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып һәм кызыклы нәтиҗәләр чыгарып башкарган саллы тикшерүе истә калган. Тукай премиясенә лаек булган «Саташып аткан таң» (2003) дигән



*Университетның татар әдәбияты кафедрасында.*
*Беренче рәттә (сулдан уңга): Ибраһим Нуруллин, Флёра Ганиева, Хатип Госман, кафедра лаборанткасы Динә Биктаһирова, Резеда Ганиева; икенче рәттә: Нил Юзиев, Мөхәммәт Мәһдиев, аспирант Наип Лаисов, Марсель Бакиров, Зәет Мәҗитов.*

роман-трилогиясендә дә ул телебездәге калыплашкан һәм үзе иҗат иткән күчерелмә гыйбарәләрне гаҗәеп мач һәм оста итеп кулланучы сүз художнигы булуы белән игътибарны җәлеп итә.

Без исә бу очракта «асылынсаң, асылын агачның асылына» мәкален, фән белән шөгыльләнсәң, җитди һәм зур проблемаларны өйрәнергә алын, дигән мәгънәдә кулланабыз. Бу мәгънә минем мәсләгемә һәм алга куйган максатыма туры килә. Ачыклап әйткәндә, поэзияне яратканлыктан, ары таба мин сүз сәнгате буларак, шигырьнең, бигрәк тә төрки халыкларда шигъри-ритмик сөйләмнең ничек яралуын һәм нинди эволюцион үсеш баскычлары үтүен өйрәнергә алынырга булдым. Шушы глобаль тема «Генезис и древнейшие формы общетюркской поэзии» дигән докторлык диссертациямнең асылын, төп эчтәлеген тәшкил итәчәк гыйльми-гамәли өлкәгә әверелде. Ошбу максатка ирешү өчен мин күп елларымны сарыф иттем.

Сүз дә юк, баштарак шигырь төзелеше буенча дәвам ителгән яңа эзләнүләремне һәм табышларымны бергә туплап, докторлык диссертациясе итәргә һәм чагыштырмача иртәрәк тә якларга була иде. Әмма минем моңарчы бер тюркологның да теше үтмәгән өлкәгә – шигъриятнең чишмә башына юл сабып, тирән катламнарга үтеп керәсем килде. Шуңа күрә дә укытудан бушаган вакытларымны һәм биш елга бер тапкыр стажировкага – эшчәнлегеңне камилләштерүгә бирелә торган өч аемны мин, башлыча, төрле китапханәләрдә утырып, кирәкле теорияне өйрәнү һәм бөртекләп, фактик материал җыю белән шөгыльләнүгә багышладым.

Атап әйткәндә, миңа аерым-аерым, ә кайберләрендә хәтта берничә тапкыр Мәскәү, Ленинград, Алма-Ата, Ташкент, Фрунзе (Бишкәк), Еревандагы (Матенадаран) милли үзәк китапханәләрдә атналар буе утырырга туры килде. Мәскәү Милли китапханәсендә янәшәмдә утырып, докторлык диссертациясен язган телче Фәрит Йосыповның без фәкыйрегезнең көн дә бер-ике «тележка» тутырып алып килгән китапларны өйрәнеп-«сөреп» чыгуым турында башкаларга сөйләгәне истә калган. Ә инде үзебезнең университет китапханәсеннән чыкмыйча да ятуым турында әйтеп торасы да юк. Бервакыт Әбрар Кәримуллин яныма килеп, аркамнан кага-кага әйтте: «Марсель, кайчан гына килсәм дә, син монда, әллә монда кунып ятасыңмы?» – диде, ярымшаяртып. Алда әйтелгәнчә, ул мине студент чагымда рәссам итеп университетның Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенә вакытлыча үзе эшкә урнаштырган вакыттан ук белә иде инде.

Күп көч салган һәм дә моңарчы тюркологларның кулы тимәгән яки аз билгеле булган өлкәләргә һәм материалларга үтеп кергәнгәдер инде, докторлык диссертациямне фән-культура җәмәгатьчелеге хуплап һәм югары бәя биреп каршылады. Беренче оппонентым Мансур Хәсәнов үзенең бәяләмәсендә менә ничек яза: «Татар әдәбият белемендә төрки әдәбиятның үзенә генә хас нигезләрен өйрәнгән хезмәтләр бар. Ләкин төркиләр тудырган поэтик иҗатның бу кадәр ерактагы яралгы чорына моңарчы беркемнең дә мөрәҗәгать иткәне юк иде. Тикшеренүләрнең методологик нигезен тәшкил итүче тарихилык принцибы диссертантка гомумтөрки поэзиянең ничек яралганлыгы һәм төрки художестволы-сәнгати иҗатның тарихи поэтикасы турында теория тудырырга мөмкинлек биргән. Бакировның тикшерүе – моңарчы филология фәне үтеп керә алмаган өлкәгә беренче булып юл яра торган пионер хезмәт».

Ә икенче оппонент, Башкортстаннан академик Гайсә Хөсәеновның бәяләмәсендә болай диелә: «М.Х.Бакировның диссертациясе тюркологиядә, поэзия һәм шигырь теориясендә яңа юнәлеш ача. Анда тюркологиядә беренче буларак һун-гун иҗатындагы моңарчы билгеле булмаган поэтик үрнәкләр һәм жанрлар бергә җыйналган, күрсәтеп бирелгән. Диссертант ачкан һәм тикшергән материаллар буенча, безнең ерак бабаларыбыз бай һәм тармаклы иҗатлары, шулай ук риторик матур сөйләү сәнгатьләре булган кавем булып күз алдына баса. Мондый оригиналь һәм зур ачышның, минем белүемчә, тюркологиядә әлегә кадәр булганы юк иде».

Алга китеп әйтим: ошбу диссертациягә нигез булган монографиямдәге борынгы һун-гун бабаларыбызның кытай, латин чыганаклары аша килеп җиткән һәм хәзерге телгә тәрҗемә ителгән уннан артык фольклор жанры үрнәкләрен, шулай ук аларның һәм аларны дәвам итүче борынгы төркиләрнең риторик-матур сөйләү сәнгате текстларын бәйнә-бәйнә өйрәнгән өлеше «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында (2014) урнаштырылган иде. Оппонентларымның һәм аннан соңгы рецензентларымның (Ә.Шәрипов, Ә.Закирҗанов, Ф.Садриев, Н.Тобуроков, А.Брыжинский) бәяләвенә караганда, һичшиксез, татар әдәбияты фәнен һәм татар әдәбияты тарихын Орхон-Енисей язмаларыннан (VI-VIII гасырлар) гына башлаучы башка төрки әдәбиятлардан аерып тора торган бик җитди казаныш иде.

Әмма ошбу хезмәтемне яңартылган икенче басмасына ул минем һун-гун бабаларыбызның иҗатына багышланган концептуаль тикшерүем кермичә, төшеп калды. Шулай ук «Чура батыр эпос-дастаны» дигән безнең икенче мәкаләбез дә кире кагылып, әлеге каһарманның прототибы Казан морзасы – хыянәтче, сатлыкҗан Чура Нарыков белән тиңләштереп аңлатыла торган ялгыш концепцияле мәкалә белән алмаштырылды.

Һәм тагын бер гыйбрәтле мисал. 2015 елда «Милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре системасында төрки-татар фольклоры һәм борынгы вә урта гасырлар поэзиясе» дигән уртак темага берләштереп, бер төркем хезмәтемне Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим иткән идем. Әлбәттә инде, бу тематик төркемгә мин һун-гун һәм борынгы төркиләр иҗатына багышланган «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» (тулыландырылган русча нәшер ителгән вариантының исеме – «Древнетюркская поэзия», 2014) дигән, әдәбият белгечләренең һәм әдәбиятчыларның югары бәясен алган китабымны да керттем. Ләкин җәмгысы 32 гыйльми совет әгъзалары арасында – аларның берничәсе килми калган иде – күпчелек, ягъни 16 тавыш җыюыма карамастан, бер түрәнең күрәләтә гаделсезлек кылуы аркасында откан премиямнән дә мәхрүм калдым. Үзенә бу турыда әйткәч, ул: «Оту өчен син тавышларның өчтән ике өлешен (?!) җыярга тиеш идең», – дип, саламга ябышып, күзләремә төтен җибәрде.

Ләкин Академия президенты ошбу шухыр-мухырны сизеп калган булып чыкты, янында чакта минем дә шул хакта искәртүем белән килеште, акланмады. Ә икенче елны, өемә шалтыратып, документларымны кабат комиссиягә бирүемне сорады. Мин: «Бакиров дәүләт премиясен кат-кат йөдәтеп кенә алды», – дип авыз чайкамасыннар өчен яңадан барып йөрмәдем, документларымны кабат бирмәдем.

## Мәшәкать-мазасыз дөнья сансыз

Кем булуына карамастан, ир кешенең, гаилә башлыгының үзе корган гаилә алдында да бурычлары бар. Хатын булган кеше гадәттә: «Мин сиңа бала ияртеп килмәдем», – дияргә ярата. Димәк, балалар таптыргансың икән, син аларны матди яктан тәэмин итәргә, тәрбияләүдә катнашырга һәм, әлбәттә, киләчәк язмышлары турында кайгыртырга тиешсең.


Баштагы чорда, акча җитмәгәнлектән, шактый кыенга туры килде. Кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң, алты ел буена аз гына эш хакы ала торган кече гыйльми хезмәткәр һәм ассистент вазифаларын башкардым. Шәфкать туташы булып эшләгән хатынымның да эш хакы түбән булганлыктан, аңа бер ярым «ставка»га, ә миңа параллель рәвештә төрле елларда гомумбелем бирү мәктәпләрендә, балалар иҗат йортында, шулай ук музыка мәктәбендә һәм консерваториядә дәресләр алып барырга һәм лекцияләр укырга туры килде.

Бу очракта мин, билгеле, доцент булып алганнан соң, хәтта профессор дәрәҗәсенә ирешкәннән соң да Мәскәү әдәбият институтында, Самара университетында

оештырылган рус-татар бүлегендә һәм Чаллы педагогия институтының татар филологиясе факультетында җитәкчелек чакыруы буенча лекцияләр укуым турында сүз алып бармыйм. Шулай ук Концепциясен һәм Уставын үзем төзеп, параллель рәвештә Фольклор үзәгендә эшли башлавымны да исәпкә алмыйм. Анысы – кирәк яки мохтаҗлык булган урыннарга ярдәм кулы сузу, яисә эшләп алу – үз фәнен профессиональ югарылыкта үзләштергән белгечнең зарури бурычы. Ә алда саналган төрле өстәмә эшләрдә эшләвем җитмәүчелекне каплау ихтыяҗы белән бәйле иде.

Ачның хәлен тук белми, дигәндәй, деканыбыз кафедра мөдиренең минем турыда борчылып йөрүенә бөтенләй колак салмады, мине күптән инде лаек булган югарырак статуска, әйтик, өлкән укытучы вазифасына күчерү белән кызыксынмады. Хәлбуки, мин аңа Мәскәүдә стажировка үткәндә, сүзен тыңлап, дефицит товарлар табышуда һәм поездга илтеп, Казанга озату кебек эшләрдә вакытымны әрәм итеп йөргән булсам да. Аның каравы факультетта күрсәткән үрнәк хезмәтем өчен факультет профбюросы карары белән миңа тәгаенләнгән «Фидакарь хезмәт өчен» медален ул үз белдеге белән деканатның диспетчер-секретарена бирдерде. Бу медальне миңа бирү турындагы карар факультет партбюросында берничә ел буе көз көне студентларны шефлык ярдәме күрсәтергә колхозларга җибәрү эше белән җитәкчелек иткәнем һәм фольклор буенча хуплап каршыланган җитди монография бастырган өчен чыгарылган иде. Шул ук вакытта мин хезмәт ияләренең район советына сайлаулар чорында Совет районы буенча университетка беркетелгән сайлау участогының җитәкчесе булып эшләп алган идем. 99 нчы аудиториядәге бер парта өстенә кемдер кулы белән: «Есть ли бог? Бога нет, а есть декан», – дигән сүзләр юкка гына язып куелмаган булган икән. Үзен «баш-түш» итеп санаган деканыбыз минем хезмәтләремне искә алып чыгарылган профбюро карарын кодрәтле кулы белән сыпырып кына ыргытты.


Көтеп-көтеп тә законлы штат мәсьәләсе һаман хәл ителмәгәч, мин университет ректоры Михаил Тихонович Нужинга мөрәҗәгать итәргә булдым. Ул гаҗәеп кешелекле, татарларга, татар факультетына бик теләп ярдәм итә торган үтә дә гадел җитәкче иде. Мин аңа алтын таулар вәгъдә итеп, кафедрада калдырсалар да, ишле гаиләмне хет хәл чамалы булса да, ашау-эчү һәм



*Марсель Бакиров бертуган апасы Шәркия һәм абыйсы Марс белән. 1980 нче еллар башы.*




*Галим 85 яшьлек юбилеенда хатыны Кифая белән.*



*Сөекле балалары (сулдан уңга): Гөлназ (табибә), Айдар (адвокат һәм эшмәкәр), Гүзәл (табибә).*

кием-салым белән тәэмин итәрлек акча алмавымны аңлатып бирдем. Ул бу турыда үзенә җиткерүче булмаганлыгын әйтте. Һәм – мин бик-бик рәхмәтле аңа – киләсе айдан ук без фәкыйрегезне өлкән укытучы эш хакына күчерде. Шуның артыннан ук доцентлыкка да сайлаттырды.

Кайсыдыр акыл иясенең, фән белән җитди шөгыльләнү өчен баш өстеңдә түбәң булуы кирәк, дигән бик дөрес фикере бар. Үз фатирың булуы гаиләңне кешечә яшәтү өчен дә зарури шарт ул. Менә шуңа күрә дә ишле гаиләмә тиешле уңайлыклар, ә үземә тавык кетәклеге кадәр генә булса да, аерым эш урыны булдыру өчен «хрущёвка»бызны киңрәк фатирга алмаштыру максаты белән ике елдан артык «разнорабочий» булып та бил бөгәргә туры килде. Ачыклап әйткәндә, Чехов урамында университет өчен салына торган йорт төзелешенә йөреп, атна саен бер яки ике көн җир («котлован») казу, носилка белән цемент һәм кирпеч ташу, рама араларын мүкләү кебек төрле авыр эшләрдә эшләдем.

Әмма йортның төзелеп бетүе булды, югары урын биләүче, үз фатирларын балаларына яки оныкларына калдырырга омтылучы профессура шундук хәрәкәткә килде. Миңа дип тәгаенләнгән өч бүлмәле фатирны исә болай да нормаль шартларда яшәп яткан ашханә директорына бирергә булдылар. Сәбәп итеп китергән «нигезле» сылтау яки дәлилләре – имеш, минем медицина институтында укый торган ике кызым киләчәктә кияүгә чыгып, төп йорттан китәргә тиешләр (?!). Менә шул рәвешле җитәкче түрәләр тарафыннан авантюрага, чеп-чи ялганга корылган тагын бер законсыз адым ясалды.

Рус мәкалендә әйтелгәнчә, «мир – не без добрых людей». Шул чагында миңа Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары Мансур Хәсәнов һәм Башкортстан партия Өлкә комитетының идеология эшләре буенча секретаре Таһир Ахунҗанов ярдәмгә килделәр. Аларның юллавы буенча, үзебезнең обкомда идеология секретаре Рәис Беляев янына керергә җыенганымны күреп алып, университет ректоры Александр Коновалов, законсызлыкка юл куйганлыгын тирәнгә җибәрмәскә теләптер инде, Беляев янына кермәскә кушты. «Бар, кайтыгыз, Бакиров, мин сезнең «хрущёвка»гызны өч бүлмәле фатирга алмаштырырга күрсәтмә бирәм», – диде. Менә шулай итеп, кулымнан килгәнчә көрәшеп, күрәләтә кылынган кырын эшне кире кагарга һәм дөреслекне өскә чыгарырга насыйп булды.

Аллага шөкер, балаларым үзләре теләгән вузларны тәмамлап чыгып (ике кызым – табиб, улым – юрист, эшмәкәр) җаваплы урыннарда эшләделәр, абруйлы нәселләр белән кушылып, матур гаилә кордылар. Ә улым Айдар хәзер дә эшли. Туристлар җибәрә торган салон тота. Килен һәм кияүләребезгә шулай ук тел-теш тидерерлек түгел. Оныкларыбыз да нәселебез юлыннан бара. Икесе университетның юрфагында, берсе экономфагында, янә берсе КАИның юристлар әзерли торган бүлегендә белем алдылар. Ләйсән исемле оныгым башта монда үз белгечлеге (юрист) буенча – кандидатлык, ә Америка Кушма Штатларында инглиз телендә докторлык диссертацияләре яклады. Табиб ире халыкара грант откач һәм африкалыларга ярдәм итеп кайткач, алар Америкага киткәннәр иде. Ике балаларын да татарча сөйләшергә өйрәтәләр, өйләрендә үз телебездә генә аралашалар. Анда яшәүче татарларның бергә җыелып уздыра торган милли җыеннарын да калдырганыбыз юк, диләр.

Бу уңай белән алар монда ялга кайткач булган бер кызыклы һәм үтә гыйбрәтле вакыйга турында эндәшмичә калу мөмкин түгелдер. Оныгым Ләйсән моннан ике ел элек, җәй көне, 6 яшьлек улы Тимурны ияртеп, әти-әнисе яшәгән йорт ишегалдындагы балалар мәйданчыгына чыккан. Кечкенә Тимур тирә-ягында үзара рус телендә генә такылдаучы, чыр-чу килүче татар мәркәзе балалары арасында ятсынып басып торган-торган да (ул чакта аны русча да сөйләшергә өйрәтмиләр иде әле) әнисе янына килеп:

– Аларның сөйләшкәнен мин аңламыйм. Әйдә, моннан китик, – дигән.

Икенче көнне болар янә мәйданчыкка килергә булганнар. Әмма бу юлы ят

кунакларның Америкадан кайтканлыгын олылардан ишетеп белгән балалар Тимур оныкчыгым белән Ләйсәнемне кызыксынып каршы алганнар. Әни кеше яннарына җыелышкан «ташбаш»ларга ымлап, улына:

– Хәзер мин сине, балакаем, булачак дусларың белән таныштырам, – дип әйткәннән соң, арадан бер шугы моңа бәлки кайбер башка балаларның да башына килгән сорауны биргән:

– Тётя, тётя, а вы говорите с ним по-английски, да?

Бу трагик-комик хәлне монда аерым тукталып шәрехләмәсәң дә, нинди аянычлы нәтиҗә соралганлыгы аңлашылып тора.

Ә менә Ләйсәнемнең Казанда яшәүче бертуган энесе – Руслан оныгымның (хатынының исеме Миләүшә) гаиләсендә саф үз телебездә генә сөйләшәләр. Уллары Бәхтиярны татар мәктәбендә укыталар. Айдар улымның улы – бүгенге көндә 9 нчы сыйныфта укучы Әмир исемле оныгым исә мине үзенең уңышлары белән шатландыра. Ул компьютерда теге яки бу мәсьәләнең чишелешен хәл итә торган программалар төзергә өйрәнү белән шөгыльләнә, программист булырга җыена. Аның быел шушы өлкә буенча республика күләмендә үткәрелгән бәйгедә беренче урынны алуы, ә бөтен Россия масштабында Новосибирскида оештырылган ярышта – өченче һәм күптән түгел генә Казандагы шундый ук алышта хәтта беренче урыннарны яулавы киләчәктә максатына ирешәчәгенә өмет-ышаныч уята. Беренче урынга чыккан өч кешедән торган аларның командасына теләсә кайсы техник вузга имтихансыз укырга керү хокукы бирелде.

Димәк, геннарыбызны гына түгел, ә юлыбызны дәвам итәчәк һәм безне – бабаларындәү әтиләрен алмаштырачак горурланырлык оныкларым һәм оныкчыкларым бар минем.

## Кафедрабыздагы һава үзгәрешләре

Аспирантурада уку елларын исәпләмәгәндә, мин университетта 47 ел буена укытучы-мөгаллим булып эшләдем. Ә җәмгысы, димәк, төгәл ярты гасыр. Шушы чор эчендә әдәбият кафедрасында биш мөдир алмашынды. Хатип ага мөдирлек иткәндәге елларның ничек үткәнлеге турында алда әйтеп киттем инде.

Ошбу остазыбыз ялга – пенсиягә чыккач, аны «Чаян» журналыннан килгән Альберт Яхин алмаштырды. Ул үзенең булачак докторлык диссертациясен күздә тотып, башта мәзәк-анекдот жанрын өйрәнергә кереште һәм акрынлап әйтем, мәкаль, табышмак һәм җыр жанрларын да өстәү исәбенә темасын киңәйтте. Тик шунысы гаҗәп: үзе халык иҗатын тикшерергә алынганлыктан, үзенә кадәр өйрәнелеп килгән фәнни темаларны яптырып, бөтен кафедра әгъзаларын да фольклор темаларын өйрәнүгә күчерде. Ошбу «үзгәртеп кору»ның нәтиҗәсе буларак, кафедра укытучыларының «фольклорны система итеп тикшерү» дигән гомуми баш астында берничә җыентык басылып чыкты.

Яхинның докторлык диссертациясенә нигез булырга тиешле монографиясе исә 1984 елда «Система татарского фольклора» дигән исемдә дөнья күрде. Әлеге хезмәтнең кульязма текстын киңәйтелгән кафедра җыелышында тикшергәндә, мин аңа, тезеп-тезеп, үзем тотып алган җитешсезлекләрен санап күрсәттем. Әйтик, табышмак жанрында дөньяны танып белү функциясе юк дип каравы; мөнәҗәтләрне һәм бәетләрне җыр жанрына кертүе һ.б. Ләкин үзенең хаклыгына, «системалы фикер йөртү»енә сукырларча ышанып, мөдиребез кычкырып торган хаталарын атап күрсәткән искәрмәләремне кабул итәргә теләмәгән булып чыкты. Мәскәүдә, күрәсең, Алма-Атада якланган әлеге фәнни хезмәтнең башка кимчелекләрен дә тапканнардыр – диссертацияне расламадылар.

Кафедра мөдиренең «системалы фикер йөртү»е тенденцион төс алды һәм кафедра әгъзалары белән ике арада кискен конфликт китереп тудырды. Ачыклап

әйткәндә, профессор Ибраһим Нуруллинның дәреслегенә һәм укытуына адым саен бәйләнеп, үзен укыткан һәм заманында аспирантурага чакыртып алган ошбу остазын кафедрадан кысып чыгарды. Аны рус әдәбияты кафедрасына күчәргә мәҗбүр итте. Шулай ук ул студентларның кумиры булган Мөхәммәт Мәһдиевне дә лекцияләрен «тугарылып укуда, эзлексезлектә» гаепләү юлына басты; Хатыйп Миңнегуловның дәресендә булганнан соң, имеш, лекциясендә Утыз Имәни иҗатын дөрес итеп ача алмады, бозып аңлатты дип тәнкыйтьләде. Мөдирнең мондый гаделсез һәм хәтәр кыланышы, билгеле, кафедра әгъзаларын берләштерде һәм безнең, күмәк кул куеп, обкомга җибәргән хатыбыз чыгырыннан чыккан коллегабызны урыныннан алып ташлауга китерде.

1981-1982 уку елында Яхинны аңынчы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән Азат Әхмәдуллин алмаштырды. Азатны мин студент чагыбыздан ук беләм. Без аның белән бер группада укыдык, аның баянда оста итеп уйнавы һәм комсоргыбыз булуы истә калган. Тыныч табигатьле булганлыктан, ул җитәкчелек иткәндә, кафедра һавасы әйбәт булды. Бергәләшеп, аның мөхәррирлегендә «Әдәбият белеме сүзлеге» (1990) чыгардык. Минем исә «Шигърият дөньясына сәяхәт. Фольклордан язма шигырьгә күчеш тарихыннан» (1999) дигән силлабик һәм гаруз шигырь төзелешләрен тикшергән монографиям басылып чыкты.

Аннары безгә Хатыйп Миңнегулов җитәкчелегендә эшләргә туры килде. Ул әле кафедрада эшли генә башлаган чорда гаиләсе белән, ә мин аспирантурада укыганда, университетның беренче тулай торагында (Кызыл Позиция урамы) өч ел буена бергәләп яшәдек. Бер-беребезгә йөрешеп, дуслашып киттек. Ул кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң да дустанә мөнәсәбәтләр дәвам итте. 1977 елда әлеге диссертациягә нигез булган Сәйф Сараи турындагы китабын «Марсель дуска» дип язып бүләк итте. Докторлыкка нигез булган китабына (1993) язган багышлама текст та: «...кылган игелекләрең өчен янә бер мәртәбә рәхмәт белдерәм», дигән ихлас сүзләр белән тәмамлана иде.

«Кылган игелекләрең өчен» дигәндә, мөгаен, минем иң яхшы фәнни хезмәтләр өчен университет премияләре бирү комиссиясендә факультет вәкиле буларак катнашып һәм ялкынлы чыгыш ясап, Хатыйпка (автордашы – Ш.Садретдинов) XIX йөз татар хрестоматияләрен анализлаган һәм шул чорның ике шагыйре (Шәмсетдин Зәки, Әбелмәних Каргалый) шигырьләрен, нигездә, текстологик яктан тикшергән ике зур булмаган китаплары өчен беренче премияне алдыруга ирешүемне дә күздә тоткандыр. Шулай ук бүлекнең партгруппа җыелышында дилбегәне үз кулында тотучы деканыбыз Хатыйпның яңа парторг булып яңа срокка сайлануына кискен каршы чыкканда, минем аны партбюро исеменнән яклап калуымны да әле онытмаган булгандыр. Ул чакта мин факультет партбюросы әгъзасы идем һәм декан: «Миңнегулов үзен эре тота, басым ясарга ярата, башкалар белән исәпләшми», – дип сөйләвенә һәм аны алыштырырга тәкъдим итүенә карамастан, мин: «Партбюро Миңнегуловны кабат парторг итеп калдыру ягында», – дип, ялганга бардым.

Янә килеп, Хатыйпның: «Мин сездән алдарак яклап, күтәрелеп киттем. Ничектер, уңайсызрак миңа», – дигән үзен кечелекле тотып әйткән сүзләре дә истә калган. <...>

Ел йомгакларына багышланган фәнни конференциядә докладымны иң борынгы шигырьнең нинди булганлыгына мөнәсәбәтле күзәтүләремә һәм табышларыма багышладым. Моңарчы шигырь белгечләреннән немец галиме Б.Фабо һәм рус галиме В.М.Жирмунскийның, иң борынгы шигырь ике юллык булган, дигән карашы киң таралган иде. Мин, бу фикер белән килешмичә, иң архаик шигырь формасы кат-кат кабатлауга нигезләнгән бер юллык булган, дигән караш белән чыктым. Бу карашымны мин төрле борынгы халыклардан, шул исәптән Миклухо-Маклайның Гаити утрауларында яшәгән кыргый кабиләләр иҗаты турындагы күзәтүләренә һәм

мисалларына таянып ясадым. Иң борынгы синкретик иҗат төренә хас булганча, үсеш ягыннан түбән дәрәҗәдә торган халыкларда һәм кабиләләрдә бер үк юлны туктаусыз кабатлый-кабатлый җырлау ысулының уртак булуы һәм киң таралганлыгы ачыкланды.

Өстәвенә миңа хәтта шушы ук канунга корылган архаик эпос яралгысына юлыгырга да насыйп булды. Яңа Гвинеядә (Африка) яшәгән «киваи» кабиләсеннән язып алынган мифологик эчтәлекле, нибары 16 юлдан торган әлеге эпик текст, сәяхәтченең аңлатуынча, хор белән башкарылган. Бер юлы кат-кат җырлангач – икенчесенә, аннары өченчесенә күчелгән. Моңа һич тә гаҗәпләнергә кирәкми. Тормышта күп нәрсәләр, хәтта дөнья яратылу да Бердән башланган. Мин конференциядәге чыгышымда шундый мисалларга нигезләнгән ачышымның турыдан-туры шигырь төзелешенә кагылганлыгы, иң борынгы строфа формасы булганлыгы турында сөйләдем. Ары таба шигырь төзелешенең шул бер юлга тора-бара янә бер яки күп юллар өстәлү юнәлешендә үсеп киткәнлегенә басым ясадым. Конференцияне алып баручы Хатыйп исә мин мисалга китергән берьюллыкларның шигырь яралгысы булуы белән килешмәде: «Бер юллык шигырь бармыни?!» – дип, каршы чыкты. Мин күрәләтә ачышымны күрмәмешкә салышуы, хәтта кистереп инкарь итүенә нык хәтерем калып, аудиториядән чыгып киттем.

Бу гыйбрәтле маҗараның ахыры кызык булып бетте. Шактый вакыттан соң кафедра җыелышында Хатыйп безнең игътибарыбызны Валерий Брюсовның «О-о, закрой свои бледные ноги» дигән бер юллык шигыренә юнәлтте һәм шагыйрьнең моны үзе «поэма» дип тамгалаганлыгын әйтте. «Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына» дигән бит. Җай чыгудан файдаланып, мин моның авызын капладым:

– Син онытмадыңмы әле: мин теге вакытта доклад ясаганда, «бер юллык шигырь була алмый» дип, миңа каршы чыккан идең бит, – дип ярып салдым.

Ничек кенә булмасын, мин Хатыйпка 60 нчы еллардан бирле хәерхаһлы мөнәсәбәттә. Үзе теләмәгәч, һичкайчан аның белән дустанә мөнәсәбәтләрне кире кайтаруга дәгъва иткәнем булмады. Дөресен әйтим: үзем дә төшеп калганнар исәбендә йөрмәсәм дә, мин аның гаҗәеп дәрәҗәдә игътибарны җәлеп итә торган тынгысыз табигатен хөрмәт итеп, вакыт-вакыт «ак көнләшү» кичереп яшәдем. Бигрәк тә миңа аның терекөмеш кебек үтә җанлы, актив холкы-фигыле, итальян композиторы Джоакино Россини операсындагы кебек, «Фигаро здесь, Фигаро там»га охшап, һәркайда өлгереп яшәгәнлеге ошый. Энергиясе кимегәнгә түгел, ә яше җиткәнгә Хатыйпны алыштырган һәм аннан соңгы елларда кафедрабызга җитәкчелек иткән галимә – Тубыл педагогия институтыннан килгән профессор Флёра Сәгыйть кызы Сәйфуллина. Аның кул астында эшләгәндә һәм параллель рәвештә республика Традицион культураны үстерү үзәгендә (директоры Фәнзилә Җәүһәрова иде) халык иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнгәндә, русчага тәрҗемә иттереп һәм монография итеп тулыландырып, университет һәм үзәк грифы белән «Татарский фольклор» (2020) дигән китабымны чыгардым.

Моннан тыш, университет тарафыннан оештырылган «Филология и культура» дигән ВАК («Высшая аттестационная комиссия») һәм «TATARICA» журналларында әдәбият һәм фольклор темаларына караган яңа эзләнүләрем дөнья күрде. Шулай ук Казакъстанда шигырь белгече, академик Зәки Әхмәтовның фәнни эшчәнлегенә багышланган халыкара конференция җыентыгында «Иң борынгы шигырь нинди булган?», «Фольклор шигыре һәм аның төрләре» исемле ике докладым текстлары басылып чыкты (Астана, 2013). Күренекле төрки шигыре белгеченә арналган бу зур конференциядә без фәкыйрегезнең текстлары турыдан-туры шигырь теориясенә һәм төзелешенә караучы бердәнбер материаллар иде. Бу – әлеге проблема белән шөгыльләнүче әзерлекле белгечләрнең юк дәрәҗәсендә икәнлеген күрсәткән игътибарга лаек факт.

***

Татар филологиясе бүлеге тормышымда һәм аерым студентлар язмышында зур роль уйнаган «Әдәби сүз» стена газетасына аерым тукталасы килә. Бу – заманында бүлекнең беренче студентлары булган Мәхмүт Хөсәен, Фазыл Фасиев, Гариф Ахунов, Ибраһим Нуруллин кебек олпат затларыбыз тарафыннан оештырылып чыга башлаган газета. Аның ничәмә еллар буена яшь талантларга чирканчык алырга мөмкинлек биргән, машинкада басылган өйрәнчек һәм тәүге әсәрләре белән башкаларны таныштыручы мәйдан хезмәтен үтәгәнлеге күпләребезгә билгеле.

Без аспирант булып килгән дәвердә «Әдәби сүз» университет күләмендә өченче урынны били иде. Ул факультетыбызда рус телендә чыгарыла торган «Ленинское знамя» дигән газетадан калыша иде. «Әдәби сүз»нең мөхәррире итеп билгеләнгәч, журналистлык тәҗрибәсен файдаланып һәм талантлы студентларны җәлеп итеп, без аны акрынлап беренче урынга чыгардык. Мин мөхәррирлек иткән төрле елларда Азат Ганиев, Мөдәррис Вәлиев, Мәхтүм Мостафин, Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Нәҗип Исмәгыйлев кебек талантлы һәм киләчәктә зур юлга чыгачак студентлар бу газетаның бизәлешенә, шрифтларының матур итеп язылышына һәркайсы кабатланмас һәм үзенчәлекле өлешен керттеләр.

Менә шулай яратып, йөрәк җылысын кушып чыгарылганга күрә дә безнең газета «Кожевник-меховщик»лар клубында Совет районы буенча үткәрелгән стена газеталары ярышында беренче урынга чыкты. Шуннан соң берничә ел үткәч, Педагогия институтының «Поле Ершова» урамында урнашкан спорт залында вуз стена газеталарының шәһәр күләмендәге бәйгесе оештырылды. Зур зал идәненә һәр институтның өчәр газетасы җәеп салынган иде. Төзелеш институты (КИГС), КАИ студентлары тарафыннан чыгарылганнарында оста куллар белән ясалган рәсемнәр барыбызның да игътибарын җәлеп итеп, үзенә тартып торды.

Ләкин комиссия әгъзалары газеталарның күзгә чалынып торган аерым урыннарына гына түгел, ә аларның гомуми сыйфатына, бербөтен буларак нинди тәэсир калдыруына игътибар иткәннәр. Шул исәптән материалларның тематик төрлелеге һәм ничек урнаштырылулары белән дә кызыксынганнар. Язган ризык теш сындырып булса да керә, дигәндәй, шул күпсанлы газеталар арасында, безнеке, җиңеп чыгып, беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

Тагын бер житди чара белән бәйләнешле мәгълүмат та билгеле булсын. Республикабызның гербы һәм флагы проектларын тикшерү һәм кабул итүгә багышланган Дәүләт Советы сессиясенә без Нәҗип Исмәгыйлев белән минем идея һәм композиция буенча эшләнгән үз герб проектыбызны тәкъдим иткән идек. Һәм ул Президентыбыз М.Шәймиевкә дә, шулай ук Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшинга да ошаган иде. Расланырга һәм кабул итәргә аз гына тавыш житми калды. Сәбәбе, сизенүемчә, венок эчендә ясалган Сөембикә манарасы очындагы ярым ай билгесе булды сыман.

## Тарихи темага һәм русча да язуга күчү

Мөхәммәт пәйгамбәрнең: «Бишектән ләхеткәчә гыйлем өйрән», дигән хәдисе бар. «Гыйлем» дигәндә, монда дини генә түгел, ә дөньяви белемнең дә күздә тотылганы, минемчә, шиксез. Минем моңарчы дөньяви фәнни эшчәнлегем, аерым чыгарылмаларны исәпкә алмаганда, төп өч өлкәдә барды: шигырь теориясе һәм шигырь төзелеше; фольклор һәм халык иҗаты жанрлары; борынгы һәм урта гасырлар төрки-татар поэзиясе. Бу очракта мин хәзерге җанлы әдәби процесста даими рәвештә катнашып һәм аерым шагыйрьләр, прозаиклар иҗаты, аларның яңа әсәрләре турында вакыт-вакыт рецензияләр язып торганлыгым турында сүз алып бармыйм, билгеле. Югарыда аталган фәнни өлкәләрне өйрәнгәндә, мин зарури рәвештә теге яки бу күренешнең,

әйтик, шигырьнең яки аерым фольклор жанрларының ничек яралганлыгына үтеп керергә һәм иң борынгы формаларын да тикшереп ачыкларга тырыштым.

Һәм мондый методика аклана да кебек. Белүебезчә, тарихилык принцибы ул объект-күренешнең ничек барлыкка килүен, нинди үсеш этаплары үтүен һәм хәзерге чорда нинди хәлдә булуын ачыклауны күздә тота. Мифларның бәет, мөнәҗәт кебек жанрларның ничек формалашуын, шулай ук шигырь һәм поэзия генезисын архаик чыганакларга һәм һун-гун бабаларыбыз иҗатына бәйләп өйрәнгәч, минем алга тагын да глобальрәк проблема килеп басты: ә төрки кавем һәм төрки тел ничек вә кайда барлыкка килгән соң? Электән фараз рәвешендә кузгатылган (немец галиме Х.Хоммель) һәм шумер-төрки, этруск-төрки тел тәңгәллекләрен өйрәнгән аерым авторларның (Олҗас Сөләйманов, Адиле Айда, Мирфатыйх Зәкиев, Фәрит Латыйпов, Тариел Азертюрк) хезмәтләрен исәпкә алмаганда, төрки этногенезын Алгы Азия һәм Якын Көнчыгышта безнең эрага кадәр берничә мең ел элек яшәгән халыклар фонында иңләп тикшергән хезмәтләр юк. Мондый планда башкарылган тикшеренүләр соралып торганлыктан һәм алар безнең өчен генә түгел, ә башка төрки халыклар өчен дә актуаль һәм зарури булганлыктан, яңа фәнни тикшеренүләремне мин рус телендә язарга булдым.

Турысын әйтим: ошбу күпкырлы һәм моңарчы күпләрнең теше үтмәгән проблемага тотынырга да куркыныч иде. Чөнки фәнни тикшеренү-эзләнүләрне ул тел гыйлеме, фольклор, этнография, культурология, тарих, археология, антропология, генетика кебек төрле фәннәр үзара очрашкан ноктада алып баруны һәм шуларның казанышларына таянып, яңа табышлар белән тулыландырып эш итүне таләп итә. «Бүредән курыккан – урманга бармаган»: глобаль проблема алдында өркеп калмыйча, тәвәккәлләргә туры килде. Һәм, әлбәттә, бу катлаулы проблеманы максатчан өйрәнгәндә һәм концептуаль сөземтәләр чыгарганда, өч айлык стажировкалар вакытында төрле төрки республикаларның башкалаларында һәм Россиянең үзәк шәһәрләрендәге китапханәләрдә иртәдән кичкә кадәр утырып, бөртекләп җыйган материалларның ярдәме искиткеч зур булды. Нәтиҗәдә «Прототюрки: изначальная прородина, ранние племена и язык, история и этнокультура» дигән 463 биттән һәм рәсемле өлешләрен дә кушып исәпләгәндә 31,5 басма табактан торган китап барлыкка килде.

Этнос белгече Ю.Бромлейның: «Милли үзенчәлекләр, барыннан да элек, этник культура өлкәсендә чагыла», дигән характерлы билгеләмәсе бар. Без моның чыннан да шулай икәнлеген милли тел, милли йолалар һәм ышанулар, милли фольклор һәм әдәбият, милли киемнәр һәм милли ашлар, милли биюләр һәм милли музыка мисалларында беләбез. Без фәкыйрегез исә, шушыларга өстәп яки конкретлаштырып, үзебезнең тикшеренүләребездә мифологик ышанулардан килә торган бер башлы канатлы еланны (сазаган, ләү) изгеләштерү, бүрене тотемлаштыру, сул якны – йөрәк ягын олылау һәм киемне дә сул якка эләктерү, көньякка – кояш чыгышы ягына табыну, кавем яки кабилә башлыгы тау куышында яралган дип ышану, ат ите ашау һәм кымыз эчү кебек нәкъ төрки бабаларыбызга хас булган сыйфатларны аерып чыгардык. Этник индикатор ролен уйнаган мондый сыйфатларны этник билгеләр («этнические определители») дип атадык.

Иң мөһиме, ерактан килүче шул билгеләрне бик борынгы, инде үле яки яшәвен дәвам иткән кабиләләргә һәм халыкларга карата кулланып, алар арасыннан иң борынгы бабаларыбыз булгандыр дип уйларга нигез булган этник төркемнәрне аерып чыгардык. Ахыр килеп, ошбу гоманыбызны тагын да куәтлерәк этник индикатор – архаик тел фактлары белән дә ныгытуга һәм раслауга ирештек.

Аерым алганда, борынгы язма чыганакларда теркәлгән тел фактларына һәм ерактан килүче җанлы сөйләм күрсәткечләренә таянып, Якын Көнчыгыш һәм Алгы Азиядә (хәзерге Гыйрак, Сүрия, Иран, өлешчә Төркия биләмәләрендә һәм, күченеп, Төньяк Африка территориясендә) яшәгән һәм дә үзебез аерып чыгарган үле һәм архаик кабиләләр сөйләшкән телләрдәге байтак сүзләрнең хәзерге төрки телләрдә дәвам

иткәнлеге, аларның лексикасы белән уртак тамырдан булганлыгы ачыкланды. Без берәмләп җыйган шундый бик борынгы сүзләрдән торган, без фәкыйрегез тарафыннан реконструкцияләнгән чагыштырмалы лексик-семантик һәм өлешчә этимологик сүзлек хәзерге вакытта меңнән артык берәмлекне берләштерә. Аларның шактый өлеше асылда, әлеге сүзләр теркәлгән телләрнең граматик төзелешен дә кертеп, төрки баба телнең нинди регионда һәм нинди агглютинатив телле кабиләләр катнашында яралганлыгын чагылдыра. Төрки этногенезы турында глобаль характердагы мәсләгем, гомуми рәвештәрәк шәрехләгәндә, менә шундый.

Шушы мәсләгебезнең җитдилеген, нигезле булуын раслый торган бик тә борынгы гасырлар чоңгылыннан килгән тел фактларының кечтеки генә өлешен булса да күрсәтеп китик. Иң башта килеп чыгышларына, этимологияләренә махсус тукталмыйча теркәлгән аерым сүзләр: ат/атан – ишәк > ат | еш / ешә – ишәк | зрк / зар – сарык | барра / барро – бүре | прас – барс +юлбарыс | тавш-ала – табышган (бор.төрки) – куян | клн / калла – килен | куда – кода | буд/будат – орлык, бодай | тал/талә – агач, тал | балл /пулут – болыт | кут/куд/куот – рух, җан саклаучы илаһ | кик/кок – күк | к-н/г-н – көн/ кояш > көнбатыш һ.б.

Ә болары – нинди әйбернең мәгънәсен-аталышын (этимологиясен) белдерүдән башланган һәм ары таба нинди эволюцион объект-мәгънә үзгәрешләре яралуын күрсәткән сүзләр: сак – җирне чокып орлык утырту өчен башы очланган таяк > кәтмән, матыйк > кәтмәнләү-ск сак/сака – җир эшкәртү, сөрү > сөрү>сука – агач сабан һ.б. һаба – кәтмәнләү, матыйклау, сөрү >сабан – плуг | ка/кап – яфраклардан ясалган савыт > кабак/ка+бак – (бак – тыква) кабактан ясалган савыт...казан/ ка+зан – (зан, зон, чон–кабилә) кабилә савыты > кап – юкәдән үреп ясалган «савыт» | кул – рука, төп эш коралы>культура – кул катнашлыгында нәрсәләрнедер эшкәртү, ясау һ.б. >культиватор – кәсләрне ваклап, җир йомшарта торган машина.

Кеше тарафыннан ясалган бөтен җисми әйберләр, белүебезчә, матди-материаль культурага, ә материаль булмаган, кеше тудырган объектлар – тел, фольклор, әдәбият, мораль-этик нормалар исә рухи культурага керә. Ә «кул» сүзе исә – борынгы бабаларыбыз чыккан Алгы Азиядә барлыкка килгән борынгы уртак сүз. Менә шуңа күрә дә мин үзебез шул яктан алып килгән сүз катнашлыгында ясалган «культура» сүзеннән баш тартып, «мәдәни» дигән сүз куллануга күчүебезне хата дип исәплим. «Мәдәният» сүзе ул асылда «цивилизация» дигән мәгънәгә туры килә. Анатолий төрекләре бик дөрес эшләгәннәр: алар үзләренең сөйләм һәм әдәби телләрендә «культура» сүзен саклап калганнар.

Безнең карашыбызча, протөрки катламына караучы борынгы халыкларның баш идарәчене, хөкемдарны белдергән титул-атамаларында да Алгы Азиядән башлангыч ала торган кардәшлек, күчемлелек күзәтелә. Мәсәлән, шундый атамаларның бер тармагы: мидия, дравид телләрендә – сан-ги, Туран түбәнлегендә Герат исемле идарәченең титулы – сан-аб, сакларда – сон/саон, һуннарда атаманың кытайча бирелеше шань-ю/ шан-юй, төркиләрдә – хан. Күренүенчә, хаким-хөкемдарның ерак бабаларыбыз яшәгән төрле регионнардан һәм төрле чорлардан күчеп килгән атамаларның тамыры асылда уртак: сан > сон > шон > шан > хан. Бары авазлар гына чиратлаша.

Йомгак ясап әйткәндә, Якын Көнчыгыш ареалы казанында кайнап чыккан прототөрки бабаларыбызның варислары телендә бихисап күп архаик сүзләрнең, күп чорлар аша үтеп, эстафета рәвешендә килеп җиткәнлеген мин бәхәссез һәм бик табигый дип исәплим. Чөнки төрләнгәндә сүзнең тамыры үзгәрә торган флектив (день-дни, рост-расти) табигатьле һинд-европа телләреннән аермалы буларак, агглютинатив характердагы төрки телләрдә сүз тамыры үзгәрешсез кала, бары кушымчалар ялганган өлеше генә үзгәрешкә дучар була. Димәк, вакыт сынавына бирешмәгәнлектән, чал гасырлар тирәнлегеннән килгән сүзләр дә тотрыклы саклана.

Яңа концепциягә һәм өр-яңа табышларга корылган ошбу хезмәтемне фән һәм

культура җәмәгатьчелеге хуплап каршылады. Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гамирҗан Дәүләтшин, тюрколог, тарих фәннәре кандидаты Рафаэль Мөхәмәтдинов һәм Америкада яшәүче тюрколог, биохимия фәннәре докторы Тариел Азертюркның китапка югары бәя биргән рецензияләре басылып чыкты. 100гә якын чөй язмалы шумер-сувыар текстларын төркичә укыган ошбу Америка галиме үзенең рецензиясен болай тәмамлый: «Хочется особо отметить, что удивляет терпение и выносливость автора этого фундаментального творения – немолодого уже исследователя, но мудрого и многостороннего специалиста. Ориенталистика ждала именно такого рыцаря науки, талантливого тюрколога, как профессор М.Бакиров».

***

Моннан соң без фәкыйрегезнең тарихи темага язылган, 28,5 табак күләмендәге «Тайны происхождения наших предков» дигән монографиясе узган 2022 елның өченче кварталында дөнья күрде. Аннан алдагы этногенезы һәм этник вә этнокультура тарихы турындагы «Прототюрки...» исемле монографиямнең дәвамы рәвешендә язылган бу хезмәт Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгын бәйрәм итү көннәрендә чыгып өлгерергә тиеш иде. Чөнки китабымның күпчелек өлеше болгар кавеменең һәм болгарлар белән бер төркемгә кергән хазар, сувар, барсил, бәҗәнәкләрнең кавем-этнос буларак яралуын, янә телләренә хас үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлана. Шул исәптән яңа фактларга нигезләнеп һәм үзәккә алып, чувашларның һәм тел ягыннан алардан кискен аерылып торган, өстәвенә, ислам динен кабул иткән болгар-татар бабаларыбызның болгар кавеменә мөнәсәбәтләре тикшерелә. Татар теленең, чувашлардан аермалы буларак, ике төрле аңлаешлы сөйләшкә нигезләнгән болгар кавеменең акрынлап кыпчаклашуы һәм көнчыгыштан үтеп кергән уйгур-угыз төркемнәре белән кушылуы җирлегендә формалашуы исбатлана.

Әмма яңа монографиям дин кабул ителү юбилеена чыгып өлгерә алмады, гәрчә кульъязма текст нәшриятка 2020 ел азагына ук тапшырылган булса да.

Бу китабымны да белгечләр күтәреп алдылар. «Звезда Поволжья» газетасында академик Индус Таһировның, «Мәдәни җомга»да академиябезнең мөхбир-әгъзасы Фаяз Хуҗинның уңай рецензияләре басылып чыкты. Турыдан-туры болгар мирасын өйрәнүгә мөнәсәбәтле соңгы авторның бәяләмәсеннән шуны раслый торган бер өзек китерик: «Аның бу китабын мин, Идел болгарлары археологиясе белән шөгыльләнүче галим буларак, бигрәк тә кызыксынып укып чыктым, чөнки автор биредә күбрәк болгар, хазар, барсил, савир/сувар телләре турында сүз алып бара, бик тә бәхәсле болгар һәм чуваш телләренең үзара мөнәсәбәтенә, чувашларда болгар мирасы мәсьәләләренә дә киң туктала. Автор күтәргән проблемалар, ул проблемаларны чишүгә юнәлдерелгән яңа фактлар, шул фактларны анализлау нәтиҗәсендә туган гоман-фаразлар, моңарчы аз билгеле булган чыганаклар белән расланган төпле фикерләр телче һәм тарихчы галимнәрнең генә түгел, ә милли тарихыбызга битараф булмаган киң катлам укучыларыбызның да игътибарын җәлеп итәр, дип уйлыйм».

Һич тә мактанып түгел, ә Аллага шөкер, дип әйтәм: рус телендә нәшер ителгән монографияләрем дә, шулай ук аңа кадәр дөнья күргән татар телендәге китапларым һәм 600дән артып киткән әдәби-тәнкыйди характердагы, шулай ук культура мирасы һәм этнос проблемасына кагылышлы мәкаләләрем дә – барысы да уңай, хәтта югары бәя алдылар. Ә хезмәтләремнең фәнни дәрәҗәсен төшерергә, димәк, авторны батырырга исәп ителгән үчлек һәм көнчелек омтылышлары исә җиңелүгә дучар булды. Мәдәният министрлыгы тарафыннан үткәрелгән «Елның иң яхшы китабы» бәйгесендә этногенез, шулай ук этник һәм этнокультура тарихына багышланган китапларым – икесе дә беренче урынны алды.

Әгәр миннән: «Фәнни эзләнү-тикшеренүләреңнең уңышлы чыгуының сере нәрсәдә?» – дип сорасалар, ике дә уйламыйча: «Системалы фикер йөртүдә һәм

гомум рәвештә танылган, дөрес дип саналган нәрсәләргә дә шикләнеп карауда», – дип җавап бирер идем. Француз философы Декарт (XVII йөз), танып белү гомум рәвештә хакыйкать дип таныган, икърар ителгән бөтен гыйлемгә шикләнеп караудан башланырга тиеш, дигән, минемчә, бик дөрес мәсләктә торган.

Язган китапларымда мин А.Веселовский, Л.Гумилёв, Г.Поспелов, С.Кляшторный кебек танылган башка галимнәр белән дә фикер көрәштереп, аларның теге яки бу мәсьәләгә кагылышлы карашларын яки нәтиҗәләрен кире кага торган үз фәнни нәтиҗәләремне яки нык дәлилләнгән альтернатив тикшеренүләремне тәкъдим иттем.

Мәсәлән, мине, кыскача итеп әйткәндә, А.Веселовскийның поэзиянең яралуын эштән соң ял иткәндә башкарылган «синкретик хор»га гына бәйләп каравы, хезмәтнең үзенчәлекле дәвамы булган йолалар (материаль алшарт) һәм мифология (рухи яки идеяви-сәнгати алшарт) берлеген – «йола-миф синкретизмы»н тану югарылыгына күтәрелә алмавы канәгатьләндермәде. Мәскәү университеты профессоры Г.Поспеловның исә мифологияне, тирәлекне танып белергә омтылу һәм кырыс тирәлеккә ярашу функцияләрен урап үтеп, борынгыларның томаналыгы, көчсезлеге «продукты», өстәвенә, «бөтен иң борынгы иҗат үрнәкләрен дә (йола җырлары, биюләр, ташсыннар, кыяга яки тау куышына ясалган рәсемнәр), үзе дә сизмәстән, табигатьнең билгесез көчләре алдында куркып калу һәм баш иеп яшәүгә, кыргыйлык һәм аңсызлык нәтиҗәсенә» кайтарып калдыруы белән мин катгый рәвештә ризалашмадым.

Ә менә исеме алда аталган С.Кляшторныйның искергән чыганакларга таянып, һун-гун бабаларыбызны һәм борынгы төркиләрне физик-антропологик яктан монголоидлар булган дип караган, без каршы чыккан хата карашы хәтта күптән түгел нәшер ителгән «Татар тарихы»на («История татар», К., 2002, с.130-132) үтеп кергән. Шушы ялгыш фикергә ышанып без, татарлар, үзебезне монголоидтан европеидка күчкән халык дип исәпләргә тиеш булабыз. Бу караш искергән, дөрес булмаган методикага корылган антропологик тикшеренүләргә нигезләнә. Чөнки Алгы һәм Якын Көнчыгышта формалашкан бабаларыбыз европеид кыяфәтле булганнар һәм, киресенчә, аларның бер өлеше Туран, Кавказ аша Үзәк Азиягә, шулай ук Себер якларына үтеп керү һәм шунда күп гасырлар буена монголид кабиләләр белән аралашу нәтиҗәсендә генә үзләренең кыяфәтләрен үзгәрткән. Без үз хезмәтебездә абруйлы антропологларның Кляшторный игътибарыннан төшеп калган тикшеренүләренә таянып, менә шушы хакыйкатьне расладык, димәк, бәхәсләшеп, дөреслекне өскә чыгардык.

## Дөнья дуслар белән бара

Синең белән фикердәш һәм кирәк чакта ике дә уйламыйча ярдәмгә килә торган дуслар сирәк була. Үзен аямаучы һәм мине аңлаучы андый фигыльле иң беренче дустым – Иске Вәрәш авылында укыганда, классташым булган Ирхәт Галиев иде. Такташ әйтмешли, без аның белән «ике малай, дөнья белән танышып йөргән идек бергәләп». Кызганычка, ул урып-җыю вакытында эшләгәндә икмәк суктыру машинасына кысылып үлде.

Ә Мөслимгә күчеп килгәч, мин бишенче класстан унынчыга тиклем, димәк, алты ел буена, Индус Фәтхуллин исемле классташым белән бер партада утырдым. Математикадан авыр мәсьәләләрне аның белән бергәләп чишә идек, спектакльләрдә дә уйнадык, бергәләп танцыга һәм кызлар артыннан йөрдек.

Аннары инде мин университетка, ә ул КАИда укыган елларда, бигрәк тә стипендия алмаган чакларында, вакыт-вакыт ул минем янга – тулай торагыбызга килеп йөрде. Гаиләләре ишле булганлыктан, аңа өйдән ярдәм бик чамалы иде. Шуңа күрә барлы-юклы акчамны бүлешеп, мин аны ашханәгә алып керә идем. Ә кайбер көннәрдә ул хәтта куна кала – башларыбызны икебез ике якка куеп, минем караватта йоклый идек.

Менә шушы дуслык соңыннан аның тарафыннан сынау үтә алмады, ялганга,

ярашуга корылган әшнәлек булып чыкты. Мондый үзгәреш яки алмашыну мин аспирантурага килгәч билгеле булды. Мин Уфада яшәгән чорда ул бик уңышлы карьера ясаган, заманында «ужас» белән «ужасный» сүзләрен дөрес итеп укый белмәгән егетебез русча бик шома сөйләшергә өйрәнеп, акрынлап күтәрелеп киткән. Вертолёт заводында үзен техник яктан әзерлекле инженер итеп күрсәткән, оештыру сәләте аркасында шул ук заводта, аннары Киров районында комсомол комитеты секретаре итеп үрләтелгән. Һәм мин килер алдыннан, 1965 елда, сайланып, шул ук район башкарма комитеты рәисе дәрәҗәсенә ирешкән. Казанга килеп, студент чагымда яшәгән беренче тулай торакка урнашкач, бу мине тыны белән тартып алырдай булып сөйләшер инде дип өметләнеп, аңа шалтыраттым.

– Индус, исәнме?!

– Кто это?

– Бу синең яшьлек дустың – Марсель.

– Как ты оказался здесь?

– Мин аспирантурага укырга килдем. Очрашасы иде, – дим.

– Добре, добре. Позвони завтра в конце рабочего дня, – диде дә сөйләшүне өзде бу.

Икенче көнне баргач, рәисебез кереп-чыгып йөргән кыска итәкле секретарена кат-кат кемнәр беләндер тоташтырырга кушып, алдында тезелеп торган телефоннарының әле берсе, әле икенчесе аша сөйләште. Аннары, аңлавым буенча, өлкән яшьләрендәге торак бүлеге башлыгын чакыртып һәм гаепле малай кебек каршына бастырып, тетмәсен тетеп алды. Кыскасы, элекке дустым минем алда зур дәрәҗәле түрә булып китүен гәүдәләндерә торган тамаша уйнап күрсәтте. Өенә алып кайту яки каядыр кереп утыру кебек гамәл булмады. Өченче кеше итеп чакырылган, чишелеп сөйләшергә комачаулаган ниндидер танышы белән якындагы агачлыкта тукталып, бер яртыны сындырдык та таралыштык. Кабаттан очрашу турында ни ул, ни мин сүз кузгатмадык.

Шул очрашудан соң бер ел үткәч, моны тагын да югарырак урынга – Азык-төлек промышленносте министры итеп үрләтүләре мәгълүм булды. Диссертациямне машинкада бастырырга кибетләрдә сыйфатлы кәгазь булмаганлыктан, ике елдан соң янә моңа мөрәҗәгать итәргә туры килде. Бу юлы ул тагын да битәррәк эреләнгән, кабинетындагы үзенә кадәрге мебельне алмаштыру белән генә чикләнмичә, үзе дә танымаслык дәрәҗәдә алышынган, кеше буларак нык үзгәргән иде.

Студент вакытта якыннан аралашкан дустымның бер тулай торакта яшәгән Әгерҗе егете Юныс Әминов булганлыгы турында мин алда әйттем инде. Ул гел «бишле»гә генә укыды. Философиядән «дүртле» билгесе алгач, озак тынычлана алмыйча йөрде. Диплом алыр алдыннан имтиханын кабат тапшырып, әлеге билгесен «бишле»гә төзәтте. Бик тырыш, үз-үзенә карата гаҗәеп таләпчән егет иде ул. Мин Уфада вакытта мәдәният министры урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелүенең сәбәбен мин шунда күрәм. Аның дәвамчысы булган, Татарстан телерадиокомпаниясенең башлыгы, ә соңгы елларда «Татарстан–Яңа гасыр» компаниясенең генераль директоры булып эшләүче улы Илшат Әминовны мин кыяфәте белән генә түгел, ә үтә таләпчән булуы, эшен менә дигән итеп башкаруы ягыннан да этисенә охшатам.

Аспирантурада укыганда уртак тел табып, дуслашып киткән танышым – Хөсәен Локманов. Ул минем кебек үк гаиләле, Уфадан килгән булып чыкты. Аның белән тулай торакта, кара-каршы бүлмәләрдә ут күршеләр булып яшәдек. Тарихчы, университет профессоры Я.Шарапов җитәкчелегендә 20 нче елларда Башкортстанда рәсми рәвештә уздырылган милли чаралар һәм гамәлләр турында диссертация язды ул һәм бик уңышлы яклады. Соңыннан, пенсиягә чыкканчыга кадәр, Уфа университетында тарих фәнен укытты. Хатыны Халисә исә педагогия институты укытучысы иде, күп еллар буена чит телләр факультетының деканы булып эшләде. Алар белән безнең гаилә бүген дә дустанә мөнәсәбәттә, үзара бәйләнештә.

Хәзерге вакытта исеме күпләргә билгеле булган галим, педагог һәм шагыйрь

Әнвәр Шәрипов белән дә мин беренче башлап университет тулай торагында яшәгәндә таныштым. Мин укуымны тәмамлаган елны (1969) аның да аспирантурага кергәнлеге һәм җитәкчесенең уртак остазыбыз Хатип Госман икәнлеге билгеле булды. Таныш-белешләренә һәм, гомумән, башкаларга карата да гаҗәеп дәрәҗәдә игътибарлы мөнәсәбәттә булуын, үтә дә гадилеген, эчкерсез, беркатлырак табигатен үз итеп, аралаша-аралаша, мин моның белән дуслашып киттем. Аның кешелекле, игелекле мөнәсәбәте төрле шартларда сыналды һәм иң мөһиме, чын дус булуын ул кирәк чакта ярдәмгә килә белүе белән кат-кат раслады. Алабуга һәм Чаллы педагогия институтларында укытучы һәм кафедра мөдире булып шактый еллар эшләгән Әнвәр Мәгъдәнур улы хәзерге вакытта пенсиядә, әмма фән һәм иҗат белән шөгыльләнүен дәвам итә.

***

Әлбәттә инде, үзем кебек үк Мөслим районында туып-үскән дусларым да бар минем. Шундыйларның берсе – Шолохов кебек авыл җирендә, Мөслимнең үзендә торып иҗат итүче, хәзерге көндә «Татарстанның халык язучысы» дигән мәртәбәле дәрәҗәгә ирешкән Фоат Садриев. Китап укучылар аны кабатланмас һәм бай иҗаты өчен яраталар, ә мин, шулар өстенә, Фоатны мөрәүвәтле табигате, искиткеч ярдәмчеллеге, шатлык һәм борчуларыңны уртаклаша белә торган тугрылыклы дус булганы өчен яратам, нык хөрмәт итәм.

Менә ничәмә ел инде район Сабан туена кайткач, ул мине туганнарыма түгел, ә үз өйләренә төшерә, өстәлләрендә сыгылып торган милли ризыклар белән кунак итә. Аның күптән түгел генә вафат булган хәләл җефете Сәйденур ханым да – урыны җәннәттә булсын – үзе кебек үк, ихлас күңелле, үтә кунакчыл кеше иде. Фоат мине ел да диярлек үзе туып-үскән һәм әтием кулга алынгач, безнең гаилә дә сыену урыны табып, яшәп алган Олы Чакмак авылына алып кайта. Ә миңа 85 яшь тулган елны шушы авылның Сабан туенда көлеп сөйләрлек һәм, әлбәттә инде, кеше ышанмаслык хәл булды. Яшь чагымда җае туры килгәндә кул көрәштергәнемне белеп, Фоат, кыстый-кыстый, мин-бабагызны мәйданга кул көрәштерергә чыгарды. Нәселдән килгән галәмәттер инде, 5-6 ир-егетне җиңгәч, «кул көрәше, беренче урын» дип язылган зиннәтле бүләкне миңа бирделәр, әй. Юри оештырылган хәл бу, дияр идең, җиңелүчеләр арасында армиядән кайткан егетләр һәм хатыннары «шул бабайга бирешәсеңме?!» дип үртәп-оялтып торган ирләр дә бар иде.

Икенче якташ һәм бик якын дустым – Татарстанның Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган табибы, хирург Равил Шәймәрданов. Аның Казанда төрле җаваплы эшләрдә (медицина академиясендә проректор, кичектергесез хирургия кафедрасы мөдире, шәһәр күләмендә баш хирург һ.б.) эшләгәнлеген, шулай ук үзебезнең республикада һәм чакыру буенча илебезнең төрле төбәкләренә барып ясаган санап бетергесез операцияләрен исәпкә алып, мин үзем аны «суперхирург» дип атыйм. Аның чыннан да атаклы табиб булуы һәм үз өлкәсендә җитди фәнни ачышлар ясаганлыгы – бәхәссез. Без Равил белән вакыт-вакыт күрешеп торабыз. Очрашсак, сөйләшеп туя алмыйбыз. Арттырып әйтмим: аның белән теләсә нинди темага гәп корып, чишелеп сөйләшеп була. Чөнки ул бар нәрсә белән дә диярлек кызыксына торган, төрле өлкәләрдән хәбәрдар шәхес. Моңа ышану өчен аның бай шәхси китапханәсендә тупланган китапларның күплегенә һәм төрлелегенә игътибар итү дә җитә. Алар арасында Равил үз кулы белән туган авылы Ташлыяр һәм аның кешеләре турында язган «Ташлыяр авылы архивыннан сәхифәләр» дигән саллы китап та күзгә чалынып тора.

Университетның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында – үзем бүгенге көндә өлкән гыйльми хезмәткәр вазифасында эшемне дәвам иткән һәм диссертацияләр яклау советында әгъза булып торган уку йортында да минем бик

җилле фикердәшем бар. Әдәбият һәм сәнгать әһелләре, киң катлам укучылар аны күпкырлы галимә, әдәбият белгече һәм театр-сәнгать тәнкыйтьчесе буларак beləләр. Әлбәттә инде, мин заманында рус филологиясе бүлеген тәмамлаган, хәзерге вакытта Филология институтының татар бүлегендә укытучы, шул ук институт тарафыннан ВАК статусында нәшер ителә торган «Филология и культура» һәм «TATARICA» журналларының җаваплы мөхәррире, доцент Миләүшә Хәбетдинова турында сүз алып барам. Бик тә татар җанлы, тиктормас һәм үтә кызыксынучан табигатьле кеше булганлыктан, тора-бара ул милли культура-мирасыбызга, милли әдәбият һәм сәнгать дөньясына да шактый тирән үтеп керә алды. Аның халык язучысы Аяз Гыйләҗев һәм «халык академигы» Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивларын берничә ел буена өйрәнеп ирешкән казанышлары – беренчесенең үзе төзегән 6 томлыгына фәнни мөхәррир буларак язган текстлары һәм аңлатмалары, ә икенчесенең тормышы һәм иҗаты турындагы моңарчы күбесе билгесез булган материаллардан төзелгән автобиографик җыентык – үзләре генә дә алтын бәясенә торырлык. Соңгы хезмәтнең рецензенты без фәкыйрегез иде.

Быел август аенда матбугатта Рәисебез Рөстәм Миңнехановның фәнни-педагогик эшчәнлегебез, фәндә һәм мәгариф системасында ирешкән казанышларыбыз өчен без фәкыйрегезгә «Дуслык» ордены бирү турында Указы игълан ителде. Бу мәртәбәле дәүләт бүләген юллау, кирәкле документлар әзерләү белән турыдан-туры Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы шөгыльләнгән. Ә «орденга лаек» дигән идеяне күтәрүче һәм тормышка ашыруда «беренче скрипкә» ролен уйнаучы кеше исә институтның директоры Рәдиф Җамалетдинов булган. Мин аларга һәм, әлбәттә, хөрмәтле Рәисебезгә хезмәтемне шулай югары бәяләгәннәре өчен чиксез зур рәхмәтемне белдерәм.

Ә моңа кадәр Рәисебез, Мәдәният министрлыгына «Прототюрки...» дигән зур яңгыраш алган китабымны инглиз теленә тәрҗемә иттерергә кушып, күрсәтмә юллаган иде. Уңай җавап алынуга карамастан, ни сәбәптәндер бу таләп тормышка ашырылмый калды. Мин исә, җитәрлек күләмдә тавыш җыюга карамастан, Дәүләт премиясе бирелүдән гаделсез рәвештә төшереп калдырылгач, кабат документларымны Академиягә илтүдән баш тарткан кебек, бу очракта да министрлыкка барып, ни өчен биргән вәгъдәләрен үтәмәгәннәрен сорап йөрмәдем.

Үзеңне кимсеттермәүгә, горурлыгыңны саклауга ни җитә!

Сүз уңаенда искәртим: «Прототюрки...» дигән масштаблы монографиямнең иң беренче рецензенты – бәяләүчесе, юк вакытын бар итеп укып чыгып, хезмәтнең тюркологиядә, этногенез һәм этник тарихыбызны өйрәнү өлкәсендә зур яңалык икәнен кистереп әйткән компетентлы телче галим Рәдиф Җамалетдинов булды. Шуңа күрә дә «Тайны происхождения наших предков» (К., 2022) дигән аннан соңгы монографиямдә мин аның исем-фамилиясен китапның титул битенә чыгардым, чөнки бу хезмәтемне дә ул кызыклы ачышлардан торган фәнни казаныш дип бәяләде.

«Дөнья дуслар белән бара» дигән халык әйтеменең мәгънәсен мин менә шундый фикердәш шәхесләр һәм сине көндәше итеп күрми торган дуслар белән якыннан аралашып яшәүдә, кайгы-шатлыкларыбызны үзара бүлешеп һәм бер-беребезгә таянып, тормышыбызны нәтиҗәле һәм бәрәкәтле итүдә күрәм. Әгәр 90 еллык гомеремдә мин алда өлешчә булса да берәмләп аталган ниндидер казанышларга ирешкәнмен икән, моның өчен мин, барыннан да элек, әниемә, гаиләмә, һәм әлбәттә инде, остазларыма, теләктәшлек иткән дусларыма, коллегаларыма бурычлы һәм мең-мең рәхмәтле.

Иң ахырда әйтергә теләгән сүзем шул: мин күп еллар буена китапханәләрдә утырып, төрки кавемнең (төркләрнең бабалары, әлбәттә, башка исемнәрдә булган) гасырлар чоңгылыннан килгән чал тарихына һәм культура мирасына караган бихисап күп материаллар тупладым. Якынча булса да системага салып, папкаларга урнаштырдым. Алар җәмгысы – 200гә якын папка. Арада кул тимәгәннәре дә байтак. Гомеремнең чигенә килеп җиткәнлегемне һәм ниятләгән аерым темаларны язарга да вакытым

калмаганын сизенеп, мин «Җаным әрнем яшәп туймаганга...» дигән шигырь чыгардым. Узган гомеремә һәм хезмәт юлыма йомгак ясау рәвешендә язылганлыктан, мин аны тулы килеш тәкъдим итәргә булдым.

## Җаным әрнер яшәп туймаганга

*Кеше үлгәннән соң да*
*өч көнлек эше кала.*
Җеназа йоласы белән
бәйле гыйбарә-әйтем

*Мин китәрмен. Инде туксан миңа,*
*Җир астыннан юл юк, бер киткәч.*
*Мәшәкатем төшәр башкаларга,*
*Ыгы-зыгы тынар эш беткәч.*

*Җаным әрнер яшәп туймаганга,*
*Эшем калганына бүленеп,*
*Эштә яну яшәү рәвешем булды,*
*Яшәдем гел эшкә күмелеп.*

*Олы яшьтәгеләр аңлар мине,*
*Гаепләсә – яшьләр гаепләр.*
*Чөнки сүзем үлем белән бәйле,*
*Әманәтем калсын, дим, мәгәр.*

*Тына алмас бары җаным гына,*
*Җан-рух үлми, дию хак булса.*
*Гүрдә генә ял итәрмен диеп,*
*Әйтә идем дә бит гел юкса.*

*Үлчәп булмый еллар саны белән,*
*Исәп иткән таудай эш кала.*
*Ниятләрне тиздән әҗәл кисәр,*
*Шуңа сыкрый күңел, эч яна.*

*Эстәгән аң-белем мәгарәдә*
*Әбүгалисина – гаян ир.*
*Безнең өчен китап-мирасханә*
*Еллар буе булды шундый җир.*

*Чорлар күмгән тирән катламнарда*
*Энә белән кое казыдым.*
*Эзенә төштем ерак бабамнарның,*
*Чоңгылларда маяк кабыздым.*

*Тик сүтелми кала ахыргача*
*Үзем җыйган серләр йомгагы.*
*Без – фанатик могиканнар, киткәч,*
*Тамчыдан күл ясар кем тагы?!*

*«После меня хоть потоп» түгел миңа,*
*Газиз халкым булсын гомерле.*
*Өзелмәсен милли тамырыбыз,*
*Без соң шуңа лаек түгелме?!*

*Археологлар тапса ят бер чүлмәк,*
*Лаф оралар бу, дип, зур ачыш.*
*Татар соң чүлмәк калдыгымыни?!*
*Халкыма язсын кояшлы язмыш!*

Әйе, милләтебез әле исән, үзенең барлыгын һәм ата-бабадан килгән куәтен һәр өлкәдә күрсәтеп торганда, аның гомере, этник тамырлары өзелүгә юл куелмаска тиеш! Мин фәкыйрегезне шулай ук без шөгыльләнгән һәм бездән кала торган өлкәнең уңышлы дәвам итүе кызыксындыра. Эстафетаны дәвам итүчеләр әлеге өлкәгә караган фәнни объектны – «айсберг»ны өйрәнгәндә, аның өске катламында гына чокчынып ятмыйча, төбенә, тирәндәге катламнарына да үтеп керергә ашкынсыннар иде. Дөньяны шаулаткан безнең төрк кавеменең данлы үткәне, чал тарихы чын-чыннан шуңа лаеклы.

# ШАМИЛ УСМАНОВ: МАТУР ТОРМЫШ ТӨЗҮГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

2023 елның 26 декабрендә Шамил Хәйрулла улы Усмановның тууына 125 ел тула. Кызыл комиссар һәм хәрби җитәкче, Татарстан Республикасын төзүгә зур өлеш керткән сәясәтче, татар совет мәдәниятен тудыруга катнашкан әдип һәм оештыручы... Совет чорында мәктәптә һәм вузда без аны шулай таныдык һәм бәяләдек. Мәктәп программасындагы «Гает корбаны» хикәясе акгвардиячеләрнең кансызлыгын күрсәткән әсәр буларак өйрәнелә иде. Университетта мөхтәрәм остазыбыз Альберт Гатуф улы Яхин безне кабат аның шәхесенә якынайтты: Татарстанда беренче булып радио оештыруын, эсперанто телен популярлаштыручылардан икәнлеген, Казан шәһәрендә, меңләгән катнашучы җыеп, ачык һавада мәдәни чаралар уздыруын, гаепсезгә һәлак ителүен сөйләде. Студентлар тулай торагына кызы Айсылу ханым Сагайдак килеп, әтисе хакында истәлекләр белән уртаклашты. Әмма бу шәхескә кагылышлы күп кенә мәгълүматлар совет чорында әйтелеп бетмәгән кебек, 39 ел гына яшәгән, хәтта кабере дә билгесез Шамил Усмановның тормышы, эш-гамәлләре бүгенге вазгыятьтә дә ничектер ачылып-ачыкланып бетмәгән килеш кала төсле.

### Хаҗи малае Габдулла

Габдулла (Шамил) Усманов 1898 елны Саратов губернасы Кузнецк өязе (хәзерге Пенза өлкәсе Кузнецк районы) Пәндәлгә авылында мөгаллим Хәйрулла Гыйззәт улы гаиләсендә алты малайның икенчесе булып дөньяга килә.

Әтисе Хәйрулла – укымышлы, ачык фикерле, дөнья хәлләреннән хәбәрдар кеше була. Яшь вакытында ул, ерак туганнары фабрикант Акчуриннардан берсенең гозерен үтәп, аның урынына хаҗга бара, юл уңаеннан өч ел Мисыр уку йортларында гарәп телен һәм дин гыйлемен тирәнтен үзләштерә. Хаҗ сәфәреннән кайткач, Пәндәлгәдәге туку фабрикасы мәктәбендә укыта һәм мөгаллим Миндән кызы Гайшәгә өйләнә. Кызыксынучан, актив табигатьле Хәйрулла малайларын ир-егетләр итеп тәрбияләүгә зур игътибар бирә: җәй көннәрендә урманга китеп, палаткалар корып яшәү, револьвердан атарга өйрәтү, мөстәкыйльлек күрсәтерлек өй эшләренә җаваплы итеп кую кебек гамәлләрне ул чор татар гаиләләре өчен табигый дип булмас.

6 яше тулгач, улы Габдулла да әтисе мәктәбендә укый башлый. Әмма мәктәп ябыла, эшсез калган Хәйрулла гаиләсе белән үзенә һәм хатынына укытучылык эше тәкъдим ителгән Әстерханга күченә. Күрәсең, җәдиди укыту тарафдары Хәйрулла хаҗиның абруе татар дөньясында инде билгеле була: аны Оренбургка – мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсенә геометрия, арифметика, тарих һәм кыйраәт предметларын укытырга чакыралар. Олы уллары Гали һәм Габдулла, имтихан биреп, мәдрәсәнең рөшди (урта) интернат группасына кабул ителә: дөньяви белем алалар, рус телен үзләштерәләр. Өченче уллары Габдрахман башлангыч сыйныфка керә.

Алдынгы фикерле татар зыялылары тәрбияләү бурычы куйган «Хөсәения»дә шәкертләр, белем алу белән бергә, актив иҗтимагый-мәдәни тормыш алып баралар: газета-журналлар яздырып, илдәге һәм дөньядагы хәлләр белән танышып торалар,

үзләре дә кулъязма мәдрәсә газетасы нәшер итәләр, кичәләр оештыралар… Хәйрулла малайлары арасында да чаялыгы, кыюлыгы, хәрәкәтчәнлеге, кызулыгы белән аерылып торган Габдулла барлык яңа эшләрне башлап йөрүчеләрдән була. Гаиләдә дә этисенең иң ышанычлы ярдәмчесе – шул. Әйтик, әнисе Гайшәне Илецк шәһәренә озатып куюны этисе 13 яшьлек Габдуллага ышанып тапшыра. Энеләре Габдрахманны Сембер коммерция училищесына имтихан биреп урнаштырырга да аны җибәрәләр...

1910 елны укуларын бик яхшы тәмамлаган Гали һәм Габдулла, сәүдәгәр Хөсәеновлар стипендиясе хисабына, 4 сыйныфлы Оренбург һөнәр училищесына урнашалар. 4 ел һөнәр үзләштергәч, стипендия алу шартлары буенча, Габдулла сәүдәгәр Хөсәеновларның Тургай өлкәсендәге Актүбә шәһәрендәге он тегермәнендә слесарь булып, кышкы чорда телефон станциясендә эшли. Аннары егетләр икесе дә Акчуриннарның Сембер губернасы Зөябаш (Гурьевка) авылында урнашкан туку фабрикасына эшкә китәләр.

2 мең татар эшчесен туплаган туку фабрикасындагы тормыш төпле дини һәм дөньяви белем, тәрбия алган Габдуллага бик көчле тәэсир итә, аның карашларын үзгәртә. Эшчеләрнең өметсез, караңгы, фабрика белән тулай торак арасында юктан кызык табып үткәргән көнитеше егеткә чыгып булмаслык баткаклык булып тоела. Габдулла йотлыгып, матур әдәбият укый, хәтта этисе кушкан Габдулла исемен (гарәп. «Аллаһ колы») үзенең рухына һәм күңел халәтенә туры килгән шәхес, Л.Толстойның «Хаҗи Морат» повесте герое, Кавказ халкы азатлыгы өчен көрәшүче батыр Шамил исеменә алыштыра. 1914–1917 елларның тынгысыз рухы Усмановны да көрәшкә өнди: 1917 елның 10 мартында ул большевиклар партиясенә язылa. Хәрби хезмәткә алынып, июль аенда Шамил Сызрань шәһәре запас полкында теркәлә, солдат советына сайлана. Шушы вакыттан аның хәрби-сәяси эшчәнлеге башлана.

Күрәсең, Шамил язмышы аның шикелле гаярь татар егетләренең революциягә килү, большевиклар вәгъдәләренә ышану сәбәпләрен дә аңларга ярдәм итәдер. Эшчеләр мохитенә эләгеп, ул гади халыкның иң хокуксыз катламнары тормышын күрә. Шуннан чыгу юлын эзләгәндә, һәркем өчен тигез бәхетле социалистик тормыш төзү тәгълиматына ышана, үз акылын, көчен шушы эшкә багышларга карар итә.

## Кызыл комиссар

Татарча һәм русча төпле, ышандырырлык чыгышлар ясау, үз артыннан күпләрне ияртә алырлык кирәкле сүзләрне таба белү сәләте (харизма) Шамилгә Сызрань шәһәре хәрбиләре арасында үз урынын табарга ярдәм итә. Большевиклар шәһәрдәге 45 меңлек гарнизон солдатларын октябрь аенда Советлар ягына чыгарга күндергән булалар. Шулар арасында үткен акылы, башсызлык чигенә җиткән кыюлыгы, ораторлыгы белән аерылып торган Шамил тиз арада инициативалы шәхес булып таныла. Аны Казан хәрби округы советлары II съездының гадәттән тыш утырышына җибәрәләр. Монда ялкынлы чыгыш ясаган 19 яшьлек егет хәрби округ белән идарә итү өчен оештырылган вакытлы коллегиягә сайлана.

Кайтуга, ул 80 гаскәридән торган Беренче Сызрань партизан пулемёт отряд оештыра. Үзенең истәлекләрендә Шамил хәрби эштә берни аңламаган килеш әлеге эшкә алынуын, гаскәриләр белән ничек идарә итәргә планлаштыруын сөйли.

Әлегә хәрби өлкәдә мәгълүматы аз булса да, Шамилнең үз-үзенә һәм үз гамәлләренең хаклыгына ышанычы зур була. Күрше Кузнецк шәһәрендә эшчеләр советының офицерлар тарафыннан таркатылуын ишеткәч, 150 хәрбидән торган отряд белән анда барып, агитация аша ул 3 көндә 2 мең солдатны коралсызландыруда катнаша. Шунда ук отряды белән үзе теләп, тимер юл белән хәрәкәт итүче ак чехларны коралсызландырып торуга алына.

1918 елның маенда, Оренбург төбәгендә атаман Дутов җитәкчелегендәге казаклар активлашкач, Ш.Усманов отряды Көнчыгыш фронтка җибәрелә. Бередә отряд Кәриб Хәйруллин оештырган Оренбург мөселман батальонына кушыла, Шамил исә батальон комиссары итеп билгеләнә. Бу вазифада ул төрле милләт, дин кешеләреннән тупланган хәрби берләшмәләрдә тәртип урнаштыруның авыр икәнлеген күрә. Шул ук вакытта ислам динен, татар телен белгән, башка төрки халыклар белән дә иркен аралашкан (алты төрки халык телендә иркен сөйләшәм, дип яза ул) егетне мөселман гаскәриләр аеруча хөрмәт итәләр. Каты сугышлар узып, батальон Актүбәгә килеп җитә. Шамил исә мөселман батальоны нигезендә 1200 хәрбидән торган III Интернационал исемендәге легион төзи. Бу легион Яйсан шәһәрен ала, Орскины азат итә, 1919 елның гыйнварында Дутовның казакларын Оренбургтан куып чыгара.

Бу вакыйгаларны Ш.Усманов «Легион юлы (Тургай далаларында)» дилогиясендә җентекләп тасвирлый. Ул әсәрне унике ел дәвамында – 1923 елдан 1935 елга кадәр яза.

Вакыйгалар 1918 елның 4 апрелендә, кызыллар кулындагы Оренбургны берничә мең кешелек аклар гаскәре яулап алу, әмма 500 кешелек кызылгвардия отрядының шәһәрне коткаруыннан башланып китә. Бозаулык янында җыелгән Кызыл Армия отрядлары да Оренбургка поездда чигенәләр. Үзенең прототибы булган комиссар Хәйдәр белән әдип шушында таныштыра. Аның исеменнән үк бу егетләрнең максатын әйттереп үтә: «Иптәшләр, һич шөбһә юк, без бөек вакыйгалар алдында торабыз. (...) Без хәзер шул көрәшкә бик ныклап катнашырга, аңа бөтен көчне бирергә тиешле булабыз» *(Ш.Усманов. Сайланма әсәрләр. Казан, 1958. 39 б.).*

Әмма кызыл гаскәр шәһәрне калдырып чыгарга, Актүбә-Ташкент якларына чигенергә мәҗбүр була. «Легион юлы» – мадьярларны, немецларны, татарларны, башкортларны, казакъларны, таҗикларны, полякларны, румыннарны һ.б. бик күп милләт вәкилләрен туплаган гаскәри бердәмлекнең, күпсанлы станицаларны, далаларны һәм тауларны, Каратургай, Яйсан, Тозтүбәләрне азат итә-итә, Оренбургка әйләнеп кайтып, аны Дутов казакларыннан коткару юлы ул.

Армиянең нindiлеге гаҗәеп күренешләрдә тасвирлана: мылтык тота белмәгән авыл агайларының армиягә язылулары, поездга һөҗүм ясалгач, кешеләрдән бигрәк, яралы атны коткарырга талпынулары, яшь сугышчыларның, Оренбургны калдырып чыкканда, кирәге булмаса да, «шәһәр төбендә яхшылап кына бер сугышып алырга» теләк белдерүләре шундыйлардан. Хәрби эшкә махсус хәзерлекле булмасалар да, гаскәрләрнең кыюлыгы, җиңү өчен үләргә әзер торуы, ярдәмчеллеге барлык вакыйгаларда да калку күрсәтелә.

Төрле милләтләрдән җыйналган гаскәрнең бербөтен көч булып оешып җитә алмавы да әсәр буенча искәртелә бара. Бу сызыкның иң югары ноктасы – мадьярлар белән мөселманнар арасында тавыш чыккач, легион командиры Белевичның атылып үлүе. Вакыйга легионда өч көч – мадьярлар, немецлар, мөселманнар – аерылып торуны, әмма уртак максат кына этник сыйфатлары төрле булган төркемнәрне берләштерә алмауны сөйли. Ш.Усмановның татар бригадасы төзү фикере тамырлары белән шушы күзәтүләргә барып тоташа.

Әсәр кызыл гаскәрнең Оренбургны азат итүе белән төгәлләнә, дидек. Елъязма тәртибендә Тургай далаларында сугышып йөрүне тасвирлап, әдип мондый нәтиҗә ясап куя: «Тургай далаларында үткәргән җиде ай вакыт безнең гаскәрне сугыш белеменә өйрәтте. Алар кулына мылтык тота белгән, нервлары таза, чыныккан сугышчы өчен ачык далада атына атланып чапкан казак куркыныч түгел икәнен аңладылар. Әле канатланып җитмәгән яшь Кызыл Армия өстендә кылыч уйнатырга гадәтләнгән казачийлар да каршындагы дошманның болай бердән ныгып китүенә аптырап калды...». Шул рәвешле, «Легион юлы» – әсәр башында гаскәргә язылырга килгән эшче-крестьян халкының оста сугышчыларга әйләнү юлы да икән.

Шулай ук әсәр буйлап аерым кешеләрнең уртак эшкә аяк чалуы, сатлыкҗаннар

мотивы күренеп-күренеп китә. Бу мотив әдипнең икенче әсәре – «Памирдан радио» (1925) повестенда көтелмәгән чишелеш таба. Анда вакыйгалар кызыл командир Җаббарга яла ягудан башлана. Гаделлек тапмыйча, герой Төньяк Африкага китеп, Риф кабиләләре белән французларга каршы сугышып йөри, шуннан кайтып кына дошманнарның чын йөзен ача ала.

Совет әдәбият белеме әсәрне, әлеге Мароккога китү өлешенә бәйле, фантастик, хыялый текст буларак бәяләп килде. Әмма, дилогиядәге кебек үк, монда да төгәл урын-вакыт, билгеле вакыйгалар, чыннан да аларда катнашкан кешеләр сурәтләнү аны шулай ук сугыш елъязмасына әйләндерә. Эпиграф та әлеге фикерне көчәйтә: «Бу хикәямне Фәрганә фронтының корбаны – сөекле энем краском Габбаска багышлыйм. Автор.» *(Күрс.китап. 221 б.).*

Әсәр 1921 елның августында, Фәрганәдә басмачыларга каршы көрәшкән полкка кызыл командирлар курсын тәмамлаган Җаббарның взвод командиры булып хезмәткә килүеннән башланып китә. Полкның командир-комиссары Кукушкинның кызыл гаскәрләргә каршы эшләгән явызлыклары аның Җаббарны сатлык итеп күрсәтүенә кадәр килеп җитә.

Чишелеш өлеше Октябрьның 20 еллыгына – ягъни 1947 елларга алып китә. Бу вакытта «Советлар Союзы Балтыйк диңгезеннән Урта диңгезгә кадәр җәелгән «Иске дөнья Совет җөмһүриятләре Федерациясе» исемендә бөтен Европа, Азия һәм Африканың зур кисәген, җир шарындагы халыкның биштән дүрт өлешен эченә алган бер мәмләкәткә әйләнгән иде инде.

Аның төзек шәһәрләре, яңа оешкан коммуналары арасында Казан шәһәре зур урын тота. Ул элекке СССРдагы химия сәнәгатенең мәркәзе. Искедән калган клиника, больница һәм университетлары белән медицина дөньясында да Казан зур роль уйный. Ул Британия белән элеккеге Япония атауларын тоташтырган Транс-Арктик һава юлы өстендә торуы аркасында, Идел буе һава юлларының үзәгенә әйләнгән. Транс-Арктик юлдан башка ул, Казан – Истамбул, Казан – Һиндстан, Казан – Пекин юлларының һәм якындагы шәһәрләр белән тоташтыра торган уннарча һава юлларының үзәгендә тора. Аның шәһәр үзәгендә, элекке Арча кырында, ясалган мәркәз һава вокзалы Федерациядә беренчеләрдән санала иде». Алга таба тизйөрешле машиналар, гүзәл бакчалар, 3-4 айлык балаларны, аналарыннан аерып, коммуна балалары итеп тәрбияләү, пневматик почталар, электр белән эшләүче экологик чиста фабрикалар турында бәян ителә. Бу картиналарда Ф.Әмирханның фантастик күзаллаулары да күренеп китә, әлбәттә.

Әмма биредә төп фикер булып Кукушкин-Осиповны 20 елдан соң гына фаш итү, бигрәк тә геройның, үз илендә хаклыкны исбатлап булмавын аңлап, Африкалар аша узып кына моңа ирешүе килә. Күрәсең, сугышлар аша узганда, Ш.Усманов яңа тормышның күп кенә җитешмәгән якларын да күрә, алар хакында да уйлана, каләм ярдәмендә кисәтергә дә омтыла. «Көчле мандат» хикәясендә, яраланган кызылармеецларга утырырга урын булмаганда, наркомфин агентының берүзе бер вагонда баруын тасвирлау да шул хакта сөйли. Мондый күренешләр Ш.Усмановның драмаларында да очрый.

Күп кенә әсәрләрендә шушы кисәтүне каләмгә тотынырга мәҗбүр иткән сәбәп төсендә үзе дә билгеләп уза. Әйтик, «Командир хатыннан» хикәясендә төп герой үзенең дустына болай дип яза: «Синең белән мине көнлекче эшчедән командир дәрәҗәсенә мендергән ул елларда алынган белем, тәҗрибә хәзерге яшь буынны сугарып тора» *(Күрс. китап. 376 б.)*. Ягъни автор үзе язганнарның киләчәк буыннар өчен кирәк булуын искәртә.

## Татар бригадасы төзү

Гражданнар сугышы шартларында күп кенә шәһәрләрдә мөселман полклары оеша башлый. Усманов та Оренбургта мөселман полкы оештырырга уйлый. Ул моны русча начар белгән, еш кына башка милләт вәкилләре арасында югалып кала торган, әмма

кыю, ышанычлы һәм батыр мөселман гаскәриләре өчен үзләрен күрсәтү, үз көчләренә ышаныч уяту юлы дип караган. Әмма бу эшнең кирәклеге турында төрле югары даирәләрдә никадәр сөйләсә дә, җирле хәрби җитәкчелек моны хупламый.

Эшләп килүче мөселман полклары Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариаты каршындагы Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә буйсыналар. Аның рәисе М.Солтангалиевнең Уфага килгәнен ишетеп, Шамил чатнама суыкта атка атланып, аның белән очрашуга чыгып китә. Бу вакыйганы архив материаллары нигезендә өйрәнгән А.Яхин Шамилнең Мәскәүгә бу хакта дистәләрчә рапортлар, гаризалар, жалобалар язуын әйтә *(А.Яхин. Шамил Усманов. Казан, 1963. 12-13 б.)*. Л.Троцкийга язган хатында Ш.Усманов әлеге мәсьәлә белән Сталинга керүен дә телгә ала. Һәм мондый нәтиҗә дә ясый: «В красной Москве, где я ожидал разрешения всех вопросов, я хожу по ее улицам. Истрепал себе сапоги, истратил последние деньги и везде ответы: не можем, завтра, подождите... Махровым цветом расцветает канцелярщина, и к любому «превосходительству» и «Высочеству» было пробиться гораздо легче, чем к ревкомандирам красной Москвы». Туры сүзле, үзенең хаклыгын кан түгеп раслаган кызыл комиссар киләчәктәге матур тормышны да – хаклык белән, дөресен әйтеп кенә төзеп була дип ышана.

Ниһаять, 1919 елның мартында, советларга Колчак гаскәрләре яный башлагач, Казанда мөселман бригадасы – «Аерым Идел укчы татар бригадасы» – төзергә рөхсәт алына, Ш.Усманов аның комиссары итеп раслана: бригада оештыру тулысы белән аның карамагында була. Комиссар колачлы сәяси-агарту эшен җәелдерә. Гадел, сүзендә тора торган, кыю комиссарны тыңлыйлар, яраталар. Яңа хәрби берләшмәдә батальон командиры булган Якуб Чанышев соңрак аны – бригаданың җаны иде дип атый.

Тиздән бригада командиры итеп Йосыф Ибраһимов билгеләнә. Бригаданың Беренче полкы май аенда, калган полклары август башында сугышка китә. Татар бригадасының алга таба каты сугышларда үрнәк тәртип һәм оешканлык күрсәтүендә, гел җиңүгә омтылуында, бердәмлегендә Ш.Усмановның да роле зур була.

1919 елның сентябрендә Ш.Усманов каты яралана, умыртка баганасын җәрәхәтли, дәваланырга Ташкентка китә, аннан Казанга кайта. Сәламәтлеге какшау аңа фронтка әйләнеп кайтырга мөмкинлек бирми. Шуңа күрә аны, бригада комиссары вазифасыннан азат итеп, 1919 елның 8 октябрендә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политбүлеге җитәкчесе итеп билгелиләр. Бу олы вазифа, асылда, мөселман полклары, бригадалары белән эшләүнең стратегик юнәлешләрен билгеләүдә, алардагы хәлне күзәтү һәм контрольдә тотуда зур мөмкинлек ача.

1922 елның мартында Ш.Усманов Казанга әйләнеп кайта. 1925 елның 1 гыйнварыннан Мәскәүдә, хәрби уку йортлары идарәсенең сәяси секретариатында өлкән инспектор булып эшли башлый. Шул ук елның сентябрендә М.В.Фрунзе исемендәге хәрби академиянең берьеллык курсларына керә, аны тәмамлагач, Ташкентта Шәрык курслары рәисенең сәяси эшләр буенча ярдәмчесе итеп билгеләнә. 1927 елның маенда, сәламәтлеге начараю сәбәпле, дивизия комиссары дәрәҗәсендәге Ш. Усманов хәрби хезмәттән китәргә мәҗбүр була.

Шулай итеп, революция һәм Гражданнар сугышы шартларында, ун ел эчендә Ш.Усманов ышанып та булмаслык хәрби карьера ясый: гади солдаттан – бригада комиссары, слесарьдан – Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политбүлеге җитәкчесе дәрәҗәләренә кадәр үсә. Үз көченә, ышандыру сәләтенә нык ышанган хәрби җитәкчесе буларак, ул зур гаскәри берлекләр оештырырга алына, ныклы ышаныч белән үз артыннан ияргән илдәшләрен туган җир, бәхетле киләчәк өчен көрәшкә рухландыра. Ирешкән уңышларының сәбәбе, безнең фикеребезчә, аның үзенең кавемдәшләре – мөселманнар, татарлар, төрки халык вәкилләре, башка милләт хәрбиләре өчен җаваплылыкны үз җилкәсенә алудан, беренче булып яуга ташланудан, үз фикерен өзеп әйтүдән курыкмавында була.

Бу вакыйгалар турында әдипнең күп кенә публицистик язмалары бар. «Казан, 26 октябрь» *(«Кызыл армия», 1919, 26 октябрь)* мөрәҗәгате мондый сүзләр белән төгәлләнә: «Үзебезнең истикълялиятебез исеменә, халкыбызның иркен яшәве исеменә без хәзердән үк аларга (иске идарәне кайтарырга тырышучыларга – **Д.Ф.**) каршы сугышучы гаскәр сафына басарга, аның әләмен ныграк тотарга, революция таләп иткән нәрсәләрне алда тотып, аңа ныграк буйсынырга тиешбез. Бу – безнең мөкатдәс бурычыбыз».

«Татар бригадасы безгә нәрсә бирде?» *(«Кызыл армия», 1919, 24 октябрь)* язмасында ул, барлык гаскәрләрнең 25 процент тәшкил иткән татарларның, рус телен белмәү, һөнәре булмау сәбәпле, «түбән хезмәтләрдә» эшләве, «полк яки бригада командиры» дәрәҗәсенә күтәрелә алмавы турында ачынып яза. Полк яки бригада төзү идеясенең инде өлгергән мәсьәлә булуын исбатлап, кабат Тургай далаларында үткән вакыйгаларга күз ташлый, «7-8 ай казаклар белән булган сугышларда кыргыз сәхрәләрендә шул берничә йөз татар гаскәриләренең үз араларыннан командирлар, офицерлар җитеште. Ул гына да түгел, шул батальонда тәрбияләнгән кайбер командирлар мадьяр, немец батальоннарына командирлыкка тәгаен ителеп, татар эшче-крестьянының да эш башында тора белүен исбат иттеләр». Әмма милли низаглар чыгудан куркуның бу эшләргә каршы килүен дә ачыктан-ачык белдерә. Туры сүзле, батыр каләмле Шамил «Октябрь һәм татар кызыл гаскәр бүлекләре» *(«Татарстан», 1923, 7 ноябрь)* мәкаләсендә хәтта болай дип яза: «Көрәш елларында кызыл гаскәр идарәсе сафларын узган иске урыс офицерлары бу туачак татар кызыл гаскәрендә «Чыңгыз гаскәре тудыру» хыялыннан куркып, бөтен көчләре белән каршы төшә иделәр». Ш.Усманов фикеренчә, татар офицерларыннан – кызыл генераллар үсеп җитешкәндә генә, алар үз милләттәшләре өчен үрнәк, әйдаман булачаклар. Совет идеологиясенең бөтен Җир шарына җәелүен, уңышын ул менә шул киләчәкнең кызыл генераллары белән бәйли. Бу сүзләр әдипнең еракка карап эш итүче сәясәтче, бер үк вакытта үз халкы мәнфәгатьләрен кайгыртучы милләтче булуын да искәртәләр.

## Мылтыкны һәм каләмне корал итеп...

Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политбүлек җитәкчесе булып эшли башлагач, Ш.Усманов тормышында яңа этап башлана. Бер яктан, ул әле дә хәрби операцияләр планлаштыру һәм әзерләү белән яши. Икенче яктан, татар полкларында һәм бригадаларында яшьләрне тәрбияләүгә, зур максатларга хезмәт итәрлек кешеләр итеп үстерүгә көннән-көн ныграк игътибар бирә. Политбүлекнең киң вәкаләтләре арасында агитация өчен материаллар әзерләү һәм нәшер итү дә, аларны хәрбиләргә җиткерү дә, яшьләр арасында хәрби гыйлем тарату да, солдатлар һәм офицерлар өчен кыска вакытлы белем күтәрү курслары оештыру да һәм тагын бик күп эшләр күренә. Ш.Усманов әлеге курсларны масштаблы итеп оештыруга, анда укытырга кешеләр җәлеп итүгә, курсантларның сәяси дәрәҗәсен камилләштерерлек чаралар уйлап табуга зур игътибар бирә.

Яшь солдатларга тәэсир итә торган иң кыска, иң үтемле юлны ул матур әдәбиятта дип таба. Шуңа күрә Усманов политбүлек тирәсенә күп кенә язучыларны һәм артистларны тарта, алар сугышчылар арасында актив культура-агарту һәм пропаганда эше алып баралар. Әмма, үзе 1920 елны әйткәнчә, «каләм тотып яза белә торган берничә язучы» *(«Кызыл армия», 1920, 30 март)* белән ерак китеп булмый! Шамил агитацияләүдә вакытлы матбугатны киң файдаланырга тырыша: коллегия газетасы булган «Кызыл армия»дә күпсанлы мәкаләләр бастыра. Аларда алда торган стратегик бурычларны аңлатырга, әле генә булган вакыйгаларга бәя бирергә, киләчәккә юллар сызарга ашыга.

Ул үзе дә пьесалар язарга керешә. Бер-бер артлы «Канлы көннәрдә» (1919), «Беренче адым» (1919), «Бай кызы» (1922) драмалары дөнья күрә. Алар революция

чоры каршылыкларын – бер кеше рухында, бер гаилә, туганнар, бер авыл, җәмгыять эчендәге тартышларны – тасвирлыйлар. Әдәби-эстетик ягы камил булмаса да, болар татар совет әдәбиятының беренче әсәрләре исемлегенә керәләр.

Ш.Усмановның иҗтимагый эшчәнлеген өйрәнгән И.Г.Гыйззәтуллин фикеренчә, аның сәяси активлыгы аеруча Татарстан Республикасын игълан итүгә әзерлек барышында күренә. Татарстан Республикасы турында декрет чыккач, 1920 елны Ш.Усманов ТАССР Советларының оештыру съездын хәзерләү өчен корылган республика революцион комитеты сәркатибе итеп билгеләнә. Әмма шушы вакытта көтелмәгән хәл килеп чыга: съездда кимендә 50 процент татар делегатлары булырга тиеш дигән фикер уздырганы өчен Усманов милләтчелектә гаепләнә һәм Төркестан фронтына җибәрелә.

Әмма бу авыр хәл аны үз республикасын үстерүгә хезмәт итүдән читләштерә алмый. Әйтик, Ш.Усманов Татарстан АССРны яклап ялкынлы мәкаләләр яза, Казанда Кәрим Тинчурин җитәкчелегендә политбүлеккә карый торган татар артистлары труппасы оештыра. Бик күп гамәлләре Татарстанның нигез баганалары булып чыгалар. Әйтик, Бакый Урманчега Өстәл календаре ясарга мөмкинлек тудыра һәм үзе дә, мавыгып китеп, бу эштә катнаша. Шунда басылган ТАССР гербы киләчәктә республикабызның рәсми гербын ясау өчен үрнәк була.

1922–1925 елларда ул – Казанда 16 нчы пехота командирлары әзерләү курсының сәяси бүлеге мөдире, аннары берләштерелгән Татар-башкорт хәрби мәктәбенең комиссары. Курсантларның уку һәм көнкүреш шартларын яхшырту, хәрби белем күтәрү өлкәсендә дә кызыл комиссар нәтиҗәле эш башкара, зур абруй казана.

Шовинизмда гаепләүләр аны турысын сөйләүдән дә тыя алмый. Мисал өчен, 1923 елның 4 маенда Татарстан Республикасының Мәскәүдәге вәкиле М.Х.Солтангалиев кулга алына. Шамил өчен Мирсәет Хәйдәр улы – революцион хәрәкәт теоретигы, остаз һәм фикердәш. Казаннан Солтангалиевне азат итүне сорап җибәрелгән хатка, 15 җаваплы хезмәткәр белән беррәттән, Ш.Усманов та кул куя.

1924 елның апрелендә, партиянең Татарстан өлкә комитеты эшчәнлегендәге кимчелекләрнең хәтәр төс алуын күрсәтеп, Мәскәүгә тагын бер хат языла. Анда 39 кеше арасында Ш.Усманов имзасы да тора. Тиешле чара күрәсе урынга, башкала имза куючыларны эзәрлекли башлый: хөкүмәт башлыгы К.Мохтаров, аның урынбасары Г.Мансуров, Үзәк башкарма комитет рәисе Р.Сабиров, җир эшләре комиссары урынбасары А.Енбаев эштән алына. Ш. Усманов исә, май аенда уздырылган Татарстан өлкә партия конференциясенең IX съездында хаттагы үз имзасыннан ваз кичүе турында чыгыш ясарга мәҗбүр ителә һәм Мәскәүгә китеп бара. Аны башкалада да тынычлыкта калдырмыйлар: бу хакта үз кулы белән кечкенә генә записка язып, ул кабат бу хаттан баш тарта. Дошманга каршы кылыч күтәреп, яу кырында бергә-бер алышкан кызыл комиссар өчен мондый идән асты уеннарын узу җиңел булмагандыр, диясе кала.

Казанга әйләнеп кайткач, Усманов үзен тулысынча иҗат эшенә багышларга карар итә. 1923-1924 елларда булып узган күңелсез вакыйгалар да аның сәяси эшчәнлектән читләшүенә сәбәп була, күрәсең.

## Иҗат ялкыны белән

Әмма Шамилнең тынгысыз җаны, кайнар йөрәге тик кенә тора алмый. 1922 елда ул, очраклы рәвештә күреп, Казандагы радиолаборатория эшчәнлеге белән кызыксынып китә. Бу вакытта инженер А.Т.Углов радиодулкыннар тапшыру аппаратурасына сынау уздыра торган була. Сынау уңышлы тәмамлана. Ш.Усманов 1925 елда Казанда радиотапшырулар үзәге ачу мәсьәләсен күтәрә. Әмма ил тормышындагы авыр вакытта бу эшне башкарып чыгу мөмкин булмый.

1927 елның җәендә Казанга әйләнеп кайткач, ул республика җитәкчелегенә күп чыгымнар тотмыйча да Татарстанны радиолаштыру планын җиткерә һәм, Мәскәүнең

«Радиопередача» оешмасы белән килешү төзеп, зур булмаган радиостанция корыла. Октябрь инкыйлабының 10 еллыгы көнне – 1927 елның 7 ноябрендә – Ш.Усманов үзе эфирдан аваз сала: «Тыңлагыз! Тыңлагыз! Казан сөйли!». Шулай итеп, Ш.Усманов тырышлыгы белән 1930 елны эшли башларга тиешле радио Казанга 3 елга алдарак килә. Татарстанның иң ерак авыллары да татар телле радио тыңлау, үз телләрендә җырлар ишетү, ил-көн яңалыкларын күзәтеп бару бәхетенә ирешәләр.

Радио штатында журналист Ш.Усманов, диктор Г.Кутуй, артистлар Камал Икенче, В.Егорова була, музыка бүлеген С.Сәйдәшев җитәкли. Оештырыла торган радиоконцертларда Мәрьям Рахманкулова, Гөлсем Сөләйманова, Асия Измайлова, Галия Кайбицкая, Газиз Әлмөхәммәтов һ.б. артистлар башкаруында татар җырлары яңгырый. Ш.Усманов, бер яктан, радиотапшыруларның идеологик эчтәлегенә зур игътибар бирсә, икенче яктан, төрле конкурслар оештырып, күбрәк тыңлаучы җәлеп итәргә омтыла. Радио эшләп киткәч, ул телевидение булдыру хыялы белән янып яши. Гомумән, Ш.Усманов колачлы, күп кешеләрне җәлеп итеп эшләнгән тамашалар куюны – халыкны агарту, берләштерү, аны зур эшләргә рухландыру юлы итеп карый.

Бу тамашалар театр һәм концерт залларына сыя алмыйча, урамнарга ташып чыга. 1924 елны режиссёр сыйфатында, үз буйсынуындагы 2шәр мең хәрби уку йортлары курсантларын артистлар итеп киендереп, Ш.Усманов ачык һавада революцион темаларга багышланган театрлаштырылган алты тамаша оештыра. Бу шулкадәр тансык, шулкадәр гаҗәп бер күренеш була: Казан үзе, театрга килгән халык әлеге тамашаларның башкаручысына әйләнә, үзен зур тарихи вакыйгалар үзәгендә кайнаган итеп сизә.

Советлар илендә нинди фәнни яки мәдәни яңалык күренә – Ш.Усманов шунда ук аны күтәреп ала, тормышка ашыруга бөтен көчен куя. Аның алфавит алмаштыру буенча татар зыялылары арасында 1924–1927 елларда барган бәхәстә латин графикасын кертүне яклаучылар арасында иң актив татар җәмәгать эшлеклесе булуы да шуңа бәйле, күрәсең. Бу яңалыкны ул үз халкын гыйльми агарту юлы дип карый. Һәм ни гаҗәп: 1926 елны Бакуда узган Беренче тюркология съездына татар артисткаларын алып баруы соңыннан аның өстеннән әләк язуга, шул әләк исә кулга алынуына, үлеменә китерә.

Ш.Усманов исеме Татарстанда беренче пионер лагерьлары оештыручы буларак та тарихка язылган. СССРда эсперантога кызыксыну арткач, ТАССРда ясалма халыкара телне өйрәнү хәрәкәтен дә Ш.Усманов башлап йөри. 1930 елдан ул эсперантистларның Мәскәү өлкә комитетының җаваплы сәркатибе итеп сайлана, бераздан язучы-эсперантистларның халыкара ассоциациясенә керә. Бу телне дә әдип киләчәк теле, әдәбиятның иртәгәге формасы дип карый, татарлар бу яңалыклардан читтә калырга тиеш түгел дигән фикер уздыра.

Ш.Усманов 1925 елда Бөтенсоюз пролетар язучыларының беренче съездында катнаша һәм аның Ассоциациясенә әгъза итеп сайлана, ә 1934 елдан СССР Язучылар союзына кабул ителә. 1920–1930 еллар чигендә ул инде татар совет язучысы булып таныла.

Иҗат мирасында Гражданнар сугышының төрле вакыйгаларын яктырткан хикәяләр сериясе билгеле бер урын тота: «Ил кызы», «Бирегез тупны кире», «Идел буйлап», «Көчле мандат», «Өч снаряд белән» һ.б. Туку фабрикасында эшләгән елларын искә төшергән «Фабрика анасы» (1926), «Тиң түгелләр» (1927), «Эшче кызы Нина» һ.б. хикәяләре эшчеләр тормышын сурәтлиләр. Хикәяләр кебек үк, инде телгә алынган күләмле чәчмә әсәрләре – повестьлар да әдип үзе күргәннәргә нигезләнеп языла. Очеркларга тартымлык, публицистик башлангычның көчле булуы, образлылыкның, психологизмның – тормышны ничек бар шулай тасвирлау белән алмашынуы Ш.Усманов әсәрләренең укылышын, җәлеп итү мөмкинлеген киметәләр. Бүгенге укучы өчен алар – фактологик яктан, Гражданнар сугышы вакыйгаларын белеп, бу дәвердә кешеләрнең нинди ваемнар, өметләр белән яшәгәнлеген бөтен ваклыкларында тергезгән чыганаклар буларак кыйммәт.

Шунысын да әйтергә кирәк: Ш.Усмановның беренче драма әсәрләре – «Канлы көннәрдә», «Беренче адым» – язылуга сәхнәгә менә, йөзләрчә тапкыр уйнала, басылып чыгып кына түгел, кулдан-кулга күчерелеп укыла. Боларның популярлыгы – бәлки, без бүген кимчелек итеп карый торган сыйфатта, үз дәверенең вакыйгаларын ничек бар шулай тасвирлауда булырга да мөмкин. Чөнки тамашачы үзе яшәгән мохитне, үзе аралашкан кешеләрне, үзен борчыган мәсьәләләрне сәхнәдә күрә, аларны әдип белән бергә шәрехләп карый.

Иң уңышлы драма әсәре саналган «Кичеккән фәрман» драмасын автор үзе 1933 елны русчага тәрҗемә итеп, Мәскәүдә иң яхшы пьесаларга үткәрелгән конкурска җибәрә һәм меңнән артык әсәр арасында 3 нче урынны ала. Ул 1935 елда Мәскәүдә «Страна родная» исеме белән китап итеп бастырыла. Пьесада Зәки Вәлиди җитәкчелегендә милли-буржуаз башкорт хөкүмәтенең совет хакимияте ягына чыгуы сурәтләнә. Үзәк герой Харис Садыйковның (прототибы Зәки Вәлиди) большевиклар ягына авышуы төрле социаль катлау вәкилләренең үзара мөнәсәбәтләре һәм конфликтлары аша тасвирлана. Кызганычка каршы, соңрак бу әсәр Ш.Усмановны милләтчелектә, контрреволюцион эшчәнлектә гаепләүгә сәбәп була.

## Мәхәббәт һәм гаилә турында

Хәрәкәтчән, җитез, янып торган Шамил Усманов – кызлар күзе төшәрлек егет була. Кызыл комиссар кәләшне дә үз карашларын уртаклашкан, революция өчен көрәшкә кушылган кызлар арасыннан сайлый: чибәр һәм үткен Газизә (Азик) Алимбәк белән гаилә кора. Кызлары Айсылу туып, матур гына яшәп киткән кебек булсалар да, шул заманның «ирекле никах» тәгълиматына бәрелеп, 1922 елда гаилә таркала. Газизә икенче кат кияүгә чыга, Үзбәкстанга китеп бара.

Шамил 1924 елда Асия Измайловага (1903–1993) өйләнә һәм 1925 елда өч яшьлек кызы Айсылуны Мәскәүгә, яңа гаиләсенә алып кайта. Танылган опера җырчысы (меццо-сопрано), татар профессиональ җыр сәнгатенә нигез салучыларның берсе, чибәр һәм нәзберек ханым Асия Измайлова Гражданнар сугышы дәверендә концерт бригадалары белән йөри, Татар бригадасы каршында да чыгыш ясый. Быел тууына 120 ел тулган актриса Татарстанда опера сәнгате үсешенә, җырчы кадрлар әзерләүгә гаять зур өлеш кертә.

Ш.Усманов белән Казанга кайткач, Асия Измайлова мондагы мәдәни тормышның үзәгендә кайный. Бер генә җитди концерт яки спектакль дә аның катнашыннан башка куелмый. Бу күпләрнең күңелендә көнчелек уты кабындыра. 1929 елны Ш.Усмановның кабат Мәскәүгә китү сәбәпләренең берсе дә җырчы А.Измайлованың талантыннан көнләшеп һәм нахакка гаепләп, эшеннән алдырту була. Измайлова Мәскәү консерваториясенең татар студиясенә укырга керә, бу вакытта Ш.Усманов Язучылар союзында эшли. Әмма икенче гаилә тормышы да озын гомерле булып чыкмый: 1935 елны аерылышып, Шамил 1936 елны кызы Айсылу белән Казанга әйләнеп кайта.

Бу вакытка инде улын хаиннәр кулыннан һәлак булу куркынычы турында кисәткән, әмма сынмаска-сыгылмаска, үлемнең күзенә туры карарга васыять иткән Хәйрулла хаҗи вафат, әниләре олы улы Габдрахманның күп балалы гаиләсе белән Казанда яши. Бу урында тагын бер мәсьәләгә ачыклык кертеп узарга була: Хәйрулла Усманов, кавемдәшләренең тормышын үзгәртү өчен кискен иҗтимагый-сәяси адымнар кирәклеген аңласа да, моны советлар сайлаган юл белән түгел, бәлки мөселман халыклары бергәләп ирешә ала торган эш итеп карый. 1920 нче елларда ул, Бохара әмиренең төшерелүен ишетеп, борынгы мәдәни мирас үрнәкләрен югалудан саклап калуга өлеш кертәм дигән изге теләк белән әлеге шәһәргә чыгып китә. Үзенең күптәннән килгән хыялын тормышка ашыру – Ш.Мәрҗани белем алган мәшһүр Күкелдаш мәдрәсәсен күрү, шундагы гыйлем ияләрен тыңлау өчен шушы уку йортына комиссар итеп билгеләнә. Күкелдашның гыйлем үзәге булудан туктаганлыгын аңлап, яңа хакимияткә хезмәт итүдән баш тарта.

Әтисен, аның холкын искә төшереп, хатирәләрендә Шамил үзендәге «барлык яхшы сыйфатларның» әтисеннән килүе, болар: «һәрдаим тынгысызлык – үзең өчен түгел, башкалар өчен борчылу, иҗтимагый омтылышлар белән яшәү, җәмгыятькә каршы булган һәр нәрсәгә каршы төшү» булуны әйтә. Шамил ир туганнары өчен дә терәк тә, үрнәк тә, ярдәмче дә була. Казанны ул – татар халкының мәркәзе дип карый, шушы шәһәр аша үз халкына хезмәт итү уен соңгы көннәренә кадәр йөрәгендә йөртә.

## «Алданган буынның вәкиле»

А.Л.Литвин Ш.Усмановның соңгы фаҗигале көннәре турындагы язмасын «Алданган буынның вәкиле» дип атый. «Ул 19 яшендә большевик була, партия идеяләренә тугрылыклы хезмәт итәргә ант бирә; 39 яшендә ВКП (б) аны сата, үзеннән этәрә, тугры хезмәте өчен рәхмәт урынына, палачлар кулына тапшыра».

Нахакка гаепләнеп, кичәге кызыл комиссар 1937 елның 8 апрелендә кулга алына. 1917 елдан большевик булган Шамил милләтчелектә, Солтангалиев оешмасында катнашуда гаепләнә. «Мулла малае» булуын да искә төшерәләр... Әдип, чыннан да, үз иҗатында муллаларны көлү объекты ясамый – бу «Гает корбаны» хикәясендә дә күренә. Кулга алганда төзелгән исемлектә төрле телләрдәге китаплар арасында Коръән китабы булу да бу мәсьәләгә күпмедер ачыклык кертә булса кирәк.

Усмановны чит илләргә чыгып киткән татар мөһаҗирләре белән бәйләнештә дә гаеплиләр, аерым алганда, Г.Батталның илдән качуында да аның катнашы бар дип күрсәтелә. Үзенең күргәннәре турында детальләп язылган истәлекләрендә Г.Баттал Ш.Усманов исемен телгә алмый. Димәк, бу гаепләү дә ялган булып чыга.

Соңгы сорау алуга аны 1937 елның 2 декабрендә кич белән китерәләр. 3 декабрьдә иртәнге сәгать 3-тә ТАССР Эчке эшләр комиссары бүлмәсендә 39 яшьлек язучының кыйналудан йөрәге туктый. Бары тик 1939 елда гына үлеме хакында гаиләсенә хәбәр итәләр.

Татарстанда һәм татар дөньясында билгеле шәхес – Ш.Усмановның кулга алынуы, үлеме күп кенә фаразлар тууга да сәбәп була. Аерым алганда, зыялылар арасында аның, протоколларга кул куймас өчен, үз күзенә каләм белән кадап үлүе турында сөйләк йөри. Ул, бәлки, Шамилнең чыннан да протоколларга кул куймаганын, берәүне дә сатмаганын белгәннәр тарафыннан, исемен хөрмәтләп, уйлап чыгарылгандыр...

Шамил Усмановның данлы исемен җәмәгатьчелеккә кайтаруда кызы Айсылу Сагайдак-Усманова зур хезмәт куйды. Аның мөрәҗәгате буенча, 1955 елда әдипнең исеме аклана. Әтисе турында замандашлары истәлекләрен туплап һәм язучының шәхси архивын өйрәнеп язган «Глазами памяти» китабы (1982, 1988) һәм «Перебитые крылья» (2014) тарихи романы аның эш-гамәлләрен, көрәшче рухын, гаҗәеп тормышын яктыртып җибәрделәр.

Шамил Хәйрулла улы Усманов исеме бүген дә татар халкының йөрәгенә уеп язылган. Ни өчен? Совет идеологиясенә, Гражданнар сугышы афәтләренә, татар бригадаларының Урта Азиядә яңа тормыш төзүенә һәм тагын башка бик күп вакыйгаларга мөнәсәбәт үзгәрсә дә, бер кыйммәткә бәя үзгәрми. Ул – шәхеснең үз тормышын халыкның, илнең киләчәге якты булсын өчен багышлавы. Күрәсең, Ш.Усманов феномены да шуның белән аңлатыла.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы.*

# «ГЫЙСӘ УЛЫ АМӘТ»

Күләме һәм жанры белән дастан категориясе таләпләренә тулысынча туры килә торган бу дастан – алты әсәрне үзендә туплаган «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгында урын алган эпик ядкарьләрнең берсе.

XVII гасыр истәлеге булган «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгын, исеме сакланмаган дип исәпләп, әле дә төрлечә атыйлар: «Дастаннар җыентыгы», «Мәҗмуга», «Дастаннар китабы», «Татар елъязмасы», «Чыңгызнамә» һ.б. Бу кулъязмада туплап бирелгән эпик әсәрләрнең барысын да уртак тема берләштерә: алар тарихтан мәгълүм атаклы Чыңгыз нәселеннән булган ханнарга яисә алар корган дәүләткә мөнәсәбәтле шәхесләргә багышланган. «Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан», «Аксак Тимер нәселе турындагы дастан», «Гыйсә улы Амәт турындагы дастан», «Идегә би турындагы дастан», «Урыннар һәм шәһәрләр турындагы дастан», «Тарих турындагы дастан» – XVII гасырга караган китаптагы әсәрләр исемлеге. Болар – бер-берсе белән генеалогик бәйләнештәге, әмма һәркайсы мөстәкыйль сюжетлы дастаннар.

Җыентыкта урын алган «Гыйсә улы Амәт» сәнгатьлелек җәһәтеннән башкаларыннан аерылып тора. Әсәр халыкта популярлык тапкан, яратып укылган. «Чыңгызнамә» составында, шулай ук аерым күчермәләрдә төрле вакытта табылган һәм әле дә табылып тора торган кулъязмалары шуны раслый. Дастан текстының безнең көннәрдә дә берничә кат басылып чыккан булуы мәгълүм.

Дастан «Дәфтәре Чыңгызнамә» составындагы әсәр булуы белән бәхетле язмышка ия, чөнки әлеге җыентыкның күпсанлы күчермәләре галимнәр игътибарыннан читтә калмаган, шактый җентекле өйрәнелгән. Академик М.Госмановның шушы темага махсус хезмәте бар *(Усманов М. А. Татарские исторические источники. Казань: Изд-во ун-та, 1972)*. Анда «Гыйсә улы Амәт» дастаны хакында да тәфсилләп сөйләнә, җыентыктагы әсәрләрнең өйрәнелү тарихына зур урын бирелә, күчермә нөсхәләре хакында киң мәгълүмат җиткерелә, әсәрләргә тарихи яссылыктан торып бәя бирелә. Биредә әсәрләрнең барлыкка килү чоры, таралу формасы һ.б. мәсьәләләр дә яктыртыла, шулай ук «Дәфтәре Чыңгызнамә» дигән исемнең беренче дастан исеме генә булмыйча, җыентыкның гомуми аталышы булуы да галим М.Госманов тарафыннан документаль дәлилләнгән.

Бу кыйммәтле кулъязма күчермәнең тулы һәм тулы булмаган нөсхәләре, фрагментар кулъязмалары һәм шулай ук борынгы басма текстларының саны кырыктан артып китүе мәгълүм. Шуларның дистәдән дә ким булмаган нөсхәсендә «Гыйсә улы Амәт» дастаны бар.

Каһарманлык эпос-дастаннарына хас булганча, «Гыйсә улы Амәт» тә чынбарлык вакыйгаларына нигезләнә. Дастан каһарманнары – Алтын Урда ханы Җанибәк, аның хатыны Тайдулы, уллары Бирдебәк, ханның кызы һәм Амәт – реаль шәхесләр, топонимик атамалары – бүгенге Татарстан территориясе атамалары белән тәңгәл, каһарманнар арасындагы мөнәсәбәтләрнең күбесе документаль чыганаклар белән дә ныгытыла. Әмма, тарихи фактлар никадәр генә кызыклы тоелмасын, вакыйгалар сәнгатьчә тасвирланган һәм фольклорлашкан. «Гыйсә улы Амәт» – героик дастаннарга хас булганча, үзенең эчтәлегендә орыш-көрәш картиналары белән бергә маҗаралы мәхәббәт тарихын, кубыз, думбра кебек уен коралларында җыр әйтешү эпизодларын үз эченә алган, ил-халык язмышын эпик сурәтләгән, чәчмә белән тезмә аралашып

үрелгән күренекле язма-китаби фольклор ядкаре. Гыйсә улы Амәт белән Җанибәк ханның кызы мәхәббәтеннән дөньяга туган Салчының тулгавында гына да Казан ханлыгы чорына кагылышлы бик күп мәгълүматларга юлыгабыз, шул ук вакытта бу юллар төрки эпоска хас традициядән килә торган шигъри монолог үрнәге буларак та кыйммәт:

*Ак Сарайда балчымын,*
*Ана Иделдә салчымын,*
*Әчтерханда тучымын (байрак тотучы),*
*Кыр-далада уенчымын,*
*Анам сорсаң – никяхсыз,*
*Атам сорсаң – белексез.*
*Төбем сорап нидәсез,*
*Үзем артык туган соң.*

Казан ханлыгы – Алтын Урданың Идел буендагы варисы; дастанда Казан ханлыгы мөстәкыйль дәүләт булып оешкан чорда хакимлек иткән сәяси вазгыять, ханлык территориясенә кергән җирле топонимнар (Зөя тамагы, Идел якасы һ.б.), күпмедер дәрәҗәдә Казан ханлыгының башка татар ханлыклары белән тоткан мөнәсәбәтләре чагылыш тапкан. Дастанның Алтын Урда таркалып, Казан ханлыгы чорында барлыкка килгәнлеге һәм соңрак дистәләгән вариантта кульязмалар булып таралу факты әлеге эпик ядкарьне Казан ханлыгы чоры истәлеге буларак карарга җирлек тудыра.

Биредәге текст С.Гыйләҗетдинов төзегән, «Мирастан биш сәхифә. XVII – XIX гасыр әдәби-тарихи ядкарьләре» дип аталган җыентыктан алынды.

«Гыйсә улы Амәт» дастаны 1859 елда С.Кукляшев хрестоматиясенә кертелгән булган. Соңрак, «Дастаннар җыентыгы»н тулысынча бастырып чыгарган Рәхимҗан Җиһаншин китабында (1882) урын алган. Бу китапның исеме бик озын: «Һәза китабы фаслы дастан нәсли Чыңгыз хан вә Аксак Тимир нәслиндән бәйан идәр», кем хисабына басылуы турындагы мәгълүматка нигезләнеп, фәнни әдәбиятта «Җиһаншин басмасы» исеме белән атап йөртелә. Әлеге басманың үзенчәлеге шунда: ул дастанның иң яхшы дип саналган кульязмаларыннан да сыйфатлырак булуы белән аерылып тора. Күрәсең, җыентыкны төзүче дастаннарның борынгырак һәм тулырак күчермәләре белән таныш булган.

С.Гыйләҗетдинов әсәрне шул басмадан алган, башка кайбер мәгълүм кульязмалары белән дә чагыштырып, хәзерге татар әдәби теленә якынайтып эшләгән. Чыганагы Р.Җиһаншин басмасыннан гыйбарәт текст, С.Гыйләҗетдинов тарафыннан басмага әзерләнеп, сүзлек һәм аңлатмалар белән «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгында да басылып чыкты.

Дастанның С.Кукляшев хрестоматиясеннән алынган тексты 1963 елда «Борынгы татар әдәбияты» дәреслек-хрестоматиясенә *(текстны Х. Мөхәммәтов әзерләгән)*, 1984 елда «Татар халык иҗаты. Дастаннар» җыентыгына кертелгән (Б. 102 – 106), 2004 елда шул ук текст «Татар эпосы. Дастаннар» китабында да басылган (Б. 381 – 385).

Төрле кульязмалардагы яисә басмалардагы «Гыйсә улы Амәт» текстлары, җөмлә корылышындагы кайбер лексик-синтаксик, чорга бәрабәр морфологик һәм шулай ук тулылык-кимлек ягыннан бер-берсеннән аерылып торсалар да, аларның һәркайсында сюжет, нигездә, бер үк.

*«Гыйсә улы Амәт» дастаны хакында мәгълүматны һәм дастан текстын журнал өчен әзерләүче – Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов ис. ТӘһСИнең баш фәнни хезмәткәре, доцент* **Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА**

## ГЫЙСӘ УЛЫ АМӘТ ТУРЫНДАГЫ ДАСТАН

Көннәрдән бер көн хәзрәте Җанибәк хан кош чөеп, ау ауларга чыкты. Җанибәк ханның хатыны Тайдула ханша йөкле иде. Хан әйтте: «Әй ханша, мин аудан кайтканчы бала туса, кыз бала туса үтер, әгәр ир бала булса, төшлек җирдән үзең сөйгән кешене сөенче сорарга җибәр, – диде. – Әгәр кыз бала туып үтермәсәң, үзеңне үтерермен», – диде.

Хан ауга киткәннән соң, Тайдула ханшаның күзе ярылды. Тәңре Тәгаләнең фәрманы белән кыз бала туды. Кызны үтермәде, Бирдебәккә җибәрде. Олы улы Бирдебәк кызны асрады. Аннан соң ханның үзенә кеше җибәрмәде, ханга каршы кеше бармады. Хан Җанибәк кыз туганын белде. Килеп, сарайга керде. Сорады, үтердеме, дип. Белгән иделәр, үтермәде бугай, диделәр.

Хан сарайга килде. Тайдула ханша каршы чыкты. Хан ук белән атты, ботына тиде. Хан инанмады. Ханша тугыз солтан анасы иде. Угланнарның ачулары килеп, аталарына сүз әйттеләр: «Угыл кирәк булса, тугыз улың бар, бер кыз баланы күпсенәсең», – диделәр.

Аннан соң хан, ачуланып, кызны үтерергә кеше җибәрде. Тайдуланың ике аргамагы бар иде. Бер аты Ашыкча дигән, берсенең аты Туйкычак дигән иде. Бу ике атны кушып, кызны качырсын дип кеше җибәрде. Бирдебәккә хәбәр төште. Кызны алып качты. Чиркәскә барып, мәкам-йорт тотты.

Җанибәк ханның бу эшенә халыкның күңеле яман булды. Улларын куа башлады дип әйттеләр. Хан, халыкның күңеле яман булганын белеп, беркөн әйтте: «Кем дә кем минем улымны китерә, кызымны аңа бирермен», – диде. Гыйсә углы Амәт әйтте: «Әй ханым, әгәр бүләк бирсәң, мин китерермен», – диде. Хан әйтте: «Хуш, алай булсын», – диде.

Гыйсә углы Амәт әйтте: «Син халык алдында ачуланышкан бул, – диде. – Мин анда барып алдаем, яхшы булыр», – дип. Бу эшләрне күп кеше белми иде. Амәт китәр көнне хан халыкка аш бирде. Үз кулыннан халкының барчасына аш ашатты. Аннан Амәтне өндәде, аңа тутырма бирде. Амәт әйтте: «Әй ханым, халыкка яхшы аш бирдең, миңа ни бирәсең?» – диде. Ханның бу сүзгә ачуы килеп: «Тотыгыз, үтерегез!» – диде. Амәтнең аты тышта хәзер иде, атка менеп качып китте.

Бирдебәккә барды. «Ханнан качып килдем», – диде. Бирдебәк Амәтне яхшы гыйззәт кылды, сыйлады. Беркөн Бирдебәк ау ауларга китте. Амәт бер корткага барып әйтте: «Мин сине ана итәрем, күп мал бирермен син барып әйтсәң, шул кызның миңа күңеле төшәрме?» – диде. Кортка әйтте: «Кыз итагатьле булыр, кызны белмим, ханша сине ошатыр». «Хуш, шулай булсын, барып әйт», – диде. Кортка ханшаның каршына барды, күзен ача алмады, утырган иде. Ханша әйтте: «Ни өчен йоклыйсың?» Кортка әйтте: «Һич дәрманым калмады, ханнан качып килгән Амәт би иркемә куймады», – диде. «Һичкемдә андый нәрсә күргәнем юк иде, – диде. – Күп кенә күргән идем», – диде. Ханша әйтте: «Барып китер, – диде. – Безнең белән уйнасын», – диде. Аннан соң кортка барып, Амәтне китерде. Үзе кайтты. Уйнадылар, көлделәр, гайре эш кылмадылар. Амәт әйтте: «Син ireңә әйт, мин синең белән йокалармын, диген. Кич белән ул килер, син аның белән җеп бәйләгеч уйнаган булып, бармагын бәйлә, чылбыр кагырсың, мин шунда килеп үтерермен», – диде. Кич булды. Бирдебәк килде, бер сәгать булды. Ханша чылбырны какты.

Амәт бинең бер колы бар иде. Ул колга кылыч бирде: «Барып, Бирдебәкне син кылыч белән чапкан бул, әмма кылычның йөзе белән чапма», – диде. Колы йөгереп килде. Бирдебәккә кылычның сырты белән тиде. Бирдебәк ачуланып: «Һай, бу ни эш?» – дигәндә, Амәт үзе йөгереп барып, колның кулыннан тартып алды, колын үтерде. Аннан соң ханшаны үтерде, ул кортканы да үтерде. Аннан солтан Бирдебәккә әйтте: «Алган хатының мондый эшне эшләде, бүтәннәр нәрсә эшләмәс, – диде. – Кил, ханга кайтыйк», – диде. Шуннан Бирдебәк әйтте: «Хуш, алай булсын», – диде. Күчеп кайтты. Амәт белән Бирдебәк үз илләренә кайттылар. Хан каршы чыкты. Мәнгәл дигән

байның өенә төштеләр. Җыелышып эчтеләр. Хан исереп йоклады. Мәңгәл байның Тимер атлы бер улы бар иде, һич кеше күргәне юк иде. Хан ялгыз ятыр иде. Мәңгәл улы Тимер килде, күркәм кеше иде. Хан күңеленнән әйтте: «Минем кызым моңарга икән», – диде. Ул угыл торып олылады. Амәт килде:

*– Охшармы бикләр, охшармы,*
*Монча дәүләт бар булса,*
*Аргамакның аягын*
*Ефәк белән юшармы?*

*Тимер икән таш аткан*
*Гыйса улы Амәт барында*
*Мәңгәл утлы Тимергә*
*Кызын бирмәк охшармы?*

Кырык кыркын яратып, Кырымга китте, кул теләде. Кырым мөселманга гаскәр бирмәде. Конткарга барды, ул тагын җибәрмәде. Аннан Кызылбашка барды. Кызылбаш Кырымнан куркып, ул да бирмәде. Кайтып, ил читенә килеп, шымчы җибәрде. Хан ауга чыкканда, кызын алып качты. Зөя тамагына барып, Идел якасында торды. Инде аны Кыз тавы диләр. Хан аудан кайтты. Амәт кызын алып качканын белде, кая киткәнен белмәделәр. Ике елдан соң хәбәре килде: йөкле, имеш. Ай-көн узды. Хәзер барган кеше алыр дигәч, хан гаскәр җибәрде. Өч йөз кеше белән Алачин Алауны баш итеп җибәрде. Җәй көне иде. Амәт биек тауның башында утырып тора иде, кыз ерактан карап күрде: берничә кеше килә, бер җирән атлы кеше. Артында белмим садагы, белмим кеше, диде. Бераздан Амәт үзе күрде. Алачин Алау ханнан килә икән. Ул вакытта углан туган иде. Бишеге белән алып килә алмады, бер агач ботагына утыртып китте, куйның койрык маен бала авызына каптырып, Тәңренә тапшырып, сугышка каршы бардылар. Алачин куып җитте. Атына атты, иярнең арт кашына тиде. Амәт әйтте: «Ант-шарт иткән дус идең, җанымны алырга булдың. Аткан алай атмас, болай атыр», – дип, аргамагын ега атты, ятып калды, янә үзгә аргамакка менеп килде. Тагын атты, атының ялын ияртә төште. Амәт тагын атты, янә ятып калды.

Алачин Алау бер бүз аргамакта менеп килеп җитте. Садактагы угын кырыйга атты. Амәт кармап бакты, бер угы бар икән. Килеп, атының умырткасының кырына атты. Ат егылды. Алачин атыннан егылды. Алачин Алау әйтте: «Әй дус, бер кашык каным үтенермен... антымны бозган идем, үземә килде, – диде. Амәт әйтте: «Ни күрсәң, аны йийгәйсең, – диде. Идел башына чыкты. Идел башында мәкам-йорт тотты.

Җанибәк хан үлгәннән соң, Бирдебәккә килеп кушылды. Ханның ярты йортын биләде. Ул вакытта Хаҗи Тарханда Тимер Котлы хан иде, улы-кызы юк иде. Ул заманда Хаҗи Тарханда бүрәнә актарырга барган кешеләр бер бала табып алып килделәр. Ханша ул баланы үзенә алып асрады. Бала үскәннән соң, Хаҗи Тарханда карак була башлады. Халык ул балага рәнҗеде: «Ханым, безне сөймәс булсаң, аны сөйсәң, аны тот», – диделәр.

Шунда хан әйтте: «Бу бер угыл белән ни булыр, миңа халкым кирәк», – диде. Угланны, салдан алып килгән өчен, Салчы дип атаган иде. Көннәрдән бер көн Салчы гаскәргә барды, анда Өчкиекле дигән җирдә уеннар өйрәнде: кубыз, думбра төрле уеннар өйрәнде. Анда-монда һәркем белән сүзгә килеп: «Әй атасыз-анасыз», – дип әйтер булсалар, ул әйтер:


*«Ак Сарайда балчымын,*
*Ана Иделдә Салчымын.*
*Хаҗи Тарханда байракчымын.*
*Атамны сорасагыз, белсәгез, никахсыз,*
*Үзем артык туган.*
*Соң төбем сорап нитәсез»,*

– дия иде. Салчы Җанибик ханның кызыннан туган угыл булыр. Ханнарга ана ягыннан туган угыл булды. Гыйса углы Амәт углыдыр.

Тәмам валлаһу әгъләм биссаваб.

# «АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ» ИСЕМЛЕ ФӘННИ-ПОПУЛЯР ҖЫЕНТЫККА БӘЯЛӘМӘ[1]

Татарстанның халык язучысы, Татарстан АССРның Г.Тукай һәм РСФСРның М.Горький исемендәге дәүләт бүләкләре, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый һәм С.Рәфыйков исемендәге әдәби премияләре иясе, Татарстан, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Аяз Гыйләҗевнең (1928–2002) әдәби һәм публицистик иҗаты татар әдәбият гыйльмиятенең, тәнкыйтьнең һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Соңгы өч дистә елда язучының күпкатламлы иҗади мирасын өйрәнүгә, дөнья әдәбияты мәйда-нында танытуга, әсәрләре хакындагы төрле дәвердәге әдәби тәнкыйтьне туплауга, классик иҗатны концептуаль якын килеп бәяләүгә әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова керткән өлеш бәһаләп бетергесез. Аяз Гыйләҗевнең шәхси архивында эшләү нәтиҗәсендә галимә тарафыннан язучының яңа академик алты томлыгы төзелде. Иҗади мирас рус, инглиз, төрек, венгр, хакас телләрендә дөнья күрде, драматургиясе аерым төрки халыкларның сәхнәләрендә беренче тапкыр тәкъдим ителде. Галимә татар әдибенең дөнья әдәбияты үсешенә керткән өлешен нигезләп, күпсанлы гыйльми хезмәтләр бастырды. Язучы аралашкан дөньякүләм мәгълүм иҗат әһелләре белән элемтә урнаштырып, М.Хәбетдинова венгр әдибе Арпад Галгоцины татар әдәби-мәдәни мохитендә танытты. Сәясәтчеләр, күпсанлы зыялылар, язучының гаиләсе истә-лекләрен барлап, фәнни җәмәгатьчелек алдында даими чыгышлар ясап килде.




«Аяз Гыйләҗев» фәнни-популяр җыентыгы – татар әдәбиятын дөнья әдәбияты мәйданында танытуны гыйльми тормышының кыйбласы иткән галимәнең чираттагы хезмәт җимеше.

Кереш сүзендә М.Хәбетдинова җыентыкны төзү максатын укучыга мөрәҗәгатендә аермачык белдерә: «А.Гыйләҗев – талантлы әдип кенә түгел, намуслы гомер кичергән милләт хадиме дә. Кадерле укучы! Китапны кулга алуга татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучыны искә ал, хөрмәтлә, укып ләззәтлән!»

Җыентыкны Аяз Гыйләҗевнең автобиографик язмалары ачып җибәрә. Биредә әдипнең 1972 елдан башлап 2000 еллар аралыгында иҗат ителгән тугыз язмасы туплап бирелгән. Беренче 1972 елгы «Үзем турында үзем» язмасында әдип үз иҗатының кыйбласын атый: «Туган илеңә, халкыңа бирелгәнлек, туган телеңә сүнмәс мәхәббәт – менә

[1]«Аяз Гыйләҗев»: исемле фәнни-популяр җыентык / төз. Хәбетдинова М.М. Казан: Җыен, 2023. 672 б.

ул язучының үзгәрмәс кыйблалары! Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп торса да, бу бөек төшенчәләр мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар». 1984–1989 еллар аралыгында язылган «Яра» повестеннан алынган «Үзем» бүлеге – җыентыктагы беренче бүлекне йомгаклап килгән кайма – әдипнең сайлаган кыйбласына тугрылыгын дәлилләү өчен урнаштырыла: «Мәңгелек – безнең изге җиребез, зәңгәр планетабыз. Мәңгелек – безнең зәңгәр күгебез, мәңгелек нурлы кояш, ягымлы-ягымлы ай, гомеребезне бизәп, бәйрәм ясап балкыган сансыз-исәпсез йолдызлар. Иделебез, сыгылмалы матур телебез, моңыбыз, Тукай, Сәйдәш... Безнең күңелләргә Бетховен, Шаляпин, Григлар да иркен керә, океан-диңгезләр, елга-дәрьялар, Кавказ-Кырым таулары да сыя, алар да синеке, син – кеше, синең күңелең күпне тели, күпне үз итә ала. Җан диләр, йөрәк диләр, татар халкы шулар уртасына Күңел дигән серле дәрья урнаштырган. Кеше Күңеле күзгә күренми, барлыгы беленми, әмма ул бар. Күңел кеше белән бергә туа, бергә ярала, әле ул буш була, тора-бара, тормыш тәҗрибәсе, хисләр, тәэсирләр, мәхәббәт белән байый». Аяз Гыйләҗев татар әдәбиятын дөнья әдәбиятының аерылгысыз бер канаты итеп күрә, иҗади мирасны милләтне дөньякүләм танытуга йөз тоткан мәрҗән дип күзаллый.

Икенче бүлектә язучының хатлары урын ала. Бүлеккә кереш итеп бирелгән «Хат – сәнгатьнең бер төре ул» исемле мәкаләсендә галимә хатларга әдипнең аерым әһәмият бирүен ассызыклый: «Хатларны саклау үтенече белән әдип якыннарына еш мөрәҗәгать иткән, ләкин, төрле сәбәпләр аркасында, күп кенә язмалар юкка чыккан. Ә инде сакланып калганнары безгә язучының тәрҗемәи хәлен өйрәнергә, шул чорга хас булган сәяси-иҗтимагый вакыйгалар турында фикер тупларга ярдәм итә». Шунысы да игътибарга лаек, М.Хәбетдинова соңрак А.Гыйләҗевнең эчке халәте төшенкелеккә үзгәрүенә басым ясый, хатлардан китеп, көндәлек жанрына мөрәҗәгать итүен язучының үз сүзләренә таянып нигезли: «Туксан икедә хатларны нык киметтем, хисләрне бүлешерлек, уйларны уртак итәрлек, сер чишеп җиңеләйтерлек адәмнәр калмады. Уйларымны ялгызлар тыкрыгына алып кереп киттем дә караңгы күлгә – «көндәлекләргә» яшердем».

Ике дистәдән артык хатлар әдипнең сөекле тормыш иптәше, гаиләсенә һәм ире сайлаган юлга тугры мөгаллимә Нәкыя Гыймадиева-Гыйләҗевага, хөр фикерле әдипләр, каләмдәшләре Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Галиев, Якуб Зәнкиев, Нәҗип Әсәнбаевка, «Казан утлары» редакциясенә, тәрҗемәче Искәндәр Гыйззәтуллинга, тәнкыйтьче Мансур Вәлиевкә, милләтпәрвәр шәхесләргә адреслана. Хатларда – әдипнең йөрәгендәге милли гамь, тирән әрнү-сызланулары, шул чор әдәби-мәдәни барышына мөнәсәбәтле тәнкыйди фикерләре, бәясе урын алган. Хатларны бер төпләмгә туплау принцибын аңлату өчен язучының 1982 елны М.Вәлиевкә юлланган хаттан өзекне китерү җитә: «Бүгенгедән Тукай, Такташ, Җәлилләр белән янәшә куярлык күпме хәзинәбез калыр? Дөрес, китапларның язмышын, язучыларның көч-куәтен билгеләү хокукы киләчәккә бирелгән, әмма мәсьәләнең болай куелышы да безгә таләпчәнлекне йомшартырга хокук бирми, киресенчә, без әдәбиятыбызның үсеш югарылыгы өчен һәрчак сакта һәм көрәштә булырга бурычлы. Без исә соңгы вакытта таләпчәнлекне бик нык йомшарттык, үзебезнең әдәби мирасыбыз янәшәсенә заман сынауларын уза алмаслыгы бүгеннән үк мәгълүм булган байтак әсәрләрне куярга маташабыз, безгә хәзер Ф.Хөсни дә классик, Г.Минский да классик, гел очраклы кешеләргә бөек гражданиныбыз Г.Тукай исемен йөрткән бердәнбер премиябезне бирәбез, мактаулы чуар ярлыкларябыштырабыз...» Әйтергә

кирәк, галимә М.Хәбетдинованың әдип хатларын бәяләгән фәнни хезмәтләрендә иҗади мирасның бу тармагына тулы анализ тәкъдим ителә.

Өченче бүлектә А.Гыйләҗевнең көндәлекләреннән өзекләр урын ала. Бүлеккә кереш вазифасын үтәгән «Уйларның төрмәсеннән котылу» ысулы» дип исемләнгән язмада китапны төзүче болай билгеләп үтә: «1992–1997 елларда көндәлек алып бару А.Гыйләҗевнең бурычына, кыйммәтле шәхси актына әверелә. Алга таба, авырып китү сәбәпле, әдип язмаларны мөстәкыйль рәвештә теркәп бара алмый башлый, һәм бу эш авырая». Бүлекнең башлам өлешендә галимә А.Гыйләҗевнең 1980 елны язылып, 2005 елны дөнья күргән «Мин шулай уйлыйм» мәкаләсен урнаштыра. Биредә 1960–1980 еллар әдәби барышында язучыны борчыган мәсьәләләр кабыргасы белән куела, туган әдәбиятларына киңрәк масштабта танылырга юл куймаган татар зыялылары, шул чордагы әдәби мохитнең чын милләтпәрвәр шәхеснең рухын җимерүгә йөз тотканлыгы фаш ителә: «Ничек исән калынган, дигәндә, Мәскәү коткарды. Мәскәү руслары, Мәскәү яһүдләре аралап калган, алар алга атларга көч биргән, дәрт өстәгән». 1992 елгы көндәлекләрдән өзекләрдә үзен «җирдәге хаклык өчен көрәшергә бурычлы санаган» әдипнең туксанынчы елларда урнашкан иҗтимагый шартларда, татар язучыларының рухи кыйблалары түбәнәйгәннән түбәнәя барган хәлдә әдәби-мәдәни барышның киләчәге өчен борчылуы үзәккә алынып тәкъдим ителә.

Җыентыкның дүртенче бүлегендә Аяз Гыйләҗевнең сигез сандагы әдәби-тәнкыйть мәкаләсе урнаштырылган. Биредә иҗат кыйбласына тугры каләм иясенең әдәбиятның «халык күңеленә үтеп керү» тиешлеге принцибыннан чыгып чордашларының иҗатларына тәнкыйди бәясе урын ала. Татар әдәбияты, һичшиксез, дөньякүләм яңгыраш алырга хаклы да, тиеш тә: «Әдәбият, башка бик күп бурычлары белән беррәттән, төрле-төрле халыкларны бер-берсенә якынайта, таныштыра, аларда дуслык, туганлык хисләре тәрбияли. Бу – аның иң изге бурычларының берсе. Һәм иң олы бурычларының берсе, дип тә өстәр идем мин. Әдәбиятның көчен бу өлкәдә һич бәяләп бетерерлек түгел. Әдәбият – шагыйрьләр, язучылар сүзе – илләр, чикләр аша үтә, дөньяның барлык почмакларына барып җитә. Димәк, әдәбият тормышыбызның гүзәл бер максатын – халыклар туганлыгына юл ачарга, аны ныгытырга тиеш». Бу җәһәттән, әдәби тәнкыйтьнең торгынлыгы, театр тәнкыйтьчеләренең үзәк матбугатка сирәк чыгулары, опера театры белән уртак тел таба алмау һ.б. күпсанлы проблемалар кабыргасы белән куела. Язучы һөнәренең бөтен нечкәлекләрен тоеп эш иткән классик әдип яшь язучыларга иҗатның асыл серен уйдырып сала: «...язучы үзенең беренче ныклы адымнарыннан ук, беренче җитди сүзеннән үк тирә-ягына, халкына, җирдәшләренә, милләттәшләренә үткен, уйчан күз белән карарга өйрәнсен. Чөнки туган телне белү, аның кадерле җәүһәрләрен барлау, әсәрләрендә аны туплау, ныгытып калдыру – язучының төп бурычларыннан берсе». Беренче адымнарыннан ук әдәбиятка намуслы хезмәт иткән әдипләр рәтенә язучы Ә.Еники, М.Әгъләмовларны кертүен әйтә.

Җыеп әйткәндә, галимә М.Хәбетдинова кыю, хөр фикерле әдипнең рухи батырлыгын тасвирлаган материалның сөземтәсен бер җыентыкка туплый. Җәмәгатьчелеккә Сталинның төрмә-лагерьларын үз башыннан үткәргән татар әдибенең Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романы басылуга дөнья күргән «Җан авазы» исемле саллы мәкаләсе тәкъдим ителә. Чынлап та, А.Гыйләҗевне борчыган һәр проблема, нинди генә нечкә һәм четерекле булуына карамастан, публицистик язмаларында урын ала. Әйтик, җыентыктагы «Имән чикләвеге» мәкаләсендә әдип шагыйрь Хәсән Туфан-

ның олылыгы алдында баш исә дә, күрми калырга ярамый торган хакыйкатьне билгеләп үтә: «Төрмә юлларын үткән, ничәмә-ничә ел «лаеш шулпасы эчкән» Туфанның чорыбызның бөек пәйгамбәре Александр Исаевич Солженицынга кизәнүен ни белән аңлатырга? Ул Солженицынны беренче сулышыннан ук танып алырга тиеш иде ләбаса?!»

Бишенче бүлеккә урнаштырылган унбер хатирә – әдипнең рухи батырлыгын ул яшәгән дәвердә үк таныган һәм бәяләгән шәхесләрнең истәлекләре. Биредә Татарстан Республикасының беренче Президенты, Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев, галимә И.Андреева, язучылар Г.Ахунов, Р.Зәйдулла, Ш.Рәкыйпов, Р.Вәлиев, А.Литвин, М.Галиев, Т.Галиуллин, Р.Мөхәммәдиев истәлекләрендә Аяз Гыйләҗевнең кулга алынуына сәбәп булган фактлар, әдипнең, М.Галиев теле белән әйткәндә, «Алласыз һәм тарихсыз татар прозасы вәкиле» булуга мөнәсәбәте, ниһаять, «каршылыклы фикерләрнең нык чәкәләшкән еллары»ндагы әдәбиятның чын йөзе ачыла.

Алтынчы бүлектә тәкъдим ителгән биш документ – Нәкый Исәнбәтнең 1961 елны язылган Аяз Гыйләҗевне Язучылар берлегенә алу тиешлеген дәлилләгән мәкаләсе, 1963 елны Мәскәүдә «Дружба народов» журналы редакциясендә «Өч аршин җир» әсәре турында фикер алышу стенограммасы, 1976 елда Татарстан Язучылар берлегендә «Күзгә-күз» повестен тикшерү беркетмәсе, Мөхәммәт Мәһдиевнең әдип иҗаты хакындагы 1977 елгы телевизион чыгышы, венгр әдәбияты вәкиле, тәрҗемәче Арпад Галгоциның 2018 елгы әдип иҗатына багышланган конференциядәге чыгышы стенограммасы – фәнни җәмәгатьчелек һәм әдәбият сөючеләр өчен бәһаләп бетергесез кыйммәтле материал.

Китапның соңгы бүлеге – татар әдәбиятын дөнья аренасында күрергә хыялланган әдипнең иҗади мирасы белән рухланып язылган Арпад Галгоци һәм татар шагыйрьләренең иҗат җимешләре, соңарган мәдхиясе, дияр идем.


«Аяз Гыйләҗев» дип исемләнгән әлеге фәнни-популяр җыентык – милләт хадименең иҗади мирасына бөтен дөньяга сибелгән төрки телле әдәбиятчыларның игътибарын җәлеп итәчәк китап. Әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова Аяз Гыйләҗевнең васыятен – милли әдәбиятыбызны дөнья аренасында таныту хыялын тормышка ашыру өчен күпер эшләп, иҗади мирасның каймагын бер җыентыкка туплап, киң җәмәгатьчелеккә бөтенлекле, саллы хезмәт рәвешендә тәкъдим итүгә ирешкән.

**Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА,**
*Казан федераль университеты доценты,*
*Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә*
*стратегик тикшеренүләр фәнни белем бирү*
*үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре.*

*Без яшь чакларда татар өенә килеп керсәң, түр башыннан урын тәкъдим итәрләр, һәм алдыңа бу гаиләнең иң кадерле елъязмасы булган фотоальбом китереп куярлар иде. Безнең өчен син – кадерле кеше, мин чәй-фәлән хәстәрләгән арада караштыра-таныша тор, дигәнне аңлата иде бу. Һәм чынлап та, андагы фотоларны күздән кичереп, таныш-белешләрне искә алып, тәгаен генә танып бетермәгәннәре хакында сораштырып утырган арада, сүз арты сүз ияреп, җылы һәм матур гына әңгәмә башланып китә торган иде.*

*Дөнья тиз үзгәрә торган булып китте, бүген инде килгән кунакны фото белән шаккатырып булмый, фотоның исәбе-хисабы югалды кебек. Һәм, дөресен әйткәндә, фотоның кадере дә бетеп килә түгелме икән. Компьютор яисә телефон эштән чыкса, алар еш кына юкка да чыга. Ә моңарга безнең исебез китми, әле яңаларын да төшерербез, дип юатабыз үзебезне... Шул рәвешле баштан кичкән вакыйгалар ерагая, хәтер тарая, үткәннәр белән элемтә югала. Аяныч күренеш...*

*Мин күргән-аралашкан кадерле затларның, остазларым, хәтта дус-ишләремнең дә күбесе инде бакыйлыкка күчкән бер заманда «Казан утлары» аша укучыларыма кайбер истәлекле фоторәсемнәр тәкъдим итәргә булдым. Кемнәр белән генә очрашылмаган, кемнәр белән генә сәяхәт ителмәгән һәм кемнәр белән генә гомер кичермәгәнбез. Бергә уйнап үскән дуслар, сабакташлар, каләмдәшләр һәм әллә кемнәр тагы...*



Ринат Мөхәммәдиев туган авылы Кече Кирмәннең (Мамадыш районы) җиләкле тау башында.



Миңа тормыш бүләк иткән әти-әни һәм туганнарым белән.




Бергә уйнап үскән дус-иш һәм классташларым арасында.



*Утырганнар (сулдан уңга): СибгатХәким, Риза Ишморат, Муса Җәлилнең хатыны Әминә Җәлил, Ринат Мөхәммәдиев, Шәмси Хамматов, басканнар: Нил Юзиев, Рафаэль Мостафин. Узган гасырның 80 нче еллары башы.*



*Армия генералы Мәхмүт Гәрәев белән.*



*Легендар шәхес, фронтовик-партизан, шагыйрь Зәки Нури (уңда) белән «Казан утлары»нда эшләгән еллар истәлеге.*



*Кунакчыл Балтач районында еш була идек... 1994 ел.*

*Фотолар редакция һәм Ринат Мөхәммәдиевнең шәхси архивларыннан алынды.*

# Uqucı süze
# Укучы сүзе

* * *

*Хөрмәтле «Казан утлары» редакциясе!*

*Сезгә олы хөрмәт белән даими укучыгыз хат яза. Бер гасыр инде халкыбызга хезмәт куючы, аң-белем таратучы, халкыбызның тирән тарихын, бөек шәхесләрләребезне барлаучы, аларның бай иҗатларын, тиңсез хезмәтләрен, гыйбрәтле гомер юлларын безгә җиткерүче кадерле, дәрәҗәле, бай эчтәлекле, олпат язучыларыбыз кебек мәртәбәле журналыбызга ихлас рәхмәт хисләремне җиткерәсем килә.*

*Быел журналның сигезенче санында Марсель ага Галиевның «Күңел кушуы» дигән язмасында «Ни кызганыч, бу гасырда инде кулга каләм-кәгазь алып, сырлап-чуклап хат язулар бөтенләй бетәр, ахрысы» дигән юллары искә төште. Әйе, тирән эчтәлекле, матур итеп хатлар язу гадәте югалып бара, хатларны хәзер компьютерда җыябыз. Телефонда котлаулар язу да юкка чыгып бара, тиз генә «әзер» котлауны бер-береңә күчереп җибәрү гадәте модада. Бик кызганыч, әлбәттә. Ә нинди җылылык ул хатларда. Марсель ага Галиевның «Хатлар яздым утырып» дигән рубрикасындагы хатлар укып туйгысыз! Хатлар язу-алу заманында тәрбияләнеп үстек без. Әтием хатларны бик матур итеп яза иде. Туганнары «Хәмзәдән килгән хатларны укып туеп булмый, анда нигез җылысы да, яшьлек тә, авылдашлар да... туган якларга кайтып килгән кебек булабыз», – дия иделәр.*

*Яраткан журналыма булган хисләремне хат аша юлларга булдым әле.*

*Рәхмәт Сезгә, хөрмәтле «Казан утлары» журналы редакциясе! Рөстәм Госман улы җитәкчелегендә искиткеч саллы хезмәт куясыз. Журналның традициясенә тугры булып, яңача яшәүдән дә артта калмыйсыз. Кечкенә чакта да әти-әниләрдән соң, чират буенча укый идем, инде үзем урта яшькә җитеп киләм, һәр санызызны яратып укыйм, көтеп алам. Журналны кулга алып, һәр битен актарып, үз иткән рубрикаларыннан башлап ахырына җитәм.*

*Журналның һәр санында яңа әсәрләргә дә, тарихи фактларга да, шигърияткә дә, фәнни күзәтүләргә дә, ихлас хатларга да, җылы тарихи фотоларга да һәм иң мөһиме – халкыбызның бөек шәхесләрен төрле яклап ачуга, аларның иҗатын, хезмәтләрен танытуга зур урын бирәсез. Бүгенге көн иҗатчыларын, тарихчыларны, галимнәребезне, читтә яшәүче милләттәшләребезне дә, төрки халыклар иҗатын да барлыйсыз.*

*Мисал өчен быелгы саннарга әз генә күзәтү ясасаң да, күп кенә әсәрләрне атап китәр идем. Марат ага Әмирхановның тарихи «Яугирә»се безне ерак тамырларыбызга алып кереп китте, Хисаметдин ага Исмәгыйлев «Таш түккән – сихри боҗра»сы белән бүгенге заман афәтләрен ачып салды. Асия апа Юнысова ихлас бәяннары белән җаннарны кузгатты. Илдус ага Заһидуллинның тарихка күзәтүләре бик бай һәм бик кирәкле.*

*Менә журналның 7, 8 һәм 9нчы саннарында Рафис ага Корбанның «Артык кешеләр» исемле роман-эссесы дөнья күрде. Татар музыкасына нигез салучы олы талант иясе, бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевкә багышлап язылган әсәрдә күпме язмыш, күпме тарихыбыз урын алган. Рафис агага китап укучылар исеменнән олы*

*рәхмәтләрем! Аның алдагы елларда журнал битләрендә бастырылган, халкыбызның бөек шагыйре, патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә багышлап язылган «Ватан» романы да искиткеч гыйбрәтле әсәр иде.*

*Журнал язучыларыбызның тәүге әсәрләрен биреп бара, яңа исемнәр ача.*

*Журнал уйландыра. Тарих чоңгылларына чумдырып, җанны сызландыра. Хакыйкатьне ача… Әрнетә. Тарих кабатланышын күрсәтә.*

*Мин журналда бирелгән күп материалны мәктәп программасына кертер идем. Балалар үз тарихыбызны белергә тиеш.*

*Яраткан һәм олпат шагыйребез, «Казан утлары»нда чирек гасырга якын баш мөхәррир вазифасын башкарган Равил ага Фәйзуллинның 80 яшьлеге уңаеннан журнал битләрендә «И Казансу!..» дигән шигыре урын алды. Андагы «Идел суына кушылып, тоташасың диңгезгә. Син – чишмә дә, син – инеш тә, дәрья дә син безгә! И Казансу, Казансу!» дигән юллары журналга карата да туры килә кебек. Илебез, дөнья тарихында татар халкының тоткан урынын билгеләүче, тарихын гәүдәләндерүче, дәрәҗәсен билгеләүче, горурлык хисләре тудыручы, тарихны төшендерүче журналыбыз турында «И Казан утлары, Казан утлары!» диясе килә.*

*Рәхмәт Сезгә! Иҗади уңышлар!*

*Олы хөрмәт белән,* **Гөлназ ИСМӘГЫЙЛЕВА**
*Казан*

## ЯҢАЧА ЯЗЫЛГАН РОМАННАР

*Рафис Корбанның «Казан утлары»ның 7, 8, 9 нчы саннарында урын алган «Артык кешеләр» романын зур кызыксыну белән укып чыктым. Әсәрдә татарның иҗаты белән кабатланмас композиторы Салих Сәйдәшевнең тормышы, иҗаты, ул яшәгән мохит шактый кызыклы рәвештә ачыла. Композитор тормышының без белеп җиткермәгән яклары яктыртыла. Анда тасвирланган вакыйгалар һаман күз алдыннан китмичә, күңелне тетрәндереп, искә төшеп тора. Әмма бу язмада әсәрдәге вакыйгаларга тукталып тормыйча, гомуми фикер генә әйтеп үтәсем килә.*

*Соңгы елларда Рафис Корбан зур активлык белән бер-бер артлы романнар иҗат итә башлады. Әйтергә кирәк, ул бу жанрда бик уңышлы эшли. Романнар нинди сыйфатлары белән үзенә тартып тора соң? Беренче чиратта, аларның безнең әдәбиятта моңарчы булмаган яңа алым белән иҗат ителүен әйтер идем. Хәзерге вакытта без кайнап торган мәгълүмат дөньясында яшибез. Рафис Корбан заманның шушы үзенчәлеген истә тотып, романнарындагы геройлар турында кызыклы мәгълүматлар китерә, роман тукымасын һаман саен баета бара, һәм бу үзенчәлек укучының игътибарын үзенә җәлеп итә. Шушы сыйфат роман геройларының тирәнрәк ачылуын тәэмин итә. Шушы алым «Артык кешеләр»дә генә түгел, аның башка әсәрләренә дә хас. Бу безнең прозада барлыкка килгән өр-яңа күренеш дип әйтер идем. Автор әсәрләрендә республикабыз тарихында булып узган хәтәр елларда иҗат әһелләренең нинди авырлыклар кичерүен, кайберләренең сәяси басым йогынтысында рухи яктан сынып ук китүен ышандырырлык итеп тасвирлый. Әлбәттә иҗат әһелләренең шундый хәлгә төшүен күрү авыр тәэсир калдыра. Әмма ул елларда вазгыять шундый булган. Мәсәлән, Хәсән Туфанның Салих Сәйдәшевне гаепләп язып чыгуы турында укыганда аптырап та куясың. Шул ук вакытта гыйсъянчы Такташның үз вафаты алдыннан Солтангалиевне тукмавын белү дә ул еллардагы вазгыятьнең нинди катлаулы һәм рәхимсез булуын күрсәтә.*

*Гомумән, Рафис Корбанның без белгән иҗат әһелләре турында романнар язарга керешүе – хуплауга лаек күренеш. Бу бит безнең әле яңа гына үтеп киткән, тарих буларак кабул ителеп тә бетмәгән тормышыбыз. Шулар турында язып, автор аларга*

*бәя бирә, гыйбрәтле вакыйгалар аша киң катлам укучыларның күзен ача, аларны уйланырга мәҗбүр итә.*

*«Артык кешеләр» романын укып чыкканнан соң Салих Сәйдәшевнең нинди шартларда яшәве, канатланып иҗат итүе, Кәрим Тинчурин белән берлектә музыкаль драма жанрына нигез салулары, шәхси тормышында кыенлыклар кичерүе, еш кына үзен бу тормышта артык кешедәй хис итүе романда тормыш вакыйгалары аша җентекле рәвештә сурәтләнә.*

*Гомумән алганда әле яңа гына дөнья күргән «Артык кешеләр»не дә, Рафис Корбанның «Ватан», «Әхмәров», «Җидегәннән төшкән нур», «Алиш» романнарын да мин безнең әдәбиятта яңалык күренеше дип кабул иттем.*

**Солтан ШӘМСИ**
*Казан*

## ХӘТЕРЛӘР АЧЫЛЫРМЫ?..

*Татар хатын-кызлары образын төрле яктан, төрле язмыш сынаулары аша ачкан әдәби әсәрләр белән беррәттән, публицистика, рәсем һәм скульптура сәнгате, киноэкраннар күптән инде тормышыбызга үтеп керде. Мәгълүм, халык авыз иҗатыннан башлап, татар хатын-кызы образы – патша кызы, дус кыз, илһам чыганагы, көндәш, кәләш, «бичара», хуҗабикә, ак әби, хәтта, сугышчы, үч алучы, «советлаштырылган» явызлык чыганагы, сихерче кебек рольләрдә ачылды. Образлар укучы күз алдында матур яки ямьсез, сөйкемле һәм кара йөзле булып килеп басты.*

*Татар әдәбиятында да шулай: күптөрле һәм кабатланмас хатын-кыз образлары инде бихисап күп булса да, һәр рәссамның сурәте, язучының сүзе – ничек кенә булмасын, яңадан барлыкка китерелгән үзгә «тавышы» төсләрнең, ярымтөсләрнең, буяуларның, сүзләрнең исәпсез-хисапсыз байлыгыннан хатын-кыз образларының яңа бер төрен барлыкка китерә, хатын-кызны яңадан ачу, күрү мөмкинлекләрен тудыра.*

*Рәдиф Сәгъдинең хатын-кыз образын үзәккә алган «Әлмирәнең хәтере ачыла» («Казан утлары» журналы, 11-12нче саннар, 2022 ел) романына тукталып, төп героиняның тормышына һәм аерым сыйфатларына җентекләбрәк тукталасы килә. Шуңа бәйле, төп идеяне ачарга омтылыйк.*

*Кагыйдә буларак, татар әдәбиятында үзәк урынны яулаган ханымнар – милли җанлы, үрнәк персонажлар. Р.Сәгъдинең дә героинясы шундый, Әлмирә – тормыштан алынган реаль, үрнәк шәхес.*

*Милли традицияләргә тирән хөрмәт саклаган, әхлакый кыйммәтләрне үзәккә алган чын татар гаиләсендә тәрбияләнә Әлмирә. Инде үсеп буй җиткәч, мәктәпне бик уңышлы тәмамлап, абыйсы, Казан шәһәренең үзәгендә урнашкан данлыклы Камал театры рәссам-мөхәррире Әхмәт Закиров кебек үк, рәссам булу хыялы белән Санкт-Петербургка юл ала. Ә анда аны очсыз-кырыйсыз хаталар, сынаулар, шатлык һәм борчулар көтеп торган икән...*

*Шулар арасында иң зур хата дип, автор, Әлмирәнең рус егете Роман Мартынияновичка кияүгә чыгуын күрсәтергә тели кебек. Әлбәттә, мондый никахның азагы үкенечле тәмамлануын ачкан әсәрләр безнең әдәбиятта җитәрлек. Т.Миңнуллинның «Илгизәр + Вера»сы гына да ни тора! Әлмирәнең дә гаилә тормышы күңелсез тәгәлләнә. Дөрес, автор бәхетсезлектә Роман яки Әлмирәне генә гаепле итеп, сәбәп аларның төрле милләт вәкилләре булуларында, төрле тәрбия алуларында дип кенә ассызыкларга теләми. Сәбәп тирәндәрәк – ул җәмгыять, аерым бер төркем тудырган сәясәт, карашлар белән бәйләнә. Романның әнисе – Алевтина Ивановна*

*да, каяндыр, кемнәрдәндер ишетеп, бәлки, укып та, татар милләтенә тискәре карашта тәрбияләнгән, шуңа бәйле рәвештә ул Әлмирәне үз итәргә, гаиләсенә кертергә теләми. «...озын буйлы пәһлеван гәүдәле, унсигез яшендә «Динамо» волейбол командасы капитаны» дәрәҗәсенә ирешкән Роман, әнисе каршысына «матур, тәртипле, акыллы» Әлмирәне китереп бастыргач та, татарларны «басурманка», «монголоид», «сихерче» дип инанган әнисен уеннан кире кайтара алмый. Мондый вакыйгаларда, һәр уңайлы форсаттан файдаланып, автор «Анна Ахматованың улы – бөек тарихчы, искиткеч шәхес», «татарларны чын күңелдән яраткан, ихтирам иткән рус кешесе, татар тарихын дөресләп язган, шуның аркасында күп явызлыклар күргән галим» Лев Гумилёв исеменә басым ясый, аның татарлар турындагы язмаларын укучы хәтерендә кабат-кабат яңарта. Нәтиҗәдә, чынбарлыктан алынып, әдәби яссылыкка күчерелгән гадәти тормыш-көнкүреш вакыйгалары тирәнрәк эчтәлеккә байый башлый, Рәдиф Сәгъди тарафыннан максатчан рәвештә, әсәрнең тарихи кыйммәте арттырыла. Алга таба, төп идеяләрнең берсен – татар милләтенең зурлыгын, бөеклеген дәлилләргә алынган саен, әлеге затлы галимнең исеме кызыл җеп булып кабатлана бара. Бу – авторның Алевтина Ивановна кебек татарларга нисбәтле ялгыш карашта торучыларга җавабы да: «Имеш татарлар кыргыйлар, бернинди цивилизациясе дә юк, дип төшендерделәр. Ә Гумилёвны тыңласаң, сездән дә дан-шөһрәтле халык юк икән».*

*Аерым вакыйгаларда Әлмирә Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повесте герое Гөлбануны да хәтерләтә. Ире Роман белән аерылгач та, аның өендә яшәргә мәҗбүр бу героиняның ныклыгын күреп, гаҗәпкә каласың: «Унбиш көн дә үтмәгәндер, аларның гаиләләре таркалды. Алевтина Ивановнаның шатлыгы эченә сыймады. Улын тизрәк Танюшага өйләндерергә иде дип тырышты. Ике айдан бу хыялы да тормышка ашты. Шуннан бирле Әлмирә үз бүлмәсендә улы белән генә бикләнеп яшәде».*

*Рәдиф Сәгъдинең «Әлмирәнең хәтере ачыла» әсәрен укыган вакытта, Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романы да хәтердә яңарды. Зөләйха кебек, әсәр дәвамында Әлмирәнең дә күзләре ачыла бара: әмма бөтенләй башка яссылыкта, башка югарылыкта. Роман белән килеп туган проблемалардан соң, Алевтина Ивановна тарафыннан хаксыз кимсетүләр ишеткәннән соң, төп героиняда милли тарих белән кызыксыну тагын да арта, күбрәк белгән саен күңелендә милли горурлык үскәннән-үсә, үз милләтенә дәлилле карашы, хөрмәте ныгый. Хакыйкать – хаксыз рәнҗетүләр җәзасын ала: гомер азагында Алевтина Ивановна гына түгел, инде тормышның төпкеленә үк тәгәрәгән Роман да яшәешнең үзе тарафыннан ук күңел газабына, үкенечләргә дучар ителә.*

*Мәгълүм ки, 1990 нчы еллар Россия тарихына бик каршылыклы, куркыныч еллар булып кереп калды. Кайберәүләр өчен бу чорлар бандитлар, талау һәм атышлар белән бәйле булса, кемнәрдер аны яңа чыккан магнитофон тартмалары, беренче кәрәзле телефоннар белән хәтерлидер. Рәдиф Сәгъди дә әсәрендә бу тарихи дәверне читләтеп үтми, дөресрәге, үтә алмый. Чөнки төп героиняның язмышы да узган гасырның 90нчы еллары белән бәйләнә. Романда әлеге чорның тасвиры, һәм сәнгатьчә бирелеш яссылыгында, һәм тарихи яссылыкта да югары бәяләнергә хаклы: «...болганчык, дөньяның асты өскә килгән, адәм баласының гомере бер тиенгә дә тормаган куркыныч чорлар башланды! Әле анда үтерәләр, әле монда яндыралар, талыйлар-суялар, һәркемнең үз хәле хәл!» Әсәрдә бу вакыйгаларның сәнгати яктыртылышына тукталып, язучы иҗатына багышланган очрашуда Камил Кәримов та: «Дөресен генә әйткәндә, детектив язучыларыбыз безнең бармак белән генә санарлык дисәк тә, Рәдиф Сәгъди исемен әйткәч, туктап калырга туры килә. Ул баррикаданың теге ягын да, бу ягын да яхшы белә. Җинаятьчеләрне дә белә, җәзаланган кешеләрне дә белә. Ул шулкадәр шәп белә, 1990 нчы елларда Рәдиф*

*Сәгъди баррикаданың кайсы ягында йөрде икән дигән уй туа хәтта», – дип, юкка гына басым ясамады, әлбәттә.*

*Мондый буталышларны Алевтина Ивановна да үз файдасына кулланырга омтыла: иң кулай юл – Әлмирәне куркытып, прорискадан төшерү. «Банда»лар кулына күчкән илдән бандит Лёханы табу Алевтина Ивановнага зур кыенлык тудырмаган булса кирәк. Әмма, бу урында да каршылыкларга бай романга каршы кую теркәгече кабат килеп керә: роман вакыйгалары аша фикер йөртсәк, бу катлам арасында да гадел «хөкемдарлар» булган икән. Шулар арасыннан, тормышының иң авыр вакытында Әлмирәгә ярдәм кулы сузган, хәтта, матди ярдәм күрсәткән «курку белмәс, зәп-зәңгәр янып торган күзле» Артур, автор тарафыннан яратып, хөрмәт белән тасвир ителгән геройларның берсе. Бәхәссез, прототип тормыштан алынган (кем белә, бәлки аның турында әле кабат әсәрләр язылыр). Әсәр геройларыннан Валентина Валерьевна-Валя биргән бәя бу образны тулырак ачарга ярдәм итә: «Якташың, Казан егете! Бик намуслы, ярдәмчел шәхес! Җинаятьчеләр арасында мондыйлар бармак белән санарлык». Дөрес, аның турында автор алдарак та мәгълүматлар биреп уза. Балтач кешесе Миңвәли һәм «Песков бандасы» – Абрам Николаевич белән бәйле вакыйгалар, хаксызлык, явызлык күренешләре укучы тарафыннан әкияти сурәтләр – явызлык һәм аның җәза алуы кебек кабул ителә. Әмма, реаль чынбарлык, татар Робин Гуды биредә дә гади авыл кешесен яклаучы, гаделлек символы буларак ачыла. Аның Лев Гумилёв лекцияләренә йөрүе һәм милли тарих белән кызыксынуы исә – теләсәк-теләмәсәк тә аңа карата тирән соклану хисләре уята.*

*Язучы, галим Тәлгат Галиуллин «Сәет Сакманов» исемле трилогиясен язып, мондый төр геройга мөнәсәбәтле каршылыклы уйларга сәбәпче булган иде инде. Чөнки тормыштан алынган, язучының сәнгати хыялы ярдәмендә баетылган Сәет Сакмановка күпләрнең мөнәсәбәте уңай булып, хуплаучылары да бар иде. Әмма, уңай мөнәсәбәттә калган хәлдә дә, әлбәттә, аны үрнәк герой кысаларына кертеп булмый, ул мондый таләпләргә җавап бирми иде. Автор үз вакытында Россиядәге шул дәвернең киң панорамасын ачып, чор шартларының Сәет Сакмановны бу юлга басарга мәҗбүр итүен дәлилли һәм укучыны да шуның белән кызыксындыра алды. Рәдиф Сәгъдинең әсәрендә исә Артурга артык зур урын бирелми. Әмма, Сәет Сакмановтан аермалы буларак, тасвирланган һәр ике вакыйгада да ул уңай яклары белән генә ачыла, һәм, күңел түрендә бер якты, үрнәк образ булып балкый башлый.*

*Гомумән, романның сюжет сызыгында кызыклы образлар күп: Лиза һәм Валя, Исрафил, Анастасия Ивановна, вахтёр Вера Андреевна – һәрберсе тормыш дәреслеге кебек.*

*Лиза һәм Валя – Әлмирәнең бүлмәдәшләре, дус кызлары. Бер яктан караганда, алар Әлмирә кебек түгел, тормышка карашлары, тәрбияләре тәнкыйть тә ителергә хаклыдыр. Әмма, авторда андый фикер юк, ул кемнедер гаепләргә яки мактарга алынмый. Кызлар гадел, эчкерсез, ярдәмчел, әмма, аларда башка караш, башка минталитет. (Валя соңрак чит илдә, СССР илчелегендә хезмәт итә). Шуңа күрә, автор карашы артыннан барсак, аларны ничек бар, шулай кабул итү дөрес, һәм бу – хакыйкатьнең үзе! Шуны ассызыклау өчен булса кирәк, бу героиняларны сурәтләгәндә автор, Әлмирә авызыннан аларны ачу өчен «дуамал баш, җанкисәккәем», «акылсыз матурым» кебек бик назлы, яратып ачулану сүзләрен «әйттерә».*

*Инде, тулы бер картина тудыру өчен романда урын алган тагын бер геройга, Әлмирәнең «Исрафил абыйсы»на тукталу үзен аклар.*

*Авылда тәрбияләнгән Исрафил, Әлмирә кебек үк гади, саф, «ярдәмчел, чибәр» герой, Әлмирәнең яшьлек мәхәббәте. Зур тормыш сынауларыннан соң, Әлмирә, бәхетен нәкъ менә аның белән таба. Романда лирик чигенешләр бу герой белән бәйләнә һәм ул укучының акылын кайнап торган чор вакыйгаларыннан аралап, хисләр дөньясына алып кереп китә.*

*Дөрес, романда мавыктыргыч мәхәббәт тарихы тасвирланмаган, әмма анда тыныч, акыллы, саф, әмма газаплар һәм ялгышлар белән тулы чын ярату бар. Исрафил һәм Әлмирә мөнәсәбәтләре романда төп мәхәббәт линиясе, «мәңгелек, чын сөю» темасы булып тора. Бу тарих турында язганда, ир-егет һәм хатын-кыз арасындагы хисләр турында гына түгел, ә туган җиргә, кешеләргә, иң мөһиме, туганнарга һәм милләткә булган мәхәббәт турында сөйләшү дә дөрес булыр кебек.*

*Романның үзәгенә алынган, төп конфликтны әйдәп баручы уңай һәм тискәре геройларны дәвамлырак төстә күрсәтү белән бергә, автор аерым тарихи шәхесләрнең эпизодик образларын да тудырырга омтыла. Бу образлар бер яктан, Әлмирәнең тормышка карашы формалашуын чагылдыруга ярдәм итсә, икенче яктан, бу образлар чор әдәбият-сәнгать әһелләренең яшәешен, томышка карашын, рухын, уй-омтылышларын гәүдәләндерү максатында да файдаланыла, өченчедән, тарихи исемнәр кабат тарихка теркәлә. Абыйсы Әхмәт Закиров белән якын аралашкан зыялылар, татарның атаклы әдәбият-сәнгать әһелләре Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Марсель Сәлимҗанов, Рафаэль Сәхәбиев, «яшь бәрән йонын хәтерләткән бөдрә чәчле, итләч калмык битле, көр тавышлы» Туфан Миңнуллин, «җирән чәчле, сипкелле, тик шулай да сөйкемле» Шәүкәт Биктимеров, эпизодик персонажлар гына булсалар да, истә калалар, һәм, әсәрне төрле төсләр белән баетып, югарырак баскычка күтәрәләр.*

*Чыннан да, татар әдәбияты тарихында язучы Рәдиф Сәгъди исеме бар, һәм ул инде күптәннән талантлы язучылар рәтендә. Аны укыйлар, яраталар, бәялиләр.*

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА**
*филология фәннәре докторы.*

## ГАДИ БЕР ФИКЕР

*(Факил Сафинның «Күкләр җиргә тоташкан» әсәренә мөнәсәбәттә)*

*Әдәбият өчен күтәрелмәгән тема-проблемалар, сурәтләнмәгән герой-характерлар, яшәеш төсмерләре инде калмагандыр да сыман. Ә, юк, Аллаһы Тәгаләдән салынган иҗат дәрте, куәсе бәреп чыгарга җирлеген, сәбәбен барыбер таба тора. Талантлы каләм сурәтләү объектын үз «төше» белән күрсәтә белә. Танылган язучы Факил Сафинның «Күкләр җиргә тоташкан» исемле яңа повестена карата фикерләремне шушы җөмләләрдән башлап карыйм әле.*

*Әлеге әсәр «Казан утлары» журналының 2023 елгы беренче санында дөнья күрде. Әсәр укучыны иҗатчыга якынайта торган алым белән башлана. Автор укучысы белән диалог кора. Бу әсәр нинди уңайдан язылган, уй-фикерләрен, күргән-белгәннәрен, хатирәләрен җиткерергә нәрсә этәргән? Әйтергә кирәк, бу алымны язучылар бик яратып кулланалар. Укучы, билгеле, бер хисси дулкынга көйләнә, иҗатчының сурәтләрен ихластан кабул итә, сурәтләнгәннәрне тормышчан итеп кабул итә. (Шәхсән, мин үзем мондый әсәрләрне укырга бик яратам. Г.Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр», Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Ә.Еникинең «Матурлык», Ф.Садриевның «Рәхмәт, әтием!» әсәрләрендә шушы алым кулланылган. Авторлар сурәтләнгән геройлары белән таныш булуларына, аларның көндәлекләренә, хатларына ишарә итәләр.) Хикәяләүче – балачагы, үсмер еллары 50нче еллар ахыры – 60нчы елларга туры килгән герой. Бәян ителәчәк вакыйга – хәлләрнең үзәгендә торган «Коры» кушаматлы авылдашы Әлфир агайны белә ул. Аның күңелендә әлеге авыл агаена мөнәсәбәтле хатирәләр яңара башлый. Аңлы тормышындагы иң тәүге хатирәләр яше җитлегү тәртибендә хронологик рәвештә үстерелә, бер-берсен тулыландыра бара. Әлеге дә баягы хикәяләүче авыл тормышын, чынбарлыгын, кешеләренең шул*

*чордагы психологиясен, көнкүрешен яхшы белә. Халыкның хәерчелеге – күңел байлыгы, ихласлыгы – хәйләкәрлеге, чарасызлыгы – тапкырлыгы, җорлыгы һ.б. әдипнең халыкчан сурәтләргә бай теле белән шулкадәр оста тасвирланган ки, әсәрне укыганда хис-сагышлардан күңелең бер елый, бер көлә. Автор әлеге чордан бераз читкәрәк баскан да, хәзер инде өлгергән шәхес буларак, чорга бәясен бирә, киләчәк өчен идея-фәлсәфәсен җиткерә. Алда әйтелгәнчә, повестьның үзәк герое – «Коры» кушаматлы Әлфир. Үз чоры авылының кешеләреннән аермалы буларак, ул чит җирләрдә яшәп караган. Белем дәрәҗәсе ягыннан да беркадәр өстенрәк тора. Геройның холкы-гамәленә хас «төш» исә шунда, ул һәрнәрсәнең «закунлы» булуын таләп итә. Ничә еллар буе френчлы, галифелы кешеләрдән куркып-өркеп яшәгән, хокук нечкәлекләреннән бихәбәр, әмма җае чыкканда «закунны» бозарга гына торган кемсәләрне һәрчак аның сагында уяу торган органнар белән куркыта белә ул. Дөрес, һәркемне түгел. Урлашканнарны, кеше хакына кергәннәрне, алдашканнарны үз урынына утырта. Юрганыңа карап аягыңны суз. «Эшләпәле» радио гына тиеш икән, син шуны гына тыңларга тиеш. Көчлерәк динамикалысын заманчарагын әлегә кулланырга ярамый, чөнки синекенә энергия күбрәк алынып, башкаларныкы чыш-пыш кына килергә, яисә бөтенләй сөйләмәскә мөмкин. Тәртип тек тәртип. Авыл җирлегендәге радио өчен җаваплы абзагыз тиешлесен таләп итә. Тәртипне бозасыз икән – рәхим итегез – законны бозган өчен чәпәү тиеш. Закон буенча җавап бирерсез. Сельпога, кибетләргә килгән товарга хак ничек куелган – шул хакына сатыламы? Авыл кешеләренә бүленеп тә, читтәгеләргә шудырылмыймы? Әһә, тотылдыңмы, кибетче апа? Халык контроле вәкиле итеп сайланган абзагыз кая кирәк – шунда язып бирер. Нигә, тикшермичә-нитмичә, гаепсез балага яла ягасың син, иптәш милиционер? Ә сез, сайлауга җаваплы итеп куелган иптәшләр, минем өчен хатыннан бюллетень ташлатып, закон боздыгызмы? Җиткерәм, чарасын күрерләр, сезнең кырын эшләрегезне сизеп торам мин, менә шуңа күрә сайлау вакыты төгәлләнергә нәкъ унбиш минут кала гына килдем дә мин. Шулай, Коры Әлфир абзагыз йомшак ягыгызны сиземли ул. Авыл халкы да төшеп калганнардан түгел. Ул да белә шул бу Корының йомшак ягын. Аның «корылыгын» юешләтергә чара бар. Эшләр тирәнгә китә башласа, кирәге булыр әле дип яшереп куелган «ярты» чыгарыла. Монда инде Коры абзыебыз принципларын читкә куя. Менә шулай, гамәлләре дөрес, ләкин бик үк дөрес тә түгел бу абзыйның.*

*Төп идея өчен аның холык-гамәлендә әһәмиятлесе шул: тәртипсезлекләргә битараф түгел, закуннар белән куркыта гына, әмма беркемне дә барып әләкләми! Бүгенге кыйшык көзгеле заман өчен бик тә мөһим җан авазы. Кем ничек кабул итәр, ә мин бу әсәрне бер тында укып чыктым.*

**Лилия ХӨСНЕТДИНОВА**
*Яр Чаллы.*

## Миргазиян Юныс хатлары

*9 февраль, 1988 ел. Голицыно*

Великий эстет, татарский Сартр, Марсель Пруст, сәлам Сиңа!

Фәрваз миңа Синең рецензияне биргән иде. Югалтканмын. Мәһдинең соңгы китабы эченә салып куйган идем, бергә югалганнар. Какая честь. Тарихка керәчәк вакыйга бу, онытма. Югалту дигәннән, Казанга соңгы баруымда ике кумирымны югалтып кайттым. Һәм ике табыш ясадым. Берсе Син. Бу табыш менә нәрсәдә: Рашатның хатыннан синең рецензиядә тәнкыйть барлыгын аңладым. Тәнкыйть бит безнең чорда тере мамонт, полакантус балыгы дәрәҗәсендә дефицит. Синең тәнкыйтьнең игелек теләү белән сугарылган булуы (хаттан ул да аңлашыла) – бусы инде минем өчен теге ике югалтуны капларлык нәрсә. Син һәм Рашат шикелле егетләр яшәсеннәр иде әле. Аллаһы Тәгалә сезнең икегезне дә саклый күрсен. Намаз артыннан һәр көн шул доганы укырмын мин сезгә.

Соңгы баруда мин унтугызынчы гасыр азагында татар Ренессансы булуын һәм аны теге асфальт астыннан тишеп чыккан үлән шикелле булса да, җәмгыятькә чыгуы һәм тагын бер хакыйкать – Казан шартларында иманны, гражданлык хисен саклавы искиткеч авыр нәрсә икәнне аңлап кайттым. Сезнең буынны мин начар беләм. Өлкәннәрдән шул язучы өчен архизарури ике сыйфатны Н.Фәттахта һәм Ә.Еникидә генә күрәм шикелле мин. Менә бит Казанга бару нинди зыянлы нәрсә. Переоценка ценностей, потеря иллюзий и невинности...

Голицынодагы иҗат йортында ике чуваш, ике башкорт, ике бурят, хәтта лезгиннар да икәү һәм шулар арасында Лобанов (кара йөрәкләрнең алласы). Ә татарлар юк. Нилектән бу?

«Европа ат сагына»ны, Алла боерса, исән-сау булганда, мин баштанаяк эшкәртеп, кондициягә җиткерәчәкмен. Теге Сусликовка багышланган эпилогны алып ыргытырга туры килер. Мин бит дустым Хәбибуллиннан көнләшеп, тулысынча аңа подражать итеп, аның укучыларын үз ягыма аудару нияте белән эшләгән идем. Менә бит ул! Көч җитмәгәнне күтәрмә, буең җитмәгәнгә үрелмә икән... Ләкин әсәрнең язмышын сыйфат түгел, Ул хәл итәчәк.

Татар язучыларының иманлыларының барысына да сәлам һәм ак теләкләр. Ә Сиңа иҗат уңышлары.

*Миргазиян Юныс.*

**P.S.** Мин нәрсә эшлим иҗат йортында, Бөек Гыйбадәтханәдә? Беренче көнне киез итек сатып алган идем. Бер тапкыр киеп чыктым – чалбар, оекбаш, аяклар чем карага буялды. Мин аны кер порошогы белән юдым. Кат-кат юдым. Кипкән иде – тәбикмәк тә түгел, көлчә дә, медузага охшашлы нәрсә. Инде атнага якын шуны чылатам да элекке рәвешенә кайтарырга азапланам. Булмый. Менә бүген аңладым. Аны калыпка утыртырга кирәк икән. Көне буе агач эзләдем. Бер-ике көн агач эзләүгә китәчәк (минем бит әле итек калыбы ясап караганым юк), аннан соң өр-яңадан итек басу, калыпка утырту һәм шуның белән иҗат йортындагы срок тәмамланачак. Амин!

Соңгы вакытта мин в полосе невезения. Казаннан кайту өчен билетны 18енә алганмын һәм шул билет белән 19ында утырып киткәнмен. Мине Канаш станциясендә «заяц» итеп мәсхәрә белән төшереп калдырдылар. Ә бит билетны карагач, татар әдәбиятының иң төгәл, иң акыллы кешесе Рәис Даутов: «Миргазиян дус, синең билетың

кичәге бит», – дип кисәткән иде. Аның сүзен тыңласам, штраф түләмәгән була идем.

Кабат сәлам Сиңа, ә теге Олы Керәшенне минем исемнән кочаклап кыс һәм сакла. Ул да бит мамонт һәм полакантус шикелле дефицит шәхес. Шул искә төшкәндә яшисе килә башлый.

***

*15 май, 2006 ел*
*Мәскәү*

Хөрмәтле Марсель әфәнде!

Тукай бүләге белән соңга калып булса да, котлыйм! Ихлас куануымны белдерәсем килә. «ТЯ»ндә басылган зур, тирән эчтәлекле, җылы язмаңны мин фәкыйрьгә багышлавыңа рәхмәт яусын.

Бакча кооперативындагы күршем Светозар Борщенко «рәхмәтне стаканга агызып булмый» дип шаяртырга яратса да, синең мәкаләңә (реферат күләмендәге) тиң иҗатыма бәя бирү миңа сезнең буын вәкилләреннән күп тәтемәде. Шуңа күрә мин күпмедер дәрәҗәдә сиңа бурычлы булып та калам шикелле.

Мәкаләдән күпкә кыйммәтлерәге – син җибәргән «Рух» китабы. Кайбер бүлекләренә кире кайта-кайта укып чыктым. Беренчедән, Ш.Насыйров халыкара китап ярминкәләрендә мәйдан тотарлык шедевр эшләгән. Китап өстәлемдә ята. Яныннан узган саен кулыма алам да әсәрне язган автор өчен дә, аны китап итеп чыгарган рәссам өчен дә татлы горурлык уянганын тоям. Насыйровны Тукай бүләгенә тәкъдим итү өчен Язучылар берлеге белән Рәссамнар берлеге якалашырга тиешләр дә... Нишлисең, бездәге мокытлык шушы көнгә кадәр Насыйровның шедеврларына күз йомып уздыруны кулай тоя.

Әгәр син бу китаптан да талантлырак әсәр яза алсаң, белмим, татар әдәбиятында синең белән ярышырлык әдип табылырмы икән?

Бер заман татар әдәбиятын эссе басты. Һәр татар язучысы Платон, Мишель Монтень, Честертон белән мәйдан тотты ул вакытта. «Рух», минемчә, җитлеккән эссе, чөнки һәр җөмлә философия белән мул сугарылуга карамастан, метафораларның көчле, телнең шигъри булуы укуны җиңеләйтә генә түгел, ләззәтләндерә дә. Шигырь укыгандай укыла.

«Догалы еллар»ның «КУ»нда басылган варианты белән китаптагы арасында куанычлы аерма-үсеш ята. Камилләштерә алуың мине куандыра. Хәзер инде Гибралтар утрау түгел, һәм гаҗәеп матур, эчтәлекле күзәтүләр өстәлгән. Чокынып укый торгач, бердәнбер төгәлсезлекне таптым: галераны җилкәнле кораблар рәтенә кертеп куйгансың. Хәбибуллинның «Кубрат хан»ында илчеләр Истанбулга елга трамваена утырып баралар. Шуның белән чагыштырганда, аны хатага санамаска да мөмкин. Кайбер галерада җилкән күтәрү өчен алынмалы мачта да булган.

Китапның иң зур кимчелеге менә нәрсәдә: «Рух»ны энциклопедик сүзлек итеп кулланырлык. Вакыйгалар, шәхесләр, зур-зур кисәк тарих калҗалары чорлар, төрле илләр, төрле культуралар, шәһәрләр, диңгезләр, халыклар һ.б. Китапның ахырына аерым шәхесләрнең, тарихи вакыйгаларның аңлатмасын (аннотациясен) урнаштырырга кирәк шикелле. Мин фәкыйрь Мөсәгыйт Хәбибуллин белән Конфуцийның янәшә торганын күреп горурланыр идем. Үзең өчен дә отышлы булыр иде ул исемлекнең китапны яктыртуы.

Китапка рецензия язарга кирәк иде. Ул эшне Миргазиян атлы бомж (инглизчә: tramp; итальянча: vagabondo) башкарырга тиештер бәлки. Син «ТЯ»ндә минем турыда яздың, мин синең турыда язсам – «кукушка хвалит петуха...» килеп чыгар шикелле. Төп сәбәп түгел бу. Соңгы вакытта язуның тәме юклыктан интегәм. Ярый әле Мәскәүдә татар

китаплары сатыла торган зират-кибетләр юк. Казанда бер көнне Бауман урамындагы кибеттә дүрт сәгать утырдым. Шул дүрт сәгать эчендә бер генә татар китабы да сатылмады. Русча китапларны 27 кеше сатып алды, шуларның 18е татарлардан иде. Ел йомгаклары вакытында без нигә шул күзәтүләрне анализламыйбыз? Ел йомгаклары тач Ахунов чорындагыча бара. Язучыларны обоймага тутыралар, бәя юк. Обоймада исә теге кургаш пулялы малокалибрлы винтовка патроны да, «Калашников»ныкы да, хәтта 12,7 мм эре калибрлы пулемётныкы да үзара тигез.

Иң зур үкенеч: инкыйразны җилтерәтеп алып баручы көч – татар әдәбиятында тәнкыйть юклыгы. Бүгенге көн язучысы (306 данә) тәнкыйтьне әсәрнең дошман теленә эләгеп хурлануы дип аңлый. Миңа татар әдәбиятының бер корифее үзен мактаткан, аллилуйя җырлаткан тәнкыйть китабын бүләк итеп бирде. Анда сукыр бер тиенлек анализ юк. Ул бәндәнең иҗаты турында рус та, чуваш та, үзбәк тә язган. Шуларның күбесе авторның әсәрен күрмәгәннәр дә шикелле. «Христа ради» ысулында әмәлләнгән арзанлы реклама.

Алмасы зур, таза булып үссен өчен алмагачка да агу сибәләр, адәм баласының исә гангрена башланса, аяк-кулларын кисеп ташлыйлар. Әдәбиятыбыз чери, инде күптән «...» исен тарата, шуны тәнкыйть ярдәмендә дәваларга куркалар.

Әдәбият – зыялылар дине. Хәзер ул шушы функциясен югалтып бетерде диярлек. Татар халкының 70-80 проценты русча сөйләшеп яши. Тел бит ул коммуникатив вазифа белән генә чикләнми. Аның коммуникатив роле бишенче-җиденче урында. «Язык – вечно самообновляющийся механизм духовности» дигән Мартин Хайдеггер. Без (русча сөйләшеп яшәүчеләр) күптән рус әхлагын үзләштергәнбез, Мәскәүдә яшәүче татарга бу феномен җәйрәп ята. Русча сөйләшеп яшәгән татар үзен психологик яктан рус итеп тоя һәм чын татарга рус булып карый. Димәк, Гаяз Исхакый әйткән инкыйраз безне инде куып җиткән. Ә инде безнең оныклар тулысынча инкыйразда яшәячәкләр.

«КУ»да минем «Ак әбинең кабере янында» исемле рецензия басылды. Аның яртысы «квазибашкорт» аталган өлешен бастырырга Әмирхан ага риза булмады. Автор буларак, минем өчен нәкъ шул өлеше кыйммәтлерәк иде. Анда мин башкортлашуның философиясен бирә алган идем. Черновикларымны яндырдым мин. Шул «квазибашкорт», минемчә, татар язучыларының башкортлыкның койрыгына ябышып күтәрелү процессын шактый аңлаешлы итеп дәлилли алган идем шикелле. Гомумән, Әмирхан ага белән озак аралашып яшәсәк тә, без бер-беребезне аңлый идек дип әйтә алмыйм. Бик сак иде бит мәрхүм. Сак булып, як-ягыңа каранып яшәү белән куркаклыкның чиген кем дөрес аера белә? Бигрәк тә язучыныкын... Ярашуны да ул ялагайланмыйча, искиткеч оста, яшерен итеп эшли ала иде.

Кызганыч ки, татар әдәбиятының көче, аның эстетик һәм әдәби егәре китап чыгаруның санына, күләменә китеп бетә. Куркыныч нәрсә бит бу... Әдәбият төп вазифасын югалта, әдиплек китап язу бизнесына әверелә.

Без тагын бер ялгышлык эшләүне искиткеч куәтле үҗәтлек белән дәвам итәбез: язучылар берлеге аша әдәби процесска бигрәк тә әдәбиятның сыйфатына берничек тә тәэсир итеп булмый. Әдәбиятны, әдәби журнал, андагы шедеврлар, тәнкыйтьнең батырлыгы, сыйфаты, баш редакторның һәр санда дөнья әдәбиятыннан берничә шедевр – эталон бирә алуы хәл итә. Бу мәсьәләгә дә без инде күптән кул селтәгәнбез. «Агыла да халтура агыла гонорар алу ягына...» Талантларны эзләп табу (чиктән тыш катлаулы процесс), аларны тәрбияләп үстерү, татар әдәбиятында, гомумән, көн тәртибеннән төшеп калган.

Сиңа бәлки кызыктыр? Мине җаны-тәне белән Наҗар Нәҗми яратмый иде. Малеевкада ул миннән Татарстанның кайсы районыннан икәнлегемне сорады.

– Баулыдан, – дидем.

– Баулыда минем яраткан кызым яши. Мин аны әле дә үлеп яратам... Кода да җибәреп карадым, үгетләүләрем, ялынуларым бушка китте. Бер калай әтәчкә күзе

төшкән булган. Шуның аркасында миңа чыкмады, – дип, бик каты зарланды. Ә мин идиот:

– Ул калай әтәч мин идем инде, Нажар ага, – дидем.

Ул кыз чыннан да кияүгә чыкмады. Киләчәккә планнар корганда, ул кыз миңа:

– Өйләнешсәк, син обязательно югары белем алырга тиешсең, – дигән иде. Ә мин дурак:

– Сиңа мин кирәкме, әллә югары белемме? – дидем. Шунысы кызык: ул шартны куйганда, минем университетка укырга керергә әзерләнеп йөргән чагым иде.

Шул сөйләшүдән соң Нажар ага мәрхүм мине күргән саен кызара-бүртенә, нәфрәтен яшерә алмыйча, миңа бер ачы сүз әйтмичә калмый иде. Мин аны зиратка күммәгәннәр дип ишеттем. Дөресме икән?

Ярый, Марсель, мин сиңа бер кочак тиле-миле сүзләр яздым. Соңгы вакытта язу эшеннән шактый алҗыдым. Язасы килми. Гомер буе Плюшкин шикелле көне-төне сюжет җыйдым, күзәттем, баш ваттым, җан атып интектем, ә язасы килмәү елдан-ел көчәйде, хәзер инде искиткеч көчле. Артык комсыз булу да зарарлы икән. Язучылар белән аралашып яшәмәү дә бик күп зыян китерә. Ә ялгызым яшәргә көчем җитми башлады.

Тукай бүләге белән кабат котлыйм. Син, дус кеше, беренче буларак, китабыңда Рудольф Нуриевның рәсемен бастырдың. Яз син аның турында. Миңа Шәриф Хөсәенов Рудольф турында язарга материал туплыйм дигән иде. Яза алды микән? Язарга уйласаң, аның материалыннан да баш тартма. Нуриевның «руский танцовщик» булуын дөньяга киң таратып өлгерделәр. Мәсәлән, «Самые знаменитые личности мира» дигән китапта аның татар булуы турында бер кәлимә сүз юк. ЖЗЛ сериясендә бастырыр идең, уйла әле бу турыда. Милләт өчен мөһим нәрсә.

*Яратып, Юныс.*

*Миндә синең адресың юк. Татар язучылары теркәлгән китап та юк. Үпкәләмә, хатны «ТЯ»нә җибәрәм. Атлас дус сиңа тапшырыр.*

**P.S.** Миннән күпләр нигә диңгезчеләрнең униформасын киеп, Казанга кайтмадың, дип сорыйлар. Эшли башлаган елларда кигәләдем мин аны, аннан соң бер бик мөһим, бик рәнҗеткеч дәлил формадан баш тартырга мәҗбүр итте. Кораб рус флагы астында йөзде. Димәк, мин рус диңгезчесе саналам. Татарстанның флоты юк. Кайсы яктан карасаң да, мин «рус диңгезчесе» саналам. Шуны расламас өчен цивильный киемнән йөрергә туры килде. Хәтта Морфлотта эшләгәндә, бер тапкыр коллегия утырышына форма кимичә килгән өчен министр Тимофей Борисович Гуженко утырышта катнаштырмады. Барыбер сүземне сүз иттем, кимәдем.

**P.P.S.** Аяз турында аның миңа язган хатларына таянып, бик кызык нәрсә яза алыр идем. Мәрхүм гел бәргәләнеп яшәде, ашыкты, кабаланды. Тормышны җентекләп күзәтергә вакыты да юк иде.

Син Аяз мәрхүмнең 75 еллык юбилеенда булдыңмы икән? Малайлары судның приговорын укыдылар: «За разглашение гос. тайны». Студент нинди «тайна» белсен? Исемен оныттым, теге керәшен язучысы Аяз турында елый-елый 4 сәгать сөйләде. Сәхнәдән суд приговорын укыгач, мин ышанырга мәҗбүр булдым...

**P.P.P.S.** Вакыт юк. Мин Мөхәммәт турында бик кызык, эчтәлекле, оригиналь истәлек яза алыр идем. Ул чиктән тыш катлаулы һәм каршылыклы шәхес. Таланты зур, шул талантын җитди рәвештә куллануы шактый чамалы.

Туктарга кирәктер. «Рух» бик күп фикерләр уятты. Язасы килә башлады. Тукай бүләгенең калаен тагып йөрүчеләр күп. Сиңа ул җитдирәк язарга, Аллаһы Тәгалә биргән тел байлыгын җитдирәк кулланырга ярдәм итәр дип ышанам.

*Ак, изге теләкләр белән, Әтәмби Закиры малае.*

## Вахит Юныс хатлары

*Мәскәү, Останкино*
*14.12.90*

Марсель туган!

Менә тагын 3 фото салам. Минемчә, Миргазиян белән икәү авылда төшкән фоторәсем бәлки ярар? Үзең кара инде. Башка архивлардан эзләргә вакыт юк иде. Иртәгә таң белән Миргазиян белән загородка китәбез, аннан ике көннән генә кайтабыз. Аннан соң минем бик еракка – Шәм Шәрифкә (Сүриягә) китүем ихтимал (21.12.90 иртән иртүк).

Газетада синең интервью чыккач, миңа җибәрергә тырыш әле, ә? Минем адрес булачак:

*г. Дамаск, Сирия, Торгпредство СССР, г. Ас-Саура, 182012, Юнусову В.З.*

Исән-сау күрешергә насыйп итсен!

*Үзеңне яратып, тирән ихтирам белән, Вахит.*

**P.S.** Кирәк булмаган фотоларны кире йә Мәскәүгә, йә Сүриягә җибәр.

***

*8.04.91*
*г. Ас-Саура*
*Сүрия*

Марсель туган!

Мин менә тагын пәйгамбәрләр яшәгән җирләрдә. Инде 4 ай монда килгәнгә. Гыйрактагы сугыш тавышы ишетелеп торды, моннан бик якын бит.

Эш монда бик күп, вакыт калмый диярлек, тик юлъязмалар, очерклар, күзәтүләр, эссе формасында сызгалыйм.

Менә «Аваз»да басарга тәкъдим итеп, бер кечкенә күзәтү җибәрәм: «Өзелмәгән әфлисуннар». Кызганычка каршы, минем монда машинка юк (инглиз һәм гарәп телендә генә), кулъязмада җибәрәм.

Синең берәр әсәреңне укыйсы килә, җибәрә алмассыңмы? Адрес:

Сирия, Генконсульство СССР в г. Алеппо, г. Ас-Саура, 182012, Юнусову Вахиту Закировичу.

Менә сиңа адресым язылган конверт җибәрәм, шушы элекке маркалар һәм конвертлар белән язышабыз әле һаман да, барысы да килә.

Дөньялар үзгәреп барамы? Мин монда Мәскәүнең Беренче программасын карап барам. Кысмыйлармы, искелеккә кайтмыйлармы татар матбугатында? Кемнәр ничек? Мәһди, Ризван, Гәрәй, Туфан, Аяз?

Минем теге интервью чыга алдымы, юкмы? Яз әле миңа, яме? Казан газеталарында минем әйберләр күренмәдеме?

Әгәр дә вакытлыча «шөрепләрне бик кыссалар» да, кешелек җәмгыяте кануннары үзенекен итәчәк – моңа иманым камил. Куркып-өркеп, дерелдәп, шөлләп яшәмәячәкбез! Вөҗданыбыз кушкан сүзне әйтмичә дерелдәп калмабыз!

Марсель дускай, син миңа бу хатны алу турында кош теле җибәр әле, яме?

*Сиңа дусларча күп сәламнәр озатып, тирән ихтирам белән, яратып, Вахит.*

**P.S.** Сиңа бүләккә бер йөзек алдым.

***

*8.08.91*
*Мөхәррәм аеның 28 кичәсе, 1412 е*
*(«Һиҗрә камәрия»)*

Марсель туган!

Син ничектер югалдың...

Мин сиңа хатлар яздым, җавап булмады.

Исәнме, иминме син, сау-сәламәтме, дөньяга очлы күз белән, сатира-юмор белән каравыңны югалтмадыңмы? Тормышның ифрат нечкә, нәфис якларын сиңа гына хас булган шигъри чагыштырулар аша күрә белүеңне ташламадыңмы?

Минем интервью – чүп нәрсә, аңа игътибар итмә! Аның басылмавының 100 сәбәбе булырга мөмкин; миндә комплекс неполноценности юк, дөньяга мин фәлсәфи күзлектән карыйм. Хәйям язганча:

*«Берәү күкрәк кага-кага: «Бу – мин!» – ди.*
*Берәү байлыкка мактана: «Бу – мин!» – ди.*
*Дәрәҗә, мал вә дан булды дигәндә,*
*Кинәт үлем килеп тота: «Бу – мин!!!» – ди».*

Мин ярты дөньяны гизеп, озак еллар «башка планета»ларда эшләгән һәм чәч агарткан кешегә дан да, дәрәҗә дә кызыктыра торган курчак түгел... Үзең беләсең, татар әдәбиятында әдипләрнең тормышы данда йөзеп түгел, ә хәер сорашып үтә, шуңа күрә мине андый язмыш кызыксындырмый. Бездә генә түгел, хәтта чит илдә дә баеп булмый...

Шулай да, кайда син, ничек син?

Мин сиңа бик кечкенә «Өзелмәгән әфлисуннар» дигән уйлану җибәргән идем, алдыңмы? Әгәр инде «Аваз» өчен ул кирәк түгел икән, «Шәһри Казан» яисә «Татарстан яшьләре» газетасына бир. Бирмәсәң, миңа яз: «Кирәкми аны басарга!» – диген. Мин аңлармын, аңламый торган томана, аңгыра кеше түгел...

Син, егет кеше, яз әле, ә?

Менә сиңа адресымны язган конверт җибәрәм, шуның эченә хат салып җибәрү өчен. Әгәр шуның эченә үзеңнең берәр тозлы-борычлы мәкаләңне дә салып җибәрсәң, мин бик тә мәмнүн һәм шат булырмын.

Әгәр дә инде бу хатка да җавап язмасаң, мин сине дуслар исемлегеннән сызып ташламам, әлбәттә, тик очрашканда, русча гына сөйләшермен: «Драстуй, ты миня ув-в-важ-жаишь?»

*Күп сәламнәр озатып, дусларча ихтирам белән, яратып, Вахит.*

**P.S.** Татар әдәбиятында нинди яңалыклар бар?

*Бу хатны «Шәһри Казан» редакциясенә язам. Бәлки өеңә язганы сиңа барып җитмәгәндер?*

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

*Шамил Усмановның тууына – 125 ел*

# РАДИО ДӘВЕРЕН АЧКАН ӘДИП



Татар халкының легендар улы, хәрби язучы, армия һәм сәясәт эшлеклесе Шамил Усмановның тууына –125 ел. Без – Татарстан радиосында эшләүчеләр һәм күпсанлы тыңлаучыларыбыз өчен ул аеруча якын, кадерле кеше. Чөнки Татарстан радиосының дөньяга яралуы, иң беренче чиратта, аның исеме белән бәйле. Татар сүзен беренче булып эфирда нәкъ менә ул яңгыраткан, шушы яктан гына караганда да, бу исем халкыбыз тарихына җуелмаслык булып язылырга тиештер.

Сез беләсез, нинди дә булса яңалыкны башлап җибәрү өчен мең төрле бюрократик киртәләр үтәргә, кырыкмаса-кырык түрәне күндерергә кирәк бит әле. Радио оештыру өчен җанын бирердәй булып йөргән Шамил Усмановка да әнә шундый каршылыкларны җиңеп чыгарга туры килә. Ул үз тирәсенә тугрылыклы фикердәшләр туплауга ирешә. Һәм биш ел көрәштән соң, 1927 елның ноябрендә, ниһаять, Татарстан радиосы дөньяга аваз сала.

Журнал укучыларга тәкъдим ителә торган язмада композитор Җәүдәт Фәйзинең Татарстан радиосының нәкъ менә беренче адымнары турындагы истәлекләре урын алды. Аларны Илдус Әхмәтҗан укый.

Аннары сез радиобыз фондында үтә кадерләп саклана торган бер уникаль язма тыңларсыз. Бу – Шамил Усмановның кызы Айсылу Сагайдак белән әңгәмә. Ул кызыклы язмыш, 1937 елда Сталин төрмәләрендә харап булган фаҗигале тәкъдир иясе Шамил Усмановның якты образын тулырак күзалларга ярдәм итәр дип уйлыйбыз. 1997 елда тасмага язып алынган әңгәмәне шагыйрь, радиобызда әдәбият-сәнгать тапшырулары редакциясе баш мөхәррире булып эшләгән олпат зат Әхмәт Рәшит алып барган.

Язма Шамил Усмановның 1929 елның 29 гыйнварында «Кызыл Татарстан» газетасында басылган «Йә, кем?» дигән мәкаләсе белән йомгаклана. Аны тыңлар алдыннан шунысын аңлатып китәргә кирәктер, татар халкы 1917 елга кадәр үк инде Россиядә иң укымышлы халыкларның берсе була. Тик менә техник яктан белеме мактанырлык булмый. Шушы нәрсәгә бәйле рәвештә кызыклы, хәтта кайвакыт көлкеле хәлләр дә килеп чыккалый. Ерак авылларда яшәүчеләр радиодан ишетелгән авазларны берәр хәйлә, сихер дип кабул итәләр, тавышның эфир аша килүенә ышанып бетмиләр. Мәкаләдә әнә шундый хәлләрнең берсе чагылыш тапкан.

Менә шул рәвешчә, Шамил Усманов һәм аның максатташлары тырышлыгы белән, ул елларда радио башта бюрократик киртәләрне, аннары хорафатларны җиңә-җиңә, халык күңеленә таба юл яра. Һәм акрынлап, радио тыңлау кешеләрнең көндәлек ихтыяҗына әверелә.

Татарстан радиосында Шамил Усмановның тууына 125 ел тулу уңаеннан тулы бер тапшырулар циклы әзерләнде. Әдипнең юбилее якынлашкан көннәрдә сез эзтабар язучы Рафаэль Мостафинның аңа багышланган язмаларын, әсәрләрендә Шамил Усманов образын тудырган язучылар белән әңгәмәләр ишетерсез. Халкыбыз тарихында якты эз калдырган шушы кадерле затны рәхмәт белән искә алырбыз.

*Марсель Гыймазетдиновның тууына – 80 ел*

# ТУГАН ЯКНЫҢ КИТМӘС КОШЫ



Шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның иҗаты белән танышканда, «Җир» белән «Җыр» сүзләренең ни өчен шулай бер-берсенә үтә дә якын булып рифмалашуы аңлашыла башлый. Чөнки шагыйрьнең бөтен гомере игенчелек хезмәте – Җир һәм якты хисле шигърият – Җыр белән бәйле.

Авылдашлары оештырган «Минем Бәзәкәм» (Менделеев районы) сайтына күз салсак, аның атасы Гыйльфан ага колхоз оештыруда катнашкан, аннары 20 ел дәвамында авыл советы рәисе булып эшләгән. Улы Марсель исә Алабугада пединститут тәмамлап кайтып, Ык Тамагы авылында мәктәп директоры, район үзәгендә интернат директоры, «Батыр кул» колхозы партоешма секретаре булып эшләгәннән соң, әтисе төзегән һәм беренче җитәкчесе булган Тукай исемендәге колхозга рәис итеп сайлана.

Кайчандыр миллионер колхоз булган бу хуҗалык ул елларда бераз какшап китә, дүрт ел эчендә Марсель Гыйльфан улы аны районда беренчеләр рәтенә чыгара. 1990 елдан халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары итеп билгеләнә, ләкин аның хөр күңеле кырларга ашкына һәм ул иң артта сөйрәлүче «Бондюжский» совхозына җитәкче булып китә. Тагын берничә елдан әлеге хуҗалык районның горурлыгына әверелә, аңа «Татарстан» исеме бирелә.

Үзенең кыска гына гомерендә М.Гыймазетдинов «Яшәү мәгънәсе» (1990 ел), «Язлардан алалмыйм күземне» (1992 ел), «Син мине белмисең» (1994 ел) исемле шигъри җыентыклар чыгарып өлгерде. Шигырьләрендә төп тема – туган як табигате, хезмәт кешесенең тормышы.

М.Гыймазетдиновның күп кенә шигырьләрен З.Хәйретдинов, М.Иванов, Ф.Хатыйпов, В.Усманов, И.Закиров кебек композиторлар көйгә салды һәм алар бүгенге көнебездә дә популярлыкларын югалтмадылар. Татарстан радиосы фондында Марсель Гыймазетдинов шигырьләренә иҗат ителгән дистәдән артык җыр саклана. «Кайтчы, иркәм, кайтчы яныма» (Фирзәр Мортазин музыкасы), «Аккош канат кагына» (Сафьян Ибраһимов), «Өйләнеп авылга кайт әле», «Туган якның китмәс кошлары» (Илгиз Закиров) кебек җырлары төрле җырчылар башкаруында концертларда әледән-әле яңгырап тора.

Журнал укучылар игътибарына Марсель Гыймазетдинов шигырьләреннән һәм аларга язылган җырлардан төзелгән әдәби-музыкаль композиция тәкъдим ителә. Шигырьләр 1990 нчы елларда күренекле артистыбыз Ирек Баһманов тарафыннан яздырылган иде. Аның да газиз тавышын ишетерсез.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# 2023 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЛАРЫ**

2023 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

«Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. №5

«Татарстан Республикасының Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында. №12

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ә м и р х а н о в М. Яугирә. *Роман.* №4-5

Б а т у л л а Р. Әҗем хан. Назик үтереш. *Хикәяләр.* №3

Б ә д р е т д и н о в Р. Намазлыксыз намаз. *Хикәя.* №12

В а ф и н Г. Тукай. *Хикәя.* №12

Г а л и у л л и н Т. Төерле пылау. *Хикәя.* №7

Г ы й л ь м а н о в Г. Иблис коткысы. *Кыйсса.* №8-10

Г ы й м а л т д и н о в Ф. Урда ханы Үзбәк. *Роман.* №1-3

Г ы й м а т д и н о в а Н. Ике рәссам. *Повесть.* №6

Җ и һ а н г и р о в а Ш. Мәхәббәт ничәү була? *Хикәя.* №1

З ә й н и е в И. Бәхет. Җәннәткә кадәр ярату. Раннур. *Хикәяләр.* №10

И д и а т у л л и н Ш. Тубагач. *Хикәя. (Л.Әбүдәрова тәрҗемәсе).* №9

И м а м о в В. Теләкәй чишмәсе. *Тарихи роман.* №10

И с м ә г ы й л е в Х. Таш Түккән – сихри божра. *Роман.* №4-5

К ә б и р о в М. Башка авыл кешесе... *Хикәя.* №5

К о р б а н Р. Артык кешеләр. *Роман-эссе.* №7-9

М ө д ә р р и с о в а Х. Калхуз хикәятләре. №4

М ө х ә м м ә д и е в Р. Галимә туташ. *Хикәя.* №3

Н у р и е в В. Нәби Дәүли йөз кызарта. Кара ипи һәм сары май. Исемем Лалә, диде ул. *Хикәяләр.* №8

С а ф и н Р. Язмыш сукмаклары буйлап. *Повесть.* №6

С а ф и н Ф. Күкләр җиргә тоташкан. *Повесть.* №1

Т и м е р г а л и е в З. Мәңгелек хәрәкәт. *Повесть.* №7

Ш ә й д у л л и н а - М у р а т Р. Тау башында бүре бар. *Роман.* №11-12

Ш ә ф и г у л л и н Р. Шәп аттың, Галимулла! *Хикәя.* №2

**ШИГЪРИЯТ**

А й з а т Г. Сынаулар бирә Раббыбыз... *Шигырьләр.* №8

А й м ә т Р. Галиҗәнап шигъри сүзнеке мин. *Шигырьләр.* №2

Ә к б ә р о в З. Көлим дисәң, көл, укучым... *Мәсәлләр.* №11

Ә х м ә т җ а н о в а С. Гел сөенче көтәм... *Шигырьләр.* №4

Б а й т и м е р о в Р. Каен суы. *Шигырьләр.* №4

Б а т т а л Г. Сагындырган икән ап-ак карлар. *Шигырь.* №1

Б а т т а л Г. Мин үзем дә уллар үстерәм. *Шигырьләр.* №2

Б ә ш ә р Р. Көек исе килә кыйтгалардан... *Шигырьләр.* №11

В ә л и е в а Л. Мин инде мин түгел шикелле... *Шигырьләр.* №9

Г а б д е р ә х и м Ф. Кабатлыйсың бабаң хатасын... *Шигырьләр.* №1

Г а р и п о в а - Д е н и з Г. Күкләрне туз дип белдем лә... *Шигырьләр.* №6

Г а р и ф у л л и н а Р. Шул исемне аклап, атлап киләм... *Шигырьләр.* №7

Г а т а у л л и н Р. Июль. *Шигырь.* №7

Г а я з о в Ә. Хат алышу. *Поэма.* №2

Г ы й б а д у л л и н а Л. Татар нефте. *Цикл.* №11

Г ы й з з ә т у л л и н а Ф. Күрше хакы – тәңре хакы. *Шигъри дастан.* №4

Д ә ү л ә т б а е в Ф. Кояшы бар күңел өметле ул... *Шигырьләр.* №6

Д ә ү л ә т о в З. Эретер сыман йөрәгем котыпның карын... *Шигырьләр.* №10

Җ а м а л е т д и н о в а Ф. Килә тын сукмактан үтәсем. *Шигырьләр.* №6

Җиһангирова Ш. Гомер кышы озак тоелса да... *Шигырьләр.* №12

Захарова З. Зәй үзе дә тынлык ярата... *Шигырьләр.* №11

Ибраһим Б. Безнең яз ул – җылы апрель ае... *Шигырь.* №4

Ибраһим Б. Тайгакланган дөнья, юллар тая... *Шигырьләр.* №10

Измайлова Н. Ялгыз яфрак. *Шигырь.* №9

Иксанова И. Көтәм көн туганын... *Шигырьләр.* №10

Лерон Л. Ятим сабый булып, мин ул елыйм... *Шигырьләр.* №9

Мансуров З. Каршылыклы хисләр карулаша... *Шигырьләр.* №7

Миңнуллин Р. Күрдем... *Шигырь.* №8

Мирза М. Адәм баласы. *Бишьюллыклар.* №1

Морат Г. Чыраг тотып якты эзләгәннәр... *Шигырьләр.* №5

Нәгыйм Д. Меңәр җанның өермәсе миндә... *Шигырьләр.* №7

Низамова Ф. Тау юлыннан төшеп киләмен... *Шигырьләр.* №5

Ногман И. Кан хәтере җанны бимазалар... *Шигырьләр.* №10

Рәхим Г. Ядәч. *Шигырь.* №10

Сафина Э. Җыр-биюләр безне көчле итә... *Шигырьләр.* №3

Сафин Ф. Июнь җиле. *Шигырь.* №6

Сәгыйдуллина Л. Алсуланып, янә кояш чыга... *Шигырьләр.* №1

Сәлахиев Р. Башымда хыяллар кәрваны... *Шигырьләр.* №3

Ситдыйкова Ә. Ялгызлык диңгезе упкындай... *Шигырьләр.* №9

Сөләйманов Р. Без – мең үлеп, мең терелгән милләт... *Шигырьләр.* №8

Фатыйхов В. Өметләр чишелми төйнәлә... *Шигырьләр.* №2

Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. №8

Харрасова Ф. Күрелмәгән юлны кичкәндә. *Поэма.* №5

Шаһиев Р. Гамәл дәфтәремне тикшерәмен... *Шигырьләр.* №4

Шәех Л. Ә югыйсә, яшәү бөек иде... *Шигырьләр.* №12

Юныс Р. Җыр җырлыйлар кызлар. *Шигырь.* №3

Янсуар Л. Шәмнәргә ут элəм... *Шигырьләр.* №12

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Әхмәтгалиева А. Күз нурларым. *Драматик хикәя.* №10

Зәйниев И. Чия тавы. *Драма, ике пәрдәдә.* №2

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Әблиева Л. Җиде нота гына җитми икән... *Шигырьләр.* №8

Әхмәтгалиев А. Галәмнәрдән ишетелә аһәң. *Шигырьләр.* №11

Газизова Г. Ә офыкта ак җилкәннәр йөзә... *Шигырьләр.* №12

Исмәгыйлева Р. Сугарасым килә халкымны... *Шигырьләр.* №10

Нуриева Г. Соңарганчы, бер тын алсаң иде... *Шигырьләр.* №6

Рамазанова З. Көн саен дежавю... *Шигырьләр.* №7

Сафиуллина Г. Ике бөртек. *Хикәя.* №9

Фәрхетдинова Д. Язмышның соңгы бүләге. *Хикәя.* №1

Фәхретдинова Г. Аяз иде юкса кичә... *Шигырьләр.* №5

**«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ**

Әхмәтҗанова С. Сабыр сөю сагышы. *Повесть.* №7

Галиева Ә. Сары атым алтын нукталы. *Хикәя.* №12

Җамалетдинова Ф. Кешенекен алу – язык. *Хикәя.* №11

Зәйдулла Р. Кани калды Нишапур. *Хикәя.* №3

Зәйнуллина Ә. Очрашу. *Хикәя.* №8

Кара К. ЧТД. *Хикәя.* №9

Рахман Р. Гади вакланма. *Повесть.* №5

Хафизов С. Басынкы Бастам. *Повесть.* №11

Шакирова Ф. Гөлчәчәкнең яңа тормышы. *Хикәя.* №4

Шәрифуллин Н. «Шагалиев шәүләсе». *Хикәя.* №10

Юнысова А. Сылукай. *Бәян.* №6

**ЕРАКТАГЫ УТЛАР**

Айбулатов Н. Яшем арткан саен уфтанамын... *Шигырьләр.* №10

Х ә к и м җ а н Р. Хәтеремдә – янган учаклар. *Шигырьләр.* №10

Ч а х о р о в с к и й М. Минем гомер – ерак бер ил... *Шигырьләр. (Л. Шәех тәрҗемәләре)*. №3

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ**

А н д р о с о в Г. Кырыымпа моңнарына тоташ күмелүебез... *Шигырьләр. (Р. Мөхәммәтшин тәрҗемәләре).* №4

Г а б и л о г л у М. Әрмән-Армен – Шушаник мәхәббәте. *Хикәя. (Русчадан Ф. Җамалетдинова тәрҗемәсе).* №5

Г а з а е в а Ә. Йөрәгем яктыра күңелле уйлардан. *Шигырьләр. (Балкарчадан Р. Корбан тәрҗемәләре)*. №7

К а һ а р м а н о в а М. Җизнәм. Мандолина. Зәңгәр төймә. *Хикәяләр.* №11

К о л ы н ч а к о в а Б. Үкенеч. *Хикәя. (Ногайчадан Р. Корбан тәрҗемәсе)*. №8

С а г а т а е в А. Минем халкым – калын тайга... *Шигырьләр. (Ф.Гыйләҗев тәрҗемәләре)*. №1

У з д е н о в а И. Мин тау гөле, ташны тишеп чыгам... *Шигырьләр.* (*Р. Корбан тәрҗемәләре).* №2

Х а м д а м У. Бер чынаяк су. *Хикәя. (Үзбәкчәдән Ф. Сафин тәрҗемәсе)*. №6

Ы б ы р а е в М. Бер улыңмын, и кадерле Ватаным! *Шигырьләр. (Казакъ теленнән Р. Корбан тәрҗемәләре).* №10

**ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ**

Е л ь с а е в А. Профессор. *(Чечен теленнән А.Әхмәтгалиева тәрҗемәсе).* №12

З ә й д у л л а Р. Тау гөлләре ташта да үсә. *(Кереш сүз).* №12

Т у г у з о в А. Төш. *Шигырьләр. (Чечен теленнән Р. Мөхәммәтшин тәрҗемәләре)*. №12

У с м а н о в А. Әбүбәкер. *«Гомер дәвамында» романыннан өзек. (Чечен теленнән Р.Җамал тәрҗемәсе).* №12

Ц у р у е в Ш. Бар хыяллар тереләй күмелгән... *Шигырьләр. (Чечен теленнән Р.Зәйдулла, Ф. Гыйләҗев тәрҗемәләре).* №12

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Г а л и м у л л и н Ф. Әдәбият фәне аксакаллары. *(Тәлгат Галиуллинга 85 яшь)*. №7

Г а л и у л л и н Т. Йолдызларга гашыйк шагыйрә. №4

Д ә ү л ә т ш и н а Л. «Шагыйрә күңел тәрәзәсен ача». №9

М а к а р о в а В. Борынгы мифның яңача укылышы. *(Илгиз Зәйниевнең «Мәдинә» әсәренә бәяләмә)*, Илгиз Зәйниевнең «Өйләнәм.Тат» комедиясендә көлке үзенчәлекләре. №6

М а н с у р о в З. Тынычсыз хиссият балкышы. №5

Р а х м а н и Р. Шагыйрь гомере. №8

Х ә б и б у л л и н а А. Ак чәчәкләр кебек... №11

**ФӘН**

Б а р г а н Һ. Яңарыш чоры төрек әдәбиятының 1860–1917 еллар арасында Идел-Урал татар әдәбиятына йогынтысы. *(Төрекчәдән Р. Сәфәров тәрҗемәсе).* №4

Г а ф ф а р о в а Ф. Татар телендә аңлатмалы сүзлекләр. №11

Д е м и р к а я А., З а һ и д у л л и н а Д. Үткән белән бүгенге арасында күпер кормак мәсьәләсе бу... №2

З а һ и д у л л и н а Д. Рәшит Сүнәевнең гыйлем галәме. №3

З а һ и д у л л и н а Д. Азәрбайҗандагы тукайчы-галим. №4

З а һ и д у л л и н а Д. Номгон ташъязмасы: XXI гасырның иң олы ачышы. №5

З а һ и д у л л и н а Д. Татар тамырларыннан үскән җете гөлләр. №7

З а һ и д у л л и н а Д. «Ут бөтерчеге». №8

**ПУБЛИЦИСТИКА**

А х у н җ а н о в а Р. Сөббух Рәфыйков ядкяре. *Документаль бәян.* №7-8

В ә л и е в Р. Нокталы өтер, ягъни милләтне саклау серләре. №6

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

Г а б б а с о в а Р., Г а п т у л л и н Н., И б ә т у л л и н а Г., Н ә б и у л л и н а Р., С а б и р о в а Ф., С а ф и н а А., С о л т а н г у л о в а Г., Т у к м а ч ё в Н., Х ә л и м о в а М. *шигырьләре.* №2

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Б а к и р о в М. Кара таплы бәхет. *Биографиям, тормыш һәм хезмәт юлым турында бәян.* №11, 12

Й о с ы п о в а Н. Шигъри сүз кодрәте *(Мөхәммәт Мирза иҗатына бер караш)*. №1

ӘНГАМ АТНАБАЕВНЫҢ ТУУЫНА – 95 ЕЛ

С ө л ә й м а н о в  Ә. Ничекләр генә сагындыра әле үткәннәр... №2

РҮЗӘЛ ЮСУПОВКА – 85 ЯШЬ

Ш ә р и п о в  Ә. Яшьнәп узган гомер. №9

**ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР**

*(Сәхифәне Нәсим Акмал алып бара)*

КАМИЛ МОТЫЙГЫЙНЫҢ ТУУЫНА – 140 ЕЛ

Ирек хисләре җырчысы. №2

ФӘЙЗИ БИККИНИННЫҢ ТУУЫНА – 125 ЕЛ

Гармуннар падишаһы. №10

ШАМИЛ УСМАНОВНЫҢ ТУУЫНА – 125 ЕЛ

Радио дәверен ачкан әдип. №12

АСИЯ ИЗМАЙЛОВАНЫҢ ТУУЫНА – 120 ЕЛ

Тәүге йолдыз. №8

ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА – 120 ЕЛ

Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем... №11

РИЗА ИШМОРАТНЫҢ ТУУЫНА – 120 ЕЛ

Фидакарь әдип. №11

НИЯЗ ДАУТОВНЫҢ ТУУЫНА – 110 ЕЛ

Ул заманда опералар милли иде. №9

МӘХМҮТ ХӨСӘЕННЕҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Түбәтәйле әдип. №4

РАМАЗАН БАЙТИМЕРОВНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Шигырьләре көйгә ятып тора... №4

МӨХӘММӘТ САДРИНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Бездән соң да яшәп калачак. №5

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВАНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Милләт бакчасы тәрбиячесе. №8

ӘЗҺӘР АБДУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Халык җырларына гомер бирде. №10

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ ТУУЫНА – 95 ЕЛ

Рухына, йәгез, бер дога... №1

ИЛДАР ЮЗЕЕВНЕҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Аның моңы безгә шундый таныш. №1

ЗӘКИ ЗӘЙНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Каләмендә аның – атом көче. №7

ЭМИЛЬ ҖӘЛӘЛЕТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Тормышта да, сәхнәдә дә затлы булды. №7

ӘЗҺӘР МӨХӘММӘДИЕВНЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Акчалардан тарих сөйләтте. №9

АЙДАР ХАФИЗОВНЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Арабызда кебек әле дә. №5

ВЕНЕРА ГӘРӘЕВАНЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

«Татар моңын яшәтерлек яшьләр килә...» №6

МАРСЕЛЬ ГЫЙМАЗЕТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Туган якның китмәс кошы. №12

ШАҺИНУР МОСТАФИННЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Каһарманнарны күтәргән эзтабар. №2

ФӘННҮР САФИННЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Хушлашмый да китеп барды.... №6

**ХӘТЕР**

А р с л а н о в  Г. Дөнья җәүһәрләре Минзәлә театрында. *(Сабир Өметбаевның тууына – 115 ел)*. №10

А х у н җ а н о в а  Р. Легендар Миңлекамал. *(М.Әмирнең «Миңлекамал» пьесасындагы төп герой Миңлекамалның прототибының кызы Гәүһәр ханым белән әңгәмә).* №5

Б а й м ө х ә м м ә т о в  А. «Курай булып кайтырмын...». *(Роберт Миңнуллинның тууына – 75 ел)*. №8

Г а и т о в  М. Җыр шигърияте алиһәсе. №1

З а һ и д у л л и н а  Д. Шамил Усманов: матур тормыш төзүгә багышланган гомер. №12

К о р б а н  Р. Дәвамчысын калдырып китте. №5

С ө л ә й м а н о в  Ә. «Сагышлы моңнар» иясе Рәшит ага, яки ул гаиләдә һәммәсе шагыйрь. *(Журналист, шагыйрь Рәшит Гатауллинның тууына – 85 ел)*. №7

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Ә б ү д ә р о в а  Л. Чытырманлыкта бар да тәртип. *(Марсель Галиевның «Чытырманлыкта» тәрҗемәләр җыентыгына күзәтү).* №10

Г а й н у л л и н а  Г. «Аяз Гыйләҗев» исемле фәнни-популяр җыентыкка бәяләмә. №12

Д ә ү л ә т ш и н а  Л. Татар халкының рухи мирасын барлау. №7

С и б г а т у л л и н а  Ә. Татар мулласы – солтан кунагы. №11

Ш а к и р о в  Ә. Әхсән хатларында моң ята. №3

**ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ**

Г а м з а т о в  Р. Син йолдыз булып балкыйсың, Ватан! *Шигырьләр.* (Р. Корбан тәрҗемәләре). №9

К о р б а н  Р. Шигърият рәсүле. №9

**ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ – 1100 ЕЛ**

Заһидуллин И. Мәхкәмәи шәргыянең XVIII гасыр азагы – XIX йөз уртасында эшчәнлеге. №1; Татар сәүдәгәрләре ислам динен тарату системасында. №3, 5.

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НДА – «АГЫЙДЕЛ»**

Кунафин М. Әдипләр иңендә халык сүзе һәм какшамас намус ята. №3

Абдуллина Л., Аралбай К., Әбүзәр С., Гарифуллина А., Ильясова Й., Искәндәрия Т., Карамышева Т., Кәлимуллина Г., Котыева Г., Назар Х., Сакмар Л., Ситдыйкова Г., Үтәбай Ә., Ханнанова З., Юлдашев Х., Юнысова Г., Якупова Г. шигырьләре. №3

Солтангәрәев Р. Татар белән башкорт. Хикәя. №3

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

Кадыйров М. Кәҗә белән юлбарыс хикәяте. №6

**2023 ЕЛ – ДАСТАННАР ЕЛЫ**

«Гыйсә улы Амәт» дастаны. *(Л.Мөхәммәтҗанованың кереш сүзе белән).* №12

Закирова И. Татарда дастан бармы? №4

«Идегәй» дастанының Александр Ходзько тарафыннан язып алынган варианты. №9

Мөхәммәтҗанова Л. Дастаннар – үткәннәрнең сабыр сурәте. №3

Мөхәммәтҗанова Л. Түләк китабы. №6

Мөхәммәтҗанова Л. Янә дә «Идегәй» хакында. №9

**МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ**

Заһидуллина Д. Татарстаннан читтә – татар галимнәре династияләре. №1

**ЗАМАНДАШЫБЫЗ**

Нәсыйхова Л. Җиләкле гомер. №4

**ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП**

Аяз Гыйләҗев хатлары. №9-10

Галиев М. Күңел кушуы. №8

Кояш Тимбикова хаты. №8

Миргазиян һәм Вахит Юныс хатлары. №11-12

Мостай Кәрим хаты. №8

Наҗар Нәҗми хаты. №8
*Сәхифәне М.Галиев алып бара.*

**УКУЧЫ СҮЗЕ**

Исмәгыйлева Г. Кайтаваз. №12

Минһаҗева Л. Хәтерләр ачылырмы?.. №12

Хөснетдинова Л. Гади бер фикер. №12

Шәмси С. Яңача язылган романнар. №12

**2023 ЕЛ – РОССИЯДӘ УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ**

Шәмсетдинов А.: «Телләр белү – кешенең иң яхшы сыйфатларыннан». *Әңгәмәдәш – Хәбибуллина А.* №11

Яруллина Л. «Туган тел дип яшәдем». №10

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Мәңге яшь «Чаян»га – 100 яшь! *Сәхифәне А.Хәмзин әзерләде.* №1

**ФОТОАРХИВ**

Ибраһим Нуруллинның тууына – 100 ел. *Сәхифәне А. Шәйхин әзерләде.* №4

Каһарман-шагыйрь Абдулла Алишның тууына – 115 ел. *Сәхифәне Р.Арсланова әзерләде.* №10

Ләбибә Ихсанованың тууына – 100 ел. Венера Ихсанованың тууына – 90 ел. *Фотолар «Казан утлары», «Сөембикә» журналлары архивыннан алынды.* №9

Марс Шабаевның тууына – 90 ел. №7

Равил Фәйзуллинга – 80 яшь. *Фотолар Р. Фәйзуллинның шәхси архивыннан.* №8

Флүс Латыйфиның тууына – 80 ел. №6

Ринат Мөхәммәдиевка – 75 яшь. №12

«Казан утлары» архивыннан. №1, 2, 3, 7, 11

2023 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. №1

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №1-12. *Сәхифәне В.Нуриев алып бара.*

Яңа китаплар. №1, 2, 3, 10

Хушлашу сүзе. Разил Вәлиев. №11

**ТУГАН ТЕЛ ФОРУМЫ**

Казанда Бөтенроссия «Туган тел» форумы булып узды. Аның эшендә Россиянең 28 төбәгеннән, шулай ук Татарстаннан 800 гә якын делегат – татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм мөселман дини укыту оешмалары мөгаллимнәре катнашты. Форумның «Тәрбия. Белем. Тел» дигән темага багышланган пленар утырышы «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә узды. Аны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев ачып җибәрде һәм алып барды. Форумда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады.

**СӘФӘРЛӘР**

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин Төньяк Кипр Төрек Республикасында узган Халыкара әдәбият фестивалендә катнаштылар.

* * *

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин Халыкара әдәбият форумы кысаларында Үзбәкстанның «Шәрык йолдызы» журналы баш мөхәррире Сиражетдин Рәүф белән очрашып, татар шагыйрьләре антологиясен – үзбәк, үзбәк шагыйрьләре антологиясен татар телендә бастырып чыгару турында килештеләр. Ике республиканың әдәби журналларының алмаш саннарын әзерләү турында да сөйләштеләр.

* * *

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Анкарада үткән төрки дөнья язучыларының V корылтаенда катнашты һәм чыгыш ясады. Ул әдәби әсәрләрне дөньяга чыгаруда тәрҗемә эшенең әһәмиятен ассызыклады, төрки язучылар өчен Нобель премиясенә тиң бүләк булдыру зарурлыгын искәртте.

**ЯКУТСКИДА ТАНТАНА**

Саха (Якутия) Республикасының Якутск шәһәрендә «Казан» скверын һәм каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә бюст ачу тантанасы булып узды. Анда ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев катнашты.

**ИСКӘ АЛУ**

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында Татарстанның халык шагыйре, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, җәмәгать эшлеклесе Роберт Миңнуллинның тууына 75 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе (сценарий авторы Альберт Шакиров, режиссёры Марсель Мәхмүтов) булды. Анда язучылар, галимнәр, киң җәмәгатьчелек вәкилләре, шагыйрь иҗатын яратучылар, әдипнең хатыны Клара ханым, балалары, туганнары катнашты. Кичәдә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады. ТР Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан оештырылган Роберт Миңнуллин исемендәге әдәби конкурста җиңүчеләргә премияләр тапшырылды. Бүләкләрне ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин тапшырды. Кичәдә Роберт Миңнуллинның шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Аларны Татарстан Республикасы театр һәм җыр сәнгате осталары ирештерде. Филармония фойесында Р.Миңнуллинның гомер юлы, иҗади мирасы турында күргәзмә тәкъдим ителде.

* * *

Г.Тукай әдәби музеенда Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттахның тууына 95 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Чарада язучылар Рабит Батулла, Газинур Морат, Вахит Имамов, Зиннур Хөснияр, Рүзәл Мөхәммәтшин, Нәҗибә Сафина, Фәнил Гыйләҗев, Г.Камал театры артисты Равил Шәрәфиев, музей директоры Гүзәл Төхбәтова һ.б. чыгыш ясады.

**ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ**

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, академик, ТРның атказанган фән эшлеклесе Тәлгат Галиуллинга 85 яшь тулуга багышланган «Гомер тәлгәшләре» дип аталган кичә (сценарий авторы Фәүзия Солтан, режиссёры Зөфәр Харисов) булды. Бәйрәмдарны

ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов котлады. Аңа ФАнең «Фәндәге казанышлары өчен» алтын медален тапшырды. Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановның Тәлгат Галиуллинга «Татарстанның халык язучысы» исемен бирү турында Указын ирештерде. Галим һәм язучыны шулай ук КФУның филология һәм милләтара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, Г.Тукай исемендәге милли мәгариф һәм мәдәниятнең югары мәктәбе деканы Рамил Мирзаһитов, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Олег Хисамов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Алабуга, Чаллы педагогика университетлары галимнәре Гомәр Даутов, Радик Галиуллин, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ирек Шәрипов, Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире Ленар Шәех, Р.Ваһапов фонды директоры, продюсер Рифат Фәттахов, Норлат, Балык Бистәсе районнарыннан килгән делегацияләр вәкилләре һ.б. котлады. Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, галимә Дания Заһидуллина, галим, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев видеокотлаулар җибәрделәр. Чарада Г.Камал театры артисты Илдус Әхмәтҗанов, җырчылар Мирсәет Сөнгатуллин, Резеда Шәрәфиева, Азат Тимершәех, Индира Илалова, «Сәйдәш» бию ансамбле чыгыш ясады. Кичәне Артём Пискунов белән Резеда Сәлахова алып бардылар.

* * *

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, прозаик, драматург, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты Халисә Мөдәррисовага 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды. Юбилярны ТР мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, иҗатташ дуслары Рәдиф Гаташ, Илсөяр Иксанова, Рифә Рахман, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, Башкортстаннан килгән кунаклар – әдибә Диләрә Булгакова, М.Гафури исемендәге академия театры директоры Ришат Фәйзуллин, Башкортстанның халык артисты Илсөяр Газетдинова һ.б. котлады. Татар эстрадасы җырчылары Зөһрә Сәхәбиева, Айгөл Бариева, «Фәридә-Алсу» дуэты, Мөдәррис Газетдинов, М.Гафури театры артисткасы Светлана Хәкимова шагыйрә сүзләренә язылган җырларны җырладылар. Бәйрәмне Илдар Кыямов белән Резеда Сәлахова алып барды.

* * *

Актаныш һәм Актаныш районының Киров бистәсе мәдәният йортларында драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Данил Салиховның 65 яшьлегенә багышланган әдәби-музыкаль чаралар, шуның кысасында Г.Афзал исемендәге әдәби премияне тапшыру тантанасы булды. Премия шагыйрь Фәнис Дәүләтбаевка бирелде. Чараларда Казаннан Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат һәм шагыйрь Фәнил Гыйләҗев катнашты.

**ТАРИХТА ЭЗЛЕ ИНСАН**

Түбән Камадагы Г.Тукай исемендәге Үзәк китапханәдә язучы, дин галиме, мәгърифәтче, халык табибы Таҗетдин Ялчыголның тууына 260 ел тулуга багышланган «Тарихта эзле инсан» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция булды. Анда Түбән Кама, Зәй, Мамадыш (Ялчыгол бу районнарда яшәгән) тарихчылары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр катнашты.

**ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА – 120 ЕЛ**

Фронтовик-шагыйрь, драматург Гадел Кутуйның тууына 120 ел тулу уңаеннан Пенза өлкәсенең Татар Кынадысы авылында төбәкара конференция һәм мәдәни чаралар булып узды. Бирегә Пенза, Самара, Саратов өлкәләреннән галимнәр, язучылар, укытучылар, мәктәп укучылары җыелды. Чараларда Казаннан язучы-журналист Рахман Шәфигуллин, галим, «Татар төбәкчеләре» җәмгыяте рәисе Альберт Борһанов катнашты.

* * *

Казанда Гадел Кутуй яшәгән йорт (Мөштәри урамы, 33) диварында яңартылган истәлек тактасы ачылды.

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

ТР Рәисе Указы белән Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Чаян» журналы мөхәррире, юмор остасы, автор-башкаручы **Алмаз Хәмзин** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

2023 елның 5 ноябрендә 75 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, язучы-сатирик, күпсанлы җырлар авторы, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Дамир Гыйсметдин (Дамир Минсәгыйр улы Гыйсметдинов)** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы Самосырово мөселман зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ «На вершине горы обитает волк», рассказ Р.БАДРУТДИНОВА «Намаз без молитвенного коврика», рассказ Г.ВАФИНА «Тукай»; стихи Л.ЯНСУАР, Ш.ЗИГАНГИРОВОЙ, Л.ШАЕХ.*
*«Новые имена»: стихи Г.ГАЗИЗОВОЙ.*
*«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»: рассказ А.ГАЛИЕВОЙ «Опоздавшие слова любви».*
*«Дружба между литературами – дружба народов»: статья Р.ЗАЙДУЛЛЫ, стихи А.ТУГУЗОВА в переводе Р.Мухаметшина, стихи Ш. ЦУРУЕВА в переводе Р.Зайдуллы, Ф.Гилязова, рассказ А.ЕЛЬСАЕВА «Профессор» в переводе А.Ахметгалиевой, отрывок из романа А.УСМАНОВА «Длиною в жизнь» в переводе Р.Джамала.*
*«Юбилеи»: автобиографическая повесть М.БАКИРОВА «Счастье с оттенком грусти».*
*«Память»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ, посвящённая 125-летию со дня рождения Ш.Усманова.*
*«2023 год – год Дастанов»: дастан «Амат, сын Айсы» с предисловием Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ.*
*«Обзор книги»: статья Г.ГАЙНУЛЛИНОЙ.*
*Фотоархив, посвящённый 75-летию Р.Мухамадиева.*
*Отзывы Г.ИСМАГИЛОВОЙ, С.ШАМСИ, Л.МИНГАЗОВОЙ, Л.ХУСНУТДИНОВОЙ.*
*«Памятные письма»: письма М.Юнуса и В.Юнуса М.Галееву.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 125-летию Ш.Усманова и 80-летию М.Гимазетдинова. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Библиографический список произведений, опубликованных в 2023 году.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Парк Чёрное озеро (г. Казань). Фото И.АБРАМОВОЙ; литературовед Гульфия ГАЙНУЛЛИНА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by R.SHAIDULLINA-MURAT «A Wolf Lives on the Top of the Mountain», story by R.BADRUTDINOV «Namaz without a namazlik», story by G.VAFIN «Tukay»; poems by L.YANSUAR, S.ZIGANGIROVA, L.SHAEKH.*
*«New names»: poems by G.GAZIZOVA.*
*«Literary contest «Teacher is a wonderful person on Earth!»: story by A.GALIEVA «Late love words.»*
*«Friendship between literatures is peoples' friendship»: article by R.ZAYDULLA, poems by A.TUGUZOV translated by R.Mukhametshin, poems by SH.TSURUEV translated by R.Zaidulla, F.Gilyazov, story by A.ELSAEV «Professor» translated by A.Akhmetgalieva, excerpt from the novel «Abubakir» by A. USMANOV «Lifelong» "translated by R.Jamal.*
*«Anniversaries»: autobiographical story by M.BAKIROV «Happiness with a touch of sadness.»*
*«Memory»: article by D.ZAGIDULLINA, dedicated to the 125th anniversary of Sh.Usmanov.*
*«2023 is the year of Dastans»: dastan «Amat, son of Aisa» with a foreword by L.MUKHAMETZYANOVA.*
*«Book review»: article by G.GAYNULLINA.*
*Photo archive dedicated to the 75th anniversary of R.Mukhamadiev.*
*Reviews by G.ISMAGILOVA, S.SHAMSI, L.MINGAZOVA, L.KHUSNUTDINOVA.*
*«Memorable Letters»: letters from M.Yunus and V.Yunus to M.Galeev.*
*«Priceless Voices»: articles for the 125th anniversary of Sh.Usmanov and the 80th anniversary of M.Gimazetdinov.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*Bibliographic list of works published in 2023.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Black Lake Park (Kazan). Photo by I.ABRAMOVA; literary critic Gulfiya GAINULLINA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Черек Күл паркында. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* әдәбият галиме Гөлфия Гайнуллина.